ИКЪТИСАД ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ

2 нче китап

ИКЪТИСАД

ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ

Профильле белем бирү

10-11

ИКЪТИСАД
ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10—11 нче сыйныфлары өчен дәреслек

Профильле белем бирү

Ике китапта

2 нче китап

Икътисад фәннәре докторы, профессор С. И. Иванов редакциясендә

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2006

УДК 373.167.1:330*10/11
ББК 65.01 я721.6
И40

Основы экономической теории : Учебник для 10—11 кл. общеобразоват. учрежд. Профильный уровень образования : В 2-х кн. Кн. 2 / Под ред. С. И. Иванова.— 9-е изд., с изм.— М. : Вита-Пресс, 2006.

Дәреслек А. И. Герцен исемендәге Россия дәүләт педагогика университеты укытучылары тарафыннан әзерләнгән:
икътисад фәннәре докторы, проф. *С. И. Иванов* — 1—2 нче бүлекләр (*В. В. Шереметова* белән берлектә),
9, 11—12, 13 нче бүлекләр (*В. В. Шереметова* белән берлектә), 14—16 нчы бүлекләр, глоссарий;
икътисад фәннәре докторы, проф. *М. А. Скляр* — 5 нче бүлек, 6 нчы бүлек (*Б. И. Табачникас* белән берлектә), 7—8 нче бүлекләр, статистик кушымта;
икътисад фәннәре канд., проф. *А. Я. Линьков* — 17—19 нчы бүлекләр;
икътисад фәннәре докторы, проф. *Б. И. Табачникас* — 10 нчы бүлек;
икътисад фәннәре канд., доц. *В. В. Шереметова* — 3—4 нче бүлекләр.

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Икътисад теориясе нигезләре : Татар урта гомуми белем бирү
И40 мәкт. 10—11 нче с-флары өчен д-лек. Профильле белем бирү : Ике китапта. 2 нче китап / С. И. Иванов ред.; Русча үзгәрт. 9 нчы басмадан Л. Х. Мөхәммәтжанова, Я. М. Абдулкадыйрова тәрж.— Казан : Мәгариф, 2006.— 351 б. : рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1162-5

Дәреслек югары сыйныф укучыларын базар икътисады нигезләре белән таныштыра. Икътисадны бу дәреслектән өйрәнү укучыларда кеше, предприятие (фирма) һәм дәүләтнең икътисади эшчәнлеге турында белемнәр системасы, икътисади фикерләү культурасы, шулай ук үзлегеннән укып белем алу һәм дөньяны танып белү сәләте формалашуын тәэмин итә. Алынган белем укучыларга икътисади күренешләрнең һәм алар арасындагы бәйләнешнең асылы турында тулы күзаллау төзергә мөмкинлек бирә.

Дәреслек, икътисад буенча белем бирүнең яна стандартын исәпкә алып, өстәмәләр белән эшләнде.

ISBN 5-7755-0969-2 (кн. 2)
ISBN 5-7755-0970-6

© ООО Издательство «Вита-Пресс», изменения и дополнения, 2000, 2002, 2003, 2004, 2005, 2006
© Художественное оформление. ООО Издательство «Вита-Пресс», 1999
Все права защищены

ISBN 5-7761-1162-5

© Татарчага тәрҗемә, «Мәгариф» нәшрияты, 2006

11 нче бүлек

ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ ҺӘМ МИЛЛИ КЕРЕМ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җавап табарсыз:

- ни өчен теге яки бу илдә һәр елда барлыгы күпме товар һәм хезмәт күрсәтү җитештерелүен белү кирәк;
- тулай милли продукт һәм тулай эчке продукт нәрсәдән гыйбарәт;
- тулай милли продукт һәм тулай эчке продуктның зурлыгы нинди методлар белән исәпләнә;
- илнең милли кереме нәрсә ул, һәм ул ничек бүленә;
- халыкның кулга кергән шәхси кереме ничек формалаша;
- тулай милли продукт, тулай эчке продукт һәм милли керемнең номиналь һәм реаль күрсәткечләре нәрсәдән гыйбарәт.

Әлегә кадәр без икътисадның аерым товарлар базары, аерым фирмаларның яки кулланучыларның үзләрен ничек тотулары, аерым товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр ничек куелуына бәйле сорауларны тикшердек. Хәзер безгә икътисадны бербөтен итеп карарга кирәк булачак. Биредә сүз аерым фирма җитештергән товар һәм хезмәт күрсәтүләр турында түгел, ә билгеле бер илнең барлык тармаклары һәм предприятиеләре җитештергән товар һәм хезмәт күрсәтүләре турында, аерым кешеләрнең яки йорт хуҗалыкларының керемнәре һәм чыгымнары турында түгел, ә бөтен икътисадта табылган керемнәр һәм җитештерелгән чыгымнар турында барачак. Без ясарга тиешле анализ объекты булып тулай эчке продукт, милли керем һ. б. кебек берләштерелгән яки гомумиләштерелгән (агрегирланган) күрсәткечләр тора.

Нинди дә булса илнең икътисады, ягъни милли икътисад хосусый фирмалар һәм йорт хуҗалыкларының ниндидер механик суммасыннан тора дип уйлау бик зур ялгышлык булыр иде. Гәрчә милли икътисадның үзен тотышы күбрәк аерым кешеләрнең яки фирмаларның үзләрен ничек тотуга бәйле булса да, ул аларга тәңгәл түгел. Теге яки бу ситуациядә индивидуум үзен ничек тотудан аермалы буларак, бербөтен булып икътисадның үзен тотышында үз законнары бар.

Бу бүлектә шулай ук милли икътисад эшчәнлегенең нәтиҗәләрен исәпләүгә бәйле сораулар да өйрәнеләчәк.

11.1. НИ ӨЧЕН МИЛЛИ ПРОДУКТНЫҢ КҮЛӘМЕН БЕЛЕРГӘ КИРӘК

5 нче бүлектә һәр гаиләнең билгеле бер керем алуы ачыкланган иде, һәм кулланучы буларак, аның үзен тотышы шактый дәрәҗәдә ул нинди керем алуга бәйле. Теге яки бу керемне алу өчен, кеше аны эшләп табарга тиеш. Ләкин теләсә кайсы кешенең, теләсә кайсы гаиләнең мул тормышта яшәве аларның шәхси кеременә генә түгел, ә бирелгән илнең тулай кеременә дә бәйле. Американы яки япон кешесенең уртача хезмәт хакы россиялененң уртача хезмәт хакыннан берничә тапкырга артыграк. Мәсәлән, 2001 елда американың уртача кереме елына 26,6 мең доллар булган, бу якынча 72,2 млн сум тәшкил иткән. Әгәр россиялеләрнең уртача кереме шундый ук булса, алар кеременең гомуми суммасы Россия икътисадында җитештерелгән продукция бәясеннән 14 тапкырга артыграк булыр иде. Икенче сүз белән әйткәндә, россиялеләрнең керемнәре американыларның керемнәреннән якынча 14 тапкырга кимрәк, чөнки американылар арасында бүленә торган «җәмәгать бәлеше» россиялеләр арасында бүленә торган «бәлештән» шактыйга зуррак. Бу үзе генә дә бирелгән илдә җитештерелгән милли продуктның, аның «җәмәгать бәлешенең» күпме булуын белүнең нинди әһәмияткә ия булуын әйтә.

Бирелгән ил халкының гомуми тормыш дәрәҗәсе үсәме әллә кимиме дигән сорауга җавап шулай ук зур әһәмияткә ия. Моның өчен кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә билгеләнгән илдә җитештерелгән товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми дәрәҗәсе үсәме әллә кимиме икәнен ачыкларга кирәк. Эшчеләр һәм эшмәкәрләр, пенсионерлар һәм

дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәрен арттыру өчен тырышалар. Әгәр хезмәт хакы, табыш һәм пенсия 10% ка артса, ә базарга килгән товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми микъдары элеккечә калса, алар барысы да теләгән нәтиҗәгә ирешә алырлармы? Акча шуның белән яхшы: аңа теләсә нинди әйберне сатып алырга яки аны теләсә нинди хезмәт күрсәтү өчен түләргә була. Күбрәк акча алып та, гаиләләр аларга күбрәк товар ала алмасалар, кешеләрнең күз алдында акчаның кадере бетәчәк һәм акча кыйммәтсезләнә башлаячак. Илдә товар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү кимесә, халыкның акча кереме күпме генә үссә дә, аның матди хәле начараячак.

Шулай итеп, теләсә нинди ил халкының уртача тормыш дәрәҗәсе аның милли икътисады торышына бәйле. Ләкин бер генә, хәтта иң югары квалификацияле икътисадчы да, йөзәрләгән мең зур һәм кече предприятиеләрнең һәм аларда хезмәт иткән миллионлаган кешеләр эшчәнлегенең гомуми нәтиҗәсен белмәсә, ил икътисадында эшләр ничек бара, узган ел белән чагыштырганда аның хәле ничек үзгәргән һәм киләчәктә нәрсә көтәргә була дигән сорауларга җавап бирә алмас иде.

Дәүләт Думасы депутатларының һәм сенаторларның кул астында милли производство дәрәҗәсе үскәнме әллә кимегәнме һәм ул нинди дәрәҗәдә икәнлеге турында мәгълүматлар булмаса, алар президентның һәм хөкүмәтнең икътисади сәясәтенең нәтиҗәләрен объектив бәяли алу мөмкинлегеннән мәхрүм булачак.

Барлык кешеләрнең, күп төрле халык катлавы вәкилләренең мәнфәгатьләре илдә күпме микъдарда матди һәм рухи байлыклар җитештерелүгә, илнең милли продукциясе күпме булуга бәйле. Милли продукциянең динамикасы нинди булуын, үткән елларда аның күпме җитештерелүен, милли производство үсәме яки кимиме һәм киләчәктә аның үсүенә өмет бармы икәнлеген белү шулай ук зур әһәмияткә ия.

Хәзерге вакытта милли продукцияне исәпләүнең әһәмияте зур икәнлеге бөтен дөньяда мәгълүм. Милли производство нәтиҗәләре турында мәгълүматлар барлык илләрдә дә диярлек басылып тора. Берләшкән Милләтләр Оешмасы бу мәгълүматларны гомумиләштереп нәтиҗә чыгара. Болар барысы да дөньяда, аерым континентларда һәм регионнарда икътисади хәлнең гомуми картинасын ачыкларга, дөньядагы барлык илләрнең икътисади үсеш дәрәҗәсен чагыштырырга мөмкинлек бирә.

11.2. ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ НӘРСӘ УЛ

Төрле фабрикалар җитештергән продукцияне ничек исәпләргә

Аерым предприятие яки тармак җитештергән продукция күләмен билгеләү чагыштырмача авыр түгел. Мәсәлән, нефть промышленносте яки кара металлургия эшләп чыгарган продукцияне —табылган нефть яки эретеп коелган металлны тонналар белән, электроэнергетика эшләп чыгарган электроэнергияне киловатт-сәгатьләр белән һ. б. белдерергә була. Тегү промышленносте кебек тармак продукциясенең күләмен исәпләү берникадәр катлаулырак. Тегү фабрикасы эшләп чыгарган продукцияне данәләрдә исәпләп булмый, чөнки мамык-җеп күлмәкләр һәм йон костюмнар якынча да бер түгел, 10 мең костюм теккән фабрика, 10 мең ирләр күлмәге теккән фабрикага караганда, шактый күбрәк продукт җитештергән.

Әлеге ике фабрика продукциясе күләмен ничек чагыштырып була соң? Бу мәсьәләне чишәргә базар ярдәм итә. Базарда төрле товар һәм хезмәт күрсәтүнең файдалылыгын базар бәяләре ярдәмендә чагыштырылуын без күргән идек инде. Димәк, бер күлмәкнең бәясе 1 мең сум, ә костюмның бәясе 10 мең сум булса, беренче фабрика продукциясен 10 мең күлмәк × 1 мең сум = 10 млн сум, ә икенче фабрика продукциясен 10 мең костюм × 10 мең сум = 100 млн сум буларак күзалларга була. Бу катлаулы булмаган исәп-хисап 11-1 рәсемендә күрсәтелгән; ул ике фабриканың продукциясе 110 млн сум (10 млн сум + 100 млн сум = 110 млн сум) тәшкил итүен күрсәтә.

Костюмнар 10 мең данә		Күлмәкләр 10 мең данә		
Базар бәясе 10 мең сум		Базар бәясе 1 мең сум		
Продукция базар бәяләрендә 10 мең данә × × 10 мең сум = = 100 млн сум	+	Продукция базар бәяләрендә 10 мең данә × × 1 мең сум = = 10 млн сум	=	Ике фабрика продукциясе базар бәяләрендә костюмнар... 100 млн сум күлмәкләр... + 10 млн сум костюмнар һәм күлмәкләр... 110 млн сум

11-1 нче рәсем. △
Ике фабрика эшләнмәләрен базар бәяләре белән белдереп, без алар эшләп чыгарган продукциянең күләмнәрен куша алдык.

ИПИ
1 млн т x 1 мең сум = 1 млрд сум
ИТ
100 мең т x 6 мең сум = 600 млн сум
СУЫТКЫЧЛАР
25 мең данә x 10 мең сум = 250 млн сум
ҖИҢЕЛ МАШИНАЛАР
3 мең данә x 150 мең сум = 450 млн сум
ПАРИКМАХЕРЛАР ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЕ
50 млн сум
КОМПЬЮТЕРЛАР
10 мең данә x 15 мең сум = 150 млн сум
МЕТАЛЛ КИСҮЧЕ СТАНОКЛАР
1 мең данә x 600 мең сум = 600 млн сум
ТУРБИНАЛАР
100 данә x 3 млн сум = 300 млн сум

МИЛЛИ ИКЪТИСАДНЫҢ БАРЛЫК ПРОДУКЦИЯСЕ

3,4 МИЛЛИАРД СУМ

11-2 нче рәсем. △
Әгәр барлык тармакларның продукциясен базар бәяләре белән белдерсәк һәм аны кушсак, табылган сумма барлык икътисад продуктыннан, аның милли продуктыннан гыйбарәт була.

Ике фабрика җитештергән продукцияне чагыштырырга ярдәм иткән бу алым, ике фабриканың продукциясе суммасын табарга мөмкинлек бирә. Әлеге алымнан тегү промышленносте җитештергән продукциянең генә түгел, ә азык-төлек, машина төзү, авыл хуҗалыгы һ. б. ның суммасын тапканда да файдаланырга була. Ит, ашлык, нефть, машиналарны, парикмахерларның хезмәт күрсәтүләрен һәм бик күп башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне базар бәяләре белән белдереп, без теләсә нинди илнең барлык тармаклары җитештергән продукция күләмен таба алабыз. Бу алымны 11-2 рәсеме аңлатып бирә (бу ике мисалдагы барлык бәяләр дә шартлыча алынган).

Ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр

Хәзер бер мөһим нәрсәне игътибарга алырга кирәк. Эш менә нәрсәдә: барлык икътисад масштабында товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүнең соңгы нәтиҗәсе булып *барлык* җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр дә *тормый.*

Барлык милли икътисад эшчәнлегенең соңгы нәтиҗәсе *ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең* генә бәяләр суммасы рәвешендә күрсәтелергә тиеш.

Ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр дигәннән нәрсәне аңларга кирәклеген ачыклау өчен, күлмәкләр һәм костюмнар мисалына кире әйләнеп кайтыйк.

Безнең һәрберебез, күлмәк яки костюм тегү өчен, эрләгән җептән эшләнгән тукыма кирәк икәнлеген бик яхшы белә. Үз чиратында крестьяннар җеп эрләү фабрикаларын авыл хуҗалыгы чималы белән тәэмин итү өчен, мамык һәм житен үстереп җыярга, сарык йоны алырга тиеш. Шул ук вакытта тегү фабрикалары үз продукцияләрен сәүдә фирмаларына тапшыралар, ә алар бу киемне сатып алучыларга саталар. Барлык кешеләр өчен дә икътисад эшләвенең турыдан-туры практик нәтиҗәсе булып, алар үзләренең керемнәренә кибетләрдән *нәрсә* сатып ала алулары тора.

Шулай итеп, кешеләр сатып алган кием-салым ахыргы товар булып тора.

Арадаш продукт

Ахыргы товар — икътисадның күп тармаклары эшчәнлегенең нәтиҗәсе ул. Авыл хуҗалыгы чималы, эрләгән җеп һәм тукымага килсәк, бу товарлар *арадаш продукт* ролен уйныйлар. Алар барысы да бирелгән елда житештерелгән һәм шул ук елда эшкәртелгән, өстәвенә бер-бер артлы берничә эшкәртү стадиясе үткән.

Хезмәт күрсәтүләр дә шулай ук арадаш продукт була ала. Мәсәлән, күпләп сату сәүдәсе белән шөгыльләнгән фирмалар промышленность предприятиесе белән кибет арасында арадашчылык хезмәт күрсәтүен башкаралар. Күпләп сату сәүдәсе хезмәт күрсәтүен арадаш продуктка кертергә кирәк, чөнки алар кулланучы ихтыяҗын канәгатьләндерүгә юнәлдерелмәгән, ә милли продукт хәрәкәтендә аерым бер стадия булып тора. Теге яки бу товарны һәм хезмәт күрсәтүләрне арадаш продуктка кертүнең төп критерие булып алардан ничек файдалану характеры тора. Әгәр сатып алынган товарлар чимал яки ярымфабрикат буларак тагын да эшкәртелүгә китсә, алар арадаш продукт булалар. Әгәр хезмәт күрсәтүләр товарларны алып сатуга, ташуга бәйле булса, алар да нәкъ шулай ук арадаш продуктка керә.

Сатып алучының ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, сатып алынган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр *ахыргы продукт* булып исәпләнә. Азык-төлек товарларын, кием-салым, йорт кирәк-яраклары һәм күп кенә башка әйберләрне кешеләр үзләренең шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен сатып алалар. Алар шулай ук түләүле дәресләр алып баручы укытучылар хезмәте өчен, тамаша чаралары, адвокат консультацияләре һ. б. хезмәт күрсәтүләр өчен түлиләр. Барлык бу хезмәт күрсәтүләр кешеләрнең шәхси ихтыяҗларын тәэмин итүгә юнәлгән, шулай булгач, алар ахыргы продуктка керә. Икътисадка үз өлешен ваклап сату сәүдәсе дә кертә: ул фабрика, завод, авыл хуҗалыгы предприятиеләре продукциясен кулланучыга илтеп җиткерү максатында күпләп сату сәүдәсе һ. б. белән шөгыльләнүче фирмалардан аларны сатып ала. Ваклап сату сәүдәсе ахыргы продукт булып саналган хезмәт күрсәтүне башкара.

Арадаш һәм ахыргы продуктны җитештерүче буларак, авыл хуҗалыгы, туку һәм тегү промышленносте, ваклап һәм күпләп сату сәүдәсенә карата барлык әйтелгәннәрне теләсә нинди тармак комплексына карата да әйтергә була.

Мәсәлән, кыру станогы ясау өчен кара металл кирәк. Ул кокс ярдәмендә тимер рудасыннан коеп эшләнелә. Кокс үз чиратында битумлы күмердән җитештерелә.

Кыру станогы мисалында ахыргы продуктка куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләр генә түгел, ә бәлки яңадан җитештерелгән хезмәт кораллары — станоклар, турбиналар, касса аппаратлары, компьютерлар һәм башка күп төрле производство җиһазлары да керүен күрәбез.

Аерым алганда, машина төзү заводларына ия булган фирмалар металл эшкәртү җиһазларын сату өчен түгел, ә бәлки машина төзү заводында аларны монтажлап, соңыннан алар ярдәмендә яңа машиналар төзү өчен алалар. Төзелеш турында да шуны ук әйтергә була. Төзелеш фирмалары төзегән завод корпуслары хезмәт средстволары була, ә инде торак йортлар кешеләрнең торакка булган шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерә.

Шулай итеп, ахыргы продукт булып, беренчедән, куллану товарлары, ягъни кешеләрнең шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерүче товарлар хезмәт итә. Товарның бу категориясе озак һәм кыска вакытлы куллану товарларына бүленә. Озак вакытлы

куллану товарларына — автомобильләр, теле- һәм радио җиһазлары, көнкүреш техникасы, мебель (йорт җиһазы), кыска вакытлы куллану товарларына азык-төлек һәм эчемлекләр, кием-салым һәм аяк киеме, дарулар һ. б. керә.

Икенчедән, ахыргы продуктка шәхси куллану хезмәт күрсәтүләре, ягъни кешеләргә кирәкле, аларның шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерә һәм аларның тормыш эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәт күрсәтүләре керә. Бу хезмәт күрсәтүләрнең бер өлеше, мәсәлән, йорт хезмәтчесе яки хосусый практика белән шөгыльләнүче табиб хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне йорт хуҗалыклары үз өсләренә алалар. Икенче өлеше, мәсәлән, дәүләт уку йортларында эшләүче укытучы хезмәт күрсәтүләре, яки хокук саклау органнары яки метеохезмәт күрсәтүләре дәүләт тарафыннан түләнә.

Өченчедән, ахыргы продуктка барлык яңа төзелгән биналар, корылмалар, яңа эшләнгән машиналар һәм җиһазлар керә. Табигый ки, узган елларда төзелгән биналар һәм корылмалар предприятиеләрдә файдаланылса да, агымдагы елда эшләнгән продукт булып тормый. Алар инде узган елларда җитештерелгән продуктка кергән товар ролен башкарганнар.

Теләсә кайсы ил икътисады өчен аның эшчәнлегенең ахыргы нәтиҗәсе зур әһәмияткә ия. Йорт хуҗалыклары, хосусый фирмалар һәм дәүләт оешмалары өчен арадаш продуктның күләме түгел, ә бу арадаш продукттан нәрсә табылуы әһәмиятле. Милли производствоның ахыргы нәтиҗәсе булып илдә җитештерелгән барлык ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең суммасы тора.

> **ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ (ТЭП)** — бирелгән илдә бер ел эчендә җитештерелгән барлык ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми кыйммәте, яки базар бәясенең суммасы ул.

Тулай милли продукт

Хәзерге вакытта күпчелек илләрдә, шул исәптән Россиядә дә, ахыргы продукциянең төп күрсәткече буларак, тулай эчке продуктның күрсәткече файдаланыла. Шуңа карамастан соңгы вакытка кадәр *тулай милли продукт* (ТМПның) күрсәткече файдаланылды. Бу күрсәткеч хәзерге вакытта да үз әһәмиятен

югалтмады. Шуна күрә дә безгә ТМПның нәрсәдән гыйбарәт булуын һәм ул ТЭП күрсәткеченнән нәрсә белән аерылуын ачыкларга кирәк.

Алга таба (17 нче һәм 18 нче бүлекләрне кара) без теләсә кайсы илнең икътисады бөтен дөнья хуҗалыгының бер өлеше булуын һәм күп кенә фирмалар үз капиталын чит ил предприятиеләренә салуын күрербез. Мондый капитал салулар аларга билгеле бер керем китерә. Йорт хуҗалыклары саклык акчаларына үз илләре территорияләрендәге фирмаларның акцияләрен яки облигацияләрен генә түгел, ә бәлки чит илләрнекен дә ала алалар. Бу акцияләр һәм облигацияләргә алар теге яки бу суммадагы керем алалар. Ахыр чиктә билгеле бер ил белгечләре еш кына чит илдә урнашкан үз фирмаларының филиалларында яки уртак предприятиеләрдә эшлиләр. Алар анда хезмәт хакы алалар.

Шул ук вакытта чит ил фирмалары үз капиталларын бу ил предприятиеләренә салалар, башка ил гражданнары кыйммәтле кәгазьләр сатып алалар, бу кәгазьләр әлеге ил фирмалары тарафыннан эмиссия эшен башкаралар, ә чит ил филиалларында һәм уртак предприятиеләрдә чит ил белгечләре эшли. Алар барысы да салынган капитал яки үз хезмәтләре өчен теге яки бу керем алалар.

«ЛУКОЙЛ» компаниясе Азәрбайҗан нефтен чыгаруга 10 млрд сум акча керткән дип фараз итик, ә 100 Россия белгече-нефтьчесе Азәрбайҗан икътисадының бу тармагында эшли. Алга таба Россиянең бу ике житештерү факторы (капитал һәм хезмәт) 10 млрд сумга тигез булган гомуми керем китергән дип уйлыйк. Бу 10 млрд сум Азәрбайҗан эчке продуктының бер өлеше була, чөнки бу продукт аның территориясендә житештерелгән. Ләкин шул ук вакытта ул Россия милли продуктының да бер өлеше булып тора, чөнки бу 10 млрд сум акча Россия белгечләре хезмәте һәм Россия фирмасы капиталы белән житештерелгән. Шулай итеп, Россия ТЭПын исәплəгәндә, аннан Россиянең Азәрбайҗанда файдаланылган капитал һәм хезмәткә алынган керемне төшереп калдырырга кирәк. Ә инде Россиянең ТМПын исәплəгәндә, аңа чит илдә Россия житештергән хезмәт һәм капиталны кертергә кирәк.

Хәзер болай дип фараз итик: «Юнайтед текнолоджи» компаниясе (АКШ) телекоммуникация иярченнәрен жибәрү өчен, Россия ракеталары производствосына 500 млн долл. керткән,

бу аңа 50 млн долл. керем китерәчәк. Әлеге керем — Россия ТЭПының бер өлеше, чөнки ул безнең ил территориясендә җитештерелгән; ләкин шул ук вакытта бу 50 млн долл.— АКШ ТМПының бер өлеше, чөнки ул Америка капиталы белән җитештерелгән. Димәк, Россия ТЭПын исәпләгәндә, без бу 50 млн долларны безнең илнең ТЭПына кертергә тиеш, ләкин без аларны Россия ТМПыннан алырга тиеш, чөнки бу 50 млн долл.— АКШ ТМПының бер өлеше.

Шулай итеп,

ТУЛАЙ МИЛЛИ ПРОДУКТ — бирелгән илнең үзендә һәм шулай ук башка илләрдә җитештерү факторлары тарафыннан җитештерелгән барлык ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми кыйммәте, яки базар кыйммәтләренең суммасы ул.

АКШның ТМПы һәм аларның ТЭПы арасындагы аермалык һәм бу илнең ТЭПын исәплүү ысулы 11-3 рәсемендә күрсәтелгән.



11-3 нче рәсем. △
2004 елда АКШның ТЭПы һәм ТМПы.
АКШта чит ил кешеләре 361,7 млрд долл. суммада керем алганнар, һәм бу керем аларның үзләренә түләнгән. Ул — АКШ ТЭПының бер өлеше, һәм шул ук вакытта «калган дөнья» ТМПының да бер өлеше була. Бу сумманы без АКШ ТМПыннан алдык, ләкин аны бу илнең ТЭПы составында калдырдык. Бер үк вакытта америкалылар чит илдә 415,4 млрд долл. суммада керем алганнар, һәм бу америкалыларның үзләренә түләнгән. АКШ ТМПының бу өлеше әлеге ил ТЭПының өлеше булып тормый.

2004 елда АКШ ТМПы белән ТЭПы арасындагы аермалык бик кечкенә — 50,7 млрд долл., ягъни барлыгы 0,43% тәшкил итүенә без барыбыз да игътибар иттек. Бу — статистик хатадан кимрәк, ягъни зур булмаган хата булып исәпләнә, алар хәтта югары сыйфатлы статистик исәп-хисаплауларда булуы мөмкин, һәм шуңа күрә дә бөтен дөнья статистлары тарафыннан рөхсәт ителә. Икътисади анализ максатында бу ике күрсәткечнең кайсысы кулланылуы күп очракта зур әһәмияткә ия түгел.

11.3. ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ НИЧЕК ИСӘПЛӘНӘ

Барлык ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең кыйммәтен кушу авыр түгел кебек. Ләкин гади дип уйлаган юл белән барсак, биредә дә хата җибәрү куркынычы белән очрашырбыз. Туку промышленносте (сәнәгате) җитештергән тукымаларның арадаш продуктка керүен без күргән идек инде, чөнки тукымалар тегү промышленностенда эшкәртеләләр. Ләкин барлык тукымаларны да арадаш продуктка кертергә ярамый, чөнки аларның шактый өлеше халыкка сатыла. Йорт хуҗалыкларына сатылган тукымалар куллану товарлары булып санала, ягъни ахыргы продуктка керә. Шундый ук хәл икътисадның башка тармакларында да булып тора. Халык кулланган электроэнергия — ахыргы продукт, ә промышленность предприятиеләре, транспорт, банклар һ. б. файдаланган электроэнергия арадаш продукт була. Шәһәр халкына крестьяннар саткан сөт — ахыргы продукт; май заводына сатылганы чимал була. Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин.

Чыгымнар агымы суммасын табу методы

Әгәр статистлар төрле тармаклар һәм аерым предприятиеләрнең күпме товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештергәнен исәпли башласалар, алар бу товарларның кайсысы ахыргы продуктка, ә кайсысы арадаш продуктка керә дигән сорауга да җавап таба алмаслар иде. Шуңа күрә ТЭПны исәпләгәндә, статистика күпме товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерелгәнне түгел, ә *бу продукцияне сатып алуга киткән чыгымны исәпкә ала*: куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә күпме акча сарыф ителгән; биналарга һәм корылмаларга, машиналарга һәм җиһазларга, чимал, ярымфабрикат яки әзер продукция запаслары үсешенә күпме капитал кертелгән.

Статистика шулай ук товарларның бер өлешен дәүләт, төгәлрәк әйткәндә, дәүләткә кергән оешмалар һәм учреждениеләр, уку йортлары һ. б. сатып алуын игътибарга алырга тиеш. Дәүләт барлык бу дәүләт учреждениеләрендә эшләгән күп санлы хезмәткәрләрнең хезмәт күрсәтүләре өчен акча түли. Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләнгән дәүләт чыгымнары шулай ук илнең ахыргы продуктының билгеле бер өлеше өчен түләнгән чыгымнардан гыйбарәт.

Димәк, халыкның шәхси куллану чыгымнарын, хосусый фирмаларның инвестицияләрен һәм товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләнгән дәүләт чыгымнарын кушсак, илдә җитештерелгән барлык ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәяләре суммасына тигез булган сумманы, ягъни тулай эчке продуктны табабыз.

АКШның ТЭПын исәпләүне чагылдырган 11-4 рәсеменә игътибар итик.

Статистика мәгълүматлары буенча, АКШ халкы 2004 елда озак һәм кыска вакытлы куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен 8214,3 млрд долл. акча сарыф иткән. Хосусый фирмалар яңа заводлар, транспорт средстволары һ. б. өчен 1928,1 млрд долл. керткәннәр. Хосусый фирмаларның бу инвестицияләре (капитал салулары) бу суммага фирмаларның яңа биналар, җиһазлар сатып алганлыгын һәм үзләренең чимал, ярымфабрикатлар һәм әзер продукция запасларын арттырганнарын дәлилли. Ниһаять, ахыргы продуктның шактый өлешен дәүләт сатып ала: хәрби ведомстволар хосусый

11-4 нче рәсем. ▷ **АКШның ТЭПын тышкы сәүдәне исәпкә алмыйча хисаплау.**

ТЭПны исәпләгәндә, халыкның шәхси куллану чыгымнары, хосусый фирмаларның яңа биналарга һәм корылмаларга, машиналарга һәм җиһазларга һәм запас үсешенә тотылган тулай эчке инвестицияләре, шулай ук дәүләт сатып алган товарлар һәм аның хезмәт күрсәтүләр өчен түләгән чыгымнары кушыла.



фирмалардан корал һәм сугыш кирәк-яраклары сатып ала, дәүләт университетлары һәм мәктәпләре, дәүләт бюджетыннан акча алып, аларны укытучылар хезмәте өчен (ягъни хезмәт күрсәтүләре өчен) түләүгә, уку-укыту җиһазлары, мебель һ. б. сатып алуга тотканнар; шул ук дәүләт бюджетыннан больница һәм поликлиникаларга бүленеп бирелгән акчаларны табиблар һәм шәфкать туташлары хезмәте өчен түләүгә, медицина җиһазлары һәм дарулар сатып алу өчен тотканнар; дәүләт хезмәтендә эшләүче чиновниклар һәм барлык башка хезмәткәрләрнең хезмәт күрсәтүләре өчен акча түләнгән. Дәүләт 2004 елда товар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен барлыгы 2215,9 млрд долл. сарыф иткән.

Безгә хәзер шуны игътибарга алырга кирәк: йорт хуҗалыклары да, фирмалар да, дәүләт тә башка илләрдән кертелгән (импорт) товар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен зур суммалар тоталар. Мәсәлән, кулланучылар акчаларының бер өлешен



11-5 нче рәсем. △
Тышкы сәүдә һәм ТЭП.
Йорт хуҗалыклары, хосусый фирмалар һәм дәүләт АКШның үзендә булмыйча, ә башка илләрдә җитештерелгән товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә 1797,8 млрд долл. сарыф иткәннәр. Бу сумманы АКШның ТЭПыннан алырга кирәк. Ләкин 1173,8 млрд долл. суммага АКШ ТЭПының бер өлеше чит ил кешеләренә сатылган. Аны АКШның ТЭПына кушарга кирәк. Табылган аерма (−624,0 млрд долл. = 1173,8 млрд долл. − 1797,8 млрд долл.) саф экспорттан гыйбарәт була.

импорт (чит илдән кертелгән) киемнәргә яки көнкүреш техникасына тоталар; туристик круизларга баргач, алар чит ил гостиницалары һәм гидлары хезмәт күрсәтүләре өчен акча түлиләр; фирмалар үз капиталларының бер өлешен чит ил заводлары чыгарган җиһазлар өчен салалар, чит илдән чимал сатып алалар; шуна охшаш чыгымнарны дәүләт ведомстволары, мәсәлән, коралга тоталар. Чит илдән кертелгән товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең күләме чыгымнарның күпме суммасы халык, фирмалар һәм дәүләт тарафыннан башка илләр җитештергән ТЭПка киткәнен күрсәтә. Билгеле, бу чыгымнарның суммасы бирелгән илдә (АКШта) җитештерелгән ахыргы товар алуга һәм хезмәт күрсәтүләргә түләнгән чыгымнар суммасыннан алынырга тиеш. Шул ук вакытта чит ил кешеләре АКШта җитештерелгән товарларны сатып алганнар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләгәннәр. Бу сумма әлеге илнең ТЭПына кертелергә тиеш. Шулай итеп, ТЭПны исәпләгәндә, экспорт белән импорт арасындагы аерманы, яки *саф экспортны* исәпкә алырга кирәк. 2004 елда АКШның саф экспорты −624,0 млрд долл. тәшкил иткән. Саф экспортны гадәттә **илнең сәүдә балансы** дип атыйлар (11-5 рәс.).

Саф экспортның тискәре зурлык булуы мәҗбүри түгел, билгеле. Мәсәлән, 2000 елда Россиянең товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең экспорты долларларда исәпләгәндә 105,5 млрд ка тигез булган, ә Россиягә товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең импорты 60,6 млрд долл. тәшкил иткән. Димәк, Россиянең саф экспорты (сәүдә балансы) +44,9 млрд долл. тәшкил иткән.

Инде хәзер, тышкы сәүдә операцияләрен исәпкә алгач, без халыкның, фирмалар һәм дәүләтнең ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең суммасын түләүгә киткән барлык чыгымнарының соңгы нәтиҗәсен, ягъни бирелгән илдә ел эчендә җитештерелгән ТЭПны табарга була. 2004 елда АКШта бу сумманы түбәндәгеләр тәшкил иткән:

Халыкның шәхси куллану чыгымнары	8214,3 млрд долл.
Хосусый фирмаларның инвестицияләре	1928,1 млрд долл.
Дәүләт сатып алган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр	2215,9 млрд долл.
Саф экспорт (сәүдә балансы)	−624,0 млрд долл.
БАРЛЫГЫ	11734,3 млрд долл.

Шулай итеп, тулай милли продукт һәм тулай эчке продуктны исәпләүнең бер ысулы булып бер ел эчендә халыкның шәхси куллану чыгымнарының, хосусый фирмаларның тулай

эчке инвестицияләренең, дәүләт сатып алган товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең саф экспортының суммасын табу тора.

Бу ысул **чыгымнар агымы суммасын табу методы** дип атала.

Керемнәр агымы суммасын табу методы

ТЭПны исәпләүнең икенче ысулы икътисадта житештерелгән керемнәрнең суммасын табуга кайтып кала. Бу ысулның нигезендә *өстәлгән кыйммәтне* исәпкә алу ята. Шуңа күрә безгә өстәлгән кыйммәткә куелган салымнар белән эш итүче күп кенә эшмәкәрләргә һәм финанс министрлыгы хезмәткәрләренә очрый торган бу мөһим икътисади категориянең нидән гыйбарәт булуын ачыкларга кирәк булачак.

Без алдарак карап үтелгән кием-салым (күлмәк һәм костюмнар) житештерү мисалына кире кайтыйк. Кием-салымның, башлангыч чималны (мамык һәм йон), ярымфабрикатларны (эрләнгән жеп, тукыма) эзлекле рәвештә берничә стадиядә эшкәртүдән соң сәүдә челтәре аша үткән ахыргы продукт булуын искәрткән идек инде. Бу стадияләрнең һәрберсендә әлеге тармак операцияләр һәм эшләр комплексы башкара, бу эш аңа, үзе житештергән продукцияне башка фирмаларга сатканнан соң, билгеле бер суммада керем китерә. Бу процесс 11-1 таблицасында күрсәтелә.

11-1 таблицасы

Продукцияне житештерү һәм өстәлгән кыйммәт, млн сумнарда

Тармак	Чималның, ярымфабрикатның кыйммәте	Өстәлгән кыйммәт	Тулай житештерү
Авыл хуҗалыгы	0	15	15
Эрләү	15	20	35
Туку	35	20	55
Тегү	65	35	90
Ваклап сату сәүдәсе	90	10	100
Өстәлгән кыйммәтнең гомуми суммасы	—	100	—

Мамык үстергән һәм җыеп алган фермерлар, аны сатканнан соң, 15 млн сум керем алганнар дип фараз итик. Фермерлар бу керемнең бер өлешен (4 млн сум), производствода файдаланылып тузган җиһазлар һәм биналар исәбенә җыеп куярга тиешләр. Әгәр алар ялланып эшләүчеләр хезмәтеннән файдалансалар,

аларга хезмәт хакы (6 млн сум) түләнергә тиеш. Калган 5 млн сум — фермерларның керемнәре (табыш). Шулай итеп, мамык житештерү процессында ТЭПка 15 млн сумлык кертем ясалган, ул мамыкчылык тарафыннан өстәлгән кыйммәттән гыйбарәт.

Моннан соңгы стадия — эрләү производствосы. Эрләү фабрикаларының хужалары, 15 млн сумга мамык сатып алып, 35 млн сумлык жеп житештергәннәр. Бу сумманың 15 млн сумы белән мамык чыгымнарын каплаганнар. Жиһазларның тузуы 6 млн сум тәшкил иткән; эшчеләр, инженерлар һәм бу эштә катнашкан башкаларның хезмәт хакы — 8 млн сум, табыш — 6 млн сум. Шулай итеп, бу стадиядә өстәлгән кыйммәт 20 млн сумга тигез.

Киләсе стадияләрдә шуңа охшаш процесслар бара: жеп бәясенә (35 млн сум) туку фабрикалары 20 млн сумлык кыйммәт өстиләр һәм 55 млн сумлык продукция чыгаралар, тегү фабрикалары тукыма бәясенә 35 млн сумлык кыйммәт өстиләр һәм 90 млн сумлык продукция чыгаралар һәм, ниһаять, ваклап сату сәүдәсе тагын 10 млн сум өсти һәм ваклап сату бәясеннән 100 млн сумлык гомуми суммага кием сата.

Шулай итеп, һәр тармак өстәгән кыйммәтләрнең гомуми суммасы ахыргы продукциянең бәясенә, ягъни соңгы кулланучыга сатылган продукция бәяләренең суммасына тигез.

Бу кагыйдә теләсә нинди тармак комплексына карый: бөртекле ашлык — он — макарон — сәүдә хезмәт күрсәтүе; тимер рудасы һәм күмер — баетылган руда һәм кокс — металл — прокат һәм металл эшләнмәләр — күпләп сату сәүдәсе хезмәт күрсәтүләре һ. б.

Бу кагыйдәгә нигезләнеп түбәндәге фикерне әйтә алабыз:

> **ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТНЫҢ КЫЙММӘТЕ** икътисадның барлык тармаклары тарафыннан житештерелгән өстәлгән кыйммәткә, яки икътисадның барлык тармакларындагы фактор керемнәре һәм төп капитал амортизациясе суммасына тигез.

Өстәлгән кыйммәтне исәпкә алып, ТЭПны исәпләү буенча соңгы нәтижәне ясаганчы, без ТЭПны житештерүдә дәүләт секторы хезмәткәрләренең хезмәте һәм бу секторның капиталы катнашуын да искә алырга тиеш. Шуңа күрә ТЭПның бер өлеше дәүләт структуралары керемнәреннән гыйбарәт. Дәүләт

керемнәрнең бу өлешен **читләтеп алына торган (кыек) салымнар** рәвешендә ала. Нәрсә соң ул читләтеп алына торган салымнар?

Барыбызга да туры салымнар билгеле; алар йорт хуҗалыклары һәм фирмалар керемнәреннән турыдан-туры алыналар. Мәсәлән, керемнән алынган салым дәүләт бюджетына хезмәт хакыннан эшләп алынган акчаның 13% ы алынуын, фирма эшләп тапкан табышның 24% ы күчүен күздә тота. Бу тотып калынган акчалар илдә җитештерелгән ТЭПның күләмен чагылдырмый. Бу акчалар шәхси акча янчыкларыннан дәүләтнекенә күчә. Әгәр әти кеше балаларына тундырма сатып алу өчен 10 сум акча бирсә, моннан гына гаиләнең кереме һәм чыгымнарының гомуми суммасы үзгәрми. Әгәр дәүләт 1 млн сум эшләп тапкан фирманың табышыннан бу табышның 24% ын алып калса, дәүләт һәм фирманың гомуми кереме үзгәрми: 760 мең сум фирмада кала, ә 240 мең дәүләткә керә.

Читләтеп алынган салымнар белән эш башкача тора. Бу салымнар сатыла торган продукциянең бәясенә кертелә. Алар ТЭПны булдыруда дәүләтнең кертеме буларак каралырга мөмкин, һәм шуңа күрә ТЭПны хисаплаганда исәпкә алынырга тиеш. Читләтеп алынган салымга мисал булып өстәлгән кыйммәт салымы (ӨКС, русчасы НДС — налог на добавленную стоимость) хезмәт итә ала.

11-1 таблицасында күрсәтелгән мисалга кайтыйк һәм президент указы белән өстәлгән кыйммәткә 20% лы салым кертелгән дип күзаллыйк. Ул вакытта 11-1 таблицасында китерелгән тармаклар түбәндәгечә ӨКС түләячәк һәм шуңа карап үз продукцияләренә тагын да зуррак яңа бәя куячак (11-2 табл.).

11-2 таблицасы

Өстәлгән кыйммәтнең салымы һәм продукциянең бәясе, млн сум

Тармак	Чимал һәм ярымфабрикатларның кыйммәте	Өстәлгән кыйммәт	ӨКС (НДС)	Җитештерелә торган продукциянең кыйммәте
Авыл хуҗалыгы	0	15	3	18
Эрләү	18	20	4	42
Туку	42	20	4	66
Тегү	66	35	7	108
Ваклап сату сәүдәсе	108	10	2	120
БАРЛЫГЫ	—	100	20	—

11-2 таблицасыннан өстәлгән кыйммәт салымын кертү барлык товарларга да бәяләрнең артуына китерүен күрәбез. Безнең өчен биредә шуны билгеләп китү мөһим: халыкка сатыла торган ахыргы товарларга яңа бәя өстәлгән кыйммәт белән ӨКСның суммасына тигез: 100 млн сум + 20 млн сум = 120 млн сум.

Теләсә кайсы тармак комплексында (металлургия, азык-төлек һ. б.) ӨКСны исәпкә алып җитештерелгән продукциянең бәясе формалашуын күзәтсәк, шундый ук нәтиҗә килеп чыгачак.

Шулай итеп, икътисадтагы барлык керемнәрне, ягъни өстәлгән кыйммәтләрне кушсак, һәм бу суммага барлык читләтеп алынган салымнарны өстәсәк, табылган сумма тулай эчке продуктка тигез булачак. Бу положениега ТЭПны исәпләүнең икенче ысулы нигезләнә, ул **керемнәр агымы суммасын табу методы** дип атала.

Икенче метод белән исәпләгәндә, түбәндәге керемнәр исәпкә алынырга тиеш:

1) өстәмә түләүләрнең барлык төрләрен дә (отпуск, премия акчалары һ. б.) кертеп, фирмаларның эшчеләргә, инженерларга, менеджерларга һәм барлык башка ялланып эшләүче хезмәткәрләргә түләгән хезмәт хакы;

2) эшмәкәрләр, акция һәм облигацияләр ияләре, арендага тапшырылган милек һәм җир участоклары хуҗалары алган төрле төрдәге керемнәр, ягъни табыш, процентлар, дивидендлар һәм рента;

3) яллы хезмәттән файдаланмаучылар һәм керемнәре хезмәт хакына һәм табышка бүленмәгән кече эшмәкәрләрнең, аерым алганда, фермерларның керемнәре;

4) амортизация өчен калдырылган акчалар — барлык фирмаларның биналар һәм корылмалар, машиналар һәм җиһазларның тузуын каплау өчен билгеләнгән керем акчалата керемнәрнең бер өлеше;

5) читләтеп алынган салымнар, ягъни дәүләт керемнәре.

Барлык бу керемнәр, белгәнебезчә, җитештерү факторлары — хосусый һәм шулай ук дәүләт секторы хезмәте, капиталы, җире белән булдырыла яки капитал (амортизация) куллану хисабына барлыкка килә.

ТЭПны исәпләүнең бу ике ысулы практик яктан бертөрле нәтиҗә бирә. Моны без 11-6 рәсемендә китерелгән диаграммадан күрәбез. Беренче метод белән — 11734,3 млрд долл.,



11-6 нчы рәсем. △
АКШ буенча статистик мәгълүматлар, халыкның куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә, хосусый экспорт инвестицияләре чыгымнары һәм дәүләт чыгымнарының суммасы амортизация чигерүләре, хезмәт хакы, процент, рента, кече эшмәкәрләр керемнәре һәм читләтеп алынган салымнарның суммасына тигез булуын (зур булмаган статистик хата белән) күрсәтә.

икенчесе белән 11811,1 млрд долл. килеп чыга. Америка статистикасы ТЭПны исәпләүдә шактый зур — 76,8 млрд долларга тигез булган хата җибәргән дип уйлау дөрес булмас иде. Мондый исәп-хисапларда хаталардан котылып булмый. Өстәвенә хата ТЭПның гомуми суммасының бары тик 0,65%ын гына тәшкил иткән.

11.4. САФ МИЛЛИ ПРОДУКТ ҺӘМ МИЛЛИ КЕРЕМ

ТМП һәм ТЭП күрсәткечләре никадәр мөһим булмасын, аларның берсе дә төгәл генә бирелгән ил халкы, ягъни ялланып эшләүче хезмәткәрләр, эшмәкәрләр, кыйммәтле кәгазь ияләре

һ. б. күпме күләмдәге тулай керемгә ия дигән сорауга җавап бирә алмый. Бу сорауга җавап табу өчен, без *милли керемнең* күләмен исәпләп чыгарырга тиеш.

Саф милли продуктны һәм милли керемне билгеләү

Барлык эшләп торучы фирмаларның ахыргы товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне сатканнан соң алган барлык акчалата керемнәрен, аларның саф керемнәре буларак карарга ярамый. Эш менә нәрсәдә: бу — акчалата керемнең бер өлеше, ягъни ТМПның бер өлеше биналар һәм корылмаларның, машиналар һәм җиһазларның тузуын капларга тиеш. Бу максатта барлык эшмәкәрләрнең амортизация өчен өлеш чыгарганнарын без күргән идек инде. Продукция сатудан алган акчалата керемнең бу өлешен алар ирекле рәвештә тота алмыйлар. Объектив шартлар, аларга системалы рәвештә төп капиталның искерүен һәм тузуын каплау өчен, бу акчаларны яңа төзелешләр һәм яңа җиһазларны инвестицияләргә мәҗбүр итә.

Шулай итеп, җәмгыять ТМПның биналар һәм җиһазларның тузуын исәпкә алып калдырылган акчалары белән курыкмыйча файдалана алсын өчен, ТМПдан амортизация өчен чигерелгән акчаларны алырга кирәк.

ТМПның амортизация өчен чигерелгән акчаларын алганнан соң калган өлеше **саф милли продукт** (СМП) дип атала.

Ләкин, күргәнебезчә, икътисадта булдырылган керемнәрнең барысы да турыдан-туры фирмаларга һәм халыкка бирелми. Бу керемнәрнең бер өлешен дәүләт читләтеп алынган салым формасында үзләштерә. Читләтеп алынган салым хисабына капланган дәүләт чыгымнарын, нигездә, әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать бәла-казаларыннан килгән югалтуларны каплау, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә икътисадның башка тармакларына ярдәм итү буенча финанслау чыганагы буларак карарга була. Шуңа күрә читләтеп алынган салымнарны, дәүләтнең икътисад бербөтен булып эшләп торуы өчен җәмгыять житештергән хезмәт күрсәтүләргә түләү сыйфатында алынган кереме буларак карарга мөмкин. Шул ук вакытта бу керем амортизация өчен калдырылган акчаларга охшаш. Шуңа күрә милли икътисадта булдырылган саф керемне табу өчен, без милли икътисадта булдырылган саф милли продукттан читләтеп алынган салымнарны алырга тиеш (11-7 рәс.).

11 нче бүлек.



11-7 нче рәсем. △
Милли керемнең күләмен билгеләү.
Тулай милли продукттан амортизация чигерүләрен алсак, саф милли продуктны табабыз. Шуннан соң саф милли продукттан читләтеп алынган салымнарны алсак, милли керем күләмен табабыз.

> Тулай милли продукттан амортизация чигерүләрен һәм читләтеп алынган салымнарны алганнан соң калган өлеш МИЛЛИ КЕРЕМ дип атала.

Милли керемне хосусый секторда җитештерелгән фактор керемнәре суммасы буларак күрсәтергә була. 1 нче бүлектә күрсәтелгәнчә, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү өчен билгеле бер ресурслар, яки җитештерү факторлары кирәк.

Җитештерү факторлары һәм фактор керемнәре

Һәр фактор нинди дә булса керем китерә. Хезмәт җитештерү факторларының берсе булганлыктан, хезмәт хакы шул эш өчен түләү формасы була. Аерым алганда, фирма оештыручылары һәм житәкчеләренең эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле керемнәрнең аерым бер төре булып эшмәкәрлек кереме тора. Шуны искәртеп китик: статистика, эшмәкәрлек керемен хезмәт хакы белән берләштереп, һәрвакытта аны керемнең аерым бер төре буларак аерып күрсәтми.

Капитал житештерү факторы була; аңа производство биналары, жиһаз, чимал, ярымфабрикатлар, ягулык һәм акча ресурслары кирәк. Капитал иясе алган керем **процент** һәм **дивиденд** формаларында була.

Капитал хуҗалары турыдан-туры кыйммәтле кәгазьләр — акция һәм облигацияләр — яки саклык банкларындагы кертем иясе булалар. Үз капиталын кыйммәтле кәгазьләргә әйләндереп яки саклык банкларына салып, капитал иясе аны эре фирмалар житәкчеләре яки кече эшмәкәрләр карамагына тапшыралар. Күп кенә фирмалар жир, биналар, корылмалар яки жиһазлар кебек факторлар арендасыннан файдаланалар. Арендага тапшырылган жир һәм күчемсез милекнең башка төрләре, житештерү факторы буларак, **рента** формасында керем китерә.

Яллы хезмәттән файдаланмаучы кече эшмәкәрләрнең товар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерүдә катнашуы, кагыйдә буларак, аларның ике факторны — хезмәтне һәм капиталны берләштерүләрен аңлата. Шуңа күрә кече эшмәкәрләрнең кеременнәре берләштерелгән фактор кереме булып чыга.

> Фактор керемнәренең суммасы милли керемгә тигез.

Милли керемнең бүленеше

Милли керемнең ничек формалашуын тикшергәндә, икътисадта милли керем хасил булу белән беррәттән, аның *бүленеше* дә баруын күрәбез. Базар икътисадында эшләүче җәмгыять әгъзалары, товар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерүдә катнашып, аңа үз хезмәтен, капиталын кертеп яки үзенең күчемсез милкен фирмалар карамагына тапшырып, бу кертем буенча нинди дә булса керем алалар.

> Милли керем бүленешенең нигезендә житештерү факторларына куелган бәя тора.

Производство оештырырга тотынган эшмәкәрләр төрле житештерү факторлары сатып алырга тиеш. Аларга бу факторлар өчен акча түләргә кирәк. Икенче төрле әйткәндә, ялланып эшләүче хезмәткәр үз хезмәте өчен — хезмәт хакы;



11-8 нче рәсем. △
2004 елда АКШта милли керем бүленеше.
Барлык фактор керемнәрен кушсак, табылган сумма милли керемгә тигез була.

капитал ияләре — процент; җир һәм башка күчемсез милек хуҗалары рента ала. Базар системасында һәр фактор әлеге факторга сорау һәм тәкъдим нисбәтенә карап бәяләнә. Һәр фактор өчен түләүгә бәйле керемнәр бүленешенең оптималь, ягъни шуңа күрә дә дөрес варианты булып икътисадта — тигезләнеш, аерым алганда, һәр фактор өчен сорау һәм тәкъдим тигезләнеше тәэмин ителгән вариант тора. Киресенчә, тигезләнештән теләсә нинди якка тайпылу теге яки бу керемнең тиешсез артуына яки кимүенә китерә.

11-8 рәсеменнән 2004 елда АКШ халкының төрле төркемнәре нинди керемнәр алганын һәм, димәк, милли керемнең ничек формалашуын һәм бүленүен күрәбез.

11.5. КУЛГА КЕРГӘН ШӘХСИ КЕРЕМ НИЧЕК ФОРМАЛАША

Илдә формалашкан милли керем факторлар керемнәренә тигез булса да, бу әле аларның барысы да тулысынча әлеге керемнәрне алучыларның акча янчыкларына керә дигән сүз түгел. Шул ук вакытта йорт хуҗалыклары хезмәт хакы, табыш, процентлар, рента гына алып калмыйча, алар әле кече

бизнестан керем алалар. Бу шуның белән аңлатыла: керемнәрнең житештерү факторлары буенча формалашуы һәм бүленеше аларның *яңадан бүленеше* белән тулыландырыла, моның нәтижәсендә *икенчел керемнәр* барлыкка килә. Бу хәл милли керемнең яңадан бүленешендә дәүләт бюджеты катнашуыннан килеп чыга.

Дәүләт бюджеты

Моңа бәйле рәвештә дәүләт бюджеты нидән гыйбарәт булуын тикшерик (11-3 табл.). Теләсә нинди бюджет кебек үк, дәүләт бюджеты да керем һәм чыгым өлешләреннән тора. Дәүләт бюджетында керемнәр чыганагы булып салымнар хезмәт итә, алар турыдан-туры һәм читләтеп алына торганнарга бүленәләр. Соңгылары — ТЭПның состав өлеше. Алар житештерелгән товар һәм хезмәт күрсәтү бәяләренә керәләр. Турыдан-туры салымнар икътисадта житештерелгән керемнәрдән алына. Шуңа күрә йорт хужалыкларына илдә житештерелгән керемнәрнең бер өлеше — турыдан-туры салымнардан калганы эләгә.

11-3 таблицасы

2004 елда АКШның дәүләт бюджеты, млрд долл.

Бюджет керемнәре		Бюджет чыгымнары	
Турыдан-туры салымнар	2169,9	Товар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләнгән чыгымнар	2215,9
Читләтеп алынган салымнар	920,6	Трансферт түләүләре	1404,7
Салымнан тыш керемнәр	117,7		
Барлыгы	3208,2	Барлыгы	3620,6
Бюджет дефициты (керемнәрнең чыгымнардан артып китүе) — 412,4			

Дәүләт бюджетының икенче өлеше — аның чыгымнары. Дәүләт бюджетының акчалары бик күп төрле максатта тотыла. Кайберләрен без моңа кадәр искә алып киткән идек. Биредә без аларны ике зур төркемгә берләштерербез: 1) дәүләтнең товар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуы; 2) дәүләтнең трансферт түләүләре.

Беренче очракта бюджет ассигнацияләре хисабына илдә житештерелгән ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бер

өлешенә, ягъни ТЭПның бер өлешенә, акча түләнә. Бу чыгымнар фактор керемнәре – хезмәт хакы, табыш һ. б. барлыкка килүен күздә тота.

Трансферт түләүләренә килгәндә, алар товар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү формасы булып тормый. Боларга социаль страхования системасы буенча түләүләр (пенсияләр, пособиеләр (ярдәмнәр) һ. б.) керә. Димәк, дәүләт бюджетындагы трансферт түләүләре керемнәр булдыруга китерә, алар фактор керемнәре булмасалар да, барыбер йорт хуҗалыклары ала торган акчаларның гомуми суммасын арттыруга булышлык итәләр.

Йорт хуҗалыклары ала торган керемнәрне формалаштыруга акционерлар компанияләре алган табышны бүлү дә йогынты ясый. Теләсә кайсы фирма үз табышының бер өлешен технология үсеше өчен, продукция чыгару күләмен арттыру, аның сыйфатын яхшырту һ. б. өчен файдаланырга тиеш. Аңа конкуренция кискенләшү, чимал кыйммәтләнү шартларында һәм төрле көтелмәгән хәлләрдә үзенең тотрыклылыгын тәэмин итү өчен резерв фонды таләп ителә. Шуңа күрә акционерлар компанияләре алынган табышның барысын да үз акционерлары арасында дивиденд формасында бүлмиләр. 2004 елда АКШ акционерлар компанияләре табышны түбәндәгечә бүлгәннәр:

Алган табышның гомуми суммасы	1161,5 млрд долл.
Табыш салымы	258,9 млрд долл.
Саф табыш (салымнарны алганнан соң)	902,6 млрд долл.
Дивидендлар	682,4 млрд долл.
Бүленмәгән табыш	320,2 млрд долл.

Шулай итеп, йорт хуҗалыклары милли керемнең бер өлешен яңадан бүлү процессында дәүләт бюджетыннан керемнәрне трансферт түләүләре рәвешендә, башлыча пенсия һәм дәүләт бурычы буенча процентлар рәвешендә алалар. Ләкин шул ук вакытта алар акционерлар компанияләренең барлык табышын түгел, ә аның бер өлешен дивидендлар рәвешендә алалар. Милли керемне яңадан бүлүнең бу беренче адымы нәтиҗәсендә йорт хуҗалыкларына керергә тиешле *тулаем шәхси керем* формалаша. Аның зурлыгын исәплик:

Милли керем	9432,1 млрд долл.
АҖ табышыннан салым һәм бүленмәгән табыш	–579,1 млрд долл.
Пенсияләр, дәүләт бурычы буенча процентлар һ. б. түләүләр	860,3 млрд долл.
Тулаем шәхси керем	9713,3 млрд долл.

Боларны йомгаклап шуны әйтергә була: милли керем, яки икътисадта җитештерелгән фактор керемнәренең суммасы, йорт хуҗалыкларына түләнә торган һәм **шәхси керем** яки **тулаем шәхси керем** дип аталып йөртелгән керемнәр суммасы белән бердәй түгел. Ләкин тулаем шәхси керем дә тулысынча йорт хуҗалыклары карамагына эләкми. Алар керем салымы, күчемсез милек салымы һ. б. ны түлиләр. Болар һәм боларга охшаш салымнар **шәхси салымнар** дип атала. Шәхси керемнән шулай ук социаль страховкалауга акча алына. Әгәр без тулаем шәхси керемнән шәхси салымнарны һәм социаль страховкалауга бирелгән акчаларны алсак, ул вакытта без **тулаем кулга кергән керемне**, ягъни инде башка бернинди тотып калуларсыз йорт хуҗалыклары карамагына керүче акчаларны табабыз.



11-9 нчы рәсем. △
Россиядә тулаем кулга кергән керем болай формалашкан: җитештерелгән милли керемнән табыш салымнары һәм башка керемнәр, АҖның бүленмәгән табышы, социаль страховкалауның взнослары алынган, ләкин дәүләт бюджетыннан трансферт түләүләре суммасы, социаль страховкалау системасы буенча түләүләр, дәүләт заемнары буенча процентлар кушылган; шуннан соң табылган тулаем шәхси керемнән индивидуаль салымнар алынган.

2004 елда АКШта кулга кергән керем түбәндәгечә тәшкил иткән:

Тулаем шәхси керем	9713,3 млрд долл.
Халыктан алынган турыдан-туры шәхси салымнар	−1049,1 млрд долл.
Социаль страховкалауга калдырылган акчалар	−822,2 млрд долл.
Кулга кергән керем	7842,0 млрд долл.

11-9 рәсемендә 2000 елда Россиядә кулга кергән керемнәр формалашу схемасы күрсәтелгән (млрд сумнарда бирелгән).

Кулга кергән керемнең формалашуы безнең һәрберебез өчен практик әһәмияте зур. Мәсәлән, шәхси салымнарны арттыру халыкның шәхси керемнәрен турыдан-туры алу була, үз чиратында ул кулга кергән керемне киметә. Әгәр инде ул, халыкка трансферт түләүләрен арттыру белән барса, бу вакытта кулга кергән керем кимеми, ә хәтта аның үсүе дә мөмкин. Моның артында чиктән тыш югары керемнәрнең үсүен чикләүче һәм аз керемле халык катлавына (пенсионерлар һ. б.) ярдәм итә торган яхшы уйлап эшләнгән сәясәт торуы мөмкин.

Шул ук вакытта кулга кергән шәхси керемнең үсүен тоткарлаучы салымнарның үсеше рациональ булмаган, акланмаган акчалар сарыф итүгә (мәсәлән, бюрократик аппарат күперүе) сәбәпче булса, бу очракта халыктан алынган салымнар үсеше берни белән дә компенсацияләнми һәм аның нәтиҗәсе тискәре булачак.

11.6. НОМИНАЛЬ ҺӘМ РЕАЛЬ ТЭП

Аерым бер предприятие, тармак һәм икътисад җитештергән продукция, тулаем алганда, базар куйган бәяләрдә билгеләнә. Ләкин шулай ук безгә базар бәяләре үзгәрешсез тормаганы билгеле. Хәзерге вакытта барлык илләрдә дә диярлек аларның гомуми дәрәҗәсе күтәрелүе күзәтелә. Кайбер илләрдә бәяләрнең бу үсеше акрын бара — елга берничә процент кына; икенчеләрендә, шул исәптән Россиядә дә, бәяләр шактый тиз үсә. Димәк, әгәр төрле елларда җитештерелгән ТЭПны шул еллар бәяләрендә билгеләсәк, бер елда аның күләме — бертөрле бәяләрдә, икенче елда икенче бәяләр белән билгеләнә һ. б. I нче бүлектә без продукция җитештерү күләме, керемнәр һ. б. ның күрсәткечләрен агымдагы (үзгәрүчән) һәм үзгәрешсез (даими) бәяләрдә билгеләргә мөмкин икәнен ачыклаган идек инде.

Беренче очракта без — номиналь, икенчесендә реаль зурлыкларны табабыз.

Хәзер без бу мәсьәләне конкрет очрак өчен — ТЭПның номиналь һәм реаль тулай эчке продукт күрсәткеченә карата кулланабыз.

Агымдагы елның фактта формалашкан базар бәяләрендә белдерелгән барлык ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерү күләме НОМИНАЛЬ ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ дип атала.

ТЭПның номиналь күрсәткече илдә житештерелгән ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр микъдарына да, һәм аларга куелган бәяләр күрсәткеченә дә бәйле. Табигый ки, номиналь ТЭП житештерүнең реаль күләме үсүен яки кимүен бәяләү өчен хезмәт итә алмый.

Үзгәрешсез бәяләрдә, ягъни кайсы да булса елда формалашкан бәяләрдә белдерелгән барлык ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерү күләме РЕАЛЬ ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ дип атала.

Реаль ТЭП күрсәткече бәяләр үзгәрешенә бәйле булмаганлыктан, ул ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең реаль житештерү күләме дәрәжәсен һәм динамикасын чагылдыра. Шуңа күрә ул икътисад үсешенең мөһим күрсәткечләренең берсе булып хезмәт итә ала. 11-4 таблицасында китерелгән мәгълүматлар буенча Россиядә реаль ТЭП ($ТЭР_р$) 1990 елдан 1998 елга кадәр 42,5% ка кимегән. 1999 елда продукция житештерү үсә башлаган, ләкин 2004 елда әле ул 1990 ел дәрәжәсенә житмәгән.

Номиналь ТЭПның ($ТЭП_н$) тиз үсүе бәяләрнең бик тиз үсүен чагылдыра. 1996 елда аларның дәрәжәсе 1990 елга караганда 5548 тапкырга югарырак булган. 1998 елда хөкүмәт сумның (рубльнең) деноминациясен үткәрә: әйләнешкә яңа банкнотлар чыгарыла, алар 1:1000 пропорциясендә иске акчаларга алмаштырыла. Бу эш бәяләрнең үсүен туктатмаса да, 1998—2004 елларда алар тагын 4,48 тапкыр үскән, ул уйлап эшләнгән чара була.

11-4 таблицасы

1990—2004 елларда Россия Федерациясендә номиналь һәм реаль ТЭП

	1990 ел*	1991 ел*	1996 ел*	1998 ел**	1999 ел**	2002 ел**	2004 ел**
$ТЭП_н$	644,2	1398,5	2145655,5	2630	4823	10836	17008
$ТЭП_р$***	1472,9	1398,5	882,9	847,2	892,9	1064,1	1224,0
$P_{тэп}$	0,438	1	2430,2	3,104	5,402	10,183	13,895

Искәрмә. * $ТЭП_н$ агымдагы бәяләрдә млрд сумнарда белдерелә; ** $ТЭП_н$ һәм $ТЭП_р$ деноминацияләнгән млрд сумнарда; *** ТЭП 1991 ел бәяләрендә белдерелә; $P_{тэп}$ — ТЭП дефляторы (1991 елда бәяләр = 1)

Реаль ТЭПны исәпләү методларын тикшерик.

Номиналь ТЭП, шулай ук барлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәяләре дәрәҗәсе турында мәгълүматлар булганда, без реаль ТЭПның зурлыгын исәпли алабыз:

$$ТЭП_р = \frac{ТЭП_н}{P_{тэп}}, \qquad (11.1)$$

биредә $P_{тэп}$ — барлык ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәяләре индексы.

Номиналь ТЭПның гомуми күләмен статистлар безгә инде билгеле булган метод белән исәплиләр (11.2 парагр. кара): алар ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең кыйммәтен базар бәяләрендә белдерәләр һәм аның суммасын табалар, ягъни

$$ТЭП_н = Q_1P_1 + Q_2P_2 + ... + Q_nP_n = \sum_{i=1}^{n} Q_iP_i, \qquad (11.2)$$

биредә Q — бер ел эчендә җитештерелгән аерым бер товарның яки хезмәт күрсәтүнең күләме; P — бирелгән елда шул ук товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе.

Реаль ТЭП зурлыгы, нигездә, шул ук метод белән исәпләнә, ләкин ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең кыйммәтләре *үзгәрешсез* бәяләрдә, ягънининдидер бер елда базарда урнашкан бәяләрдә белдерелә. 11-3 таблицасында реаль ТЭП 1991 ел бәяләрендә күрсәтелә. Шулай итеп,

$$ТЭП_р = Q_1P_1^0 + Q_2P_2^0 + ... + Q_nP_n^0 = \sum_{i=1}^{n} Q_iP_i^0, \qquad (11.3)$$

биредә P^0 — товарларның һәм хезмәт күрсәтүнең үзгәрешсез бәяләре (мәсәлән, 1991 елда).

Шулай итеп, номиналь һәм реаль ТЭПның төрле еллардагы зурлыкларын билгеләп, статистлар табылган нәтиҗәләр нигезендә һәр елда товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең гомуми дәрәҗәсен, ягъни бу товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәяләре индексын исәплиләр:

$$P_{\text{тэп}} = \frac{\text{ТЭП}_{\text{н}}}{\text{ТЭР}_{\text{р}}}, \qquad (11.4)$$

биредә $P_{\text{тэп}}$ — бирелгән елда илдә житештерелгән барлык ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең гомуми индексы. Илдә җитештерелгән барлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең гомуми индексын ТЭПның **индекс-дефляторы** яки кыскача **ТЭП дефляторы** дип атап йөрү кабул ителгән. Шуңа охшаш рәвештә милли исәп системасында ТМП, СМП бәяләре һәм башка күрсәткечләрнең индекслары һәм шулай ук ТЭПның аерым структура элементлары буенча халыкның куллану чыгымнары, инвестицияләре һ. б. ның бәяләре индекслары исәпләнә. Моңа ярашлы номиналь һәм реаль күрсәткечләр ТЭПка карата гына түгел, шулай ук ТМПга, милли керемгә, инвестицияләргә, халыкның куллану чыгымнарына яки дәүләт чыгымнарына һ. б. га кулланылырга мөмкин.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ (РЕЗЮМЕ)

Хәзерге вакытта бөтен дөньяда илдә җитештерелгән тулай милли продукт, тулай эчке продукт яки бу күрсәткечләрнең икесенең дә күләме билгеләнә. Бу — икътисадның гомуми хәле ничек, аның хәле яхшырамы яки начараямы, әлеге илдә халыкның уртача тормыш дәрәҗәсе нинди икәнен ачыклау өчен кирәк. ТМП һәм ТЭП турындагы мәгълүматлар буенча, төрле илләр икътисадларының халыкара чагыштырулары ясала.

Илдә җитештерелгән барлык продукциянең күләмен билгеләү өчен, барлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базар бәяләрендә күрсәтелергә тиеш. Илдә җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәяләре суммасы безгә икътисадның барлык тармаклары җитештергән продукциянең күләмен бирә.

Милли икътисад эшчәнлегенең гомуми нәтиҗәсе ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең генә бәяләре суммасы белән күрсәтелергә тиеш. Аларга халыкның шәхси ихтыяҗ-

ларын канәгатьләндерү максатында сатып алына торган, фирмалар үз капиталын инвестицияләгән (производство биналары, җиһазлар һ. б.), төрле дәүләт органнары сатып алган, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең саф экспорты булып күрсәтелгән продукция керә.

Билгеле бер илнең җитештерү факторлары тарафыннан җитештерелгән барлык ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре суммасы тулай милли продукттан гыйбарәт. Әгәр элеге ил ТЭПыннан бу ил җитештерү факторлары белән чит илдә булдырылган керемнәрне алсак, һәм чит ил кешеләренә караган җитештерү факторлары белән булдырылган керемнәрне кушсак, табылган нәтиҗә тулай эчке продуктның күрсәткече була.

ТМП кебек, ТЭП та ике метод белән исәпләнә: 1) кулланучыларның, дәүләтнең һәм фирмаларның товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә түләнгән ахыргы чыгымнарның суммасын табу юлы белән һәм 2) читләтеп алынган салымнарны да кертеп, барлык төр фактор керемнәренең суммасын табу юлы белән.

Икътисадның һәр тармагы ТЭП җитештерүгә үз өлешен кертә. Ул бу тармакның башка фирмалар китергән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләүгә киткән чыгымнарны алганнан соң калган тулай продукциясе күләменә тигез. ТЭП җитештерүдә тармакның бу кертеме өстәлгән кыйммәт дип атала.

ТЭП җитештерү процессында биналар һәм корылмалар, машиналар һәм җиһазлар туза (амортизация була). Шуңа күрә барлык фирмалар, һәр ел саен биналар һәм җиһазларның күрсәтелгән тузуларын каплау өчен, акчалар бүлеп калдыралар. ТМПдан амортизация акчаларын алганнан соң калган өлеш саф милли продукт (СМП) була.

Икътисадта булдырылган милли керемнең күләмен табу өчен, СМПдан читләтеп алынган салымнарның гомуми суммасын алырга кирәк.

Теләсә кайсы җәмгыять тормышында милли керемне бүлү зур роль уйный. Аның бүленеше нигезендә җитештерү факторларының бәяләре ята.

Илдә булдырылган милли керем фактор керемнәренең суммасына тигез. Икътисадта, фактор керемнәрен формалаштыру һәм бүлү белән беррәттән, керемнәрне яңадан бүлүләр бара, аның нәтиҗәсендә икенчел керемнәр барлыкка килә.

Аерым алганда, милли керемне яңадан бүлгәндә, дәүләт бюджеты зур роль уйный, бу шуның аркасында килеп чыга. Йорт хуҗалыкларына түләнә торган фактор һәм икенчел керемнәрнең гомуми суммасы аларның тулаем шәхси керемнәрен хасил итә.

Тулаем шәхси керемнән дәүләт шәхси керем салымын һәм шуңа охшаш турыдан-туры алынучы шәхси салымнарны, һәм шулай ук социаль страховкалауга калдырылган акчаларны ала. Турыдан-туры алынучы шәхси салымнарны һәм социаль страховкалау буенча аерып калдырылган акчаларны алганнан соң калган шәхси керем суммасы кулга кергән керем була, ягъни йорт хуҗалыклары карамагына фактта кергән керемнәр.

ТМП, ТЭП, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү күләменең башка күрсәткечләрен, шулай ук милли керем һәм керемнәрнең башка төрләрен агымдагы бәяләрдә, һәм шулай ук үзгәрешсез бәяләрдә белдерергә мөмкин. Агымдагы бәяләрдә белдерелгән ТЭП номиналь ТЭП дип атала. Үзгәрешсез бәяләрдә белдерелгән ТЭП реаль ТЭП дип атала. Реаль ТЭПның күрсәткече бәяләрнең үзгәрешенә бәйле түгел, һәм шуңа күрә ул ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү күләменең артуы яки кимүенең фактик зурлыкларын чагылдыра. Бәяләр үскән (яки кимегән) вакытта номиналь ТЭП продукция җитештерү күләменең күрсәткече булып хезмәт итә алмый.

❓ *Контроль сораулар һәм биремнәр*

1. Күмер чыгару, тегү, азык-төлек сәнәгате җитештергән продукция күләмен һәм чәчтарашханәләр хезмәт күрсәтүләрен үзара ничек чагыштырырга була?
2. Нәрсә ул арадаш һәм ахыргы товарлар?
3. ТМП һәм ТЭПны чагыштырыгыз; кайсы очракта ТМП ТЭПка караганда зуррак, ә кайчан, киресенчә, ТЭП ТМПга караганда зуррак булуын билгеләгез.
4. Икътисадта нинди төр чыгымнар нигезендә ТМП һәм ТЭП исәпләнә, аларны санап китегез; нинди төр фактор керемнәре нигезендә ТМП һәм ТЭП исәпләнә, санап китегез.
5. Өстәлгән кыйммәт нидән гыйбарәт?
6. Саф милли продукт нәрсә ул?

7. Милли керем ничек исәпләнә?
8. Дәүләт бюджеты керемнәренең структурасын карап тикшерегез, турыдан-туры һәм читләтеп алынган салымнарның төп үзлекләрен чагыштырыгыз, алар бер-берсеннән нәрсә белән аерылалар?
9. Дәүләт бюджеты чыгымнарының структурасын карап тикшерегез. Трансферт түләүләре товар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләнгән дәүләт чыгымнарыннан нәрсә белән аерылуын күрсәтегез.
10. Тулаем шәхси керемнең күләме ничек исәпләнә? Тулаем шәхси керемне билгеләгәндә, булдырылган керемнән нинди акчалар тотып калынырга тиеш һәм аны исәплəгәндә, нинди керемнәр исәпкә алынырга тиеш?
11. Кулга кергән керемнең күләмен билгеләү өчен, тулаем шәхси керемнән нинди акчалар тотып калынырга тиеш?
12. Кайсы очракта реаль ТЭП номиналь ТЭПка тигез булуын, кайчан беренчесе кимрәк, ә кайчан зуррак булуын күрсәтегез.

12 нче бүлек

МАКРОИКЪТИСАДИ ТИГЕЗЛӘНЕШ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җавап табарсыз:

✦ куллану керемгә ничек бәйләнгән һәм куллануга иң чик хирыслык нәрсәдән гыйбарәт;
✦ куллану функциясе нәрсәдән гыйбарәт һәм аның графигы нинди була;
✦ милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсе ничек билгеләнә;
✦ саклык акчалар ничек формалаша, гомуми һәм индуцияләнгән саклык акчалар нидән гыйбарәт;
✦ ни өчен икътисадның тигезләнеш халәтендәге шартларда гомуми саклык акчалар автоном инвестицияләр һәм дәүләт чыгымнарының суммасына тигез булырга тиеш һәм ни өчен индуцияләнгән саклык акчалар автоном чыгымнарның гомуми суммасына тигез булырга тиеш;
✦ нәрсә ул мультипликатор;
✦ процент ставкаларының үзгәреше ничек итеп автоном чыгымнар үзгәрешенә тәэсир итә һәм *IS* кәкресе нәрсәне күрсәтә;
✦ процент ставкаларының үзгәреше ничек итеп акчага булган сораугa тәэсир итә һәм *LM* кәкресе нәрсәдән гыйбарәт;
✦ *IS-LM* моделе нәрсәдән гыйбарәт һәм гомуми макроикътисади тигезләнеш нәрсәне аңлата.

Моннан алдагы бүлектә без ТМП (яки ТЭП) структурасының шактый дәрәҗәдә катлаулы булуын ачыклаган идек. Игътибарлы булсагыз, бу структураның төрле элементлары арасында тыгыз үзара бәйләнеш булуын искәрткәнсездер.

Мәсәлән, халыкның шәхси куллану чыгымнары керем күләменә бәйсез була алмый, инвестицияләр амортизация өчен аерып калдырылган акчалар зурлыгына, табышка һ. б. га бәйле.

Әгәр илдә житештерелгән товар һәм хезмәт күрсәтүләргә сорау аларны тәкъдим итүгә тигез булса, ягъни базар икътисадының бу ике ягы арасында тигезләнешкә ирешелгән булса, теләсә нинди икътисади система уңышлы эшләячәк һәм үсәчәк. Бу бүлектә безнең бурыч — бөтен икътисад масштабында гомуми тигезләнеш нәрсәдән гыйбарәт булуын ачыклау.

3 нче һәм 5 нче бүлекләрдә без инде сорау һәм тәкъдим тигезләнеше проблемасына мөрәҗәгать иткән идек. Без анда индивидуаль товар яки хезмәт күрсәтүләр базарындагы сорау һәм тәкъдим тигезләнешенә караган сорауларны тикшердек. Хәзер безнең бурыч бөтен икътисад масштабында гомуми тигезләнеш, ягъни макроикътисади тигезләнешнең нәрсәдән гыйбарәт булуын, нинди шартларда бу тигезләнешкә ирешүне һәм икътисадның тигезләнеш хәлен нинди факторлар билгеләвен ачыклау тора.

12.1. КЕРЕМ, КУЛЛАНУ ҺӘМ САКЛЫК АКЧАЛАР. КУЛЛАНУ ФУНКЦИЯСЕ

Тормышта сез һәр көн саен диярлек гаилә әгъзаларыгыз алган зуррак керемнең төрле товарлар күбрәк сатып алырга, ешрак кинога, стадионнарга һ. б. йөрергә мөмкинлек бирү факты белән очрашып торасыз. Азрак керем, киресенчә, кешеләрне товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү чыгымнарын чикләргә, кулلануларны киметергә мәҗбүр итә.

Куллану үсешенең керем артуына бәйлелеген җентеклəбрәк тикшерик.

Автоном куллану

Теләсә кайсы кешенең, аның бөтен гаиләсенеке кебек үк, билгеле бер минималь куллану чиге бар. Шундый чик буларак, яшәү өчен кирәк булган минимумны, ягъни кешенең иң мөһим ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүче товар һәм хезмәт күрсәтүләр җыелмасы кыйммәтен исәпләргә мөмкин. Күп очракта, әгәр керем яшәү минимумыннан түбәнрәк булып

чыкса һәм ул түбәнәя барса, куллану элекке дәрәҗәдә саклана. Бу очракта йорт хуҗалыклары үзләренең куллану чыгымнарын элегрәк җыйган саклык акчалар, кредитка сатып алынган товарлар һ. б. хисабына каплыйлар. Бу хәл аерым йорт хуҗалыкларына гына түгел, ә бәлки бөтен ил халкына карый. Шулай итеп, без мондый нәтиҗә ясый алабыз: халыкның куллану чыгымнарының бер өлеше яки аның кулланулары керем зурлыгына бәйле түгел.

> Халыкның куллану чыгымнарының бер өлеше яки аның милли керем зурлыгына бәйле булмаган куллануының бер өлеше АВТОНОМ КУЛЛАНУ дип атала.

Индуцияләнгән куллану

Халыкның куллану чыгымнарының икенче өлеше керем күләме белән турыдан-туры бәйлелектә тора. Керемнең үсеше йорт хуҗалыкларының күбрәк һәм дә сыйфатлырак товар алуларына һәм хезмәт күрсәтүнең киң ассортиментыннан файдалануына китерә. Билгеле инде, кулланунын бу өлешен дә тулаем алганда барлык икътисадныкы дип карарга мөмкин, ягъни илдәге куллану чыгымнарының бу өлеше тулысы белән милли керемнең күләменә бәйле.

> Халыкнын керем күләменә бәйле һәм милли керем үзгәрү белән үзгәрә торган куллану өлеше ИНДУЦИЯЛӘНГӘН КУЛЛАНУ дип атала.

Саклыкка куюю

Йорт хуҗалыклары алган барлык керемнәр дә куллануга тотылмый. Әгәр икътисадның хәле яхшы булса һәм күпчелек йорт хуҗалыклары мул тормыш белән яшәсәләр, табылган керемнең билгеле бер өлешен йорт хуҗалыклары саклыкка җыя. Димәк, аларның керемнәре ике өлешкә: 1) куллану һәм 2) саклык өлешләренә бүленә. Керемнең куллануга һәм җыелуга болай бүленеше теге яки бу индивид яки гаиләнең нинди

төр керем — хезмәт хакы, дивиденд, рента яки теләсә нинди башка төр керем алуына бәйләнмәгән. Шулай итеп, милли керем дә шундый ук куллану һәм җыелу өлешләренә бүленә.

Куллануга иң чик хирыслык
һәм саклыкка куюга иң чик хирыслык

Керемнең артымы куллануның һәм саклыкка җыюның артымын күздә тота. Моннан соңгы анализда йорт хуҗалыкларының артымның күпме өлешен куллануга тотарга, күпме өлешен саклыкка куюга хирыслыгын ачыклау зур роль уйнаячак. Шуңа күрә безгә ике мөһим төшенчә кертергә кирәк: куллануга иң чик хирыслык һәм саклыкка куюга иң чик хирыслык.

> Куллану артымының керем артымына чагыштырмасы КУЛЛАНУГА ИҢ ЧИК ХИРЫСЛЫК дип атала; саклыкка кую артымының керем артымына чагыштырмасы САКЛЫККА КУЮГА ИҢ ЧИК ХИРЫСЛЫК дип атала.

Барлык бу билгеләмәләр математик формада җиңел белдерелә. Мондый тамгаланышлар кертик: милли керем — Q; куллану — C; саклыкка куюлар — S; керем артымы, куллану артымы һәм саклыкка кую артымы тиңдәшле рәвештә ΔQ, ΔC һәм ΔS; куллануга иң чик хирыслык — c һәм саклыкка куюга иң чик хирыслык — s.

Ул вакытта милли керем куллану һәм саклыкка куюның суммасы буларак күрсәтелергә мөмкин:

$$Q = C + S. \tag{12.1}$$

Тиңдәшле рәвештә милли керемнең артымы саклыкка кую һәм куллану артымнарының суммасына тигез:

$$\Delta Q = \Delta C + \Delta S. \tag{12.2}$$

Куллануга иң чик хирыслык мондый тигезлек белән күрсәтелергә мөмкин:

$$c = \frac{\Delta C}{\Delta Q}, \tag{12.3}$$

ә саклыкка куюга иң чик хирыслык түбәндәге тигезлек белән бирелә:

$$s = \frac{\Delta S}{\Delta Q}. \qquad (12.4)$$

(12.2) тигезлегенең сул һәм уң якларын ΔQ га (милли керем зурлыгына) бүлеп табабыз:

$$\frac{\Delta Q}{\Delta Q} = \frac{\Delta C}{\Delta Q} + \frac{\Delta S}{\Delta Q}, \quad 1 = c + s. \qquad (12.5)$$

(12.5) тигезлеге буенча, саклыкка куюга иң чик хирыслык белән кулланугa иң чик хирыслыкның суммасы бергә тигез. Моннан шул беленә: кулланугa иң чик хирыслык — керем артымының кулланылу, ә саклыкка куюга иң чик хирыслык аның саклана торган өлешен күрсәтә.

Бу тигезлекләрне түбәндәге мисалда күрсәтик. Милли керемнең артымы — 1000 млн сум, куллану артымы 800 млн сум дип күзаллыйк. Моннан

$$c = \frac{800 \text{ млн сум}}{1000 \text{ млн сум}} = 0{,}8;$$

$$s = \frac{200 \text{ млн сум}}{1000 \text{ млн сум}} = 0{,}2$$

$$\text{һәм } c + s = 1.$$

Икътисад үсеше һәм милли керем артуы белән кулланугa иң чик хирыслык ничек итеп үзгәрә икән дигән мәсьәлә социаль тикшерүне таләп итә һәм икътисад проблемалары белән безнең беренче танышлыгыбыз кысаларыннан чыгып китә. Алга таба без керем артымы һәм куллану артымы арасындагы чагыштырмаларның иң гади вариантыннан чыгып эш итәрбез, атап әйткәндә: без c (кулланугa иң чик хирыслык), димәк, s та (саклыкка куюга ин чик хирыслык) үзгәрешсез кала дип уйларбыз. Башкача әйткәндә, гомуми куллануның милли керемгә чагыштырмасы кулланугa иң чик хирыслыкка тигез, ә гомуми саклыкка куюның милли керемгә чагыштырмасы — саклыкка куюга иң чик хирыслыкка тигез; ягъни

$$\frac{C}{Q} = \frac{\Delta C}{\Delta Q} = c; \quad \frac{S}{Q} = \frac{\Delta S}{\Delta Q} = s. \qquad (12.6)$$

Хәзер без куллануның керемгә функциональ бәйлелеген чагылдыручы тигезләмәне чыгара алабыз. Куллануның гомуми күләме автоном һәм индуцияләнгән кулланулардан тора. (12.3) һәм (12.6) тигезләмәләре буенча индуцияләнгән куллану cQ тапкырчыгышы рәвешендә күрсәтелергә мөмкин. Ул вакытта гомуми куллану C ны автоном куллану C_a белән индуцияләнгән куллану cQ ның суммасы буларак күрсәтергә була, ягъни

$$C = C_a + cQ. \qquad (12.7)$$

(12.7) тигезләмәсе **куллану функциясе** дип атала. Ул тигезләмә автоном куллануның милли керем Q ның үзгәрешенә бәйле булмавын күрсәтә, һәм иң башта без автоном куллану даими дип исәплибез; моннан тыш, ул индуцияләнгән куллану cQ милли керем Q ның үзгәрешенә туры пропорциональ булуын дәлилли. Пропорциональлек коэффициенты булып c зурлыгы — куллануга иң чик хирыслык хезмәт итә.

Хәзер 12-1 таблицасындагы гипотетик мәгълүматларны тикшерүгә кайтыйк: ул таблицада куллану һәм саклык акчалар үсешенең милли керем үсешенә бәйлелеге күрсәтелә. Таблицадан күренгәнчә, автоном куллану 400 гә тигез, куллануга иң чик хирыслык — 0,8 һәм саклыкка куюга иң чик хирыслык — 0,2. Алга таба милли керем 0 дән 1000 гә кадәр, аннан соң 2000 гә кадәр һ. б. үсә дип күзаллана.

12-1 таблицасы

Куллану һәм саклыкка кую үсешенең керем үсешенә бәйлелеге, шартлы берәм.

№	Керем (Q)	Куллану			Саклык акчалар ($S = Q - C$)
		автоном (C_a)	индуцияләнгән (cQ)	гомуми ($C + c_aQ$)	
0	0	400	0	400	−400
1	1000	400	800	1200	−200
2	2000	400	1600	2000	0
3	3000	400	2400	2800	200
4	4000	400	3200	3600	400

12.1. Керем, куллану һәм саклык акчалар.

Милли керемнең бу үсеше индуцияләнгән кулланунын 0 дән 800 гә кадәр, аннан соң 1600 гә кадәр һ. б. үсүенә китерә. Нәтиҗәдә гомуми кулланунын зурлыгы 0 нче периодта 400 гә тигез (автоном кулланута), 1 нче периодта ул 1200 гә кадәр үсә; 2 нче периодта — 2000 гә кадәр һ. б.

Хәзер икътисадның тигезләнештә булу мәсьәләсенә тукталыйк.

Икътисадның тигезләнеш хәлендә булмавы һәм тигезләнеш хәлендә булуы

Милли керем нульгә тигез дигән (бөтенләй реаль булмаган) күзаллауны калдырып торып, $Q = 1000$ шартлы берәмлек булган очракны тикшерик. (12.7) тигезләмәсе буенча, бу очракта гомуми куллану 1200 (800 + 400) гә тигез. Димәк, моның буенча халык 1000 гә тигез керем алып, кулланута 1200 ен тотарга җыена, ягъни товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү күләменә караганда 200 гә күбрәк. Товар һәм хезмәт күрсәтүләргә сорауны халык алдарак җыелган саклык акчалары хисабына яки кредитка товар сатып алу хисабына капларга җыена. Шуның аркасында саклык акчалар нульдән кимрәк (−200). Илдә җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә гомуми тулаем сорау аларның тулаем тәкъдименнән зуррак булып чыга. Тулаем сорауның тулаем тәкъдимнән артып китүе икътисадның тигезләнештә булмаган халәттә торуын аңлата һәм, димәк, аның хәле тотрыклы түгел: базарларда гомуми дефицит ситуациясе чыгып тора, барлык товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең артуы күзәтелә (инфляция булып тора). Фирмалар товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүен киңәйтергә омтылалар, ләкин алар, саклык акчалар тискәре зурлыкта булганлыктан, инвестицияләрне финанслау проблемасы белән очрашалар.

Ә хәзер икенче вариантны, $Q = 3000$ булган очракны тикшерик. Бу очракта автоном куллану элеккечә 400 гә тигез булыр, ә кулланута индуцияләнгән чыгымнар 2400 гә тигез. Димәк, тулаем алганда, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында кулланучылар соравы 2800 не тәшкил итәчәк — бу тулаем тәкъдимнән кимрәк. Бу очракта икътисад шулай ук тигезләнеш хәлендә булмый, ләкин бу тигезләнештә булмауның табигате капма-каршылыклы, хәзер товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең тәкъдиме аларга булган сораудан артып китә,



12-1 нче рәсем. △

Йорт хуҗалыклары, куллану ихтыяҗлары өчен керемнәренә караганда зуррак суммада акча тотарга ниятләгән булганлыктан, икътисад тигезсезлек хәлендә торса, халык чыгымнарының бер өлеше товарларны бурычка (кредитка) алу хисабына яки алдагы еллар эчендә җыелган саклык акчалар хисабына каплана. Ул вакытта «тискәре саклык акчалар» пәйда була. Әгәр инде икътисадта тигезсезлек йорт хуҗалыклары куллану ихтыяҗлары өчен керемнәренә караганда кимрәк суммада акча тотарга ниятләгәнлектән килеп чыкса, аларның керемнәренең бер өлеше саклыкка кала. Саклыкка калган өлеш уңай зурлыкта була.

бәяләр төшү тенденциясе туа, икътисадта саклык акчалар пәйда булса да: $Q - C = 3000 - 2800 = 200$, фирмалар житештерүне киметәләр. Шулай итеп, бу очракта да икътисадтагы тигезсезлек аның тотрыксызлыгын китереп чыгара.

Ниһаять, $Q = 2000$ булган очракны карап тикшерик. Бу вариант буенча, йорт хуҗалыклары, 2000 гә тигез тулаем керем алып, куллану хаҗәтләре өчен бу керемнең барысын да тотарга ниятлиләр. Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тигезләнеш халәте урнашса, сорау тәкъдимгә тигез була, бәяләрнең үсү тенденциясе күзәтелми, фирмалар товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерү күләмен үзгәртергә ниятләмиләр.

> Товар һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем сорау зурлыгы товар һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем тәкъдим зурлыгына тигез булган милли керем дәрәҗәсе МИЛЛИ КЕРЕМНЕҢ ТИГЕЗЛӘНЕШ ДӘРӘҖӘСЕ дип атала.

Куллану функциясен график рәвешендә дә күрсәтергә мөмкин (12-2 рәс.). Графикта горизонталь күчәр (абсциссалар күчәре) — милли керем дәрәҗәсен (Q), вертикаль күчәр (ординаталар күчәре) куллану чыгымнары дәрәҗәсен (C) күрсәтә. Графикта ике сызык бар: 1) керем сызыгы, ул координаталар күчәренә 45° лы почмак белән үтә; бу сызыктагы һәр нокта милли керем белән халыкның гомуми куллану чыгымнары тигез икәнен дәлилли, ягъни милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсен



12-2 нче рәсем. ▷ **Куллану функциясе графигы.** *Куллану функциясе сызыгы куллану чыгымнарының керем артуга бәйле үсүен күрсәтә. Керем 2000 нән кимрәк булганда, кулланучылар товар һәм хезмәт күрсәтүләргә җитештерелгән керемгә караганда күбрәк сумманы тотарга ниятлиләр. Керем 2000 гә тигез булганда, халыкның товар һәм хезмәт күрсәтүләргә соравы аларның тәкъдименә тигез булып чыга. E_1 ноктасы — икътисадның тигезләнеш халәте ноктасы. Алга таба керемнең үсеше керем дәрәҗәсе белән куллану дәрәҗәсе арасындагы аерма хасил булуга һәм аның артуына китерә.*

чагылдыра; 2) (12.7) тигезләмәсе белән билгеләнгән куллану функциясенең графигы булып торган сызык. Милли керем нульгә тигез булса, куллану дәрәҗәсе автоном куллануга — 400 гә тигез булыр иде, моны ординаталар күчәрендәге тиңдәшле нокта күрсәтә. E_1 ноктасы, керем 100 гә тигез булганда, кулланучыларның 1200 не тотарга ниятләвен күрсәтә; бу нокта куллану функциясе графигында керем сызыгы өстендә урнаша. Керем һәм куллану функциясе сызыклары арасындагы ераклык дефицитның зурлыгын күрсәтә. Куллану функциясе графигы белән керем сызыгы (E_0) кисешү ноктасының координаталары $Q = 2000$ һәм $C = 2000$. Бу нокта һәм бары шул нокта гына милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсен күрсәтә. Керемнең киләсе артуы керем сызыгында теләсә кайсы ноктаның куллану функциясе сызыгындагы тиңдәшле ноктадан өстәрәк урнашкан булуына китерә. Моннан булдырылган керемнең кулланучылар чыгымыннан кимрәк булуын күрәбез; базарда товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр кирәгеннән артык булып чыга (бу артыклыкның зурлыгын тиңдәшле нокталар арасындагы ераклык күрсәтә); ниһаять, керемнең тагы да үсүе керем сызыгы белән куллану функциясе сызыгы арасындагы аерманың үсүенә китерә һәм, шулай итеп, товар артыклыгы тагын да үсә.

Хәзер игътибарны шул фактка юнәлтик: куллану функциясе, саклык акчалар нульгә тигез булганда, икътисадның тигезләнеш халәтенә ирешелүен күздә тота. Бер яктан, бу — уңай күренеш: милләт бурычка яшәүдән, алдарак җыелган саклык акчаларны, үзенең милли байлыгын ашап бетереп барудан туктый. Ләкин, икенче яктан, монда тискәре моментны күрсәтмичә булмый — саклык акчалар яңа инвестицияләрне финанслау чыганагы булып тора, һәм алар нульгә тигез булса, бу чыганак юкка чыга. Шуның аркасында икътисад үзенең үсеше, товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүне арттыру, яңа технологияләргә күчү һ. б. өчен мөһим шартны югалта.

12.2. САКЛЫК АКЧАЛАР ҺӘМ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР

Моннан алдагы бүлектә ТЭПның бер өлеше биналар, корылмалар, машиналар һәм җиһазлардан гыйбарәт булуын, ягъни фирмалар һәм йорт хуҗалыклары алган керемнәрнең бер өлеше шул товарларга инвестицияләнгәнен күргән идек. Хәзер без мөһим төгәллек кертә алабыз — инвестицияләрнең чыганагы

булып барлык керемнәр түгел, ә керемнең саклыкка җыела торган өлеше хезмәт итә. Саклык акчаларны формалаштыру һәм аларны алга таба инвестицияләү өч төп канал буенча бара.

Саклык акчаларны формалаштыру

1. Эре фирмалар (алар башлыча акционерлар компанияләре) табыш алгач, аны ике өлешкә бүләләр: аның бер өлешен алар процентлар һәм дивидендлар рәвешендә акцияләр һәм облигацияләр хуҗаларына түлиләр; табышның икенче өлеше бүленми торган табыштан гыйбарәт, ул яңа биналарга, җиһазларга һ. б.га инвестицияләнә. Бүленмәгән табыш, асылда, фирмаларның саклык акчалары була, андый табышлар аларның предприятиеләрен киңәйтүгә салына.

2. Теләсә нинди илдәге милли керемнең шактый өлеше кече эшмәкәрләрнең керемнәре белән күрсәтелә. Соңгылары үзләре житештергән товар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатканнан соң алган керемнәренең бер өлешен шәхси ихтыяжларына, ә икенче өлешен үз предприятиеләрен инвестицияләү өчен тоталар.

3. Милли керемнең күбрәк өлеше йорт хуҗалыклары керемнәренең төрле формаларын ала: бу хезмәт хакы, дивидендлар, процентлар һ. б. Йорт хуҗалыклары шулай ук куллану ихтыяҗлары өчен барлык керемнәрен дә тотмыйлар. Барлыкка килгән саклык акчаларны алар кыйммәтле кәгазьләргә алыштыралар (акцияләр һәм облигацияләр), банкларга саклыкка салалар, страховкалау компанияләренең полисларын сатып алалар. Нәтиҗәдә сәнәгать һәм сәүдә фирмалары, банклар һәм страховкалау компанияләре йорт хуҗалыкларының саклык акчаларын үзләренә тарталар, бу үз чиратында аларга өлеге саклык акчаларны товарлар, сәүдә, транспорт һ. б. ны җитештерү өчен инвестицияләргә мөмкинлек бирә.

Саклык акчаларны мобилизацияләү нәтиҗәсендә, кулдагы акчалар капиталына ия булып, фирмалар җитештерү факторларына теге яки бу күләмдәге яңа инвестицияләр планлаштыралар. Шуңа күрә алдагы параграфта без карап киткән тулаем сорау артымы йорт хуҗалыкларының куллану чыгымнарына гына кайтып калмый. Тулаем сорау товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында фирмаларның инвестиция товарларына соравын да үзенә ала. Куллануга аналогик рәвештә, икътисад теориясе инвестицияләрне автоном һәм индуцияләгән төрләргә аера.

Автоном һәм индуцияләнгән инвестицияләр

Автоном инвестицияләр — ул инвестицияләрнең керемнең күләменә бәйле булмаган бер өлеше. Күпчелек фирмалар сату базарын киңәйтү, көндәшлек сәләтен ныгыту, мораль яктан искергән җиһазларны яңаларына алыштыру максатында, капиталны яңа технологияләргә инвестициялиләр; халык саны арту да яңа инвестицияләргә ихтыяҗлык туугa сәбәпче була. Шуңа күрә билгеле бер дәрәҗәдә инвестицияләр фирмаларның нинди табыш алуына, кече предприятиеләрнең нинди керем алуына бәйле түгел. Барлык икътисад масштабында бердәм инвестицияләр, тулаем алганда, милли керем күләме зурлыгына бәйле түгел дип уйлый алабыз.

Индуцияләнгән инвестицияләр, моннан аермалы буларак, керем күләменә функциональ бәйлелектә була. Ләкин әлеге этапта бу мөһим сорау факторын тикшерүдән читкәрәк китеп торырбыз.

Ә хәзер автоном инвестицияләрнең ничек итеп икътисадның тигезләнеш торышына йогынты ясавын ачыклыйк. Шуңа бәйле рәвештә 12-1 таблицасында китерелгән гипотетик мәгълүматларны тикшерүгә кире кайтыйк, һәм таблицага тагын ике багана — автоном планлаштырылган инвестицияләрне һәм тулаем сорауны өстик, шулай ук күздә тотылган милли керем дәрәҗәләре санын арттырыйк.

12-2 таблицасы

Керем, куллану, саклык акча һәм инвестицияләр, шартлы берәм.

№	Керем (Q)	Куллану			Саклык акча (S = Q − C)	Автоном инвестицияләр	Тулаем сорау ($C_a + I_a + cQ$)
		автоном (C_a)	индуцияләнгән (cQ)	гомуми (C_a + cQ)			
0	0	400	0	400	-400	400	800
1	1000	400	800	1200	-200	400	1600
2	2000	400	1600	2000	0	400	2400
3	3000	400	2400	2800	200	400	3200
4	4000	400	3200	3600	400	400	4000
5	5000	400	4000	4400	600	400	4800

Хәзер инде товар һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем сорау халыкның шәхси куллану чыгымнары белән автоном инвестицияләрнең суммасына тигез була. Хосусый сектор ягыннан

әлеге товар һәм хезмәт күрсәтүләргә сорау, яки тулаем сорау суммасын (AD)[1] не түбәндәге тигезлек рәвешендә күрсәтергә була:

$$AD = C_a + cQ + I_a$$

яки

$$AD = (C_a + I_a) + cQ. \qquad (12.8)$$

Автоном чыгымнар

Тулаем сорауны куллану чыгымнары һәм инвестицияләрнең суммасы рәвешендә генә түгел, бәлки, беренчедән, автоном куллану һәм автоном инвестицияләр суммасы рәвешендә дә һәм, икенчедән, индуцияләнгән куллану буларак күрсәтергә була. Автоном инвестицияләрне һәм автоном кулллануны бер күрсәткечкә берләштереп, үзебезнең тикшерүгә без мөһим төшенчә — **автоном чыгымнарны** кертик. Автоном кулллануны һәм автоном инвестицияләрне бер күрсәткечкә кушу өчен нигез булып торган гомуми үзлек — аларның җитештерелгән милли керем күләменә бәйле булмавы. (12.8) тигезлеген без хәзер түбәндәгечә күрсәтә алабыз:

$$AD = A_p + cQ, \qquad (12.9)$$

биредә A_p — хосусый секторда автоном чыгымнар; AD — тулаем сорау.

12-2 таблицасын тикшерүгә кайтыйк.

Автоном инвестицияләрнең барлыкка килүе, билгеле бер милли керем булганда, тулаем сорау зурлыгын үзгәрүгә китерергән. Аерым алганда, әгәр 12-1 таблицасында керем 2000 булганда, куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә соравына тигез булган тулаем сорау 2000 не тәшкил иткән булса, ягъни тулаем сорау белән тулаем тәкъдимнең тигезләнешен тәэмин итсә, хәзер 2000 гә тигез милли керем 2400 лек тулаем сорауны күздә тота. Димәк, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тигезләнешнең булмавын исбат итә. Шул вакытта икътисадның тигезләнештә булмавы базар соравының тәкъдимнән артып китүендә генә түгел, ә бәлки инвестицияләрнең саклык акчалар күләменнән артуыннан күренә.

Бу очракта инвестицияләрне финанслау чыганагы булып чит ил заемнары һәм җыелган саклык акчалар торуы мөмкин.

---

[1] Инглиз сүзе aggregate *demand* дигәннән.



Икътисад тигезсезлек хәлендә була, чөнки йорт хуҗалыклары үз ихтыяҗлары өчен керемнәренә тигез булган сумманы тотарга омтылучан. Шуңа күрә фирмалар планлаштырган инвестицияләр тиешле саклык акчалар суммасы белән тәэмин ителмәгән. Димәк, $I_a + C_a + cQ$ суммасына тигез булган тулаем сорау Q зурлыгына, ягъни керемгә тигез тулаем тәкъдимнән зуррак.

Икътисад тигезлек хәлендә була, чөнки йорт хуҗалыкларының куллану ихтыяҗлары өчен планлаштырылган чыгымнары һәм фирмаларның планлаштырылган инвестицияләре тулаем алганда җитештерелгән керемгә тигез. Шул вакытта инвестицияләр саклык акчаларга тигез.

Икътисад тигезсезлек хәлендә була, чөнки керем, планлаштырылган куллану һәм планлаштырылган инвестицияләргә караганда күбрәк. Тигезсезлек торышы саклык акчалар суммасы инвестицияләр суммасыннан зуррак булганда да күренә.

12-3 нче рәсем. △

Инвестицияләрне кертү, йорт хуҗалыкларының тулаем чыгымнары (тулаем сорау) куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу белән генә чикләнмәвенә китерә. Хәзер йорт хуҗалыклары үз керемнәренең бер өлешен куллану товарларына тотарга, ә икенчесен, саклана торганын, җитештерү факторларына инвестицияләргә ниятлиләр. Ләкин икътисадта тигезләнеш хәле элеккечә йорт хуҗалыкларының планлаштырылган чыгымнары аларның керемнәренә тигез булган очракта гына ирешелә.

Автоном инвестицияләр кертү, автоном кулланууны арттыргандагы кебек, саклык акчаларның тискәре кыйммәтләрен 400 гә арттыруга китермәвен искәртеп китик. Моны болай аңлатырга була: инвестицияләрнең үсеше капитал җыелуга, яңа заводлар, транспорт чаралары, рестораннар һ. б. рәвешендә реаль активларның үсешенә китерә, ә инде кулланунын үсеше элегрәк җитештерелгән матди байлыкларны «ашап бетереп баруны» аңлата. Ләкин ничек кенә булмасын, икътисадның тигезсезлек торышында, $Q = 2000$ булганда, автоном инвестицияләр кертү дефицит килеп чыгуга, бәяләр үсүгә һәм башка күренешләргә китерде.

Милли керем 3000 гә кадәр үссә, хәл бераз яхшыра: дефицит кими, инвестицияләр һәм саклык акчалар арасындагы аерма 400 дән 200 гә кадәр төшә, ләкин икътисад элеккечә тигезсезлек хәлендә була. Милли керем 4000 гә кадәр житкәч кенә, аның тигезләнеш торышы ирешелә. Тигезләнеш хәзер элеккечә — тулаем сорау җитештерелгән милли керемгә тигез булганда ирешелә; моннан тыш, хәзер ул саклык акчаларның һәм планлаштырылган автоном инвестицияләрнең тигезлеген күздә тота; ягъни фирмалар үзләре мобилизацияләгән барлык саклык акчаларын предприятиеләрен киңәйтү һәм модернизацияләү өчен инвестицияләргә ниятлиләр.

Икътисадта тигезләнеш тагын бер мөһим тигезлекнең —

12-4 нче рәсем. ▷ Автоном инвестицияләр кертү нәтиҗәсендә автоном чыгымнар сызыгының күчүе.

Автоном инвестицияләрне автоном чыгым күрсәткечләренә кертү, $Q = 0$ булганда, автоном чыгымнар суммасының 400 дән 800 гә кадәр артуына китерде. Шул ук вакытта кулланута иң зур хирыслык элеккечә калды. Шуңа күрә керем үсеше һәм индуцияләнгән куллану үсеше арасындагы пропорциональлек коэффициенты үзгәрмәде: $c = 0{,}8$. Бу — автоном чыгымнар сызыгының өскә таба параллель итеп, ә тигезләнеш ноктасының уңга таба өскә E_0 торышыннан E_1 торышына күчүенә китерде.



индуцияләнгән саклык акчалар дип аталган автоном чыгымнар тигезлеге булуын күздә тота.

Моңа бәйле индуцияләнгән саклык акчаларның нидән гыйбарәт булуын карап тикшерик. Без саклык акчалар артымының керем артымына чагыштырмасы саклыкка иң чик хирыслыктан гыйбарәт булуын һәм (12.4) тигезлеге белән билгеләнгәнен күргән идек инде. Индуцияләнгән саклык акчалар милли керем белән саклыкка иң чик хирыслыкның тапкырчыгышына тигез:

$$S_i = sQ. \quad (12.10)$$

12-2 таблицасыннан, керем 1000 булганда, индуцияләнгән саклыкның $1000 \times 0{,}2 = 200$ булуын күрәбез; керем 2000 булганда, ул 400 гә тигез, ә керем 4000 булганда, $S_i = 800$. Икътисад тигезләнеш хәлендә булганда, индуцияләнгән саклык акчаларның автоном чыгымнарга тигез булуын ассызыклап үтик.

Шулай итеп, икътисадның тигезләнеш хәле өч шартның үтәлүен күздә тота:

1) $Q_e = (C_a + I_a) + cQ_e$,

2) $S_i = C_a + I_a$,

3) $S = I_a$,

биредә Q_e — милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсе.

Дәүләт чыгымнары һәм тигезләнеш

Хосусый секторларның барлык товар һәм хезмәт күрсәтүләрне дә сатып алмавын без күргән идек инде. ТЭПның шактый өлеше дәүләт түләгән товар һәм хезмәт күрсәтүләрдән гыйбарәт. Дәүләт сатып алган товар һәм хезмәт күрсәтүләрне кая кертергә: индуцияләнгән яки автоном чыгымнаргамы? Бу сорауга бертөрле генә җавап биреп булмый, билгеле. Ил баерак булган саен, анда җитештерелгән милли керем күбрәк була, дәүләт оборона ихтыяҗлары өчен дә, әйләнә-тирә мохитне саклауга да, һәм мәгарифне финанслауга да, һәм күп кенә башка максатлар өчен дә күбрәк акча тота ала. Дәүләт чыгымнарын индуцияләнгән чыгымнар категориясенә кертергә дә булыр иде кебек. Ләкин дәүләт бюджеты чыгымнары суммасына карата хөкүмәт яки Дума кабул иткән карарлар аны турыдан-туры милли керем күләме белән бәйләмиләр. Димәк, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга киткән дәүләт ассигнованиеләрен автоном чыгымнар категориясенә кертүгә

12-5 нче рәсем. ▷ Автоном чыгымнар сызыгының алга таба күчүе.

Дәүләт сатып алган 1000 сумлык товар һәм хезмәт күрсәтүләр автоном чыгымнарның гомуми суммасын 1800 гә кадәр арттыра. Бу — автоном чыгымнар сызыгының параллель рәвештә өскә күчүенә, ә тигезләнеш ноктасының тагын керем сызыгы буенча өскә таба уңга күчеп, гомуми чыгымнар (тулаем сорау) җитештерелгән милли керем зурлыгы белән тигезләшкәч туктавына китерә. Күрсәткечләрнең икесе дә 9000 гә тигез.



нигез бар. Шуңа күрә без шундый нәтиҗә ясый алабыз: хосусый һәм дәүләт секторларындагы автоном чыгымнарның гомуми күләме (A) автоном куллану, автоном инвестицияләр, товар һәм хезмәт күрсәтүләрне дәүләт сатып алуының (G) суммасына тигез:

$$A = C_a + I_a + G. \tag{12.11}$$

Тулаем сорау түбәндәге тигезлек белән билгеләнергә мөмкин:

$$AD = (C_a + I_a + G) + cQ = A + cQ. \tag{12.12}$$

Хәзер икътисадның тигезләнеш хәлендәге шартларда милли керемнең зурлыгы автоном чыгымнар белән индукцияләнгән куллану суммасына тигез:

$$Q_c = (C_a + I_a + G) + cQ_e = A + cQ_e. \tag{12.13}$$

Дәүләт чыгымнарын кертү нәтиҗәсендә, автоном чыгымнарның гомуми суммасы артуы милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсен күтәрә. Графикта бу автоном чыгымнарның сызыгы яңадан параллель рәвештә өскә, ә милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсе ноктасының керем сызыгы буенча сул якка өскә күчүендә чагыла. Бу үзгәрешләр 12-5 рәсемендә күрсәтелгән дә инде, ул рәсемнән күренгәнчә, товар һәм хезмәт күрсәтүләргә 1000 берәмлек дәүләт чыгымнары милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсенең 9000 гә кадәр үсешенә китерде.

Макроикътисади анализ өчен инглиз икътисадчысы Дж. М. Кейнс (1884—1946) тирәнтен өйрәнгән мультипликатор теориясе зур әһәмияткә ия.

12.3. МУЛЬТИПЛИКАТОР

Кабаттан 12-2 таблицасын тикшерүгә әйләнеп кайтыйк. Аннан күренгәнчә, инвестицияләр кертү нәтиҗәсендә автоном чыгымнарның үсүе милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсе үсешен тудыра: ул 2000 нән 4000 гә кадәр үсә. Бу вакытта $\frac{\Delta Q_e}{\Delta A}$ чагыштырмасы 5 кә тигез. Хәзер товар һәм хезмәт күрсәтүләрне дәүләт сатып ала башлый дип уйлыйк. Әйтик, ул 1000 гә тигез өстәмә сорау ясый, нәтиҗәдә автоном чыгымнар 800 дән 1800 гә кадәр үсә, ягъни автоном чыгымнарның артымы 1000 гә тигез була. Шуның аркасында милли керемнең тигез үлчәмле дәрәҗәсе яңадан күтәрелә һәм инде 4000 нән 9000 гә житә. Тагын шунысына игътибар итик: милли керем артымының автоном чыгымнар артымына чагыштырмасы янәдән бишкә тигез булды: $\frac{\Delta Q_e}{\Delta A} = \frac{5000}{1000} = 5$.

ΔQ_e белән ΔA чагыштырмасының даимилеге очраклы тәңгәл килүме әллә билгеле бер закончалыкмы? Хәзер менә шушы сорауга җавап бирик.

Алдарак әйтелгәнчә, куллану үсеше керемнәрнең үсешенә бәйләнгән. Шул ук вакытта бу күбрәк индуцияләнгән куллануга карый, чөнки аның артымы куллануга иң чик хирыслык белән бәйләнгән һәм $\frac{\Delta C}{\Delta Q} = c$ тигезлеге аша билгеләнә.

Хәзер керемнең артымы, куллануга иң чик хирыслык һәм автоном чыгымнар артымының нинди бәйләнештә булуын ачыклыйк. Моның өчен кабат (12.13) тигезлегенә кире кайтабыз. $AD = Q_e$ тигезлеге шартларында тулаем сорау тигез үлчәмле милли керемгә тигез. Димәк,

$$Q_e = A + cQ_e,$$

моннан

$$Q_e - cQ_e = A \text{ яки } Q_e(1 - c) = A,$$

$$Q_e = \frac{A}{1-c} = A \cdot \frac{1}{1-c}. \qquad (12.14)$$

$\frac{1}{1-c}$ вакланмасын k дип билгелик:

$$k = \frac{1}{1-c}. \qquad (12.15)$$

Әлеге *k* коэффициенты *мультипликатор* дип атала һәм аның ярдәмендә (12.13) тигезләмәсен түбәндәгечә язарга мөмкин:

$$Q_e = kA. \quad (12.16)$$

(12.16) тигезләмәсе шуны аңлата: милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе автоном чыгымнар белән мультипликатор тапкырчыгышына тигез һәм бу дәрәҗә автоном чыгымнар үсешенә туры пропорциональ рәвештә үзгәрә. Бу очракта мультипликатор пропорциональлек коэффициенты ролен үти. Гадәти шартларда куллануга иң чик хирыслык бирөмлектән кечерәк булганлыктан, бу шартларда мультипликатор һәрвакыт бирөмлектән зуррак була. Шуңа күрә мультипликаторга түбәндәгечә билгеләмә бирә алабыз:

МУЛЬТИПЛИКАТОР — милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе үсешенең автоном чыгымнар үсешеннән ничә тапкыр артыграк икәнен күрсәтә торган коэффициент ул.

Әгәр кабаттан 12-1 һәм 12-2 таблицаларында бирелгән мисалга әйләнеп кайтып, анда куллануга иң чик хирыслыкның 0,8 икәнен искә төшерсәк, бу очракта мультипликаторның $\frac{1}{1-0,8} = 5$ икәнен күрербез. Димәк, автоном чыгымнарның теләсә нинди артымы милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе артымының биш тапкыр артуына китерде; дөрестән дә, башта автоном инвестицияләр, ә аннан соң дәүләт чыгымнары кертелү нәтиҗәсендә автоном чыгымнар үсүе күренде.

Мультипликаторны башка юл белән дә исәпләп чыгарырга мөмкин.

Әйтик, автоном чыгымнарның бер элементы, мәсәлән инвестицияләр, 400 млн сумга арта, ди. Димәк, фирмалар яңа җиһазлар өчен шушы суммага капитал сала. Капиталны болай инвестицияләү — җиһазлар эшләп чыгаручы предприятиеләр бу җиһазларны сатудан 400 млн сум керем ала дигән сүз. Бу керемнең бер өлеше эшчеләргә хезмәт хакы рәвешендә түләнә, бер өлеше дивиденд формасын ала һ. б. Алынган керемнәр ике өлешкә бүленә: бер өлеше (0,8) куллануга тотыла, ә икенче өлеше (0,2) саклыкка салына. Шулай итеп, хезмәт хакы алучы эшчеләр, дивиденд алучы акционерлар һәм башкача керем

алучылар товар һәм хезмәт күрсәтүләргә 400 млн сум $\times$ 0,8 = = 320 млн сум белән чыга. Хәзер инде бу товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алынган фирмаларның кереме 320 млн сум була. Әлеге керемнең 0,8 е кулланылачак, ә 0,2 се саклыкка салыначак. Товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында чыгарылма сорауның икенче дулкыны 320 млн сум $\times$ 0,8 = 256 млн сум яки икенче төрле 400 млн сум $\times (0,8)^2$ булачак.

Бу эзлеклелекне тагын да дәвам итәргә мөмкин, тик гомуми мәгънә инде алда әйтелгәннәрдән үк аңлашыла: инвестицияләрнең яки теләсә нинди башка автоном чыгымнарның башлангыч артымы керемнәр артуны һәм шуның аркасында сорау үсешен китереп чыгара. Һәм инде керемнәрнең һәм сорауның һәрбер чираттагы артымы алдагысының 0,8 ен тәшкил итә. Димәк, автоном чыгымнарның нинди дә булса башлангыч артымы китереп чыгарган гомуми сорау түбәндәге сораута тигез була:

$$400 + 400 \times 0,8 + 400 \times 0,8^2 + 400 \times 0,8^3 + ... + 400 \times 0,8^n =$$
$$= 400\,(1 + 0,8 + 0,8^2 + ... + 0,8^n) =$$
$$= 400\frac{1}{1-0,8} = 400 \times 5 = 2000.$$

Сорауның автоном чыгымнар артымы тудырган тулы артымын гомуми рәвештә болай күрсәтәбез:

$$A + Ac + Ac^2 + ... + Ac^n = A \cdot (1 + c + c^2 + ... + c^n).$$

Әгәр n саны җитәрлек дәрәҗәдә зур һәм ул ∞ кә омтыла дип алсак, $(1 + c + c^2 + ... + c^n)$ аңлатмасы кими баручы геометрик прогрессиянең буыннары суммасын бирә, ягъни

$$AD = A \cdot \frac{1}{1-c} = k \cdot A. \qquad (12.16а)$$

Шулай итеп, мультипликаторның эффекты менә нидән гыйбарәт: теләсә нинди башлангыч капитал инвестицияләү, ягъни автоном чыгымнарның теләсә нинди артымы чыгарылма сорау артымнарының чылбыр реакциясен тудыра. Чыгарылма сорауның артымнары суммасы автоном чыгымнарның беренчел артымыннан берничә тапкыр зуррак. Икътисадта тигезләнешкә ирешү өчен, милли керем дәрәҗәсенең тулай сорауның ирешелгән дәрәҗәсенә җитүе кирәк.

Мультипликатор саф теоретик категория булып тоелса да, аның ярдәмендә икътисадның үсеш барышындагы баланслы-

лыгын бәяләргә, инвестицияләрне һәм дәүләт чыгымнарын арттырганда, ТЭПның нинди дәрәҗәгә ирешүе турында иң гомуми фаразлар ясарга мөмкин.

12.4. ТОВАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР БАЗАРЫНДА ТИГЕЗЛӘНЕШ ҺӘМ ПРОЦЕНТ СТАВКАСЫ. *IS* КӘКРЕСЕ

Әлегә кадәр без тигезләнеш проблемасын милли керемнең, куллануның һәм дәүләт чыгымнарының үзгәрүен исәпкә алып тикшердек. Ләкин базар икътисады шартларында бик зур рольне процент ставкасы уйный, бу зурлык кредитка бирелгән капиталның бер елда арткан процентлары суммасы белән бу капитал суммасының чагыштырмасына тигез. Ул күп очракларда инвестицияләр күләменә һәм халыкның куллану чыгымнарына сизелерлек йогынты ясый.

Иң элек процент ставкасы үзгәрешләренең ничек итеп инвестицияләр күләменә йогынты ясавын карап үтик.

Процент ставкасы һәм инвестицияләр

Шактый зур суммадагы акча капиталы булган нинди дә булса фирма бар дип фараз итик. Бу капиталны нәрсәләргә тотарга була икән? Беренчедән, фирма үз акчасын яңа җиһазлар өчен инвестицияләргә һәм яңа станок сатып алырга мөмкин. Моның белән фирма продукция эшләп чыгаруны арттыра һәм өстәмә табыш ала. Әмма, икенчедән, альтернатив вариант бар — фирма үз акчасын кыйммәтле кәгазьләргә, мәсәлән, дәүләт облигацияләренә салырга мөмкин.

Бу вариантларның кайсын сайлап алырга? Монысы инде күп кенә нәрсәләргә бәйләнгән. Тик теләсә кайсы фирманың менеджерлары беренче чиратта чагыштырып карыйлар: яңа җиһазга салынган инвестицияләр күбрәк табыш китерәме әллә кыйммәтле кәгазьләрдән (облигацияләрдән) килгән процентмы? Менеджерларның карары бераүдә дә шик тудырмый торгандыр — облигациягә салынганыннан күбрәк керем китерә икән, димәк, акча яңа җиһазларга салыначак; яңа җиһазларга салынган инвестицияләрдән зуррак керем кө телсә, акча облигацияләргә салыначак. Димәк, теләсә кайсы фирманың менед-

жерлары, башка барлык шартлар бертөрле булганда, процент ставкасы зурлыгы белән инвестицияләрнең эффектлылыгын чагыштыра. Мәсәлән, яңа җиһазларга салынган 100 мең сум инвестиция бер елга 24 мең сум: 100 мең сум = 24% була (12-3 табл.).

12-3 таблицасы

Процент ставкасы һәм инвестицияләр дәрәҗәсе

Инвестициянең тәртип номеры	Инвестициянең суммасы *I*, мең сум	Табыш *II*, мең сум	Инвестициянең эффективлылыгы *II/I*, %	Процент ставкасы, %		
				№ 1 вариант	№ 2 вариант	№ 3 вариант
1	100	24	24			
2	100	20	20			
3	100	16	16			
				5	10	15
4	100	12	12			
5	100	8	8			
6	100	4	4			

Хәзер кыйммәтле кәгазьләргә вкладлар (кертемнәр) буенча процент ставкалары 15% дип уйлыйк. Билгеле инде, бу очракта менеджерлар акчаны облигацияләргә түгел, җиһазларга инвестицияләргә тырышачак. Алай гына да түгел, кими баручы нәтиҗәлелек законына һәм шуннан яңа инвестицияләрнең эффектлылыгы түбәнәюгә карамастан, җиһазларга 2 нче һәм 3 нче инвестицияләр кыйммәтле кәгазьләрдән өстенрәк булып кала. Әмма 4 нче һәм аннан соңгы инвестицияләрнең дәрәҗәсе облигацияләргә караганда кимрәк булыр.

Шулай да процент ставкасы 10% ка кадәр төште дип уйлыйк. Бу очракта фирмалар 4 нче инвестицияләрне облигациягә түгел, ә җиһазларга салуны өстенрәк күрер, чөнки процент ставкасы 10% булганда, инвестицияләрнең эффективлылыгы югарырак — 12%. Әмма 5 нче тапкыр җиһазларга инвестиция салудан алар баш тартачак.

Шулай итеп, инвестиция сайлап алуга карата фирмаларның реакциясен тикшерү нигезендә, без, бер яктан, яңа җиһазларга, икенче яктан, процент ставкасына салынган инвестицияләр күләме арасында түбәндәге бәйлелекне чыгардык:

12.4. Товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тигезләнеш һәм процент ставкасы. IS кәкресе

әгәр ставка 15% булса, инвестиция күләме 300 мең сум;
әгәр ставка 10% булса, инвестиция 400 мең сум;
әгәр ставка 5% булса, инвестиция 500 мең сум.

Болардан күренгәнчә, процент ставкасының һәр 5 пунктка төшүе инвестицияләр дәрәҗәсен 100 мең сумга күтәрә бара, ягъни процент ставкасының бер берәмлеккә (яки пунктка) артымына инвестицияләрнең 20 мең сумга артымы туры килә. Шуңа күрә үзебез әле генә чыгарган инвестицияләрнең процент ставкасына бәйлелеге кагыйдәсен без барлык коммерция фирмалары, барлык икътисад өчен тәкъдим итә алабыз.

Инвестицияләрнең процентлы реакциясе

Инвестицияләр процент ставкасы үзгәрешләренә актив реакция ясый. Процент ставкасы төшүнең һәр пунктына туры килүче инвестиция үсеше **инвестицияләрнең процентлы реакциясе күрсәткече** дип атала. Безнең мисалда инвестицияләрнең процентлы күрсәткече −20 мең сум булды. Бу күрсәткеч — тискәре зурлык, чөнки процент ставкасының үсүе инвестицияләрнең кимүен китереп чыгара.

Инвестицияләрнең процент ставкасы үзгәрешләренә нинди реакция ясавын белгәндә, инвестицияләрнең процент ставкасына функциональ бәйлелеген күрсәткән тигезләмә чыгара алабыз.

Әгәр процент ставкасы нульгә кадәр төшсә, инвестицияләр I_0 гә тигез булыр иде, дип уйлыйк. Инвестицияләрнең процентлы реакциясе зурлыгын — I_i, ә процент пунктлары саны белән күрсәтелә торган процент ставкасын i дип билгелибез. Ул вакытта iI_i тапкырчыгышы процент ставкасы күтәрелгәндә инвестицияләрнең нинди суммага кимүен күрсәтер. Шулай итеп, инвестицияләрнең процент ставкасына функциональ бәйлелеген түбәндәге тигезләмә белән күрсәтергә мөмкин:

$$I = I_0 + iI_i. \tag{12.17}$$

Шундый ук бәйлелек автоном чыгымнарның башка төрләре өчен дә кулланылырга мөмкин. Аерым алганда, куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрнең бик зур өлеше кредитка яки түләүне кичектерү юлы белән сатып алына. Әгәр процент ставкасы төшсә, кулланучылар товарны кредитка яки кичектереп түләү шарты белән алырга тырышачак. Бу исә автоном

12-6 нчы рәсем. ▷ Яңа биналарга, җиһазларга һәм башкаларга инвестицияләр процент ставкасына карата кире пропорциональ бәйлелектә була.

Графиктан күренгәнчә, әгәр процент ставкасы 5% ка тигез булса, инвестицияләр 500 гә тигез, ә процент ставкасының, мәсәлән, 20% ка кадәр үсүе инвестицияләрнең 200 гә кадәр кимүенә китерә.



кулланунын үсүенә китерә. Шунысы мөһим: бу очракта куллану чыгымнарының артуы керемнәр арту белән түгел, нәкъ менә процент ставкасы киму белән бәйләнгән, ягъни керемгә карата автоном характерда. Киресенчә, әгәр процент ставкасы арта икән, кулланучылар акчаларын куллану товарларына азрак тотарга тырышачак, ә инде процент ставкаларынын артуы кешеләрне саклык кертемнәре ясауга һәм облигацияләр алуга этәрәчәк.

Шулай итеп, автоном инвестицияләрнең процент ставкасына функциональ бәйлелеген, гомумән, автоном чыгымнарга карата куллана алабыз һәм (12.17) тигезләмәсен болай язабыз:

$$A = A_0 + iA_i, \qquad (12.18)$$

биредә A_0 — процент ставкасы нуль булгандагы автоном чыгымнар; A_i — автоном чыгымнарның процентлы реакциясе.

Автоном инвестицияләр һәм автоном кулланууларның, ягъни, гомумән, автоном чыгымнарның үзгәреше милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсенең тиндәшле үзгәрешләренә китерүен без инде алдарак билгеләп үткән идек. Хәзер исә процент ставкасының артуы яки кимүе автоном чыгымнарны кыскарта яки киңәйтә дигән нәтиҗә ясадык. Димәк, процент ставкасының автоном чыгымнар ярдәмендә үзгәрүе милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе үзгәрешләрен китереп чыгара.

Моннан тыш, (12.16), (12.16а) һәм (12.18) тигезләмәләре нигезендә түбәндәгечә яза алабыз:

$$Q_e = k(A_0 + iA_i). \qquad (12.19)$$

(12.19) тигезләмәсе шуны күрсәтә: әгәр икътисадта өч күрсәткеч (мультипликатор — k, процент ставкасы нульгә тигез булгандагы автоном чыгымнар — A_0 һәм автоном чыгымнарның процентлы реакциясе — A_i) даими зурлыкларга әверелә икән, без аларны бирелгән параметрлар дип кабул итә алабыз, ул вакытта милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе (Q_e) процент ставкасы үзгәрешләренә кире пропорциональ рәвештә үзгәрә. Бу тигезләмәне башка төрле дә аңлатырга мөмкин: әгәр милли керем дәрәҗәсендә үзгәрешләр күзәтелә икән, аны, тигезләнешле дәрәҗәдә тотып тору өчен, шул ук өч параметрны калдырып, процент ставкаларын кире чагыштырмада үзгәртергә кирәк. Икенче төрле әйткәндә, Үзәк банк, процент ставкаларын төрлечә үзгәртеп, ТМП һәм милли керем динамикасына йогынты ясарга мөмкин дигән сүз (шулай ук 9 нчы бүлекне кара).

Милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсенең процент ставкасына бәйлелеген график юл белән дә күрсәтергә мөмкин (12-7 рәс.). (12.9) функциясенең графигы икътисади әдәбиятта ***IS* кәкресе** дигән исем белән йөртелә.

12-7 нче рәсем. ▷
***IS* кәкресе графигы милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсенең $A = -20$ һәм $k = 5$ булганда, процент ставкасына функциональ бәйлелеген күрсәтә.**
Әгәр процент ставкасы 5% булса, товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тулаем сорау белән тулаем тәкъдим арасындагы тигезләнеш милли керем 2500 (E_1 ноктасы) булган очракта урнаша. Процент ставкасының 20% ка кадәр артуы товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тулаем сорау һәм тәкъдим арасындагы тигезләнешкә милли керем 1000 гә (E_2 ноктасы) кадәр төшкәч ирешелә.



IS кәкресенең теләсә кайсы ноктасы товар һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем сорау һәм тәкъдим тигезләшкән очракта икътисадның билгеле бер халәтен күрсәтә.

> *IS* КӘКРЕСЕ, процент ставкасы белән ТЭП дәрәҗәсе нинди комбинацияләрдә булганда, товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында сорау һәм тәкъдим тигезләнешенә ирешеп булуны күрсәтә.

IS кәкресеннән читтә ятучы теләсә кайсы башка нокта бу тигезләнешнең бозылуын чагылдыра. Мәсәлән, X_1 ноктасы, милли керем 2500 булганда, 20% лы процент ставкасының товар базарында тигезләнеш урнаштыру өчен артык югары икәнен күрсәтә. Мондый ставка инвестицияләр һәм автоном куллануны киметүгә этәрә һәм үз чиратында милли керем дәрәҗәсен дә төшерә. Бу ноктада икътисадның хәле тотрыксызлана, бу бигрәк тә товар һәм хезмәт күрсәтүләр күләменең тулаем кимүендә чагыла. Милли керем үзенең тигезләнешле дәрәҗәсенә ирешкәнче, болай киму дәвам итәчәк.

X_2 ноктасы шулай ук икътисадның тигезсез, димәк, тотрыксыз хәлен күрсәтә. Әгәр милли керем 1500 гә тигез икән, бу дәрәҗә өчен 10% лы процент ставкасы артык түбән. Бу шартларда инвестицияләр һәм автоном куллануның арту күренеше күзәтелә, һәм, димәк, милли керем дә үсә бара. Гомумән алганда, бу, әлбәттә, уңай күренеш, әмма ул товар һәм хезмәт күрсәтүләргә булган сорауның тәкъдимнән артып китүенә китерергә мөмкин, нәтиҗәдә инфляция куркынычына да ерак калмый.

12.5. ПРОЦЕНТ СТАВКАСЫ ҺӘМ АКЧА БАЗАРЫНДАГЫ ТИГЕЗЛӘНЕШ

Икътисадта гомуми тигезләнеш сорау һәм тәкъдимнең тигезлегенә товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында гына түгел, акча базарында да ирешүне күздә тота.

Акча тәкъдиме

9 нчы бүлектә карап узганыбызча, базар системалы икътисадта банкнотлар (кәгазь) һәм вак акчалар, сорап алганга

кадәрге кертемнәр, саклык кертемнәре һ. б. рәвешендәге акча әйләнештә йөри. Кулдагы акчалар һәм сорап алганга кадәрге кертемнәр, M_1 агрегаты белән аңлатылып, **акча тәкъдимен** тәшкил итә.

Шул ук вакытта акчаның номиналь һәм реаль тәкъдимен аера белергә кирәк. Номиналь тәкъдим — ул фактта әйләнештә йөргән кулдагы акча һәм сорап алганга кадәрге кертемнәр (M_1) суммасы. Әгәр икътисадта бәяләр күтәрелә икән, акчаның сатып алу сәләте бәяләр үсүгә пропорциональ рәвештә төшә. Шуңа күрә акчаның реаль тәкъдиме дә бәя күтәрелүгә пропорциональ рәвештә төшә. Шулай итеп, акчаның реаль тәкъдиме аның номиналь тәкъдимен житештерелә торган барлык товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең уртак индексына (уртак дәрәҗәсенә) бүлеп табыла, ягъни

$$M_s = \frac{M_{nom}}{P}, \qquad (12.20)$$

биредә M_s — акчаның реаль тәкъдиме; M_{nom} — акчаның номиналь тәкъдиме; P — товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясенең уртак индексы (ТМПның индекс-дефляторы). Тик бу юлы да бәяләр үзгәрешсез кала дип фараз итәбез, һәм безнең тикшеренүләрдә акчаның реаль тәкъдиме генә күздә тотылыр.

Акчага сорау

Икътисадның яшәве өчен фирмалар һәм йорт хуҗалыкларында акчага билгеле бер сорау туу — гадәти хәл.

Йорт хуҗалыкларының да, фирмаларның да үзләрендә беркадәр акча тотуы, барыннан да элек, аның ликвидлык үзлегенә ия булуы белән аңлатыла. Сез дә нәкъ менә шул үзлеге аркасында акчаның товар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, бурычларны кайтару һ. б. алыш-бирешләр өчен уңай икәнлеген беләсез. Мондый алыш-бирешләрнең зурлыгы илдә җитештерелгән милли керем зурлыгына бәйле (яки ТЭП зурлыгына дип тә әйтергә мөмкин; шуңлыктан киләчәктә без ТЭП күрсәткеченнән файдаланырбыз. *IS* кәкресен тикшергәндә дә без ТЭП күрсәткеченнән файдалана ала идек). Даими рәвештә һәм бернинди кыенлыклардан башка кирәкле товарлар сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен, һәрбер фирма һәм теләсә кайсы гаилә үзендә яки агымдагы счетында

күпмедер акча тотарга тиеш. Бер генә хуҗабикә дә һәм фирмалардагы бер генә финанс менеджеры да алынган керемне шул көнне үк тулысынча туздырып бетерми.

Дөрестән дә, фирма яки йорт хуҗалыгы алган керем никадәр зур булса, алар карамагында шуның кадәр зуррак суммадагы акча булырга тиеш. Моннан илнең икътисадында булган акча күләме ТЭП зурлыгына туры пропорциональ икәнлеге килеп чыга. Әгәр бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе күтәрелә икән, икътисадта әйләнештә йөргән акча күләменең бәяләр үсешенә пропорциональ артуы, билгеле инде, табигый хәл. Әмма бу икътисадта әйләнештәге акча суммасы $Q \times P$ га, ягъни ТЭП күләме белән бәяләр дәрәҗәсе тапкырчыгышына тигез була дигән сүз түгел. Чөнки бер үк акча берәмлеге ярдәмендә (сум, доллар һ. б.) товарлар сатып алу-сату буенча берничә алыш-биреш ясарга мөмкин. Мәсәлән, машиналар төзү фирмасы 10 млрд сумлык продукция житештерә һәм сата. Бу акчага фирма, яңа машиналар эшләп чыгару өчен, прокатланган металл сатып ала, үз чиратында прокат сатучы фирма 10 млрд сумны металл сатып алуга тота. Шулай итеп, 10 млрд сум акча ниндидер вакыт аралыгында (әйтик, бер ел эчендә) өч әйләнеш ясап өлгерә, һәм шуның аркасында бер ел эчендә 30 млрд сумлык продукция сатыла. Моннан без нәтиҗә ясый алабыз: *әйләнештә йөргән акча күләме белән акча әйләнеше тизлеге тапкырчыгышы бер ел эчендә җитештерелгән товар һәм хезмәт күрсәтүләр күләме белән бу товарларның бәяләре тапкырчыгышына тигез булырга тиеш.*

Бу нәтиҗәне түбәндәге тигезләмә белән күрсәтә алабыз:

$$M \times v = Q \times P, \qquad (12.21)$$

биредә M — әйләнештә йөрергә тиешле акчаның күләме; v — акча әйләнеше тизлеге (бер ел эчендә M ның әйләнешләре саны); Q — тулай эчке продукт; P — бәяләр дәрәҗәсе.

(12.21) тигезләмәсе **акчаның микъдари теориясе тигезләмәсе** дип йөртелә. Ул шулай ук тигезләмәне фәнгә керткән Америка галиме хөрмәтенә **Ирвинг Фишер тигезләмәсе** буларак та билгеле.

Фишер тигезләмәсен башкача да аңлатырга мөмкин. Һәр фирманың һәм йорт хуҗалыгының билгеле бер суммада кулдагы акчасы һәм сорап алганга кадәрге депозитлары яки

агымдагы счетлары булырга тиеш дидек. Шуңа күрә икътисадта, бер яктан, кулдагы акчалар һәм депозитлар һәм, икенче яктан, агымдагы бәяләрдә исәпләнүче ТЭП зурлыгы арасындагы билгеле бер нисбәт саклана, ягъни

$$M_d = \frac{Q \times P}{v}, \tag{12.22}$$

биредә M_d — акчага сорау. Акча әйләнеше тизлеге v урынына m коэффициенты — аңа кире зурлыкны ($m = \frac{1}{v}$) куйыйк.

Шулай ук фаразларыбыз буенча, товар һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр үзгәрешсез кала, ә акчага тәкъдимне (M_s) реаль дип алабыз. Шунлыктан акчага сорау да реаль күрсәткеч булырга тиеш. Димәк, P (бәяләр дәрәҗәсе) бергә тигез дип алырга мөмкин. $P = 1$ һәм v ны m белән алыштырсак, (12.18) тигезләмәсе түбәндәгечә языла:

$$M_d = m \times Q, \tag{12.23}$$

биредә M_d — реаль исәпләүләрдә акчага сорау.

(12.21) тигезләмәсе акчага сорауның процент ставкасына бәйле түгеллеген күрсәтә. Аны процент ставкасы нульгә тигез булган аерым очрак дип тә карарга мөмкин. Ә чынлыкта процент ставкасы үзгәрешләре акчага булган сорауга һәм фирмалар яки гаиләләрнең аңа карата мөнәсәбәтенә зур йогынты ясый.

Фермерлар һәм йорт хуҗалыкларында ликвидлыкка өстенлек бирү күзәтелә. Кулдагы акча — акча саклауның иң уңайлы һәм ышанычлы формасы. Ләкин алар процент рәвешендәге керемнәр китерми, ә инфляция шартларында әле бәясен дә югалта. Сорап алганга кадәрге кертемнәргә килсәк, алар өчен процент бөтенләй түләнми яки аның ставкасы шулкадәр түбән, ул, бәяләр күтәрелү нәтиҗәсендә, акча бәясе төшүне генә капларга җитә.

Әгәр акчаны керем алуның потенциаль чыганагы дип карыйбыз икән, аларны кулда булган формада саклау акылсызлык булыр. Моның өчен акчаны кыйммәтле кәгазьләргә (акцияләр яки облигацияләргә) алыштырырга яки саклык кертеме ясарга кирәк. Бу очракта алар керем кертә башлый, әмма ликвидлыгы күпкә кими. Әгәр облигацияләр иясенә кинәттән генә телевизор сатып алырга кирәк булса, ул инде



12-8 нче рәсем. △
Акчага сорауның үзгәрүе.
Рәсемдә сурәтләнгән диаграмма, процент ставкасы нульгә тигез булганда, акчага сорауның ТЭП күләме үзгәрешләренә пропорциональ үзгәрүен күрсәтә. Әгәр акча тәкъдиме 500 млн долл., ә $M_d / Q = 0{,}5$ булса, акча базарында тигезләнеш ТЭП = 1000 млн долл. булган очракта урнаша. Шунлыктан ТЭП 1200 млн долл. булганда, акчага сорау аның тәкъдименнән артып китә. Акчага сорау процент ставкасына карап та үзгәрә. Мәсәлән, ставка 5% ка тигез булса, Q = 1200 млн долл. булганда, акчага сорау 500 млн долларга кадәр төшә һәм акча базарында кабат сорау һәм тәкъдимнең тигезләнеше урнаша. Әгәр процент ставкасы 10% ка кадәр күтәрелсә, акчага сорау 400 млн долларга кадәр төшә һәм тәкъдимнән кечерәк булып кала. Әмма ТЭП 1400 млн долларга кадәр күтәрелсә, акчага сорау яңадан күтәрелә һәм акча тәкъдиме белән тигезләшә.

облигациялəр белəн түли алмый. Башта аларны сатарга һəм шуннан соң гына кулдагы акчалар белəн товар өчен түлəргə мөмкин.

Шулай итеп, фирмалар һəм йорт хуҗалыклары һəрвакыт каршылыклы хəлдə: акчаны, процентлардан баш тартып, иң ликвид формада тотаргамы əллə, кыйммəтле кəгазьлəргə алыштырып яки саклык кертемнəренə салып, керем алырга һəм инде югары ликвидлыктан баш тартыргамы? Акчалары булган кешелəрнең нинди карар кабул итүе процент ставкасы зурлыгына бик нык бəйлəнгəн. Əгəр процент ставкасы нуль булса, акчаны облигациялəргə тотуның яки саклык кертемнəре ясауның берниндн мəгънəсе дə булмаячак. Ликвидлыкка өстенлек бирүдəн башка чара калмас, һəм акчага сорау (12.19) тигезлəмəсе нигезендə исəплəнер иде.

Əгəр процент ставкасы нульдəн зуррак булса, ул үлчəүнең бер тəлинкəсендəге гергə əйлəнə, ə каршы тəлинкəдə «ликвидлык» дигəн гер урнаша.

Процент ставкасы нульдəн зуррак булганда (əйтик, 5%), күп кенə фирмалар һəм йорт хуҗалыклары акчаларының билгеле бер өлешен саклык кертемнəренə күчерə яки облигациялəргə сала. Əгəр процент ставкасы 10% ка кадəр күтəрелсə, аларның кулдагы акчаны кыйммəтле кəгазьлəргə һəм саклык кертемнəренə күчерү омтылышы көчəя төшə. Ул вакытта ликвидлы акчага сорау кими. Һəм, киресенчə, процент ставкасын төшерү акчаны ликвид формадан керем китерə торган формага күчерү телəген киметə, ликвидлыкка күчү ешрак күзəтелə. Бу очракта кулдагы акчага сорау арта, һəм сорап алганга кадəрге кертемнəр күбəя.

Шулай итеп, процент ставкасы күтəрелешенең һəр пункты акчага сорауны билгеле бер суммага киметə, ə процент ставкасы төшүнең һəр пункты бу сорауны шул ук суммага күтəрə. Əгəр алдагы параграфта без автоном чыгымнарның процентлы реакциясен ачыклаган булсак, биредə *кулдагы акчаның һəм сорап алганга кадəрге кертемнəрнең процентлы реакциясе*, икенче төрле əйтсəк, **акчага сорауның процентлы реакциясе** белəн очрашабыз. Əгəр акчага сорауның процентлы реакциясе зурлыгын процент ставкасының һəр пунктына M_i дип билгелəсəк, процент ставкасы үзгəрү нəтиҗəсендə, акчага сорау үзгəрүнең гомуми суммасы – iM_i тапкырчыгышы белəн, ə акчага сорау белəн процент ставкасы арасындагы функ-

циональ бәйлелекне түбәндәге тигезләмә белән билгеләргә мөмкин:

$$M_d = mQ + iM_i. \quad (12.24)$$

Шунысына игътибар итик: акчага сорауның процентлы реакциясе зурлыгы (M_i) — тискәре сан, чөнки, билгеләп үткәнебезчә, ставканың күтәрелүе акчага сорауны киметә, ә төшүе — арттыра. (12.24) тигезләмәсе акчага сорауның ТЭП күләменә, m коэффициентына, процент ставкасына һәм сорауның процентлы реакциясе зурлыгына бәйле икәнен күрсәтә.

(12.24) тигезләмәсеннән файдаланып, милли керем дәрәҗәсе үзгәрешләренең процент ставкасы үзгәрешләренә функциональ бәйлелеген таба алабыз:

$$Q = \frac{M_d - iM_i}{m}. \quad (12.25)$$

Әгәр инде акча базарында аңа сорау белән тәкъдимнең тигез булуын, ягъни $M_d = M_s$ икәнен исәпкә алсак, (12.24) тигезләмәсе милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсенең процент ставкалары үзгәрешләренә бәйле рәвештә ничек үзгәрүен күрсәтә. Бу дәрәҗә акча базарында сорау һәм тәкъдимнең тигезлеген тәэмин итә. Димәк, (12.24) тигезләмәсен без башкача да яза алабыз:

$$Q_e = \frac{M_d - iM_i}{m}, \quad (12.26)$$

биредә Q_e — милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе.

Милли керем дәрәҗәсенең процент ставкасына функциональ бәйлелеген график рәвештә дә күрсәтергә мөмкин (12-9 рәс.). Рәсемдә ике график бирелгән. Икътисадта 500 күләмендәге акча әйләнештә йөри дип алыйк. Бу сумма — акча тәкъдиме ($M_s = 500$). Сул графикта моны 500 ноктасыннан абсциссалар күчәренә үткәрелгән перпендикуляр күрсәтә. Акча тәкъдиме процент ставкасына бәйле түгел. Һәм аның теләсә нинди кыйммәте өчен дә M зурлыгы 500 гә тигез.

Сул графикта шулай ук L_1, L_2, L_3 дип тамгаланган өч туры үткәрелгән. Алар милли керемгә һәм процент ставкасына бәйле рәвештә үзгәрә торган сорауның төрле үлчәмнәрен күрсәтәләр. Мәсәлән, L_1 турысы, беренчедән, акчага сорауның процент ставкасы нуль булган (M_0) дәрәҗәсенә бәйләнгән; икенчедән,



12-9 нчы рәсем. △

Рәсемдә үзара бәйләнгән ике график күрсәтелгән. Сул графикта: акча тәкъдиме үзгәрешсез калганда ($M_s = 500$), акчага сорауның төрле дәрәҗәсен күрсәтүче турылар белән тәкъдим турысы кисешкән e_1, e_2 һәм e_3 нокталарында акча базарында тигезләнеш урнаша. $\Delta M = -50$ дип уйланыла. Уң графикта: акчага сорау һәм тәкъдимнең тигезләнешенә милли керемнең билгеле бер дәрәҗәләре E_1, E_2, E_3 нокталары туры кила; бу вакытта $m = 0{,}5$ дип алына. Ике графиктан да милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе, шулай ук аңа бәйләнгән һәм шул ук вакытта тәкъдимгә тигез булган сорау процент ставкасы белән функциональ бәйлелектә икәнлеге күренә. Сул графиктагы сызык LM кәкресе була.

бу сорау процент ставкасына бәйле һәм, өченчедән, ставка үзгәрешләренә акчага сорауның нинди реакция ясавына бәйләнгән. Мәсәлән L_1 турысы, әгәр процент ставкасы нульгә тигез булса, акчага сорауның 750 гә тигез икәнен күрсәтә. Әйтик, $M_i = -50$ булсын. Ул очракта акча базарында сорау белән тәкъдимнең тигезләшүе процент ставкасы 5 булганда ($1000 + 10 \times (-50) = 500$) ирешелер иде. Шулай итеп, тәкъдим һәм сорау (e_1) турыларының кисешү ноктасы, процент ставкасы 5 кә тигез булганда, акча базарында тигезләнешкә ирешүне күрсәтә. Шуңа охшаш рәвештә L_2 турысы акча базарында тигезләнешнең $M_0 = 1000$ һәм $i = 10\%$ очрагында урнашуын аңлата; бу очракта сорау турысы тәкъдим перпендикулярын e_2 ноктасында кисә. Әгәр инде $M_0 = 1250$ булса,

e_3 тигезләнеш ноктасы $i = 15\%$ очрагында $M_d = M_s$ икәнен күрсәтә.

Хәзер кабаттан (11.20) тигезләмәсенә кайтыйк һәм акчага сорауның беренче чиратта милли керем күләменә (Q) һәм m коэффициентына бәйле икәнен искә төшерик. Әйтик, $m = 0{,}5$ булсын. Әгәр процент ставкасы нульгә тигез һәм шул ук вакытта акча базарында сорау белән тәкъдим тигезләнеш хәлендә булса, милли керем нәрсәгә тигез булыр? Ставка нуль булганда, акча базарында тигезләнеш сорау перпендикуляры абсциссалар күчәрен кисеп узган ноктада, ягъни $M_d = M_s = 500$ очрагында урнашыр. Ягъни, процент ставкасы нуль булганда, милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсе $Q_e = \frac{500}{0{,}5} = 1000$. Процент ставкасын күтәргәндә (мәсәлән, 0 дән 5% ка), акчага сорау кими. Әгәр милли керем 1000 дәрәҗәсендә калса, акча базарында тигезләнеш бозылыр иде, бу очракта сорау тәкъдимнән азрак булачак. Бу шартларда ничек итеп тигезләнешне саклап калырга соң? Милли керемне үстерергә кирәк, һәм ул акчага сорауны арттырыр иде. Милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсен билгеләү кыен түгел. Моның өчен (12.21) тигезләмәсен искә төшерү җитә. Безнең шартларда $Q_e = \frac{500 - 5\% \times (-50)}{0{,}5} = 1500$. Шундый ук юл белән теге яки бу процент ставкасы өчен милли керем дәрәҗәсен исәпләп таба алабыз. Аерым алганда, $i = 10\%$ булганда, $Q_e = 2000$; $i = 15\%$ булганда, $Q_e = 2500$ һ. б.

Шулай итеп, 12-6 рәсеменең уң ягында сурәтләнгән сызык — Q ның i гә бәйлелеге функциясе, ул (12.21) тигезләмәсе белән билгеләнгән иде инде. Бу график икътисади әдәбиятта ***LM* кәкресе** исемен йөртә.

> *LM* КӘКРЕСЕ — ТЭП дәрәҗәсе процент ставкасының акча базарында сорау һәм тәкъдимнең тигезләнешен тәкъдим итә торган комбинацияләрен күрсәтүче нокталарның геометрик урыны.

LM кәкресеннән читтә ятучы теләсә кайсы нокта икътисадның тигезләнеш хәлендә түгеллеген күрсәтә. Мәсәлән,

X ноктасында милли керем өчен процент ставкасы артык зур һәм Үзәк банкка аны төшерү өчен чаралар күрергә һәм акча базарында тигезләнеш урнаштырырга туры киләчәк. *X* ноктасында ставка бик түбән. Милли керем 2500 булган очракта, акча базарында тигезләнеш урнаштыру өчен, процент ставкасын берничә тапкыр күтәрергә кирәк.

12.6. ТОВАР ҺӘМ АКЧА БАЗАРЛАРЫНДА ГОМУМИ ТИГЕЗЛӘНЕШ. *IS-LM* МОДЕЛЕ

Товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында сорау һәм тәкъдим арасында тигезләнеш булсын өчен, процент ставкасы һәм ТМП арасында нинди нисбәт булырга тиешлеген күрсәткән *IS* кәкресен без инде карап үткән идек. Бу кәкренең һәр ноктасы тигезләнеш хәлен күрсәтә. Кәкредә мондый нокталар чиксез күп, ягъни *IS* кәкресе товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тигезләнеш хәленең чиксез күп вариантларын күрсәтә. Шуны ук *LM* кәкресенә карата да әйтергә мөмкин, аерма тик шундый вариантлар күплегенең акча базарында булуында гына. Икенче төрле әйткәндә, аерым-аерым алынган һәр кәкре — анықсыз: милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәләре чиксез күп, һәм аларның һәрберсе, базарларының берсендә тиндәшле процент ставкасы куелганда, тигезләнеш хәлен күздә тота.

Бу ике кәкрене бергә тикшерсәк, бөтенләй башка хәл күзәтелә. Мондый комбинацияне алу өчен, *IS* белән *LM* кәкресен берләштерү җитә. «Берләштерелгән» яңа график 12-10 рәсемендә китерелә.

IS һәм *LM* кәкреләре, нindидер хач хасил итеп, E_0 ноктасында кисешәләр. E_0 ноктасы *IS* кәкресендә дә, *LM* кәкресендә дә ятканлыктан, ул милли керем нинди булганда һәм процент ставкасы нинди булганда товар базарында да, акча базарында да тигезләнеш урнашуын күрсәтә. Бу нокта бердәнбер, димәк, милли керем белән процент ставкасының ике базарда да тигезләнеш урнаштыра торган бердәнбер комбинациясе бар. Әгәр *IS* һәм *LM* кәкреләрен төзегәндә кабул ителгән шартларны кабат кулланcак, милли керем дәрәҗәсе 2000 һәм процент ставкасы 10% булганда, гомуми икътисади тигезләнеш урнашуын күрербез. Барлык башка нокталар

12-10 нчы рәсем. ▷
***IS* һәм *LM* кәкреләренең комбинациясе.**

IS һәм LM кәкреләре E_0 ноктасында кисешә. Аларның кисешү ноктасы элегрәк тикшерелгән параметрлар ($k = 5$; $A_0 = 600$; $\Delta A_i = -20$; $m = 0{,}5$; $M_0 = 500$; $\Delta M_i = -50$) нигезендә гомуми икътисади тигезләнешкә, ягъни товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарындагы һәм акча базарындагы тигезләнешкә $Q_e = 2000$ һәм $i = 10\%$ булганда ирешелгәнне күрсәтә.



икътисадның тигезләнеш урнашмаган халәтләрен чагылдыра. Мәсәлән, IS кәкресендә ятучы X_1 ноктасы товар базарында тигезләнешнең булуын, ә акча базарында булмавын күрсәтә. X_2 ноктасы, киресенчә, акча базарында — тигезләнеш, ә товар базарында тигезләнешнең бозылуын чагылдыра. Ә X_3 ноктасы икътисадта ике базарның да үз тигезләнешен югалтуын белдерә.

IS һәм LM кәкреләре комбинациясе һәм ул билгеләгән гомуми икътисади тигезләнеш хәле ике билгесезле (Q_e һәм i — милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе һәм аңа тиңдәш процент ставкасы) ике тигезләмә системасы рәвешендә дә күрсәтелергә мөмкин. Бу системага керүче алты параметр бирелгән саннар итеп карала. Әлеге системаны төзүче тигезләмәләр 12.4 һәм 12.5 параграфларында чыгарылган иде. Болар — (12.19) тигезләмәсе: анда бирелгән мультипликатор (k), нульгә тигез булган процент ставкасы вакытында автоном чыгымнар (A_0) һәм автоном чыгымнарның процентлы реакциясе (A_i) буенча Q_e белән i ның функциональ бәйлелеге чыгарылды; һәм (12.26) тигезләмәсендә бирелгән m коэффициенты, нульгә тигез процент ставкасы вакытында акчага сорау (M_0) һәм акчага сорауның процентлы реакциясе (M_i) буенча Q_e һәм i арасындагы функциональ бәйлелек күрсәтелде.

$$\begin{cases} Q_e = k\,(A_0 + iA_i), \\ Q_e = \dfrac{1}{m}\,(M_0 - iM_i). \end{cases} \tag{12.27}$$

(12.27) системасы товар һәм акча базарларында макроикътисади тигезләнешнең математик моделе булып тора. Ул ***IS-LM* моделе** дигән исем белән билгеле. 12-10 рәсемендә әлеге модельнең график рәвешен күрергә мөмкин.

IS-LM моделе — ул үзенә күрә теоретик нигез, гомуми икътисади тигезләнешнең тагын да конкретрак һәм катлаулырак модельләре шуңы нигезгә корыла. Бу модельдән файдаланып, икътисади тигезләнешкә хөкүмәтнең икътисади сәясәт өлкәсендәге теге яки бу чаралары нинди йогынты ясаячагын икътисадчылар алдан билгели алалар.

Мәсәлән, әгәр хөкүмәт дәүләткә товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуны арттырырга уйлый икән, бу — автоном чыгымнарның гомуми суммасы арта дигән сүз. Шунысына игътибар итик: автоном чыгымнар үсеше процент ставкалары үзгәрешенә яки керемнәр үзгәрүгә бәйләнмәгән, ягъни (12.27) системасының 1 нче тигезләмәсендә A_0 параметры үзгәрә — процент ставкасы нуль булгандагы автоном чыгымнар күрсәткече үсә. Моның нәтиҗәсендә *IS* графигы уңга авыша һәм милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсен (*IS* һәм *LM* кәкреләренең кисешү ноктасы) уңга таба өскә күчерә. Димәк, дәүләтнең автоном чыгымнары үсү нәтиҗәсендә, беренчедән, милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсе күтәрелә, икенчедән, бу дәрәҗәгә тиңдәш булган процент ставкасы да арта. Бу шартларда Үзәк банк процент ставкасын күтәрергә тиеш. Ни өчен дигән сорау туа. Эш шунда ки, милли керемнең үсеше акчага сорауны да үстерә. Шуңа күрә акча базарында тигезләнешне саклау өчен, акчага сорауны элекке дәрәҗәсендә калдырырга кирәк, ә моңа процент ставкасын арттыру юлы белән ирешеп була.

Дәүләт чыгымнары арткан очракта, акча базарында тигезләнешне саклап калуның башка юлы да бар — акчага тәкъдимне дә арттыру. Моңа өстәмә эмиссия юлы белән ирешәләр. Мәсәлән, әле тикшерелгән мисалда, *LM* кәкресен төзү өчен, акча тәкъдиме 500 гә тигез дип алынган иде (12-6 рәс.). Ә хәзер акча тәкъдиме 750 гә кадәр үсте дип алсак, бу тәкъдимне күрсәтүче перпендикуляр уңгарак күчә. Димәк,

LM кәкресе дә унга кадәр күчә дигән сүз. Шулай итеп, акча базарында сорау һәм тәкъдимнең тигезләнеше процент ставкасын күтәрмичә дә тотып торыла икән. *LM* һәм *IS* кәкреләрен берьюлы унга таба авыштыру аларның кисешү нокталарын да унга күчерү белән бара, ягъни милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе үсә. Ә бу — хөкүмәтнең һәм Үзәк банкның килешенгән чаралары гомуми тигезләнешне, ягъни товар һәм акча базарларындагы тигезләнешне сакларга мөмкинлек бирә дигәнне аңлата.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Илдә икътисадның тигезләнешле торышы яки хәле иң беренче чиратта илдә җитештерелә торган барлык товар һәм хезмәт күрсәтүләргә карата тулай сорау белән аларның тулай тәкъдиме тигезлеген аңлата. Мондый тигезләнешкә иң гади мисал булып автоном һәм индуцияләнгән куллану суммасы белән илдә җитештерелгән милли керемнең тигезлеге тора.

Куллану дәрәҗәсе керем зурлыгы белән функциональ бәйләнгән. Әгәр тулаем сорау бары тик халыкның планлаштырылган куллану чыгымнарына гына кайтып кала икән, милли керемнең икътисадны тигезләнеш хәлендә тота алган дәрәҗәсе — бердәнбер зурлык.

Куллану чыгымнары белән беррәттән, инвестицияләр дә тулаем сорауның состав өлеше булып тора. Күләме керемнәр күләменә бәйле булмаган инвестицияләр автоном инвестицияләр дип атала. Автоном инвестицияләр кертү милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсен югары күтәрә.

Дәүләтнең товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуы, инвестицияләр кебек үк, автоном характерда була. Шунлыктан аларның артымы да милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсен күтәрүгә сәбәп була.

Автоном куллану, автоном инвестицияләр һәм дәүләт сатып алуларының гомуми суммасы автоном чыгымнарны тәшкил итә. Милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсе артымы белән автоном чыгымнар артымының чагыштырмасы мультипликатор дип атала. Мультипликатор куллануга иң чик хирыслык белән билгеләнә.

Тигезләнеш шартларында автоном чыгымнар суммасы индуцияләнгән саклык акчаларына тигез булырга тиеш.

Автоном чыгымнар күләменә процент ставкасы зур йогынты ясый. Процент ставкасын арттыру, автоном чыгымнарның кимүенә китерә. Шуңа күрә товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарындагы тигезләнеш милли керем күләменә генә түгел, процент ставкасына да бәйләнгән. Товар базарындагы тигезләнешне тәэмин итүче милли керем дәрәҗәсенең процент ставкасы үзгәрешләренә кире пропорциональ бәйлелеген күрсәтүче график *IS* кәкресе дип атала.

Милли керем үзгәрешләре акчага сорауның пропорциональ үзгәрүен китереп чыгара. Моннан тыш, акчага сорау процент ставкасы үзгәрешләренә бәйле рәвештә үзгәрә. Шунлыктан акча базарындагы тигезләнеш милли керем күләменә дә, процент ставкасы зурлыгына да бәйләнгән. Акча базарындагы тигезләнешне тәэмин итүче милли керем дәрәҗәсенең процент ставкасы үзгәрешләренә кире пропорциональ бәйлелеген күрсәтүче график *LM* кәкресе дип атала.

IS һәм *LM* кәкреләренең кисешү ноктасы милли керем белән процент ставкасының икътисадтагы товар һәм акча базарларында сорау белән тәкъдимнең тигезләнешен, ягъни гомуми икътисади тигезләнешне күрсәтә.

Контроль сораулар һәм биремнәр

1. Автоном чыгымнар графигы нәрсәне күрсәтә? Ни өчен автоном чыгымнар графигы белән керемнәр турысының кисешү ноктасы милли керемнең тигезләнешле дәрәҗәсен күрсәтә?
2. Мультипликаторның икътисади асылы нидән гыйбарәт? Ни өчен мультипликатор иң чик куллану хирыслыгына бәйле?
3. 12-2 таблицасына охшаш таблица төзегез: аңа дәүләтнең товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу чыгымнарын өстәгез һәм бу чыгымнарны 300 гә тигез дип алыгыз. Автоном куллану һәм автоном инвестицияләрдән тыш, дәүләтнең товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга тотылган чыгымнарын да кертеп, автоном чыгымнар графигын төзегез. Бу шартларда милли керемнең тигезләнеш дәрәҗәсен билгеләгез.

4. Ни өчен барлык башка шартлар шул ук булганда да, процент ставкасын күтәрү — инвестицияләр килүгә, ә төшерү аларны арттыруга илтүен аңлатыгыз.
5. 12-3 таблицасында китерелгән гипотетик саннарны карап чыгыгыз. Әгәр фирмалар үз капиталын түгел, ә заемга алынган капиталны инвестицияләр икән, процент ставкасы арткан яки кимегән очракта, аларның ничек инвестицияләве мөмкин? Сезнең фикерегез нинди?
6. Акчага тәкъдим һәм акчага сорау дигәннән сез нәрсәне аңлыйсыз? Ни өчен милли керем күләменең үзгәрүе акчага сорауның пропорциональ үзгәрешенә китерә?
7. Ни өчен процент ставкасы үзгәрешләре акчага сорауның үзгәрүенә китерә? Процент ставкасы үзгәрешләренә бәйле рәвештә акчага сорау ничек үзгәрә?
8. *IS* һәм *LM* кәкреләре нәрсәне аңлата? Ни өчен *IS* һәм *LM* кәкреләренең кисешү ноктасы икътисадтагы гомуми тигезләнешне аңлата? Гомуми тигезләнеш нидән гыйбарәт?

13 нче бүлек

ИКЪТИСАДИ ЦИКЛ, ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛГӘНЛЕК ҺӘМ ЭШСЕЗЛЕК

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җаваплар табарсыз:

- нәрсә ул икътисади цикл, һәм икътисад үз үсешендә нинди фазалар кичерә;
- ни өчен икътисад циклы үсеш ала;
- ТЭПның потенциаль (яки табигый) дәрәҗәсе нәрсә ул;
- ни өчен базар икътисады шартларында эшсезлек килеп чыга, һәм ул икътисадның циклы үсешләреннән генә бәйлеме;
- кемне эшсез дип атап була;
- тулы мәшгульлек дигәннән нәрсә аңлашыла;
- эшсезлек дәрәҗәсе югары булганда, җәмгыятьтә нинди проблемалар туа;
- дәүләт эш белән тәэмин ителгәнлекне һәм эшсезлекне нинди чаралар ярдәмендә җайга салырга тырыша.

Базар икътисады законнары икътисади үсешнең мәгълүм булган тотрыксызлыгын китереп чыгара. Икътисади тотрыксызлык — ул котылгысыз рәвештә икътисади һәлакәткә китерүче, яшәп килә торган икътисади системаны, һичшиксез, җимерүгә илтә торган һәм хөкем сөрә торган җәмгыятьтә, кичектергесез революцион үзгәртеп корулар аша, бөек сәяси лидерлар сызган юлдан яңа җәмгыять төзүне таләп итүче нindидер бер зарурлык түгел.

Әмма икътисади тотрыксызлык белән исәпләшми дә мөмкин түгел. Ул тирән һәм җентекләп өйрәнелергә, һәм, табыл-

ган нәтиҗәләргә ярашлы рәвештә, урын һәм вакыт үзенчәлекләрен исәпкә алып, дәүләтнең икътисади сәясәте эшләнергә тиеш. Икътисади сәясәтнең бурычы икътисадның эшен һәм үсешен тотрыкландыруга ирешүдән, шуның белән социаль һәм сәяси тотрыклылык өчен ныклы нигез булдырудан гыйбарәт.

Икътисади тотрыксызлыкның күп төрле формалары арасыннан өчесе аеруча җитди:

1) ТМП дәрәҗәсенең, инвестицияләрнең, куллану һәм мәшгульлекнең циклы тирбәлешләре;

2) икътисадтагы циклы тирбәлешләрнең көзгедәгедәй чагылышы булып торган эшсезлек һәм аның зур масштабларга җәелеп, эшен югалткан кешеләр өчен икътисади рецессияләрнең авыр нәтиҗәләре;

3) аерым очракларда гаять кискен форма алган һәм хәтта хәвефле характерга әверелгән инфляция.

Бу бүлектә шуларның икесе карала, инфляция мәсьәләсе 14 нче бүлектә өйрәнеләчәк.

13.1. ИКЪТИСАДИ ЦИКЛ

Икътисади үсеш ТМП күләме, мәшгульлек һәм кешеләрнең тормыш муллыгы тайпылышсыз һәм өзлексез арту процессы булып тормый. Ул җитештерүне киңәйтүнең, ТЭП һәм мәшгульлек дәрәҗәләренең түбән төшүе белән алмашынып торучы, беркадәр вакыт дәвам итүче тизләтелгән чорларның эзлекле рәвештә алмашынуыннан гыйбарәт. Күтәрелү һәм төшүләрнең мондый эзлекле алмашынуның даими кабатланып торуы икътисад үсешенә *циклы характер* бирә. Һәр циклның үз үзенчәлекләре була, ләкин үз хәрәкәтләрендә аларның барысы өчен дә уртак закончалыклар бар. Икътисади цикллар «игезәкләр кебек үзара охшаш түгелләр, ләкин аларда бер гаиләгә караган сыйфатларны табарга була» (П. Самуэльсон).

Икътисади цикл фазалары

Икътисади циклларның якынлыгы, барыннан да бигрәк, аларның охшаш **фазалар** узуында. Һәр цикл икътисади **экспансия**, яки **циклы күтәрелеш** фазасын үз эченә ала. Ул товарлар

13-1 нче рәсем. ▷
Икътисади цикл.
Рәсемдә икътисадның эзлекле рәвештә күтәрелеш фазасы үтүе һәм, үзенең иң югары ноктасына җиткәч, аның рецессия белән алмашынуы сурәтләнгән. Икътисади активлык иң түбән дәрәҗәгә — үзенең төбенә төшкәч, ул яңа күтәрелеш белән алмашына.

җитештерүнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең, нигездә, барлык төрләрен киңәйтүне; машиналарга һәм җиһазларга, биналарга һәм коралларга инвестицияләрне арттыруны; халыкның мәшгульлеген һәм реаль керемнәрен үстерүне; куллану дәрәҗәсен күтәрүне күздә тота. Вакытның билгеле бер моментында циклы күтәрелеш үзенең **иң югары ноктасына** җитә, һәм бу — цикл хәрәкәтендә бөгелү ноктасы булып тора. Үзенең иң югары ноктасына җиткәннән соң, цикл **икътисади рецессия,** яки **төшү** фазасына керә. Төшү чорында күтәрелеш вакытында күзәтелгән процессларга капма-каршы процесслар җәелдерелә башлый: ТМП һәм инвестицияләр күләме кими, еш кына халыкның реаль керемнәре һәм куллану дәрәҗәсе түбәнәя. Рецессия үзенең иң түбән чигенә (**төбенә**) килеп җиткәндә, цикл бөгелешнең икенче ноктасына — төшүдән яңа күтәрелешкә борылу ноктасына килә.

Күпчелек очракта һәр алдагы циклы күтәрелешнең иң югары ноктасы үткәннәренекеннән биегрәк була, ул икътисадның алга үсешен, аның гомуми үсүен чагылдыра. Икътисади циклның хәрәкәте схема рәвешендә 13-1 рәсемендә күрсәтелгән. Биредә цикл *икътисади активлык* динамикасын чагылдырган бердәй дулкынлы сызык рәвешендә күрсәтелгән. Икътисади активлык монда продукция җитештерү, инвестицияләр күләменең, мәшгульлек һәм башка процессларның икътисади үсеше юнәлешен чагылдырган синтетик күрсәткеч булып хезмәт итә.

Икътисади циклның озынлыгы

Цикллар теориясендәге белгечләрне генә түгел, ә дәүләт эшлеклеләрен, профсоюз лидерларын һәм бизнесменнарны да кызыксындырган мөһим проблема — ул икътисади циклның уртача күпмегә сузылуы, ягъни бер циклның иң югары ноктасы икенчесенекеннән күпме вакыт арасы белән аерылуы. Бу гаҗәп түгел, чөнки чираттагы күтәрелешнең кайчан туктавын алдан белү, яңа инвестицияләр программасын тормышка ашыру, эшсезлеккә каршы саклык чаралары кору һ. б. буенча, дәүләтнең һәм Үзәк банкның икътисади сәясәт уздыру өчен, дөрес карарлар кабул итү мөмкинлеге ача.

Американың танылган икътисадчысы Э. Хансен мәгълүматлары нигезендә 1795—1937 еллар эчендә 17 цикл булган. 1937 елдан соң бөтендөнья икътисады тагын 7 цикл уза. Димәк, циклның уртача озынлыгы 8,25 ел тәшкил итә. Әлбәттә, бу барлык цикллар да бер үк озынлыкта була дигәнне аңлатмый. Мәсәлән, циклларның берсе — 12 ел (1981—1992), икенчесе 5 ел (1903—1907) дәвам иткән. Цикллар озынлыгындагы мондый билгесезлек күтәрелешнең кайчан иң югары ноктага җитүе һәм аннан соңгы чираттагы төшүе вакытын алдан белүдә зур кыенлыклар тудыра. Ләкин бу — якынлашып килгән рецессияләрне йомшарту буенча зарури булган саклык чаралары күрүдә дәүләтнең җаваплылыгын киметми.

Икътисади циклның сәбәпләре

Икътисади тотрыклылык буенча фәнни нигезләнгән сәясәт алып бару өчен, түбәндәгеләрне күзаллау зарур: бер яктан, икътисади циклларны нинди механизмнар китереп чыгара, ә икенче яктан, дәүләтнең икътисад үсешен тотрыклыландыруга юнәлдерелгән теге яки бу гамәлләренә икътисадның реакциясе нинди була. Икътисади циклларда охшашлыклар булуга карамастан, бу катлаулы күренешнең табигатен төрлечә аңлата торган күп төрле теорияләр бар. Кайбер икътисадчылар цикллар фән өлкәсендәге зур ачышлар һәм техника өлкәсендәге казанышлар кебек тышкы факторлар белән бәйле дигән караштa, чөнки мондый алгарышлар күпләп яңалык кертү дулкыны китереп чыгара, һәм бу үз чиратында яңа заводлар һәм җиһазларга капитал салуларны бик күпкә арттыра. Тышкы этәргечләр ролен табигый факторлар да (уңыш булмау) уйнарга мөмкин.

Бу теорияләрне **циклларның экзоген теорияләре** дип атау кабул ителгән.

Цикллар теорияләренең икенче төркеме аңлатманы икътисадта бара торган эчке процесслардан эзлиләр. Болары — **циклларның эндоген теорияләре**. Аларның берсенә без соңрак тукталырбыз. Шуны әйтеп китәргә кирәк: эндоген теорияләр, цикллар эчке характердагы сәбәпләрдән килеп чыгуын һәм шуңа күрә, аларның эчке яктан базар системасына хас булуын раслап, икътисадның тирбәлеш хәрәкәтен тудыручы тышкы сәбәпләр йогынтысын да кире какмыйлар. Әмма, очраклы һәм көтелмәгән фактор буларак, экзоген факторларга икенчел дәрәҗәдәге роль генә бирелә.

Циклга карата күп төрле аңлатмалар булуга карамастан, аларның күбесендә принципиаль әһәмияткә ия булган уртак кагыйдәләр бар. Бу — макроикътисадның әлеге өлкәдәге казанышлары бәхәссез дигән сүз. Хәзерге көндә цикл теорияләренең күбесе түбәндәгеләргә кайтып кала:

— ТЭП, инвестицияләр, куллану, процент ставкалары, мәшгульлек һ. б. ның тирбәлешләре икътисадның тигезләнеш халәтеннән билгеле бер дәрәҗәдәге тайпылышының нәтиҗәсе һәм чагылышы булып тора;

— реаль капиталга инвестицияләр (һәм беренче чиратта төп капиталның актив өлешенә, машиналарга һәм җиһазларга) цикл хәрәкәтендә хәлиткеч әһәмияткә ия;

— цикл механизмындагы мөһим рольләрнең берсен ТЭПның төп компонентлары (инвестицияләр һәм куллану), мәшгульлек, эшсезлек һәм монетар факторлар (процент ставкалары һәм акча массасы) арасындагы үзара бәйләнеш механизмы уйный.

13.2. ИКЪТИСАДИ ЦИКЛ МЕХАНИЗМЫ

Икътисади цикл механизмының ни рәвешле эшләвен карап үтик.

Әйтик, рецессия нәтиҗәсендә икътисад үзенең иң түбән дәрәҗәсенә төшә, ягъни милли керем, инвестицияләр һәм куллану икътисадның тигезләнеш халәте дәрәҗәсеннән түбән була. Бу — тигезләнеш теориясе нигезендә базарда товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә сорау, аларны тәкъдим итүгә караганда югары булуны аңлата. Моңа югары булмаган процент

ставкалары да (алар, төшү үзенең иң түбән дәрәҗәсенә житкәндә, шактый күләмдә кимиләр) этәргеч була. Шуңа күрә рецессия шартларында житештерүне арттыру тенденциясе барлыкка килә һәм көчәя.

Иң элек үзидарәле (автономияле) инвестицияләр, ягъни күләме корпорацияләр һәм кече бизнес тарафыннан алынган милли керем һәм табыш зурлыгыннан бәйле булмаган инвестицияләр кинәйтелә. Бу инвестицияләрнең үсеше бик үк зур булмаска да мөмкин. Әмма, белгәнебезчә, мультипликаторның нәтиҗәсе, үзидарәле инвестицияләрне арттыруга бәйле рәвештә, әлеге үзидарәле инвестицияләр үсешеннән берничә тапкырга узып киткән тулай эчке продукт күләмен арттыруны күздә тота. Бу — икътисадта фактик милли керем күләмен арттыру тенденциясе көчәйгәнне аңлата. Табыш, хезмәт хакы һәм башка керемнәр арта башлый, һәм ул үзе артыннан индуцияләнгән куллануны киңәйтә. Милли керем үсеше үзе үк яңа инвестицияләргә юл ача. Узган бүлектә билгеләп үтелгәнчә, керем үсеше белән стимуллаштырылган инвестицияләрне индуцияле (мәҗбүри) инвестицияләр дип атау кабул ителгән.

Цикллар механизмындагы индуцияле инвестицияләрнең ролен аңлау өчен, милли керем үсеше белән индуцияле инвестицияләр чагыштырмасы турындагы мәсьәләне карап үтәргә кирәк. Бу хакта 13-1 таблицасында бирелгән фаразга нигезләнгән мәгълүматлардан карагыз.

13-1 таблицасы

Милли керем үсеше белән индуцияле инвестицияләр чагыштырмасы (акселерацияләр принцибы), шартлы берәмлекләрдә

Чор	Милли керем	Милли кеременең үсеше		Төп капитал	Төп капиталның тузуы	Инвестицияләр	Инвестицияләр үсешенең темплары, %ларда
		суммасы	узган чорга карата % ларда				
0	1000	0	0	2000	200	200	–
1	1100	100	10	2200	220	420	57
2	1300	200	18	2600	260	660	39
3	1600	300	23	3200	320	920	−17
4	1800	200	12	3600	360	760	−23
5	1900	100	6	3800	380	580	−23

Таблицадан күренгәнчә, милли керем җитештерү өчен, билгеле бер күләмдә, төп капитал кыйммәтендә күрсәтелгән производство куәтләре (заводлар, фабрикалар, шахталар һ. б.) таләп ителә. Монда төп капиталның милли keremgә чагыштырмасы (2 : 1) даими кала. Машиналар һәм җиһазлар туза, һәм без аны амортизация нормасы 10% дип исәплибез. Шуңа күрә, заводлар һәм җиһазлар тузуны каплау өчен, ел саен капитал салынырга (инвестицияләнергә) тиеш. Мәсәлән, 2000 шартлы берәмлеккә тигез булган төп капиталның башлангыч (нуль) чорында тузу дәрәҗәсен 10% итеп алсак, ул — 200, ә 1 нче чорда 220 шартлы берәмлек күләмендәге реинвестицияләр аша кайтарылырга тиеш.

Әйтик, нуль чорында милли керем (1000) үзенең тигезләнеш дәрәҗәсеннән түбән була. Бу хәл товарлар җитештерүне һәм хезмәт күрсәтүләрне киңәйтү тенденциясен китереп чыгара, шуның нәтиҗәсендә 1 нче чорда милли керем дәрәҗәсе 1100 гә җитә, ягъни үсеш, узган дәрәҗәгә карата, 100 шартлы берәмлек, яки 10% тәшкил итә. Җитештерү күләмен арттыру, шуна тәңгәл рәвештә, төп капиталны 2000 нән 2200 гә (шулай ук 10% ка) күтәрүне таләп итә. Ләкин капиталны күтәрүгә 200 шартлы берәмлек күләмендәге өстәмә инвестиция ярдәмендә дә ирешергә мөмкин булыр иде. Чөнки төп капитал 2200 гә күтәрелгәч, аның амортизациясе дә 220 гә җитә, һәм, шуннан чыгып, инвестицияләрнең гомуми суммасы 200 + 220 = 420 шартлы берәмлек тәшкил итә.

Акселерация принцибы

Монда милли керем, төп капитал, аның амортизациясе һәм инвестицияләр үсешенең түбәндәге пропорцияләренә игътибар итәргә кирәк:

1) милли керемнең 10% ка артуы, шуңа пропорциональ рәвештә, төп капиталны да 10% ка күтәрүне таләп итә; амортизация чигерүләре дә шул ук пропорциядә (10% ка) үсә;

2) инвестицияләр һәм милли керем чагыштырмасына килгәндә, беренчеләре (инвестицияләр) 2,1 тапкырга, ягъни милли керемнән шактый күпкә арта.

Милли керем һәм инвестицияләр үсеше арасындагы охшаш чагыштырмалар 2 нче һәм 3 нче чорлар дәвамында да күзәтелә. Милли керем үсешенең тизлеге беренче чордагы 10% тан 2 нче

чорда — 18% ка, 3нче чорда 23% ка житә. Милли керемнең тизләтелгән үсеше нәтиҗәсендә генә, инвестицияләрне ел саен арттыра барырга мөмкинлек туа. Әмма, 4 нче һәм 5 нче чорларда күрсәтелгәнчә, милли керемнең үсеш темпы акрынаюга, инвестицияләр дәрәҗәсе дә кинәт кими башлый. Милли керем һәм инвестицияләр үсешенең мондый чагыштырмасында акселерация принцибы (яки акселератор) күренә.

> **АКСЕЛЕРАЦИЯ ПРИНЦИБЫ** нигезендә индуцияле инвестицияләр турыдан-туры милли керем (яки тулай эчке продукт) *үсеше темплары* үзгәрүгә бәйле була.

Акселерация принцибы ни өчен житештерүнең цикллы үсеше гамәлдә чиксез дәвам итә алмавын аңлату өчен зур әһәмияткә ия.

ТЭПның (тулай эчке продукт) тизләтелгән үсеше иртәмесоңмы теге яки бу илнең халык хуҗалыгы ия булган ресурсларның тулысынча эшкә җигелүенә китерәчәк: тулы мәшгульлеккә ирешеләчәк, барлык тармакларның (яки, һич югы, күбесенең) предприятиеләре бөтен куәтенә эшләячәк; чималның башлангыч чыганакларын (авыл хуҗалыгы һәм тау сәнәгате продуктлары) күпмедер дәрәҗәдә киңәйтү дә кыенлашачак. Бу этапта икътисади үсеш үзенең «түшәменә», үз мөмкинлекләренең югары чигенә ирешәчәк. Әлбәттә, чамадан артык тырышлык хисабына, ягъни заводларны өстәмә эшләтү (мәсәлән, төнге сменалар, эш сәгатеннән тыш калып эшләүләр һәм чималның ярлы һәм аз нәтиҗәле чыганакларыннан файдалану) хисабына житештерүне беразга арттырырга мөмкин. Әмма бу инде икътисадны «артык кыздыру»га, хезмәт җитештерүчәнлегенең түбәнәюенә һәм яңа инвестицияләрнең нәтиҗәлелеге кимүгә, инфляция көчәюгә һ. б. га китерәчәк. Шуңа күрә җитештерү ресурсларының чигенә якынлашкан саен һәм бигрәк тә аларны тулы куәтенә эшләткәндә, ТЭП үсеше темпы әкренәя башлый, ә моның нәтиҗәсе булып акселерация принцибы нигезендә төп капиталга инвестицияләр *кыскара*.

Әгәр цикллы күтәрелешнең башлангыч этабында мультипликаторга таякырланган яңа инвестицияләр ТЭП үсешенә, мәшгульлек һәм куллану артуга көчле импульс тудырган булсалар, хәзер инде мультипликатор механизмы кире тәэсир

ясый: ТЭП һәм милли керем, мәшгульлек һәм куллану дәрәҗәләре түбәнәя. Икътисадның җитештерү ресурслары «түшәменә» менеп җитү икътисади циклның иң югары ноктасы һәм күтәрелештән төшүгә борылу ноктасы булып тора.

ТЭП үсеше темпларының сизелерлек әкренәюе индукцияле (үзидарәле) инвестицияләр кыскаруга китерә. Шуңа күрә рецессияләр гадәттә нәкъ менә яңа капитал салулар кимүдән башлана. Инвестицияләр кыскару үз чиратында ТЭП һәм милли керемне киметә. Куллану дәрәҗәсе милли керем күләменнән функциональ бәйле булганлыктан, милли керем кимү үз артыннан куллану дәрәҗәсен дә кыскарта. Куллану кимү алга таба милли керем һәм ТЭП кыскаруын аңлата. Икътисади активлык дәрәҗәсенең мондый гомум кимү процессы милли керемнең факттагы күләменең янадан үзенең тигезләнеш дәрәҗәсендәгедән түбән төшүенә китерә. Шуның нәтиҗәсендә инвестицияләр икътисади циклның түбән ноктасына җиткәндә, шулай ук шактый түбән дәрәҗәдә калалар; сәнәгать, төзелеш һәм башка фирмаларның акча капиталына соравы сизелерлек кими; шуңа күрә банкларга, клиентларны күбрәк тарту өчен, процент ставкаларын киметергә туры килә. Шулай итеп, рецессияләр үсеше кабат инвестицияләрне һәм ТЭП үсешен стимуллаштыруның яңа тенденцияләрен тудыра.

ТЭПның потенциаль (табигый) дәрәҗәсе

Икътисади цикл барышында, икътисад хәрәкәтен анализлаудан күренгәнчә, ТЭПның циклы үсешендә ресурслар товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүгә тулысы белән җәлеп ителә. Производство куәтләрен бөтен көченә эшләтү, эш белән тәэмин ителгәнлекнең артуы һәм эшсезлекнең кыскаруы моның күрсәткечләре булып тора. Билгеле бер моментта икътисади активлык шундый дәрәҗәгә җитә ки, тулы мәшгульлеккә ирешелә, ә производство куәтләрен бөтен көченә эшләтү оптималь дәрәҗәгә якынлаша.

> ТЭПның тулы мәшгульлеккә һәм ресурслардан (барыннан да бигрәк, җиһазлардан) оптималь файдалануга ирешелгән дәрәҗәсе ЭЧКЕ ТУЛАЙ ПРОДУКТНЫҢ ПОТЕНЦИАЛЬ яки ТАБИГЫЙ ДӘРӘҖӘСЕ дип атала.

Рецессия чорында һәм циклы күтәрелешнең башлангыч чорында фактик ТЭП потенциаль ТЭПтан түбәнрәк була. Аннан соң фактик ТЭП потенциаль ТЭП күләменә якынлаша һәм аны куып җитә. Халык саны һәм җитештерүдә актив катнашырга сәләтле эшче көчләр саны арту белән бергә, потенциаль ТЭП күләме дә арта икән, ТЭПның алга таба фактик үсеше потенциаль ТЭП үсеше күләменнән узып китмәскә дә мөмкин. Циклы күтәрелеш өчен бу — иң уңайлы вариант. Әмма еш кына фактик ТЭП күләме потенциаль ТЭП күләменнән артып китә, һәм ул, әйтеп үтелгәнчә, икътисадны «артык кыздыру» белән бәйле тискәре нәтиҗәләргә китерә. Кагыйдә буларак, ТЭПның фактик дәрәҗәсе аның потенциаль дәрәҗәсеннән ныграк ераклашкан саен, рецессия күренеше көчлерәк йогынтылы ясый, һәм, шуңа бәйле рәвештә, рецессия тирәнрәк һәм дәвамлырак булган саен, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр кыскару аркасында килеп чыккан югалтулар да зуррак була. Дәүләтнең икътисади сәясәттәге иң мөһим бурычы төшүнең *тирәнлеген* һәм *дәвамлылыгын мөмкин кадәр ныграк* чикләү генә түгел, ә ТЭПның чамадан тыш югары темпта үсешенә юл куймау, чөнки бу очракта ТЭПның фактик дәрәҗәсе аның потенциаль дәрәҗәсеннән сизелерлек артып китәргә мөмкин.

Үсештә циклылык булмау планлы икътисадның өстенлеге булып саналамы?

Совет чоры икътисади әдәбиятында (фәнни һәм уку) СССРда циклы рецессияләр булмау планлы хуҗалык системасының, базарныкы белән чагыштырганда, өстенлекле ягы итеп карала. Моны раслаучы дәлилләр булып түбәндәгеләр санала:

а) эшсезлек, бигрәк тә аның циклы формасы булмау;

б) ТЭП, инвестицияләр һәм куллануның кимүе белән бәйле югалтулар булмау;

в) ТЭПның фактик һәм потенциаль дәрәҗәләренең туры килүе һәм, шуннан чыгып, фактик ТЭП потенциаль ТЭП дәрәҗәсеннән түбән булганда, ресурсларны тулысынча файдаланмаудан барлыкка килә торган югалтулар булмау;

г) гомуми нәтиҗә буларак, икътисадның кризисларсыз, инфляциясез һәм эшсезлектән башка тотрыклы үсеше.

Административ-планлы икътисад хакимлек иткән шартларда барлык бу һәм кайбер башка күренешләр, чыннан да, күзәтелә иде. Әмма алар уңай үсешне чагылдырмадылар. СССРда иҗтимагый продуктның чагыштырмача тотрыклы үсеше шактый дәрәҗәдә икътисади механизм чыгымнары белән бәйле иде. Бер яктан, конкуренция булмау һәм күп кенә дәүләт предприятиеләренең монополия хәлендә булуы һәм, икенче яктан, житештерү күләме буенча планны үтәүнең беренче дәрәҗәдәге бурыч итеп куелуы, чималны, материалларны, электр энергиясен сарыф итүне һәм житештерүнең башка факторларын продукция бәрәмлеге исәбеннән арттырырга мөмкинлек бирде, һәм ул максатка ярашлы иде. Шуңа күрә илдәге барлык иҗтимагый продукт гаять күп күләмдә материаллар һәм энергия сарыф итү хисабына житештерелә иде. Шуның нәтиҗәсендә халыкның шәхси куллану дәрәҗәсе чагыштырмача әкрен үсте; ул тау сәнәгате, металлургия, энергетика, машина төзү һ. б. үсешеннән артта калып барды.

Административ-планлы системаның чыгымнар характеры шуннан гыйбарәт була: аерым предприятиеләрнең житәкчеләре, шулай ук министрлыклар яңадан-яңа инвестицияләрнең барысын да бюджеттан финанслауга (бу икътисади яктан акланмый) ирешәләр. Яңа төзелешләрнең мондый юл белән ирешелгән кызу темплары төзелеш материалларына, җиһазларга һ. б. га сорауны чиктән тыш арттыруга китерә, һәм ул тулысынча канәгатьләндерелә алмый. Шул сәбәпле озакка сузылган төзелешләр гаять зур чыгымнарның хәрәкәтсез ятуы, предприятиеләрнең хуҗалык эшчәнлегенең һәм, тулаем алганда, икътисадның ахыргы түбән нәтиҗәләре барлыкка килә.

Чыгымнар механизмы эшчәнлегенең гомуми нәтиҗәсе булып ТЭП һәм милли керемнең (ягъни товарлар житештерү һәм хезмәт күрсәтүләр үсешенең төп күрсәткечләре үсеш темплары) арадаш продуктлар (руда, нефть, металлар һ. б.) житештерүне киңәйтү белән чагыштырганда да һәм инвестицияләр белән чагыштырганда да, пропорциональ дәрәҗәдә булмыйча, түбән булу тора. Ә иҗтимагый продуктның иң мөһим өлеше һаман үсә баручы хәрби-сәнәгать комплексларын тәэмин итүгә юнәлдерелә. Бу комплекслар арадаш продуктларны һаман саен күбрәк йота бара, илдәге ресурсларның күп өлеше алар ихтыяҗын канәгатьләндерүгә тотыла.

Илдә гаҗәп хәл күзәтелә: җитештерү чаралары җитештерү чараларының үзләрен тәэмин итү һәм кораллануны арттыру, камилләштерү өчен җитештерелә. Ул матди ресурсларга гына түгел, ә бәлки эшче көчләргә дә (бигрәк тә югары квалификацияле белгечләргә) ихтыяҗ китереп чыгара. Мондый нигездә ирешелгән тулы мәшгульлек һәм эшсезлек булмау, ул әле халык хуҗалыгының хезмәт ресурсларыннан рациональ файдалануны күрсәтми. Җитмәсә, зур масштабларда яңа предприятиеләрне сафка бастыру шартларында хезмәт ресурсларына җитди кытлык туу яңа барлыкка килгән производство куәтләрен бөтен көченә эшләтә алмау сәбәбенә әйләнә.

Шулай итеп, тулы мәшгульлек, циклы рецессияләр булмау һәм ТЭПның тотрыклы үсеше күрсәткечләре артында илнең матди, финанс һәм хезмәт ресурсларын бик нык әрәм-шәрәм итү тора.

13.3. МӘШГУЛЬЛӘР ҺӘМ ЭШСЕЗЛӘР

Шулай итеп, без базар икътисады үсешенең тигез генә бармавын — эш активлыгы җанлану периодлары төшүләр белән чиратлашуын ачыкладык. Бу илдәге эш белән тәэмин ителгән халык санында чагылыш тапмый калмый. Әмма парадокс шунда: базар икътисады хөкем сөргән илләрдә күтәрелеш чорларында да күпмедер дәрәҗәдә эшсезлек саклана. 1944 елда, мәсәлән, АКШта эшче көчләрнең алтыдан бер өлеше армиядә була, эшче җитмәү аркасында, пенсионерлар яңадан эшкә чыга, эш атнасы 6—7 көннән тора, ә эшләргә теләүчеләрнең 1,2% ы эш таба алмый.

Мондый күренешләрнең сәбәбе нәрсәдә соң? 100% эш белән тәэмин ителүгә ирешергә буламы? Бу сорауларга җавап бирү өчен, безгә бик игътибар белән илдәге халыкның структурасын өйрәнергә кирәк.

Иң элек шуны билгеләп үтик: халыкның барысы да хезмәткә сәләтле булмый, бөтен кеше дә товар җитештерүдә һәм хезмәт күрсәтүләрдә катнаша алмый. Шуңа күрә **эшкә яраклы** (хезмәткә сәләтле) һәм **эшкә яраксыз** кешеләрне аерырга кирәк. Статистика 16 яшьтән яшьрәк һәм пенсия яшенә җиткәннәрне (хатын-кызлар өчен — 55, ирләр өчен — 60 яшь) эшкә яраксызларга кертә. Россия һәм башка күпчелек илләрдә җитештерүдә балалар хезмәтеннән файдалану закон нигезендә тыела.

Әмма эшкә яраклы һәр кеше дә җитештерүдә катнашырга теләми. Эшкә яраклы кешеләрнең билгеле бер өлеше (мәсәлән, хуҗабикәләр) эшләмиләр һәм үзләренең йорт хуҗалыкларыннан чыгып эшләргә җыенмыйлар. Шуңа күрә халыкның эшкә яраклы өлешеннән **халыкның икътисади актив өлешен** яки **эшче көчләрне** аерып карарга кирәк. Халыкның бу өлешен кайчагында һәвәскәр кешеләр, диләр. Шулай итеп, икътисади актив халык, яки эшче көчләр җыелмасы — алар барысы да эшли алучы һәм эшләргә теләүче затлар. Әмма эшли алучы һәм эшләргә теләүче кешеләрнең барысы да дәүләт хезмәтендә, хосусый фирмаларда яки шәхси бизнес өлкәсендә эшләмиләр. Ягъни икътисади актив халыкның күпмедер өлешенә эш булмый. Шуңа күрә аларны **мәшгульләргә** һәм **эшсезләргә** аеру зарур.

> МӘШГУЛЬЛӘР — илдәге икътисади актив халыкның ялланып эшләүче, шәхси бизнес белән шөгыльләнүче, дәүләт хезмәтендә эшләүче яки укучылар өлеше.

Бу Россия законнарында да чагылыш тапкан. Россиянең гамәлдәге законнары нигезендә түбәндәге гражданнар мәшгульләр булып санала:

— эш көне тулы яки тулы булмаган шартларда ялланып эшләүчеләр;

— вакытлыча эшкә сәләтен югалткан һәм чираттагы ялда булу сәбәпле, эшкә йөри алмаучылар;

— мөстәкыйль рәвештә үз-үзләрен эш белән тәэмин итүчеләр, шул исәптән эшмәкәрләр дә;

— Кораллы көчләрдә һәм эчке эшләр органнарында хезмәт итүчеләр;

— гомуми белем бирү мәктәпләрендә, һөнәри-техник училищеларда, югары һәм махсус урта уку йортларында укучылар.

> ЭШСЕЗЛӘР — икътисади актив халыкның эшләргә теләүче, эш эзләүче, әмма теге яки бу сәбәпләр аркасында эш тапмаучы өлеше.

Россия законнары нигезендә түбәндәге гражданнар эшсез булып саналалар:

— эше һәм хезмәт хакы булмаганнар;

— үзләренә яраклы эш табу максаты белән мәшгульлек хезмәте органнарында теркәлүчеләр;

— эшли башларга әзер торучылар.

Шулай итеп, эше булмаган теләсә кайсы кеше эшсезләр категориясенә кертелә алмый. Эшче көчләр сафына кушылмыйча, үз ирекләре белән эшсезләр дип аталучылар да бар. Аларның потенциаль яктан эшләү мөмкинлекләре бар, әмма эшләмиләр һәм эш эзләмиләр. Ирекле эшсезләр булып, мәсәлән, пенсионерлар, хуҗабикәләр, түләнми торган йорт эше башкаручылар һәм кечкенә яшьтәге балалар тәрбияләүчеләр санала. Эш табуга өмете сүнгән һәм аны эзләүдән туктаган эшсезләр дә шушы категориягә керә. Эшкә сәләтен югалтмаган, эшли башларга үзенең һәрвакыт әзер торуын раслаучы, һәм моның өчен, мәшгульлек хезмәте органнарында теркәлеп, даими рәвештә (Россиядә, ким дигәндә, айга ике тапкыр) теркәлүен яңартып һәм андагы вакансияләрне белешеп торучылар гына эшсезләр булып санала.

Икътисади актив халык составына төрмәдә утыру срогын узучылар яки махсус шифаханәләрдә булучылар керми. Бу кешеләр институциональ халыкка керә.

Халыкның санап үтелгән барлык категорияләре дә 13-2 рәсемендәге схемада күрсәтелгән.



13-2 нче рәсем. △

2004 елда Россиядәге хезмәткә яраклы халыкның структурасы *(млн кеше)*.

Эшсезлек масштаблары, беренчедән, эшсезләрнең абсолют саны күрсәткече белән, икенчедән, эшсезлек нормасы белән билгеләнә.

ЭШСЕЗЛЕК НОРМАСЫ — ул эшсезләр санының барлык эшче көчләр санына процентларда күрсәтелгән чагыштырмасы.

$$r_U = \frac{U}{L} \times 100\% \qquad (13.1)$$

монда U — эшсезләр саны; L — эшче көчләр саны; r_U — эшсезлек нормасы.

2002 ел башында Россиядә 71,8 млн икътисади актив халыкның 6,1 млн ы эшсезләр була. Димәк, эшсезлек нормасы 8,5% тәшкил итә. Бу мәгълүматлар эшсезлек бүген Россиядә иң мөһим социаль проблемаларның берсе булуы хакында сөйли.

Көнбатыш илләр хөкүмәтләре өчен дә бу проблема ин житдиләрдән санала. Ул 13-2 таблицасында бирелгән мәгълүматларда чагыла.

13-2 таблицасы

Базар икътисады югары үсеш алган илләрдә эшсезлек дәрәҗәсе, % ларда

Илләр	1980–1989	1990–1999	1991	1993	1998	2002
Икътисади үсеш алган илләр:	6,9	7,1	6,6	7,7	6,8	6,6
АКШ	7,3	5,9	6,8	6,9	6,5	6,0
Япония	2,5	2,9	2,1	2,5	4,5	5,7
Германия	7,0[1]	9,1	5,5	8,8	10,9	7,8
Франция	9,0	11,2	9,4	11,6	11,7	8,9
Испания	17,9	20,2	16,3	22,7	20,8	17,6

Кайбер белгечләр фикеренчә, эшсезлек нормасы теге яки бу илнең хезмәт базарындагы хәлләрне, ягъни эшче көчләргә

[1] ГФРда (ГДРдан башка) эшсезлек нормасы.

сорауны һәм аны тәэмин итүне яки хезмәткә урнашуның реаль мөмкинлекләрен тулысынча яктыртмый. Кайчагында эшсезлек нормасы чагыштырмача түбән булганда да, эшсезлек озакка сузылучан, хроник форма алырга мөмкин. Шуңа күрә, хезмәт базары торышын бәяләгәндә, бер буш эш урынына туры килгән эшсезләр санын чагылдырган күрсәткеч файдаланыла. Көнчыгыш Европа илләрендәге һәм Россиянең кайбер регионнарындагы шушы юл белән исәпләнгән эшсезлек күрсәткече, күчешле икътисад шартларында эш эзләүчеләргә хезмәткә урнашу буенча, җитди проблемалар булуын дәлилләде. 90 нчы еллар ахырында Иваново һәм Владимир өлкәләрендә, Чувашиядә, Калмыкиядә һәм Удмуртиядә вакантлы бер урынга 20 дән алып 117 гә кадәр эшсез кеше туры килә иде.

13.4. ЭШСЕЗЛЕКНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

Базар хуҗалыгында даими рәвештә эшсезлек хөкем сөрү нәрсә белән аңлатыла соң? Аның сәбәпләре берничә, һәм, эшсезлекне нинди сәбәпләр китереп чыгарудан бәйле рәвештә, эшсезлекне формаларга яки типларга да аералар.

Фрикцион эшсезлек

Барыннан да бигрәк, *фрикцион эшсезлек* котылгысыз. Аерым кеше өчен ул, кагыйдә буларак, дәвамлы булмаган, вакытлы характер ала. Бу категориягә бер эштән икенче эшкә күчү процессы кичергән яки хезмәт базарына әле килеп кенә кергән кешеләр карый. Ул үз эченә түбәндәгеләрне ала: уку йортын тәмамлаганнан соң эш эзләүче яшьләр; балалар үстергәннән соң яңадан эшли башларга теләүче хатын-кызлар; хәрби хезмәттән запаска чыгучылар яки үз теләге буенча, я булмаса яңа яшәү урынына күчү сәбәпле, эштән китеп, яхшырак эш эзләүчеләр. Әгәр эш эзләү уңышлы булса, үзенең күңеленә һәм сәләтенә ятышлы эш тапкан кеше дә ота, һәм җәмгыять тә ота, чөнки үзен канәгатьләндергән эштәге кеше хезмәте, эшне теләмичә башкаручыныкыннан, күпкә нәтиҗәлерәк була. Фрикцион эшсезлек гадәттә эшче көчләрнең 2—3% ын тәшкил итә.

Структур эшсезлек

Фрикцион эшсезлектән тыш, әле *структур эшсезлек* тә була. Аның аермасы шунда: ул, кагыйдә буларак, озакка сузылган характерда. Структур эшсезлек эш урыннары структурасы (хезмәткә сорау) белән эшче көчләр структурасының туры килмәвеннән килеп чыга. Фәнни-техник казанышлар җитештерүдә структура ягыннан үзгәрешләргә китерә һәм кайбер һөнәрләргә (мәсәлән, корыч коючы, шахтер һ. б.) сорауны киметә. Икенче яктан, эшсезлекнең яңа тармаклары һәм төрләре барлыкка килә, шуның белән бергә, яңа һөнәргә (мәсәлән, программист, информацион системаларны көйләүче һ. б.) ия булган хезмәткәрләргә кытлык туа. Структур эшсезлек, эшсез калган кешеләр күп булуга карамастан, илдә вакансияләр санының да аз булмавын чагылдыра, әмма аларга тәкъдим итү өчен эшсезләрне башта билгеле бер вакыт дәвамында, кайчагында озаграк та, яңадан өйрәтергә-укытырга кирәк була.

Технологик эшсезлек

Структур эшсезлекнең *технологик эшсезлек* дип атала торган төре дә бар, ул җитештерүгә хезмәтне җиңеләйтүнең өр-яңа җиһазларын, бигрәк тә информацион техника кертү белән бәйләнгән. Производствоны компьютерлаштыруны хезмәткәрләрнең зур категориясе бик авыр кабул итте, хезмәт базарында аларның хәле әле күптән түгел генә бераз тотрыклыланды. Эшсезләр сафына, Көнбатыш үлчәмнәреннән караганда, белем дәрәҗәсе әллә ни югары булмаган контора хезмәткәрләреннән тыш, бухгалтерлык исәп-хисабы, җитештерү контроле һәм планлаштыру бүлекләрендә эшләүчеләр күбрәк эләгә. Шушы унъеллык башыннан, күп кенә сәүдә операцияләрен компьютерлаштыру аркасында, Көнбатышның югары үсеш алган илләрендә ваклап сату белән шөгыльләнүчеләр саны арту сизелерлек акрынайды (80 нче еллар дәвамында алар башка барлык тармаклардагыга караганда да югарырак үсеш биргәннәр иде); ә 1992 елда бу өлкәдә эшләүчеләр саны кыскару абсолют зурлыкка җитте.

Эшлексезлекнең табигый дәрәҗәсе

Икътисадчылар, фрикцион һәм структур эшсезлекне котылгысыз күренеш, шуңа күрә халыкның тулы мәшгульлегенә илдә

нәкъ менә шушы ике формадагы эшсезлек булганда гына ирешергә мөмкин, дип саныйлар. Тулы мәшгульлек булганда, җитештерүдә эшче көчләр 100% тан бераз кимрәк катнаша. Фрикцион һәм структур эшсезлек шартларындагы тулы мәшгульлек хөкем сөргәндә, эшсезлек дәрәҗәсен *эшсезлекнең табигый дәрәҗәсе* дип атыйлар.

> ТУЛЫ МӘШГУЛЬЛЕК дип икътисадта фәкать фрикцион һәм структур эшсезлек булгандагы мәшгульлек дәрәҗәсе атала.

Эшсезлекнең табигый дәрәҗәсе үзгәрешсез зурлык булып кала алмый, Көнбатыш икътисадчылары фикеренчә, ул 4—6% лар тирәсендә тирбәлә. Икенче бөтендөнья сугышы елларында дәүләт, эш сәгатеннән тыш калып эшләүләрне кертеп яки эштән китүне тыеп, ясалма рәвештә фрикцион эшсезлек тудырган шартларда табигый эшсезлек дәрәҗәсе кыскара. Көчле үзгәртеп корулар барган чорларда эшсезлекнең табигый дәрәҗәсе структур эшсезлек хисабына арта.

Циклы эшсезлек

Җитештерүнең икътисади артка чигенеш чорларында эшсезләр саны арта, һәм ул циклы эшсезлек китереп чыгара. *Циклы эшсезлек* — ул базар икътисады үсешенең циклы характеры белән бәйле эшсезлек. Артка чигенеш вакытында аның дәрәҗәсе 8—10%ка җитәргә мөмкин. Ә 1929—1933 еллардагы Бөек депрессия елларында ул 25% ка җитә, ягъни һәр дүртенче кеше эшсез кала. Икътисади күтәрелеш вакытында циклы эшсезлек дәрәҗәсе кыскара, һәм ул үзенең табигый нормасына җитә.

Мәҗбүри эшсезлекне базар механизмы үзе китереп чыгара. Конкурентлык еш кына күп санлы шәхси предприятиеләрне банкротлыкка чыгара. Үзенең яшәешенең беренче өч елында шәхси фирмаларның өчтән береннән алып яртысына кадәре бөлгенлеккә төшә. Һәр елны күп санлы яңа фирмалар артып торса да, икътисади артка чигенеш елларында вак бизнес эшсезләр санын арттыруга китерә. Уртача һәм эре фирмалар да банкротлыктан гарантияләнмәгән. Банкротлык ул техник яктан артта калу яки оештыру дәрәҗәсенең йомшак булуы белән генә бәйләнмәгән. Аның сәбәпләре еш кына кредит килешүләрен



13-3 нче рәсем. △
Табигый һәм циклы эшсезлек.
Табигый эшсезлек икътисади циклның барлык фазаларында да саклана. Циклы эшсезлек төшү вакытында барлыкка килә һәм, төшү чираттагы циклы күтәрелү белән алышынганда, ул әкренләп кими һәм юкка чыга. Икътисад бу чорда тулы мәшгульлеккә ирешә.

тормышка ашырганда килеп чыккан яки сорау дәрәҗәсен исәпкә алмыйча яңа төр продукция җитештерү белән бәйле ялгышлыклардан барлыкка килә. Нәтиҗәдә әйтеп узган формаларына охшамаган эшсезлек килеп туа.

Табигый һәм циклы эшсезлек шартларындагы тулы мәшгульлек хәрәкәтенең гомуми күренеше 13-3 рәсемендә күрсәтелгән.

Яшерен эшсезлек

Яшерен эшсезлекнең дә әһәмияте зур. Яшерен эшсезлек кешеләр тулы булмаган эш көне яки тулы булмаган эш атнасы белән эшләгәндә барлыкка килә. Алар, эшсез буларак, рәсми

рәвештә теркәлмиләр, һәм аларның бер өлешен, мәсәлән, кечкенә балалары булган хатын-кызларны, тулы булмаган мондый мәшгульлек бик тә канәгатьләндерә. Әмма яшерен эшсезләр арасында тулы эш көне яки тулы эш атнасы белән эшләргә теләүчеләр, ләкин андый эш таба алмаучылар да бар. Көнбатыш Европа илләрендә — һәр сигезенче, ә Бөекбритания, Швеция, Нидерландиядә һәр өченче — бишенче эшкә яраклы кеше тулы булмаган эш атнасы белән эшли.

13.5. ЭШСЕЗЛЕК НӘТИҖӘЛӘРЕ ҺӘМ ДӘҮЛӘТНЕҢ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛҮНЕ ҖАЙГА САЛУЫ

Эшсезлекнең социаль нәтиҗәләре

Эшсезлек — барыннан да бигрәк, эшсез калган кешеләрнең үзләре өчен җитди сынау. Ул гаиләнең тулай керемен киметә һәм тупланган акчага яки эшсезлек пособиесенә яшәргә мәҗбүр итә. Гаиләнең яшәү дәрәҗәсе түбәнәя. Эшсез кеше, әгәр аның эшсезлек чоры озакка сузыла икән, үзенең квалификациясен югалта, һәм ул инде югары һөнәри хәзерлекле эшче таләп ителә торган эш дәгъвалый алмый.

Моннан тыш, эшсезлек эшен югалткан кешегә психик травма ясый, чөнки ул үзен җәмгыятьтә артык һәм кирәкми торган кеше итеп хис итә башлый. Табиблар, юкка гына озакка сузылган һәм күпләрне эченә алган эшсезлек милләтнең саулыгына зыян китерә, дип әйтмиләр.

Төрле тикшеренүләрдән күренгәнчә, эшсезләрнең үзләрен начар хис итүдән, йокысызлыктан һәм баш авыртудан башлап, үз-үзләрен кимсетеп карaулары, тормыштан канәгатьсезлекләре һәм башка күп кенә психик проблемалар нәтиҗәсендә физик һәм психик яктан хәлләре начарлана.

Эшсезлек бигрәк тә урта уку йортларын тәмамлаган яшьләр арасында куркыныч. Һөнәри әзерлекләре һәм белгечлекләре булмау аларга эшкә урнашуда шактый катлаулы проблемалар тудыра. Мондый шартларда аларның бер өлеше җинаятьчел тирәлеккә барып эләгергә мөмкин.

Эшсезлекнең икътисади нәтиҗәләре

Эшсезлекнең социаль нәтиҗәләреннән тыш, җәмгыять өчен турыдан-туры икътисади чыгымнары да була. Кешеләрнең бер өлеше эшсез кала икән, димәк, җитештерү тулы мәшгульлек шартларында ирешелә торган күләм белән чагыштырганда кими дигән сүз. Җәмгыять җитештерелми калган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәрабәренә югалтулар кичерә булып чыга. Икътисадчылар бу югалган продукцияне, фактик ТЭПның потенциаль ТЭПтан күпмегә кимрәк булуын күрсәткән зурлыкны тәшкил итүче **тулай эчке продукт күләменең артта калуы** дип бәялиләр. Потенциаль ТЭП — ул реаль ТЭП күләме, ә аңа фәкать ресурсларны тулы файдаланганда гына ирешеп була, чөнки потенциаль һәм фактик ТЭПлар арасындагы аерма фактик ТЭПның потенциаль ТЭПтан артта калуын күрсәтә:

ТЭП күләменең артта калуы =
= Потенциаль ТЭП − Фактик ТЭП.

Оукен законы

ТЭП үсеше темпларының циклы тирбәлеше үзе артыннан эшсезлек күрсәткечендә дә тирбәлешләр китереп чыгара. ТЭП үсеше темпларының артуы яңа барлыкка килгән эш урыннары санын арттыруны күздә тота, һәм нәтиҗәдә хезмәткә сорау, аны тәкъдим итүгә караганда, тизрәк арта. ТЭП үсеше темпларының кимүе моңа капма-каршы нәтиҗәләргә китерә: ТЭП үсеше темплары әкренәйсә, эш урыннары саны да әкренрәк арта; өстәвенә эш урыннары саны үсүдән бөтенләй туктарга һәм хәтта кыскарырга да мөмкин.

Шулай итеп, ТЭП үсешенең югары темплары эшсезлек кыскаруга китерә, ә ТЭП үсешенең әкрен темплары эшсезлек артуга китерә яки, һич югы, бертөрле дәрәҗәдә калдыра. Шуңа бәйле рәвештә ТЭП үсеше темплары белән эшсезлек нормасы үзгәрү арасындагы санча чагыштырма турындагы мәсьәлә теоретик һәм гамәли яктан иң әһәмиятле мәсьәләгә әйләнә. Бу сорауга **Оукен[1] законы** принципиаль җавап бирә, ул түбәндәге кагыйдәләрне эченә ала:

---

[1] Америка икътисадчысы Артур Оукен XX гасырның 60 нчы елларында АКШ президенты каршындагы Икътисади консультантлар советын җитәкли.

— әгәр ТЭП үсеше темпы елга 2,5% булса, эшсезлек нормасы үзгәрми[1];
— әгәр ТЭП үсеше темпы 2,5% тан югары булса, эшсезлек нормасы кими; монда ТЭП үсеше темпының 2,5% тан югары булган һәр процент пункты эшсезлек нормасын 0,4 процент пунктына киметә;
— әгәр ТЭП үсеше темпы 2,5% тан ким булса, эшсезлек нормасы арта; монда ТЭП үсеше темпының 2,5% дәрәҗәсеннән кимүе эшсезлек нормасын ТЭП кимүнең һәр проценты пунктына 0,4 процент пункты күләмендә арттыра.

Оукен законын гомуми формада түбәндәге тигезләмә белән күрсәтергә була:

$$\Delta U'_r = -0{,}4 \times \left(\frac{\Delta ТЭП}{ТЭП} \times 100\% - 2{,}5\%\right), \qquad (13.2)$$

монда $\Delta U'_r$ — эшсезлек нормасының артуы.

13.2 тигезләмәсе хөкүмәтнең, эшсезлек нормасын киметүгә ирешү өчен, ТЭП үсешенең нинди темпына омтылырга тиешлеге турындагы мәсьәләне хәл итүдә файдаланыла ала. Мәсәлән, әгәр илдә эшсезлек нормасы 10% ка тигез икән, эшсезлекнең котелгән дәрәҗәсе эшсезлекнең 6% күләмендәге табигый нормасына тигез булырга тиеш, һәм бу очракта хөкүмәт түбәндәге карарны кабул итә ала: еллык уртача ТЭП үсешенең темпы 5% ка тигезләнергә тиеш. Бу — эшсезлекнең һәр елны 1% ка кимеп, 4 елдан соң аның көтелгән дәрәҗәсенә ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Дәүләтнең эш белән тәэмин ителүне җайга салуы

Базар икътисады югары үсеш алган илләрнең күпьеллык тәҗрибәләреннән күренгәнчә, базарның үзкөйләнү механизмы хезмәт базары проблемаларын тулысынча үзеннән-үзе хәл итәргә сәләтле түгел. Беренче чиратта бу — эшсезлеккә кагыла. Шуңа күрә эшсезлек проблемасы дәүләт ягыннан да, профсоюзлар ягыннан да җитди игътибар таләп итә. Көнбатышның алга киткән илләрендә эш белән тәэмин ителүне җайга салуның сугыштан соңгы еллардагы нәтиҗәсе мәшгульлек сәясә-

[1] Соңгы тикшеренүләр күрсәткәнчә, ТЭП үсешенең эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен үзгәрешсез калдырган, ә эшсезлек нормасын бер пунктка киметкән темпы 2,8—3,0% ка тигез була.

тенең гомуми рецептлары, даими йогынты ясаучы чаралар булмавын күрсәтте. Ул, социаль-сәяси һәм икътисади төзелеш үзенчәлекләреннән, мәдәни традицияләрдән чыгып, илдән илгә төрлеләнеп, икътисадта һәм хезмәт базарындагы вазгыять үзгәрүгә бәйле рәвештә үзгәреп тора. Шулай да XX гасырның 50—70 нче елларында мәшгульлекне җайга салуның Дж. М. Кейнс һәм аның дәвамчылары тарафыннан тәкъдим ителгән методлары өстенлек алды.

Кейнс рецепты

Кейнс тәкъдимнәре нәрсәдән гыйбарәт соң?

Кейнсчылар исәпләвенчә, эшсезлекнең сәбәпләре гомуми сорауның җитәрлек дәрәҗәдә булмавында, һәм алар, кредит-акча һәм финанс чаралары (салымнарны һәм кредит процентларын киметү) ярдәмендә аны стимуллаштыру өчен, өстәмә эш урыннары булдыруны тәкъдим итәләр. Алар методы буенча мәшгульлеккә, хезмәтнең локаль һәм тармак базарлары арасындагы аермаларга карамыйча, макроикътисади дәрәҗәдә йогынты ясау күздә тотыла.

80 нче елларда фәкать АКШта һәм Франциядә генә, эш белән тәэмин ителүне арттыру чарасы буларак, салым ташламалары кулланылган кечкенә экспериментлар үткәрделәр. Көнбатышның күп кенә икътисадчылары фикеренчә, салым ташламалары куллану җитештерүне киңәйтергә ярдәм итәргә мөмкин, әмма ул шуңа пропорциональ рәвештә эш белән тәэмин ителгәнлек үсә дигән сүз түгел әле, чөнки фәнни-техник прогресс заманында эшләп торган фирмалар кул хезмәтен алыштыру техникасын киң кулланалар, аларда эшләүчеләр саны аз була.

Шуңа күрә 80 нче еллар уртасында дәүләтнең хезмәт ресурсларына йогынты ясаучы төп коралы булып турыдан-туры эшче көчләр базарында үткәрелә торган сәясәт санала. Ул ике юнәлештә тормышка ашырыла: эшсезлек дәрәҗәсен һәм аның дәвамлылыгын җайга салу һәм аннан зыян күрүчеләрне социаль яклау.

Эшсезлек дәрәҗәсен һәм аның дәвамлылыгын җайга салу

Эшсезлек дәрәҗәсен һәм аның дәвамлылыгын җайга салу эшкә урнаштыру хезмәтләрен (хезмәт биржалары) көйләп җибәрү аша алып барылырга мөмкин; бу хезмәтләр, бушаган

эш урыннары турында мәгълүматлар системасы оештырып һәм аларны камилләштереп, кешенең эш эзләү вакытын кыскарталар.

Хезмәт биржалары XX гасырның беренче яртысында ачыла башлый. Алар Мәскәү, Петербург, Рига, Одесса кебек эре сәнәгать үзәкләрендә шәһәр белән идарә итүчеләр (управалар) тарафыннан оештырыла. 1917 елга чаклы Россиядә, хезмәт биржалары белән беррәттән, түләүле шәхси арадашлык конторалары да киң җәелдерелә.

Россиядә «РСФСР халкының эш белән тәэмин ителгәнлеге турында»гы Закон нигезендә оештырылган һәм Көнбатыштагы шуңа охшаш оешмалар эшчәнлегенең дөньякүләм тәҗрибәсен туплаган эш белән тәэмин итү хезмәтләре эшсезләргә һөнәри юнәлешләр буенча бушлай консультацияләр бирәләр, эш сайлауда арадашлык һәм ярдәм күрсәтү оештыралар. Дәүләт яңа һөнәргә (белгечлеккә) бушлай укытуны һәм квалификация күтәрүне, яңа урынга күчкәндә субсидияләр бирүне, җәмәгать эшләрендәге вакытлыча мәшгульлекне гарантияли.

Көнбатыш тәҗрибәсе күрсәткәнчә, кыска вакытлы, түбән һөнәри дәрәҗәле эш урыннары (еш кына бу эшләр шәһәр территориясен җыештыру яки юл төзелеше белән бәйле була) булып саналган җәмәгатьчелек эшләре тәкъдим итеп кенә эшче көчләр базарындагы җитди проблемалар хәл ителми. Шулай да, эшсезлек нәтиҗәләрен бераз җиңеләйтү, аеруча мохтаҗлык кичергән, үзеннән тыш тагын аның тәрбиясендә кешеләре булган эшсезләргә матди ярдәм күрсәтү чарасы буларак, җәмәгатьчелек эшләре шактый киң файдаланыла. Европа Берлеге илләрендәге эш белән тәэмин ителгәнлек мәсьәләләре буенча комиссиянең 1993 елның кышында игълан ителгән тәкъдимнәрендә әйтелгәнчә, җәмәгать эшләре оешмасы, бигрәк тә социаль хезмәт күрсәтүләр сферасында (өлкәсендә), шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау программаларын тормышка ашыру буенча, соңгы елларда үсеп баручы эшсезлекне кыскартуда иң мөһим чаралардан санала.

Эшсезләрне һөнәри өзерләү системасы, хезмәт базарында сорауны һәм тәкъдим итүләрне балансплауның аеруча йогынтылы чарасы буларак, нигездә, эшне кыска сроклы характерда алып бара. Әйтик, 1992 елда француз эш белән тәэмин итү хезмәте юнәлеше буенча яңа һөнәр алучы 100 мең кешенең күпчелеге өчен укыту курслары 300 сәгатьтән артмый. Шуңа күрә аларның фәкать 38% ы гына эш таба ала.

Хезмәт базарында программаларны финанслау дәүләт бюджетыннан средство бүлеп бирүне таләп итә. Хәзерге вакытта бу чыгымнар Япониядә һәм АКШта ТМПның 0,6—0,7% ын, Италиядә, Бөекбритания һәм Норвегиядә 1,2—2% ына кадәр тәшкил итә. Нидерландиядә, Даниядә, Испаниядә бу максатларга ТМПның 3—5% ы тотыла.

Дәүләт ресурслары чикләнгән шартларда эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен тоту өчен, еш кына хезмәткә урнаштыруның традицион булмаган формалары кулланыла. Сүз социаль страховкалау чараларыннан файдалануның сыгылмалылыгы турында бара. Европаның 17 дәүләтендә эшсез калган кешегә, ул шәхси эш ачкан шартларда (гадәттә, бу хезмәт күрсәтү сферасындагы гаилә предприятиесе була), мөмкин булган максималь срок эчендә эшсезлек буенча пособиенең барлык суммасын түләүне күздә тоткан программалар кулланыла. Мондый очракларда дәүләт финанс ярдәме генә күрсәтеп калмый, ә консультация хезмәтләрен дә, хокукый ярдәмне дә бушлай күрсәтә. Дәүләт тарафыннан мондый ярдәм әлеге фирмаларның исән (эшләп-яшәп) калу мөмкинлеген бик нык арттыра. Махсус тикшеренүләр нәтиҗәләреннән күренгәнчә, актив эшчәнлек башлап җибәргәннән соң, бер елдан шушындый юл белән барлыкка килгән предприятиеләрнең яртысыннан күбрәге яшәүләрен дәвам итәләр, бу — шәхси фирмалар өчен уртача күрсәткечкә туры килә. Мондый программалар Россиядә дә кулланыла башлады, әмма, безнең илдәге икътисадның катлаулы икътисади шартларында, андый предприятиеләрне саклап калу бик авыр.

Матди һәм социаль яклау гарантияләре

Эшсезләрне матди һәм социаль яклау гарантияләре, әйтеп үткәннәрдән тыш, үз эченә тагын түбәндәгеләрне ала:

- эшсезлек буенча пособие түләү;
- предприятиедән азат ителгән хезмәткәрләргә компенсацияләр түләү;
- һөнәри әзерлек, башка һөнәргә өйрәтү яки квалификация күтәрү чорында стипендияләр түләү.

Эшсезлек буенча пособие күләме, соңгы эш урыны буенча бер елда алган уртача хезмәт хакына нисбәтле рәвештә, процентларда билгеләнә: беренче өч айда уртача хезмәт хакы-

ның — 75% ы, аннан соңгы дүрт айда — 60%, алга таба 45% түләнә, әмма бер генә очракта да пособие күләме республика, край, өлкәдәге минималь хезмәт хакыннан ким һәм уртача хезмәт хакыннан артык булырга тиеш түгел.

Пособие, эшсез кеше эш белән тәэмин итү хезмәте идарәсенә мөрәҗәгать иткәннән соң, 11 нче көннән дә соңармый түләнә башларга тиеш, ә түләү срогы, закон нигезендә каралган аерым очракларны исәпләмәгәндә, 12 айдан да артык була алмый.

Беренче тапкыр эш эзләүче гражданнарга пособие минималь хезмәт хакы күләмендә түләнә.

Эшсезләрне социаль яклауны тормышка ашырганда, социаль пособиенең формасын һәм күләмнәрен, аларны түләү срогын, бүлү ысулларын билгеләгәндә дәүләтнең бик сак булуы таләп ителә. Социаль сәясәт, икътисадның чынбарлыктагы мөмкинлекләре нигезендә оештырылганда гына, реаль нәтиҗә бирә, ә дәүләтнең социаль максатларга чыгымнары арту инфляция үсешенә китерми.

Дәүләт социаль ярдәме сайлаулы булырга тиеш, һәм аны пособиегә дәгъва итүче эшсез кешенең төгәл генә нинди төркемгә керүенә карап бүләргә кирәк. Үзенә «яраклы» эш урыны сайлауны озакка сузучы ирекле эшсезгә яки кыска вакытлы фрикцион эшсезлек полосасына эләгүчегә һәм, үз ихтыярыннан тыш, әйтик, предприятиенең ябылуы яки икътисадта җитди структур үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә эш урынын югалтучыга бертөрле караш булырга мөмкин түгел.

Әгәр эшсез кеше, аңа яраклы дип тәкъдим ителгән ике эштән баш тартса яки эштән хезмәт тәртибен бозган өчен азат ителгән булса, закон нигезендә пособие түләү туктатыла яки өзелә. Икенче яктан, бик мохтаҗлыкта яшәүче эшсез кешегә матди һәм, торактан, коммуналь хезмәтләрдән, җәмәгать транспортыннан, сәламәтлек саклау хезмәтләреннән һәм җәмәгать туклануыннан файдаланган өчен дотацияне дә кертеп, башка ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

Россиянең формалашып килүче хезмәт базары проблемаларын дәүләт катнашыннан башка хәл итәргә ярамый. Әмма Россия шартларында базар көчләренең җәелдерелүенә комачауламас өчен, эшчеләрнең дә, яллаучыларның да ирекен кысмас өчен, эш белән тәэмин ителгәнлек сәясәтенең элекке елларда чамадан тыш дәүләтләштерелүен һәм үзәкләштерелүен җиңеп

чыгу өчен аны катгый аеру мөһим. Башка илләр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, эш белән тәэмин ителгәнлек сәясәтендә үзәкләштерүне бетерү уңай нәтиҗәләр бирә, аңа регионнар шартларына җайлашырга мөмкинлек тудыра. Шул ук вакытта үз регионнарында җитештерүне, эшмәкәрлекне һәм мәшгульлекне үстерүдә хакимиятнең җирле органнарының әһәмияте арта.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Базар системасы алга киткән илләрнең икътисади үсеше, эш активлыгының тизләтелгән үсеш һәм кимү чорлары эзлекле рәвештә чиратлашу белән бара. Күтәрелеш һәм артка чигенеш чорларының регуляр рәвештә чиратлашуы икътисади үсешкә циклы характер бирә.

Икътисади циклларның сәбәпләрен аңлату бәхәсле булып кала бирә. Икътисадчыларның бер өлеше циклы тирбәлешләр тышкы этәргечләрдән (шоклардан) барлыкка килә дип, ягъни циклларның сәбәбен экзоген факторлар белән аңлаталар. Башка икътисадчылар, циклларны базар икътисадының эчке механизмнары китереп чыгара, дип уйлыйлар. Әмма теге очракта да, бу очракта да ТЭП, инвестицияләр, мәшгульлек һәм куллану дәрәҗәсенең тирбәлеше икътисадның тигезләнеш халәтеннән билгеле бер тайпылышлары нәтиҗәсе итеп карала.

Икътисад хәрәкәтен анализлаудан күренгәнчә, ТЭПның циклы күтәрелеше үзенең потенциаль (яки табигый) дәрәҗәсенә җиткәндә, тулы мәшгульлек һәм матди ресурсларны оптималь файдалану күзәтелә.

Базар икътисады шартларында эшсезлек — даими күренеш, постсоциалистик илләрдә дә, Көнбатышның алга киткән илләрендә дә шулай булган.

Эшсезләр булып икътисади актив халыкның эшләргә теләп тә ниндидер сәбәпләр аркасында эшкә урнаша алмаган өлеше санала. Алар, эш эзләү максатыннан чыгып, эш белән тәэмин итү хезмәтләрендә теркәлергә һәм эш башларга әзер булырга тиешләр.

Эшсезлек масштаблары эшсезлек дәрәҗәсе күрсәткече белән билгеләнә, ә ул эшсезләр санын эшче көчләрнең гомуми санына кертү юлы белән исәпләнелә һәм процентларда күрсәтелә.

Илдәге эш белән тәэмин ителгәнлек һәм эшсезлек проблемалары масштабларын бәяләү өчен, бер вакант урынга ничә эшсез кеше туры килүе исәпләп чыгарыла. Бу күрсәткечнең югары булуы илдә озакка сузылган эшсезлек хөкем сөрүен күрсәтә.

Тулы мәшгульлек ул әле җитештерүдә эшче көчләрнең 100% ы да катнаша дигән сүз түгел. Ул илдә эшсезлек табигый дәрәҗәдә булуны, ягъни икътисадта фрикцион һәм структур формалар гына булуын күрсәтә.

Гаилә кеременең кимүе, эшсез кешенең квалификациясен югалтуы, аның физик һәм психик хәле начарлану, илдә тулай эчке продуктны җитештереп бетермәү, кайбер очракларда җинаятьчелек арту эшсезлекнең житди нәтиҗәләре булып санала.

Дәүләтнең эшсезлек дәрәҗәсен һәм аның дәвамлылыгын җайга салуы эш белән тәэмин итү хезмәтләре аша тормышка ашырыла, һәм ул эшсез кешегә бушаган эш урыннары турында мәгълүмат бирүдә, укытуны һәм яңа һөнәргә өйрәтүне оештыруда, шәхси эш ачып җибәрергә ярдәм итүдә, җәмәгать эшләре оештыруда чагыла.

Эшсезләргә дәүләт тарафыннан матди ярдәм күрсәтү эшсезлек буенча пособиеләр бирү, укучы-өйрәнүчеләргә һәм квалификациясен күтәрүчеләргә стипендияләр түләү, яңа эш урынына күчү белән бәйле чыгымнарны каплау, үтә мохтаҗлыкка дучар булган эшсез кеше гаиләсенә (бигрәк тә әгәр аның тәрбиясендә башка кешеләр дә булса) матди ярдәм күрсәтү аша тормышка ашырыла.

Контроль сораулар һәм биремнәр

1. Икътисади цикл нинди фазалар үтүен күрсәтегез.
2. Циклларның эндоген һәм экзоген теорияләре нәрсәне аңлата?
3. Икътисади цикл барышында эш белән тәэмин ителгәнлек һәм эшсезлек дәрәҗәләре ничек үзгәрә?
4. «Икътисади актив халык», «һәвәскәр халык», «эш белән тәэмин ителгәннәр» һәм «эшсезләр» төшенчәләре арасында нинди бәйләнеш булуын аңлатыгыз.
5. Мәшгуль булмаган кешеләр эшсезләр категориясенә нинди критерийлар буенча кертелә?

6. Эшсезлек дәрәҗәсе ничек исәпләнә?
7. Ике илнең эшсезлек дәрәҗәсе түбәнрәк булганында эшсезлек проблемасы алай ук җитди түгел дигән фикер һәрвакыт дөреслеккә туры киләме?
8. Эшсезлекнең табигый дәрәҗәсе нәрсәдән гыйбарәт?
9. Йөз процент эш белән тәэмин ителгәнлеккә ирешеп буламы, һәм ул кирәкме?
10. Эшсезлекнең төп сәбәпләрен һәм аларга туры килгән формаларын атагыз.
11. Нәрсә ул яшерен эшсезлек?
12. Оукен законының асылын ачыклагыз.
13. Эш белән тәэмин ителгәнлекне җайга салуда Кейнс рецептының 80 нче еллар уртасында файдаланылган ысуллардан төп аермасы нәрсәдә?
14. Дәүләт эшсезләргә нинди социаль ярдәм күрсәтә һәм күрсәтергә тиеш?

14 нче бүлек

ИНФЛЯЦИЯ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җаваплар табарсыз:

- нәрсә ул инфляция;
- инфляция яки бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе күтәрелү ничек үлчәнә;
- базар икътисады шартларында инфляциянең нинди төрләре була, һәм алар икътисадка нинди йогынты ясыйлар;
- инфляцияне нинди сәбәпләр китереп чыгара;
- эшсезлек дәрәҗәсе үзгәрүе һәм бәяләр күтәрелү темпы үзгәрүе нинди чагыштырмада булалар;
- халыкның төрле катламнары керемнәренә инфляция нинди йогынты ясый.

Без инде күп еллардан бирле бәяләрнең гомуми күтәрелешен күзәтәбез. Икмәк һәм автомобильләр, кием-салым һәм төзелеш материаллары, метрода йөрү һәм кинотеатрларда билет бәяләре кыйммәтләнә. Ни өчен шулай дигән сорауга һәркем гади һәм җиңел генә итеп: «Инфляция»,— дип җавап бирәчәк. Инфляциянең, ким дигәндә, ике гасырлык тарихы бар. XX гасырның 40 нчы елларыннан башлап ул дөньяның барлык илләрен чолгап алды.

Бу күренешнең тышкы гадилеге һәм ачыклыгы артында икътисадта бара торган шактый катлаулы процесслар яшеренгән. Шуңа күрә инфляция турындагы мәсьәлә икътисад фәнендә, мөгаен, иң бәхәсле мәсьәлә булып торадыр. Инфляциянең табигате, аны китереп чыгарган сәбәпләр, аның икътисадка,

халыкның төрле социаль катлауларының хәленә йогынтысы хакында фәнни генә түгел, уку әдәбиятында да (дәреслекләрдә) төрле аңлатмалар, инфляциягә карата икътисади сәясәт үткәрү буенча төрледән-төрле тәкъдимнәр очратырга була. Без инфляция теориясенең икътисад теориясендә гомуми яки, һич югы, киң яклау тапкан кайбер положениеләрен карап үтү белән генә чикләнербез.

14.1. ИНФЛЯЦИЯНЕ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ АНЫ ҮЛЧӘҮ

Инфляцияне билгеләү

Инфляциянең теләсә кайсы очрагы бәяләр күтәрелүне күздә тота. Әмма бәяләр күтәрелүнең һәркайсын инфляция дип әйтеп буламы?

Бу сорауга җавап бирү өчен, *бәяләр күтәрелүнең өч очрагын* карап үтик.

Беренчедән, бәяләр күтәрелү сезонлы характер алырга мөмкин. Мәсәлән, Раштуа, Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан, бу бәйрәмнәргә әзерлек белән бәйле рәвештә, күп төрле куллану товарларына сорау арта. Һәм ул сорау куллану товарларына бәяләрнең гомуми күтәрелүенә китерә. Ләкин бу озакка бармый, һәм гыйнвар башларына инде ул, кагыйдә буларак, бәяләрнең гомуми кимүе белән алмашына. Бәяләрнең шулай, сезонлы характерда, кыска вакытка күтәрелүе икътисадка артык зур йогынты ясамый, халыкның күпчелек өлешенең реаль керемнәре дәрәҗәсенә үзгәрешләр китерми, һәм ул инфляция дип тә саналмый.

Икенчедән, кайбер очракларда товарларның яки хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә яки товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең зур булмаган төркемнәренә генә бәяләр күтәрелү күзәтелә. Мәсәлән, яңа төр (модалы) тукымадан киемнәр җитештерү тегү сәнәгатенең бу әйберләре белән кызыксынуны көчәйтә, һәм аларга тотрыклы сорау барлыкка килә, әлбәттә, бу очракта аларга бәяләр күтәрелү дәвамлы характер ала. Әмма ул бәяләрнең гомуми күтәрелешенә әверелми. Киресенчә, сорау киемнең төрле төрләренә бүлгәләнә, һәм ул күлмәкләрнең теге яки бу төрләренә бәяләрнең төшүенә китерә. Товарларның берсенә генә яки зур булмаган аерым төркеменә генә бәяләр күтәрелү бәяләрнең гомуми күтәрелүенә китерми,

шулай ук ул озакка сузылган очракта да инфляция буларак каралмый.

Өченчедән, бәяләр илдә җитештерелгән барлык товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә яки аларның зур күпчелегенә күтәрелергә, моннан тыш, ул инде, вакытлы характерда гына булмыйча, даимигә әйләнергә яки, һич югы, озакка сузылырга мөмкин. Фәкать шушы очракта гына без, икътисадта инфляция бара, дип раслый алабыз.

> **ИНФЛЯЦИЯ** — ул әлеге илдәге эчке базарда сатыла торган товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең гомуми дәрәҗәсенең озак вакытка тотрыклы күтәрелүе.

Беренче ике очрактан аермалы буларак, бәяләрнең инфляцион үсеше икътисад торышына һәм аның үсешенә, халыкның реаль кереме динамикасына һәм аларның бүленешенә турыдан-туры йогынты ясый.

Икътисадта бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе төшәргә дә мөмкин. Хәзерге заманда ул — бик сирәк күренеш, аны югары нәтиҗәле икътисадка ия булган илләрдә генә (Германия, Япония һәм АКШ) очратырга була. Бәяләрнең сезонлы характерда булмаган гомуми дәрәҗәсе төшү **дефляция** дип атала.

Инфляция үсеше бәяләрнең күтәрелүе әкренләп киму белән дә барырга мөмкин. Мәсәлән, кайсы да булса елның беренче өч аенда бәяләр уртача — 10% ка, ел урталарында — 8% ка, ә ел ахырында 7% ка артканда; аннан соңгы елда бәяләр уртача — 6% ка, аннан 5% ка күтәрелә. Бәяләр арту темпының болай әкренәюе **дезинфляция** дип атала.

Инфляцияне үлчәү

Бәяләрнең гомуми күтәрелеше — ул әле продукциянең барлык төренә дә бәяләр бер үк төрле күтәрелә дигән сүз түгел. Инфляциянең характерлы үзенчәлеге дә шунда: төрледән-төрле товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр арту төрле дәрәҗәдә була. Мәсәлән, соңгы 8 елда безнең илдә ипигә бәя якынча — 10 мең тапкырга, сөткә — 5,5 мең, телевизорларга 1,5 мең тапкырга артты. Икътисадны өйрәнү өчен, еш кына нәкъ менә бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе ничек күтәрелүен ачыклау зур әһәмияткә ия.

Бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе күтәрелү ничек исәпләп чыгарыла соң? Әгәр статистика ТЭПның номиналь һәм реаль күрсәткечләрен исәпләп чыгарса, бу сорауга җавап бирү кыен түгел.

Россиядә ТЭПның номиналь һәм реаль күрсәткечләре турындагы 11-4 таблицасында (11 нче бүлек) күрсәтелгән мәгълүматларны карап китик. 1991 елда ТЭП 1,4 трлн сумга (1991 елдагы бәяләр буенча) тигез була. 1991 елда ТЭП шушы елның база бәяләре белән күрсәтелгән, бу очракта ТЭПның номиналь һәм реаль күрсәткечләре тәнгәл килә. 1996 елда ТЭПның реаль күрсәткече 0,88 трлн сумга төшә, шул ук вакытта аның номиналь күрсәткече 2145 трлн сумга җитә. Номиналь ТЭПның мондый үсешенә фәкать бәяләрне арттыру хисабына гына ирешелә. Шулай итеп, әгәр без номиналь ТЭП зурлыгын реаль ТЭП зурлыгына бүлсәк, 1996 елда ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясенең гомуми дәрәҗәсе күтәрелү (1991 елдагы дәрәҗә белән чагыштырганда) күрсәткечен белербез. Шундый ук юл белән 1993, 1994 яки теләсә кайсы башка елда бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе күтәрелү күрсәткечен исәпләп чыгарырга мөмкин. Әлеге әллә ни катлаулы булмаган исәп-хисаплардан күренгәнчә, 1996 елда бәяләр, 1991 елдагы бәяләр белән чагыштырганда, 2430,2 тапкырга арткан. Аннан соңгы елларда да бәяләр күтәрелү дәвам итә.

> Ахыргы товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үзгәрүен күрсәтә торган номиналь ТЭПның реаль ТЭПка чагыштырмасы ТЭП ДЕФЛЯТОРЫ дип атала.

Гадәттә, бәяләрнең база дәрәҗәсе 100 итеп алынса, 1996 елда ТЭП дефляторы 243020 күрсәткече белән чагылдырыла. Бәяләр дәрәҗәсе динамикасының мондый күрсәткечләре — **бәяләр индексы**, ә ТЭП дефляторы бу очракта **ТЭП индекс-дефляторы** дип атала.

Реаль ТЭПны исәпләү методын чагылдырган 11-6 параграф (11 нче бүлек) мисалына кабат кайтып, без бу методка салынган идеянең ТЭП дефляторын исәпләп чыгаруда да кулланырга мөмкин булуын ачыклый алабыз. Әйтик, ТЭП өч төрле продукциядән — ипидән, ботинкалардан һәм станоклардан (14-1 таблицасы) тора. 1 нче елдагы ТЭП 100 мең сумга (шушы

ук елдагы бәяләрдә бирелә) тигез, 2 нче елдагы ТЭП 180 мең сумга (агымдагы бәяләрдә, ягъни 2 нче елдагы бәяләрдә чагылдырыла) тигез. Бу — 2 нче елдагы ТЭПның номиналь күрсәткече. Әгәр 2 нче елдагы ТЭПны 1 нче елдагы бәяләрдә күрсәтсәк, ул 146 мең сумга тигез булыр иде. Бу — 2 нче елдагы ТЭПның реаль күрсәткече. Димәк, 2 нче елдагы ТЭП дефляторы $\frac{180 \text{ мең сум}}{146 \text{ мең сум}} = 1{,}233$ кә тигез була. Әгәр 1 нче елдагы бәяләр дәрәҗәсен 100 итеп алсак, 2 нче елдагы ТЭПның индекс-дефляторы 123,3 кә тигез була.

Гомуми формада ТЭПның индекс-дефляторы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$I_p = \frac{\sum_{i=1}^{n} Q_i^2 P_i^2}{\sum_{i=1}^{n} Q_i^2 P_i^1}, \tag{14.1}$$

монда I_p — ТЭП индекс-дефляторы; Q^2_i — 2 нче елда продукция җитештерү; P^2_i һәм P^2_i — 1 нче һәм 2 нче еллардагы продукцияләрнең аерым төрләренең бәяләре; i — бирелгән төрдәге продукциянең тәртип номеры; n — икътисадта җитештерелә торган продукцияләрнең төрләре саны.

14-1 таблицасы

ТЭП дефляторын исәпләү

Продукция төре	1 нче ел			2 нче ел			
	Җитештерү күләме Q^1	Продукция берәмлегенең бәясе P^1, сумнарда	Продукциянең 1 нче елдагы бәяләрдә җитештерү Q^1SP^1, сумнарда	Җитештерү күләме Q^2	Продукция берәмлегенең бәясе P^2, сумнарда	Продукция җитештерү бәяләре	
						2 нче елда Q^2SP^2, сумнарда	1 нче елда Q^2SP^1, сумнарда
Икмәк	60 000 буханка	1	60 000	80 000 буханка	1,5	120 000	80 000
Ботинкалар	150 пар	200	30 000	160 пар	250	40 000	32 000
Станоклар	10 данә	1000	10 000	16 данә	1250	20 000	16 000
ТЭП	—	—	100 000	—	—	180 000	146 000

ТЭП дефляторы белән бергәттән, бәяләр дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәнең күтәрелүе күрсәткече сыйфатында товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә **кулланучы бәясе индексы** да киң

кулланыла. Ул ТЭП индекс-дефляторыннан шуның белән аерыла: аны исәпләп чыгарганда, беренчедән, кулланучылар тарафыннан сатып алынган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең генә бәяләре исәпкә алынмый; икенчедән, ваклап сату бәяләре дә файдаланыла. Кулланучылар бәясе индексын кулланып, без халыкның реаль шәхси куллану чыгымнары, кулга кергән реаль керемнәр һ. б. кебек күрсәткечләрнең дәрәҗәсен һәм динамикасын билгели алабыз. Бу күрсәткечләрдән без инфляция теге яки бу илдәге халыкның тормыш дәрәҗәсенә ничек тәэсир итүен билгеләгәндә файдалана алабыз.

> Бирелгән елдагы бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үсешенең узган елдагы бәяләр дәрәҗәсенә, процентларда күрсәтелгән чагыштырмасы ИНФЛЯЦИЯ НОРМАСЫ дип атала.

Мәсәлән, 1992 елда бәяләр индексы — 1,233 кә, ә 1991 елда 1 гә тигез була, бу очракта 1992 елдагы бәяләр дәрәҗәсе үсеше $1{,}233 - 1{,}0 = 0{,}233$ не тәшкил итә; әгәр индекслы формадан файдалансак, $123{,}3 - 100 = 23{,}3$ булыр иде. Димәк, инфляция нормасы (r_i)

$$r_i = \frac{I_p^2 - I_p^1}{I_p^1} = \frac{123,3 - 100}{100} \times \times 100\% = 23,3\% \text{ ка тигез була.} \tag{14.2}$$

Еш кына чагыштырмача озак вакыт эчендәге, ягъни берничә елдагы уртача еллык инфляция нормасын билгеләргә кирәк була. Бу очракта түбәндәге формула кулланыла:

$$\bar{r}_i = \sqrt[t]{r_i^1 \times r_i^2 \times ... \times r_i^t}\,. \tag{14.3}$$

Уртача еллык инфляция нормасы ($\bar{r}_i$) еллык инфляция нормаларының геометрик уртасына тигез була.

14.2. ИНФЛЯЦИЯНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ

Инфляция теориясендә хәлиткеч проблема булып аның сәбәпләрен ачыклау санала. Инфляция — гади һәм ачык булып тоелса да, шактый катлаулы күренеш. Шуңа күрә инфляциянең сәбәбен нинди дә булса бер күренештән чыгып билгеләү дөрес булмас иде.

Инфляция сәбәпләренең берсе итеп *кирәгеннән артык сорауны*, ягъни тулаем сорауның, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне гомуми тәкъдим итү белән чагыштырганда, тотрыклы һәм озак вакытка арту күренешен санарга була (14-1 рәс.). Табигый ки, икътисадта тулы булмаган мәшгульлек һәм производство куәтләреннән тулысынча файдаланмаган шартларда сорау инфляциясе (һәрхәлдә, теоретик яктан) булу мөмкин түгел. Мондый шартларда сорауның артуы, җитештерү факторларын тулысынча файдалану исәбенә, товарлар эшләп чыгаруны кинәйтүгә китерә, һәм шунлыктан аңа тәңгәл рәвештә аларны тәкъдим итү дә арта. Ә инде тулы мәшгульлеккә һәм производство куәтләрен бөтен көченә эшләтүгә ирешкәч, сорауның алга таба үсешен товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүне арттыру һәм аларны тәкъдим итүне үстерү исәбенә каплап булмый башлый. Икътисад үз мөмкинлекләренең чигендә эшләгәндә, сорау үсүен дәвам итсә, базарларда сорауның тәкъдим итүләрдән артык булуы хроник төс ала, һәм фирмаларның барысы да яки күпчелеге үз продукцияләренә бәяләрне күтәрә баралар. Мондый хәл тотрыклы рәвештә тигезсезлеккә һәм сорауның табигый (потенциаль) ТЭП дәрәҗәсеннән югары торуын китереп чыгара. Өстәвенә мондый шартларда бәяләр күтәрелү сорау белән тәкъдимнәр чагыштырмасын тигезләми. Моңа ирешү өчен, бәяләр күтәрелү керемнәрнең үзгәрешсез торуы яки әкрен үсүе шартларында гына барырга тиеш. Мондый очракта бәяләр күтәрелү реаль керемнәрнең кимүен һәм сорауның тәкъдим итүләр дәрәҗәсенә төшүен аңлатыр иде. Сорау инфляциясе бәяләрнең гомум үсеше фирмаларның товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатудан алган төшемнәренең бердәм артуына китерүен күздә тота. Бу үз чиратында фирмаларга зур табыш китерә, ә эшчеләргә, тулы мәшгульлек булган очракта, югары эш хакы алуга ирешү мөмкинлеге бирә.

Шулай итеп, сорау инфляциясенең чиге юк: кирәгеннән артык сорау — бәяләр күтәрелүгә, бәяләр күтәрелү — керемнәр артуга, керемнәр арту тулаем сорауның яңа күтәрелешенә китерә.

1992 елда Россия хөкүмәте, бәяләрне «ычкындырганнан» соң, ул вакытта барлыкка килгән артык сорау бәяләрнең якынча биш тапкыр артуына импульс бирер, шуннан соң



14-1 нче расем. △
Сорау инфляциясе.
Кирәгеннән артык сорау, ягъни шул ел дәвамында продукция сатудан алынган керемнәрдән (ТЭП) тыш чыганаклар исәбенә барлыкка килгән сорау хасил булу, бөтен икътисад масштабындагы тулаем сорауның тулаем тәкъдим итүдән югары булуына китерә. Бу — икътисадта бәяләрнең гомуми күтәрелүенә китерүче сәбәп була.

бәяләр билгеле бер чиккә җитәр, инфляция үзенең уртача варианттагы кысасына керер дип өметләнә. Әмма югарыга ыргылган бәяләр сорау түшәменә барып бәреләләр дигән өметләр акланмый. Бәяләр белән бергә, керемнәр дә кискен үсеш ала. Шул чакта сүтелә башлаган «бәяләр — керемнәр — сорау — бәяләр» спирале әлегә кадәр үз хәрәкәтеннән туктый алмый.

Кирәгеннән артык сорау чыганаклары булып түбәндәгеләр санала:

1) дәүләт бюджеты дефициты — ул дәүләт сарыф итә, димәк, үз керемнәреннән югары суммага сорау белдерә дигән сүз. Дәүләт «средстволары буенча яшәми», ул үзенең чамадан тыш югары чыгымнарын бернәрсә белән дә тәэмин ителмәгән кәгазь акчалар бастыру (эмиссия) хисабына яки кыйммәтле кәгазьләр базарында сатыла торган дәүләт облигацияләре эмиссиясеннән алынган керемнәр хисабына каплый;

2) агымдагы елда алынган табыш хисабына гына түгел, ә саклык акчалар һәм банк кредитлары хисабына да финанслана торган инвестицияләрне кискен киңәйтү;

3) хезмәт хакын нигезсез күтәрү һәм тагын шул ук саклык акчалар, һәм кулланучыларга кредит бирүне киңәйтү хисабына халыкның куллану чыгымнарын милли керем дәрәҗәсенә тәңгәлсез рәвештә арттыру.

Чыгымнар үсеше

Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерүче фирмалар тоткан *акча чыгымнары үсеше дә* инфляциянең сәбәбе булып тора.

Акча чыгымнары үсеше беренче чиратта күпчелек илләр икътисадындагы күп кенә төп тармакларның монополистик яки олигополистик структурасы белән дә бәйле. Базарда өстенлекле урын тоткан (олигополия) монополист-фирмалар яки фирмаларның кечерәк төркемнәре, үзләренең монополистик өстенлекләреннән файдаланып, бәяләрне үз инициативалары белән күтәрергә мөмкин. Монополияле бәяләр сәясәте икътисад тигезләнеш хәлендәме-юкмы, ТЭПның потенциаль дәрәҗәсенә ирешелгәнме-юкмы икәнлегенә карап тормыйча да алып барылырга мөмкин.

Акча чыгымнары үсешенең башлангыч импульсы булып хезмәт хакының артуы да (әмма ул фирма, тармак яки, гомумән, халык хуҗалыгы тарафыннан житештерелә торган продукциянең реаль күләме үсешендә чагылыш тапмый) хезмәт итә ала. Бу очракта үзенчәлекле монополистик структура сыйфатында профсоюз чыгыш ясый. Хезмәт хакын күтәрү турындагы таләпләр үтәлмәгән очракта, эштән баш тарту (забастовка) белән янау, фирма һәм хәтта бөтен икътисад өчен хезмәт

хакын күтәрүгә киткән өстәмә чыгымнардан да артыграк югалтулар булачагын искәртә. Бу очракта профсоюз таләпләре белән килешү мәҗбүри максатчан чара булып тора.

Хезмәт хакын мондый юллар белән күтәрү, бәяләрне монополистик күтәрү кебек үк, монополист-фирмалар продукциясен кулланучы фирмаларның акча чыгымнары артуга этәргеч ясый; фирмаларның акча чыгымнарының болай артуы хезмәт хакларын күтәрү белән дә бәйле була. Бу очракта продукция җитештерү белән бәйле акча чыгымнарының үсүе җитештерүгә тотылган чимал, электр энергиясе, хезмәт һәм башка ресурслар куллануны арттырудан тормый. Җитештерү факторлары чыгымнарының реаль чагылышы үзгәрешсез кала. Алар әле кимергә дә мөмкин. Әмма акча чагылышындагы бу чыгымнар әлеге факторлар хезмәтенә бәяләрнең күтәрелүе нәтиҗәсендә арталар. Күтәрелгән чыгымнарны каплау зарурлыгы җитештерүчеләрне бәяләрне күтәрергә мәҗбүр итә. Куллану товарларына бәя артканлыктан, ялланып эшләүчеләр, реаль, һич югы, хезмәт хакларының элеккеге дәрәҗәсен саклап калу өчен, үзләренең номиналь хезмәт хакларын күтәртүгә ирешәләр. Димәк, бәяләрне шок хәленә җиткерүне кем «беренче башлап» җибәрүгә карамастан, ул, нигездә, барлык тармакларда да чыгымнар артуны җәелдерүнең чылбыр реакциясен китереп чыгара, һәм бу күренеш бәяләрнең гомуми күтәрелүенә китерә.

Инфляцияне көтү

Инфляциянең барлыкка килүенә һәм үсеш алуына *инфляцияне көтү дә* зур роль уйный. Эшмәкәрләр дә, эшчеләр дә үз гамәлләрен, узган еллар тәҗрибәсеннән чыгып (һәм бик ихтимал булган), киләчәктә көтелгән үзгәрешләрне күздә тотып алып баралар. Кайбер мәгълүматларга ия булган хәлдә, фирмалар да, йорт хуҗалыклары да узган еллардагы хөкүмәт карарларын да, икътисадта барган үзгәрешләрне дә, тышкы икътисади факторлар йогынтысын да, үзләре элек җибәргән хаталарны да исәпкә алалар. Мәсәлән, әгәр парламент дәүләтнең чыгымнары керемнәреннән артык булган бюджетны раслый икән, бу вакытта яңа инфляция дулкынын көтәргә туры килә.

Инфляция нормасы күтәрелүне көтү күренеп торган нинди нәтиҗәләргә китерә соң?



14-2 нче рәсем. △
Чыгымнар инфляциясе.
Монополистик бәяләр барлыкка килү монополистлардан продукция сатып алучы фирмаларның бухгалтерлык чыгымнары күтәрелүгә китерә, һәм ул үз чиратында бәяләрне күтәрә. Әгәр монополистик бәяләр белән продукция сатып алучы фирма үзе дә монополист булса, ул үз продукциясенә чыгымнарны капларлык һәм өстәмә табыш килерлек бәяләр куя. Куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләр арту хезмәт хакын күтәрүгә этәрә, моңысы инде тагын чыгымнарны арттыруга сәбәп була. Ягъни инфляциянең «бәя — чыгымнар — бәя» спирале барлыкка килә.

Сәүдә, сәнәгать һәм башка фирмалар үзләрендә булган акча капиталын күбрәк яңа машиналарга һәм җиһазларга инвестицияләргә, материаллар һ. б. запасын арттырырга тырышалар, ягъни үзләренең инвестиция проектларын тормышка ашыруны тизләтергә омтылалар. Йорт хуҗалыклары да шундый ук адымнарга баралар, алар озак файдаланулы товарлар (автомобильләр, телевизорлар һ. б.) алып калырга ашыгалар. Фирмалар да, йорт хуҗалыклары да, саклык акчаларын гына хәрәкәткә җибәреп калмыйча, кредитка күп кенә товарлар алалар. Инфляцияне көтүнең турыдан-туры йогынтысы сорау үсешен тизләтүгә юнәлдерелә. Бу вакытта инфляция нормасы югарырак күтәрелгән саен, сорау үсеше дә көчлерәк барачак.

Инфляцияне көтү профсоюзлар һәм аерым ялланып эшләүчеләр тәртибенә дә билгеле бер йогынты ясый. Тегеләре дә, болары да, хезмәт контрактлары төзегәндә реаль хезмәт хакы дәрәҗәсен саклау зарурлыгына нигезләнеп һәм бәяләрнең алга таба үсәчәген фаразлап, эшкә түләү ставкаларын күтәрүгә ирешергә омтылалар.

Чимал табу тармаклары фирмалары да, якын киләчәктә, җитештерү факторлары белән тәэмин иткән өчен, аларга да күбрәк түләргә туры киләчәген сәбәп итеп, үз товарларына бәяне күтәрәләр; ә эшкәртү сәнәгате фирмалары исә үз продукцияләренең хакын күпләп сату вәкилләренә чимал өчен күбрәк түләргә мәҗбүр булуларына һәм алга таба аның тагын да артачагына таянып арттыралар. Күпләп сату белән шөгыльләнүчеләр ваклап сатучыларга карата, соңгылары йорт хуҗалыкларына карата шундый ук чаралар кулланалар.

Димәк, инфляцияне көтү сорау инфляциясенә дә, чыгымнар инфляциясенә дә сәбәп була (14-2 рәс.). Инфляцияне көтү шулай ук «юктан гына да» инфляция импульсы китереп чыгарырга мөмкин: артык сорауның объектив факторлары яки акча чыгымнары арту факторлары булмаса да, гомуми инфляция барлыкка килүне көтүгә, мәсәлән, дәүләт җитәкчеләре тарафыннан дәүләт чыгымнарының тагын үсүе, читләтеп алынган (кыек) салымнарны яки импорт тарифларын һ. б. арттыру һәм бигрәк тә акча реформасы кебек кискен чаралар турында саксызлык белән әйтелгән фикерләр дә сәбәп булырга мөмкин.

14.3. ИНФЛЯЦИЯ ФОРМАЛАРЫ

Инфляция — ул икътисадка җимергеч йогынты ясаучы афәт, керемнәрне һәм саклык акчаларны бәясезләндерә, шуның белән кешеләрнең матди байлыгына зыян сала, дип әйтү гадәткә кергән. Моннан шундый нәтиҗә ясала: һәр очракта да инфляциягә каршы кискен көрәш алып барырга, ничек кенә булса да бәяләрнен тотрыклылыгына ирешергә кирәк. Әмма, инфляциянең икътисадка нинди йогынты ясавын җентекләп тикшерүләрдән күренгәнчә, инфляциягә карата, чын-чынлап тискәре күренеш буларак, шулай берьяклы һәм кискен бәя бирү һәр очракта да гадел булмас иде. Инфляциянең икътисадка һәм халыкның көнкүрешенә нинди йогынты ясавын җитәрлек дәрәҗәдә ачык һәм төгәл билгеләү өчен, аның билгеле бер төрләре булуына игътибар итик.

Инфляция үсешенең интенсивлылыгына, ягъни аның нормаларына бәйле рәвештә, инфляциянең дүрт формасын аерып йөртәләр: нормаль (аны еш кына «шуышучан», диләр), уртача, сикерешле һәм гиперинфляция. Бу формалардагы аерымлыкларны билгеләүдә файдаланыла торган критерий булып беренче чиратта, нәкъ менә инфляция нормасының зурлыгы хезмәт итә. Әмма бу критерий инфляциянең әйтеп үтелгән төрләре арасындагы күләм ягыннан аермасын гына ачыклый, ул нормаль һәм сикерешле инфляция яки уртача һәм гиперинфляция арасындагы сыйфат аерымлыкларын күрсәтми.

Инфляциянең әйтеп үтелгән формаларының һәркайсы нәрсәдән гыйбарәт булуын һәм аның икътисадка нинди йогынты ясавын игътибар беләнрәк карап үтик.

Нормаль инфляция

Нормаль («шуышучан») инфляция бәяләрнең гомуми дәрәҗәсен, елга 5% тан арттырмыйча, әкрен генә күтәрүне күздә тота. Мондый югары булмаган инфляция нормасы, кагыйдә буларак, икътисадка уңай йогынты ясый. «Инфляция җиңелчә булганда,— дип саный Нобель премиясе лауреаты П. Самуэльсон,— сәнәгать тәгәрмәчләре әйбәт майланган була, һәм продукция эшләп чыгару җитештерү мөмкинлекләренә якынлаша. Шәхси инвестицияләр сизелерлек җәйлана, эш тә күп була. Шуңа күрә эшмәкәрләр һәм профсоюз эшлекләре югары булмаган инфляция югары булмаган дефляциядән отышлырак, диләр».

Иң элек нормаль инфляция шартларында фирмаларның нинди отышка ирешүен карап үтик. Ул шуннан гыйбарәт: бәяләрне әз генә күтәрү дә табышның шактый артуына китерә. Моны түбәндәге санлы мисаллар белән дәлилләп үтик. Әйтик, 1 кг конфет житештерү өчен, бухгалтерлык чыгымнары 100 сумга тигез, ә конфетны базарда сату бәясе 120 сум тора. Димәк, кондитер фабрикасының һәр килограмм конфет өчен бухгалтерлык табышы 20 сум тәшкил итә. Ә инфляция нормасы бу вакытта 5% булса, ел дәвамында 1 кг конфет бәясе 120 сумнан 126 сумга күтәрелә. Әлбәттә, бәяләр күтәрелү чыгымнарны да арттыра. Әмма фирма шикәр, какао һ. б. ны җитәрлек күләмдә җәй ахырында сатып ала, шулай ук эшчеләр белән хезмәт хакының билгеләнгән күләмен күздә тоткан контрактны да 1 елга төзегән була дип уйларга нигез бар. Шуңа күрә бәяләрнең 5% ка артуы фирманың чыгымнарын арттыруга китерми. Чыгымнар, бәяләр үсеше белән чагыштырганда, билгеле бер вакытка соңарып күтәреләләр. Шулай итеп, фирманың һәр килограмм конфеттан килгән табышы $126 - 100 = 26$ сумны тәшкил итә. Бәяләрнең 5% ка артуы табышны 20 сумнан 26 сумга кадәр, ягъни 30% ка күтәрә. Без шуны истә тотарга тиеш: табышның үсеше аның реаль чагылышында әзрәк була, әмма бу реаль табышны исәпкә алганда да ул $\frac{26 \text{ сум}}{105\%} = 24$ сум 76 тиенгә тигез була. Реаль табыш 23,8% ка арта.

Нормаль инфляция шартларында табыш арту производствоны киңәйтү өчен, җиһазларны яңарту (камилләштерү) өчен һәм заманча технологияләргә күчү өчен яңа инвестицияләрне арттырырга стимул бирә. Шул ук вакытта арта баручы табыш, яңа инвестицияләрне финанслау өчен дә, мөһим чыганак булып тора.

Нормаль инфляция ялланып эшләүчеләрнең дә күбесе өчен отышлы була. Инвестицияләр үсү яңа эш урыннары булдыруга, эшче көчләргә сорау артуга һәм мәшгульлек киңәюгә китерә. Бу хезмәт хакы ставкаларын арттыра; күп кенә очракларда хезмәт хакы ставкалары үсеше, бәяләр үсешенә караганда, бераз соңарыбрак тормышка ашырылса да, мәшгульлекнең бердәм артуы нәтиҗәсендә, халыкның реаль шәхси керемнең гомуми артуы күзәтелә. Нормаль инфляция шартларында социаль

киеренкелек көчәйми, эш ташлау күренешләре һәм эш ташлаулар (забастовкалар) киңәю белән бәйле эш вакытын югалтулар булмый.

Гиперинфляция

Инде үзенең нәтиҗәләре буенча, нормаль инфляциянең капма-каршысы булган гиперинфляцияне карап үтик.

Гиперинфляция процессы вакытында бәяләр ай саен уртача 50% ка арта, ягъни ел дәвамында бәяләр күтәрелү 128,746 тапкыр яки еллык уртача инфляция нормасы 12 874% ка тигез була.

Инфляция шундый коточкыч күләмнәргә җиткәндә һәм 1—2 көн эчендә акчалар бәясезләнеп калганда, *«акчадан качу»* күренеше барлыкка килә. Мондый шартларда беркемнең дә кулда акча тотасы килми; саклык банкларына саклауга салынган депозит белән дә шулай. 1,5—2 айдан ул акчаларга товарларны, бүгенге белән чагыштырганда, ике тапкырга кимрәк алырга туры киләчәк. Эшмәкәр, үз товарын сатканнан соң, керемен кичекмәстән реаль активларның теләсә кайсы төренә (чимал, запас детальләр һ. б.) әйләндереп калырга тырыша. Йорт хуҗалыклары эшләп алган хезмәт хакын шул ук көнне куллану товарлары сатып алуга сарыф итәләр. Германиядә, мәсәлән, 1922—1924 еллардагы кеше ышанмаслык дәрәҗәгә җиткән гиперинфляция вакытында хезмәт хакын көнгә ике тапкыр: кешеләр, алган акчалары тиеннәргә әйләнеп өлгергәнче, кирәк әйберләрен алып калсын өчен, хезмәт хакының бер өлешен — төшке ял вакытында, калганын кич белән бирәләр.

Акчаның сатып алу сәләте кайнар суда эрегән боз кебек юкка чыга башласа, акчалар үзләренең югары ликвидлы актив рәвешендәге төп сыйфатларын югалталар. Күп кенә фирмалар үзләренең складта ята торган продукцияләре өчен акча алудан баш тарталар һәм турыдан-туры товарны товарга алмаштырырга тәкъдим итәләр. Акча ярдәмендәге товар әйләнеше торган саен үсә барган масштабларда бартер килешүе белән кысрыклана. Куллану товарлары эшләп чыгаручы күп кенә фирмалар үзләрендәге ялланып эшләүчеләр белән исәп-хисапны үз товарлары белән ясыйлар. Эшләүчеләр өчен дә бу ысул отышсыз булмый, чөнки алар, үзләре өчен кирәкле куллану товарлары белән алышырга мөмкин булган матди активларга бәя күтәрелү сәбәпле, очсызлана барган акчаларны алырга бик ашыгып тормыйлар. Болар барысы да икътисадның үзенең артта калган,

ни акчасы, ни банклары, ни сәүдәсе, ни сәнәгате булмаган хәленә таба шуыша башлавына китерә.

Гиперинфляция банк системасы кредитларына да авыр йогынты ясый.

«Акчадан качу» шартларында бурычка акча алып тору акылсызлык була. Әмма шундый очракларда да банк кредитларыннан файдаланырга әзер фирмалар яки шәхси затлар була икән, аларга бирелгән кыска сроклы (әйтик, фәкать бер айга гына) кредитта бик зур тәвәккәллек була. Эш шунда ки, бәяләр тотрыклы темплар белән үсә торган нормаль инфляциядән аермалы буларак, гиперинфляция бәяләр үсеше темпларының чиктән тыш кискен тирбәлешләре белән характерлы. Мәсәлән, Германиядә 1923 елның августында бәяләр, узган айдагы бәяләр дәрәҗәсе белән чагыштырганда, 12,5 тапкырга күтәрелә, ә октябрьдә, сентябрь белән чагыштырганда, 30 мең тапкырга арта. Димәк, *гиперинфляция вакытында бәяләр үсеше бернинди кысаларга да сыймый.* Әйтик, кредитор кемгәдер 1 ай вакытка, 20 млн марка итеп кире кайтару шарты белән, 1 млн марка бирә. Кредитор бәяләрнең айга 20 тапкыр артачагын күздә тота. Әмма бәяләр 30 мең тапкырга күтәрелеп, 20 млн марканың сатып алу сәләте, үткән айдагы 1 млн марканың сатып алу сәләтенә караганда, 1300 тапкырга кимрәк була.

Акча әйләнешен, кредит һәм банк системасын бозып, гиперинфляция сәнәгатькә, төзелешкә һәм икътисадның башка өлкәләренә дә җимергеч йогынты ясый. Бартер килешүләренең акча әйләнешен кысрыклавы әзер продукцияне сатуны һәм чимал, ярымфабрикатлар һәм башка җитештерү ресурсларын сатып алуны чиктән тыш кыенлаштыра. Күп кенә фирмалар җитештерүне кыскартырга яки аны бөтенләй туктатырга мәҗбүр булалар. Үзләренең кулында сакланып калган акча капиталларын тотрыклы, конверсияләнгән ирекле валюталарга әйләндерергә һәм чит ил активларына кертергә омтылалар. Милли капиталның чит илләргә интенсив агымы барлыкка килә. Капиталны милли икътисадка инвестицияләү стимуллары параличлана, нәтиҗәдә тагын бер җитди кыенлык — продукция җитештерүнең гомуми кимүе башлана. Реаль ТЭП дәрәҗәсе түбәнәю белән гиперинфляциянең үрелеп баруы икътисад кризисының иң авыр формасына — **стагфляциягә** китерә.

Гиперинфляциянең социаль нәтиҗәләре дә бик куркыныч була.

Бер ел эчендә бәяләр йөзәр тапкырга артканда, реаль хезмәт хакы, дәүләт хезмәтендәгеләрнең эш хакы, пенсияләр кискен кими; халыкның саклауга салган акчалары, дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм страховка полислары үз кыйммәтләрен тулысынча югалта. Гиперинфляция халыкның ярлы түбән катлавын гына хәерчеләндереп калмый, илдәге сәяси һәм социаль тотрыклылыкның нигезен һәм илнең демократик строен тәшкил иткән урта сыйныфны да бөлдерә. Күп кенә икътисадчылар, социологлар һәм сәясәт белгечләре, 20 нче еллардагы немец гиперинфляциясе фашизм килеп чыгуга һәм аның бик тиз күтәрелеп китүенә нигез булды, дип юкка гына әйтмиләрдер.

Сикерешле инфляция

Сикерешле инфляция бәяләр үсешенең уртача еллык темпы 10% һәм аннан югарырак булганда барлыкка килә.

Сикерешле инфляция — ул гиперинфляцияне башлап җибәрүче. Аның үзенчәлеге бәяләр үсеше темпының бик югары булуында түгел. Монда инде нормаль инфляция шартларындагы сәламәт икътисади климат формалаштырган уңай күренешләр тулысынча яки тулысынча диярлек сүнеп бара. Бу тискәре процессның икенче ягында җимергеч процесслар туа башлый, һәм алар, үсеш алып, гиперинфляция вакытында һәлакәтле көчкә әвереләләр.

Сикерешле инфляция шартларында **инфляцияне көтүнең** әһәмияте үзгәрә, монда эшмәкәрләр капиталларын яңа төзелешләргә һәм яңа җиһазларга инвестицияләргә хәл итәләр. Сикерешле инфляциянең хәвефле ягы шунда: монда бәяләр, номиналь табыш күләмнәренә караганда, тизрәк күтәреләләр. Бәяләр үсеше белән табыш арасындагы мондый бәйләнеш реаль табышның кыскаруына китерә. Өстәвенә бәяләрнең тиз күтәрелүе шуңа тәңгәл рәвештә амортизация өчен бүленгән акчаларны да бәясезләндерә. Бу — фирмага амортизация өчен бүленгән сумма рәвешендә әйләнеп кайткан акчалар яңа заводларга һәм җиһазларга капитал салуларны каплый алмый дигән сүз. Димәк, әгәр нормаль һәм уртача инфляция шартларында инфляцияне көтү оптимизм тудырса һәм эшмәкәрләрне югары үсешле керемнәр вәгъдә итүче яңа инвестицияләргә дәртләндерсә, сикерешле инфляция вакытында инфляцияне көтү эшмәкәрләрдәге оптимизмны сүндерә, аларны сагайта һәм озак вакытлы капитал салуларны тоткарларга мәҗбүр итә.

Сикерешле инфляция процент ставкалары үсешен тизләтә. Бәяләрнең гомуми артуы нәтиҗәсендә, номиналь процент ставкасы үсә. Әгәр инфляция нормасы, мисал өчен, 25% ка тигез булса, процент ставкасы 25% тан артыграк булырга тиеш, чөнки ул, барыннан да бигрәк, акчаның бәясезләнүен капларга һәм, моннан тыш, әлеге акча капиталының реаль керемен тәэмин итәргә тиеш була. Әйтик, банклар кредитлар буенча процент ставкасын 30% итеп билгелиләр. Бу очракта реаль процент ставкасы 30% — 25% = 5% тәшкил итә. Әгәр дә нормаль инфляция шартларында мондый процент ставкасы банклар өчен кабул итәрлек булса, сикерешле инфляция шартларында 5% алар өчен бик түбән норма булыр иде. Ни өчен? Эш шунда ки, сикерешле инфляция бәяләр үсеше тизләнүенең, гомум икътисади ситуациянең начарлануының һәм фирмаларның, шул исәптән банкка бурычы булганнарның, күпләп банкротлыкка чыгуының реаль куркынычын тудыра. Ә бу — кредит бирүче банкларга зыян китерә.

Сикерешле инфляция үсешенә банклар ничек җавап бирә соң? Бер яктан, алар процент ставкаларын кискен (35—40% ка кадәр) күтәрәләр, монда алар сикерешле инфляция шартларында кредит бирү белән бәйле тәвәккәллекне 10—15% лы реаль процент ставкасы берникадәр компенсацияләргә җитәчәк дип уйлап эш итәләр. Ә икенче яктан, алар озак сроклы кредит бирү — артык тәвәккәллек сорый торган операция, шуңа күрә кыска сроклы кредитлар белән генә чикләнергә кирәк дип саныйлар.

Сәнәгать, төзелеш, сәүдә фирмалары сикерешле инфляция чорында үзләрен ничек тоталар? Әгәр процент ставкалары үсә икән, алар яңа проектларны (бигрәк тә ул проектлар озак вакытлы капитал салуларга исәпләнгән булса) инвестицияләүдән баш тарталар. Процент ставкасы югары булганда, яңа җиһазларга салынган инвестицияләр бик югары табыш китерсәләр генә отышлы була, югыйсә ул сумманы процентлар йотып бетерергә тиеш була. Сикерешле инфляция шартларында фирмалар, әзер продукцияләр бәяләренә караганда, җитештерү факторлары бәяләре тизрәк үсәчәк дип шикләнәләр. Ә бу табышның артачагын түгел, ә кимеячәген күрсәтә. Күпчелек фирмалар яңа җиһазларны инвестицияләүдән, яңа технологияләргә күчүдән, яңа предприятиеләр төзүдән баш тарталар.

Шулай итеп, кредит бирүче банклар, шулай ук банклар кредитыннан файдаланучы инвестор фирмалар күзлегеннән

караганда, сикерешле инфляция тудырган шартлар инвестицияләр (бигрәк тә озак вакытлы, ягъни яңа технологияләрне инвестицияләү) үсешенә уңай йогынты ясамый. Димәк, сикерешле инфляция техник алгарышны тоткарлый һәм ТЭП үсеше темпының кимүенә китерә.

Сикерешле инфляция, кагыйдә буларак, хезмәт хакы арту белән чагыштырганда, бәяләр үсешенең артып китүе белән бара. Күп очракларда хезмәт хакы бәяләр үсешенә реакция буларак күтәрелә. Фирмалар һәм профсоюзлар хезмәт контрактларын килешү вакытындагы бәяләр дәрәҗәсеннән чыгып төзиләр. Контракт бәяләрнең алга таба күтәрелүе дәвам итүне исәпкә алып та төзелергә мөмкин. Ләкин бу очракта бәяләрнең контракт төзүгә *кадәр* булган үсеш темпы алына. Монда килешү, үткән чордагы бәяләр үсешеннән чыгып, хезмәт хакын алга таба үстерүне күздә тота. Сикерешле инфляция нәкъ менә бәяләр үсешен тизләтүе белән характерлы да. Шуңа күрә ул номиналь хезмәт хакын арттыру белән бара, ә бу вакытта реаль хезмәт хакы кими. Шул ук вакытта әгәр нормаль инфляция инвестицияләргә, ТЭП үсешенә һәм мәшгульлек артуга этәргеч ясаса, ә сикерешле инфляция, инвестицияләргә стимулны киметеп, техник прогресска аяк чалып һәм ТЭП үсеше темпларын киметеп, мәшгульлек үсешен сизелерлек әкренәйтүгә һәм эшсезлекне арттыруга китерә. Ягъни ялланып эшләүчеләрнең көнкүреше начарлану аларның реаль керемнәре кимүдән дә, эшсезлек артудан да килеп чыга. Шуның нәтиҗәсендә сикерешле инфляция социаль конфликтларга һәм сәяси тотрыксызлыкка китерә.

Уртача инфляция

Уртача инфляция нормаль һәм сикерешле инфляцияләр арасында тора.

Бәяләрнең уртача еллык күтәрелү дәрәҗәсе 5—10% чикләрендә торганда, икътисадта уртача инфляция хөкем сөрә. Ул икътисадка нормаль инфляция вакытындагы уңай йогынтыны югалтмавы белән характерлы. Бәяләр үсешендә күпмедер тизләнеш күзәтелүгә карамастан, җитештерүгә капитал инвестицияләү стимуллары әле саклана; бу элеккечә мәшгульлек артуга, ТЭП үсешенең шактый югары темпларда саклануына, милләтнең яшәү шартларын яхшыртуга ярдәм итә.

Шуның белән бергә, уртача инфляция вакытында ук аның икътисадка тискәре йогынты ясаучы алшартлары барлыкка килә башлый. Әгәр инфляция процессы тизләшсә һәм инфляция нормасы ун процентлы чиккә якынлашса, әлеге тискәре тенденцияләр үзләрен сиздерә башлыйлар. Әгәр инде инфляция үз үсешенең бу этабында көчәеп китсә, сикерешле инфляциягә хас булган тискәре процесслар башлана. Нормаль инфляциянең уңай үзлекләре әле инвестицияләрне стимуллаштырырга, мәшгульлекнең артуына һәм милләтнең тормыш дәрәҗәсе күтәрелүгә ярдәм итә. Әмма бу чорда инде сикерешле инфляциягә хас тискәре процесслар уяна башлый. Һәм бәяләр үсеше темпы соңгы күрсәткеч (10%) чигенә якынлаша барган саен, көчле инфляцияне көтү, кредитның кыйммәтләнүе, реаль керемнәр үсеше әкренәю күренешләре торган саен ачыклана бара.

Уртача инфляциянең сикерешле инфляция дәрәҗәсенә якынлашуын күрсәтүче билгеләрнең берсе — ул да булса озак вакытлы кредитлар үсеше әкренәя башлау. Инде әйтеп үткәнебезчә, бу — банкларның берничә елга акча бирергә теләмәвенең, ә фирмаларның, бәяләрнең үз үсешләрен тизләтмичә, ә әкренәюеннән сагаеп, югары процентлы кредит алырга теләмәвенең табигый нәтиҗәсе.

14.4. ХАЛЫКНЫҢ ТӨРЛЕ СОЦИАЛЬ ТӨРКЕМНӘРЕ ӨЧЕН ИНФЛЯЦИЯ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Димәк, нормаль инфляция икътисад үсешенә — уңай, гиперинфляция җимергеч йогынты ясый. Шуна да карамастан һәр илдә халыкның күпчелек өлеше гиперинфляциягә генә түгел, инфляциянең бәяләрне кискен күтәрүне күздә тотмаган төрләренә дә тискәре караштa тора.

Бу нәрсә белән аңлатыла соң?

Бу сорауның җавабы, бәлки, иң элек **бәяләр күтәрелүнең көтелмәгәнлегендәдер**. Әгәр инфляция вакытында бәяләр теге яки бу дәрәҗәдә тигез, бер үк темплар белән күтәрелсәләр, инфляцияне алдан белеп булыр иде. Бу очракта җәмгыять һәм аның барлык социаль катлаулары инфляциягә яраклаша алыр иде. Профсоюзлар бәяләргә пропорциональ рәвештә хезмәт хакларын күтәрүгә ирешер; дәүләт үз хезмәткәрләренә эш хакын инфляция нормасына яраштырып арттырыр; җитештерү

чыгымнары һәм бәяләр, керемнәр һәм салымнар бер үк темплар белән үсәр иде. Мондый шартларда югары, әмма тотрыклы инфляция нормасы, түбән, ләкин даими рәвештә югары-түбән сикерешле инфляция нормасы белән чагыштырганда (*ул көтелмәгән була*), бик үк зур зыян китерә алмас иде. Бу шуның белән аңлатыла: инфляция нормалары үзгәрешендәге көтелмәгәнлек үзе артыннан халыкның теге я бу социаль төркемнәренең юкка чыгуына китерә.

Керемнәрне яңадан бүлү

Күп кенә предприятиеләрдә эш хаклары фирма идарәсе һәм профсоюзлар яки аерым эшчеләр арасында хезмәт килешүе буенча (ул берникадәр срокка төзелә) билгеләнә. Җиргә яки бинага аренда түләве, фатирга түләү һ. б. контракт нигезендә тоташ бер елга яки хәтта берничә елга билгеләнә. Шәһәр халкын электр энергиясе, газ һәм су белән тәэмин итүче фирмалар бәяләрне муниципалитет белән килешү нигезендә куялар һәм аларның моны үзгәртергә хокуклары булмый. Әлеге барлык очракларда да бәяләрнең көтелмәгән күтәрелүе яки инфляция нормасы ялланып эшләүчеләрне, җир биләүчеләрне, газ компанияләрен һ. б. ны җайсыз хәлгә куя, реаль инфляция нормасы күтәрелү аларның реаль керемнәрен киметә. Эшчеләр яллаган фирмалар, арендага җир алган фермерлар, газга, электр энергиясенә һәм суга түләгән шәһәр халкы, киресенчә, отышлы хәлдә калырга тиеш булалар, чөнки аларның керемнәре чыгымнарыннан күпкә артык килеп чыгарга тиеш була.

Әгәр дә хезмәт хакы, аренда түләве, газга һ. б. га бәя инфляциянең көтелгән нормасына туры килгәнчә билгеләнсә, ә инфляциянең фактик нормасы көтелгәннән түбән булса, эшчеләр яллаган фирмалар, арендага җир алган фермерлар һәм газга, электр энергиясенә, суга түләгән шәһәр халкы оттырырга тиеш була. Шул ук вакытта ялланып эшләүчеләр, җир биләүчеләр, газ һ. б. компанияләр реаль күләме күтәрелгән керем алырлар иде.

Инфляция нормасының көтелмәгән динамикасы шартларында керемнәрнең һәм чыгымнарның болай үзгәрүе заем бирүчеләр һәм бурыч түләүчеләргә дә кагылырга тиеш була.

Әйтик, коммерция банкы, көтелгән инфляция нормасы елга 20% һәм реаль процент ставкасы елга 10% исәбеннән чыгып, сәүдә фирмасына 3 елга 1 млрд сумлык озак вакытлы кредит

бирә. Бу очракта банк процент ставкасын 30% (10% + 20%) итеп билгели. Әйтик, хәзер инфляциянең фактик нормасы 30% ка тигез булды, ди. Бу — банк тарафыннан алынган процентның фәкать кредитка бирелгән капиталның бәясезләнүен капларга гына җитүен, ә банкның реаль кереме нульгә тигез булуын аңлата. Сәүдә фирмасы исә чынлыкта кредитны бушлай (процентсыз) алган булып чыга.

Инфляция нормасының көтелмәгән кимүе капма-каршы нәтиҗәләргә китерә. Әйтик, инфляция нормасы 5% ка кими. Монда реаль процент ставкасы 25% тәшкил итә. Банк шактый югары отыш ала, шул ук вакытта фирмаларның чыгымнары сизелерлек арта, нәтиҗәдә барлык бу операцияләр фирмалар өчен зыянлы була.

Әлеге очракларның барысына карата да түбәндәге кагыйдәләрне билгеләргә була:

1) инфляциядән, халыкның билгеләнгән керемнәр яки бәяләр үсеше белән чагыштырганда, шактый соңарып күтәрелә торган керемнәр алучы социаль төркемнәре зыян күрә;

2) инфляциянең фактик нормасы көтелгәннән югары булган очракта, инфляциянең көтелгән нормасына туры китереп төзелгән озак вакытлы килешүләрдә керемен арттыру каралган социаль төркемнәр оттыралар;

3) инфляциянең фактик нормасы көтелгәннән түбән булган очракта, инфляциянең көтелгән нормасына туры китереп төзелгән озак вакытлы килешүләрдә керемнәрен арттыру каралган социаль төркемнәр арта баручы реаль керемнәр алалар.

Көтелмәгән инфляциянең социаль нәтиҗәләре

Димәк, инфляция нормаларының көтелмәгән үзгәрешләре халыкның бер төркеменең реаль керемнәре күтәрелү, икенчеләренең реаль керемнәре кимү белән бергә бара. Бу — инфляция икътисадта җитештерелгән милли керемне яңадан бүлүгә китерә дигән сүз. Мондый бүленешкә кеше эшчәнлегенең аерым сфераларында хезмәт һәм капиталның югары нәтиҗәлелеге, ә башка сфераларда хезмәт һәм капиталның нәтиҗәлелеге кимү сәбәп түгел. Берәүләрнең реаль керемнәре арту, икенчеләренеке кимү, ул беренчеләре — яхшырак, икенчеләре начаррак эшли башлады дигән сүз түгел. Бу очракта инфляция үзенә бертөрле рулетка ролен үти, һәм бу «уенга»,

үзләре ягыннан бернинди теләк булмаса да, барлык кешеләр дә җәлеп итеЛӘ. Реаль керемнәрнең мондый тотрыксызлыгы һәм аларның гадел бүленмәве җәмгыятьнең күпчелек өлешендә билгеле бер дәрәҗәдә ризасызлык тудырмый калмый.

Нормаль инфляциягә хас булган бәяләр үсешенең югары булмаган темпы, уртача һәм сикерешле инфляция вакытындагы бәяләр үсешенең уртача еллык темпы югары булгандагыга караганда, гадәттә тотрыклырак була. Инфляция нормасы югары булган саен, бу норманың тирбәлеше дә зуррак һәм бер үк вакытта аның көтелмәгәнлеге дә кискенрәк була. Нәкъ менә шуңа күрә дә инфляциянең кискенләшүе керемнәрне бернәрсә белән дә акланмаган янадан бүлүне, ягъни җәмгыятьтә социаль киеренкелекне көчәйтә.

14.5. ФИЛЛИПС КӘКРЕСЕ

Эшсезлек хәрәкәте белән инфляция үсеше арасындагы бәйләнеш турындагы сорауның теоретик һәм гамәли әһәмияте зур. Бу бәйләнешне, беренче булып, XX гасырның 50 нче елларында инглиз икътисадчысы А. Филлипс анализлый.

Белгәнебезчә, әгәр товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә сорау тәкъдим итүләргә караганда зуррак икән, бу товарга яки хезмәт күрсәтүгә бәя арта. Шуның белән бергә, сорау белән тәкъдим итү арасындагы өзеклек никадәр зуррак булса, бәяләр арту темпы шулкадәр югары була. Әгәр товарга (хезмәт күрсәтүгә) сорау тәкъдимнән түбән икән, бу вакытта бәя төшәчәк.

Әлеге «сорау — тәкъдим итү — бәя» механизмы хезмәт базарына да карый. Әгәр хезмәткә сорау үссә, мәшгульлек арта, ә эшсезлек кими. Бу хезмәт хакын арттыруга уңай йогынты ясый, чөнки, бер яктан, эшчеләр, әлеге ситуациядән файдаланып, фирмаларны ташламаларга барырга мәҗбүр итәргә мөмкин; икенче яктан, фирмалар, эшчеләрне үзләренә җәлеп итү максаты белән (алар үзләренә конкурент булган предприятиегә урнашмасыннар өчен), хезмәт хакын күтәрүгә баралар.

Әгәр мәшгульлек кимесә, ә эшсезлек артса, хезмәт хакы ставкалары өчен нәтиҗәләр капма-каршы була: эшсезлек зуррак булган саен, хезмәткә сорау, аны тәкъдим итүгә караганда, азрак була, һәм хезмәт хакы ставкалары да түбән була.

14-3 нче рәсем. ▷ Филлипс кәкресе.
Графиктан күренгәнчә, номиналь хезмәт хакы ставкаларының үсеш темпы эшсезлек дәрәҗәсеннән (ягъни мәшгульләр һәм эшсезләрнең гомуми суммасындагы эшсезләр процентыннан) кире бәйлелектә тора.

Эшсезлек дәрәҗәсе белән хезмәт хакы ставкалары арасындагы бәйләнеш турындагы бу теоретик положение А. Филлипс тарафыннан уздырылган статистик анализда расланды. Аның нәтиҗәләре **Филлипс кәкресе** дип аталучы график формасында чагылдырыла (14-3 рәс.).

Әлеге рәсемдә күрсәтелгән график Бөекбританиядә 1948—1957 елларда эшсезлек дәрәҗәсе белән номиналь хезмәт хакы ставкалары темпы арасындагы бәйләнешне чагылдыра. Графиктан күренгәнчә, Бөекбританиядә, минималь хезмәт хакы ставкасының уртача дәрәҗәсе 7,8% ка артканда, эшсезләр саны, илдәге барлык эшче көчләр белән чагыштырганда, 1% тәшкил иткән. 1955 елда хезмәт хакының номиналь ставкасы, аз дигәндә, 7% ка арткан, әмма эшсезләр саны 1,2% тан югары булган; 1957 елда хезмәт хакы ставкаларының үсеш темпы тагын да түбәнрәк (5,5%), ә эшсезләр проценты тагын да югары була. 1953 елда хезмәт хакы ставкасының үсеш темпы иң түбән һәм бу каралган чорда эшсезлек дәрәҗәсе иң югары ноктага җитә. Хезмәт хакы ставкалары һәм эшсезлек проценты координаталары белән билгеләнгән нокталарны тоташтырып, без бу ике үзгәрүчән зурлык (номиналь хезмәт хакы үсеше темпы эшсезлек проценты белән кире бәйләнештә тора)[1] арасындагы закончалыклы бәйләнешне күрсәтүче кәкрене табабыз.

---

[1] Шуны билгеләп үтик: күрсәтелгән закончалык үзен тенденция буларак чагылдыра. Аерым елларда (мәсәлән, 1954, 1958 ел һәм графикта күрсәтелмәгән башка елларда) Филлипс кәкресеннән шактый тайпылышлар да була. Әмма бу тайпылышлар, кагыйдә буларак, нигездә, сәяси характерда булган тышкы факторлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Аннан соңгы тикшеренүләр, акчалата хезмәт хакы динамикасы белән эшсезлек арасында урнашкан бәйләнешнең дөреслеген раслап кына калмыйча, бәлки, аны эшсезлек динамикасы белән инфляция арасындагы үзара бәйләнешне ачыклауда да файдаланырга мөмкин булуын күрсәтте.

Белгәнебезчә, инфляция үсеше белән номиналь хезмәт хакы хәрәкәте үзара тыгыз бәйләнгән. Хезмәт хакы үсеше сорау артуны аңлата, ягъни сорау инфляциясе үсешенә этәрә; шул ук вакытта хезмәт хакы ставкалары арту фирмаларның акча чыгымнары үсешенә китерә, һәм шуңа бәйле рәвештә чыгымнар инфляциясе барлыкка килә. Ниһаять, бәяләрнең фактик һәм көтелгән күтәрелеше эшчеләрнең хезмәт хакын күтәрү турындагы таләпләренә сәбәп була. Шуңа күрә бәяләр динамикасы, ягъни инфляция нормасы динамикасы, номиналь хезмәт хакы ставкалары динамикасы белән төп-төгәл диярлек туры килә.

Болар барысы да инфляция темпы белән эшсезлек нормасы арасында, номиналь хезмәт хакы үсеше темпы белән эшсезлек нормасы арасындагы кебек үк, бәйләнеш булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Статистика әлеге нәтиҗәнең хаклыгын раслый. 14-4 рәсемендә АКШта 1961—1969 елллардагы инфляция темпы белән эшсезлек нормасы арасындагы бәйләнешне чагылдырган график бирелгән.

Графиктан күренгәнчә, 1969 елдагы инфляциянең чагыштырмача югары темпы (5%) чагыштырмача югары булмаган

14-4 нче рәсем. ▷ Филлипс кәкресе аңлатмасы (интерпретациясе). *Графикта күренгәнчә, бәяләр үсеше темпы, ягъни инфляция нормасы арту, эшсезлек нормасыннан кире бәйләнештә тора.*

эшсезлек нормасы (3,4%) белән туры килә. Инфляция темпы 5% тан түбән булган элекке елларда эшсезлек нормасы 1969 ел дәрәҗәсен узып китә. Өстәвенә инфляция темпы түбәнрәк булган саен, эшсезлек нормасы югарырак була. 1965 елда, мәсәлән, инфляция темпы 1% ка кала, ә эшсезлек нормасы бу вакытта 6,7% ка җитә. Димәк, Филлипс кәкресе эшсезлек динамикасы һәм аның дәрәҗәсе белән инфляция арасындагы бәйләнешне микъдари яктан күрсәтә. Базар икътисады югары үсеш алган шартларда җәмгыять сайлау алдында кала: көчле булмаган инфляциягә ирешеп, югары эшсезлек белән килешергәме яки, көчле инфляциягә юл куеп, чагыштырмача түбән эшсезлек юлын сайларгамы. Бу вариантларның кайсысы кулайрак? Тормышның бер генә очрагында да бу сорауга җавап юк. Дәүләт һәр очракта да җиңел булмаган бу проблеманы, урын һәм вакытның конкрет шартларыннан чыгып, икътисади гына түгел, социаль һәм башка шартларны да истә тотып хәл итәргә тиеш.

Инфляция теориясе мәсьәләсенә кире кайтып, «шуышучан» инфляциянең икътисадка уңай йогынтысын бәяләүгә житди ачыклык кертик. Тулаем алганда, «шуышучан» инфляция икътисадка уңай йогынты ясый, әмма бәяләр үсешенең аеруча түбән темпы уңайлылык тудырмый, чөнки инфляция темпы 1—2% булган вакытта эшсезлек нык арта. Шул ук вакытта Филлипс кәкресе дә көчле сикерешле инфляция (гиперинфляция турында әйтеп тә торасы юк) шартларына каршылыксыз гына тарала алмый. Җимергеч йогынтылар ясаучы гиперинфляция эшсезлекне киметми, ә арттыра. Шуңа күрә бәяләр үсешенең югары темпы, эшсезлек арту тенденциясе китереп чыгарып, кайбер очракларда **стагфляция** үсешенең нигезенә әйләнә. Стагфляция[1] — икътисад кризисының иң авыр формаларының берсе. Ул ТЭП күләме түбәнәю, эшсезлек арту һәм бәяләр күтәрелү барганын күрсәтә (14-5 рәс.).

Россия икътисады үсеше проблемаларының куелышы һәм аларны хәл итү буенча макроикътисади анализның мөһимлегенә карамастан, шуны билгеләп үтик: Россия икътисадының административ-планлы системадан базар системасына

---

[1] «Стагфляция» термины — «стагнация» (торгынлык) һәм «инфляция» терминнары кушылмасы.



14-5 нче рәсем. △
1990—1998 елларда Россиядә стагфляция.
1990—1998 еллардагы озакка сузылган артка чигенеш реаль ТЭП җитештерүне 2 тапкырга диярлек кимегүгә китерә. Шул ук вакытта 1998 елда бәяләр, 1990 елдагы бәяләр дәрәҗәсе белән чагыштырганда, 7 мең тапкырдан артыгракка үсә. Номиналь ТЭПның тиз үсүе зур тизлек белән көчәя барган, 1993—1994 елларда гиперинфляциягә әйләнеп киту куркынычы тудырган сикерешле инфляция нәтиҗәсе булып тора.

күчүенең әлеге этабында инфляция белән эшсезлек арасындагы без карап үткән закончалыкны куллану әле иртәрәктер, мөгаен. Беренчедән, Россиядә әле чын-чынлап хезмәт базары формалашып җитмәгән. Икенчедән, бәяләр билгеләүнең базар механизмы әле камилләшмәгән хәлдә кала бирә. Шуңа күрә хезмәт хакы күләмнәре динамикасы эшсезлек дәрәҗәсенә һәм аның динамикасына, шулай ук бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе хәрәкәтенә чагыштырмача аз йогынты ясый. Ниһаять, Россия икътисадында күрсәтелгән закончалыкларның булуын тикшерергә ярдәм итәрлек ышанычлы статистик мәгълүматлар бөтенләй юк. Шулай да, базар системасына хас булган икътисади реформаларның үсеше һәм аларның кискенләшүе процессында, инфляция белән эшсезлек арасындагы бәйләнеш, теге яки бу дәрәҗәдә, үзен сиздерә башлый. Шул вакытта аны икътисади сәясәт рецептлары эшләгәндә исәпкә алырга кирәк булачак.

Инфляция үсеше темпы белән эшсезлек нормасы арасындагы кире бәйләнеш кыска вакытлы чорга — берничә елга хас күренеш. Әгәр дә, бер яктан, бәяләр һәм хезмәт хакынын, икенче яктан, эшсезлекнең үсеше озакка сузылу тенденциясен карасак, билгеләнгән бәйлелек үз көчен югалта. Якынча 60 ел барган гомуми бәяләр күтәрелү, шулай ук бөтен дөньяда номиналь хезмәт хакы күтәрелүнең тотрыклы тенденциясе эшсезлек дәрәҗәсе кимүнең нинди дә булса озак вакытлы тенденциясе белән берничек тә туры килмиләр.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Хәзерге вакытта инфляция дөньяның барлык илләрендә күзәтелә торган күренеш булып санала. Ул шуннан гыйбарәт: икътисадта җитештерелә торган товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең гомуми дәрәҗәсенең озак вакытка тотрыклы күтәрелүе бара.

Инфляциянең киеренкелеге базарга китерелә торган барлык төр товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үсешенең еллык уртача темпын тәшкил итүче инфляция нормасы күрсәткече ярдәмендә үлчәнә.

Инфляциянең төп сәбәпләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтергә була: а) тулаем кирәгеннән артык сорау барлыкка килү

һәм аның үсә баруы; б) товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүче фирмалар тоткан акча чыгымнарының артуы; в) фирмалар кебек үк, йорт хуҗалыкларының да инфляцияне көтүе.

Инфляциянең төп дүрт төрен аерып күрсәтәләр: нормаль, уртача, сикерешле һәм гиперинфляция. Әгәр нормаль инфляция икътисад үсешенә, тулаем алганда, уңай йогынты ясаса, гиперинфляция аңа җимергеч тәэсир итә.

Инфляциягә хас сыйфатларның берсе — бәяләр үсеше темпы үзгәрүнең көтелмәгәнлеге. Моның нәтиҗәсендә халыкның керемнәре, инфляциянең фактик нормасына караганда, югарырак дәрәҗәгә күтәрелгән төркемнәренең реаль керемнәре арта; ә керемнәре, инфляция нормасына караганда, әзрәк үскән халыкның реаль керемнәре кими. Бу үз чиратында милли керемне гадел булмаган һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелек тудырган яңадан бүлүгә китерә.

Инфляция нормасы эшсезлек дәрәҗәсе белән тыгыз бәйләнештә тора. Инфляция нормасының кыска вакытка күтәрелүе эшсезлек нормасының кимүенә китерә, һәм, киресенчә, инфляция нормасы кимегәндә, эшсезлек нормасы арта. Димәк, базар икътисады шартларында җәмгыять, инфляцияне киметеп, эшсезлек үсү белән килешергә яки, инфляцияне көчәйтеп, эшсезлек дәрәҗәсен киметергә тиеш булып кала.

Контроль сораулар һәм биремнәр

1. Бәяләр күтәрелү нинди очракта инфляция характерында булмый һәм кайсы очракта ул инфляция булып санала?
2. Инфляция дип һәм дезинфляция дип нәрсә атала?
3. Инфляция нормасы нәрсә ул? Инфляция нормасын нинди ысуллар белән исәпләп чыгарырга була?
4. Товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә кирәгеннән артык сорау ни өчен инфляция китереп чыгара? Кирәгеннән артык сорау чыганакларын атагыз.
5. Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүгә акча чыгымнары арту ни өчен инфляциягә китерә?
6. Инфляцияне көтү нәрсә ул һәм инфляция үсешендә аның роле нинди?

7. Нормаль инфляция икътисад үсешенә нинди йогынты ясый? Гиперинфляциянең икътисадка йогынтысы нинди?
8. Инфляциянең фактик нормасының көтелгән инфляциядән тайпылуы милли керемне яңадан бүлүгә ничек йогынты ясый?
9. Инфляция нормасы һәм эшсезлек нормасы динамикасын чагылдырган таблица төзегез һәм Филлипс кәкресе графигын сызыгыз.

15 нче бүлек

ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җаваплар табарсыз:

- ✦ икътисади үсеш ул нәрсәне анлата;
- ✦ үсеш темпын нинди күрсәткечләргә нигезләп бәяләргә кирәк;
- ✦ ТЭП үсешенең уртача еллык тизлеге ни өчен икътисади үсеш тизлеге булып хезмәт итә;
- ✦ икътисади үсешне нинди факторлар билгели, һәм икътисади үсешнең экстенсив һәм интенсив факторлары нәрсәдән гыйбарәт;
- ✦ ТЭП үсешендәге төрле факторлар ролен билгеләүдә җитештерү функциясе ничек файдаланыла;
- ✦ XX гасырның 70—80 нче елларында күзәтелгән икътисади үсеш тизлегенең кимүе нәрсә белән анлатыла;
- ✦ нәрсә ул озак вакытлы цикллар, һәм икътисади үсеш барышында алар ничек чагыла.

Әгәр икътисад тигезләнеш хәлендә икән, бу әле ул «бер урында таптана» дигән сүз түгел. Киресенчә, нәкъ менә тигезләнеш халәте, аның тотрыклылыгын һәм үзгәрми торуын тәэмин итеп, икътисадның үсеш-күтәрелешенә уңай җирлек тудыра.

Теге яки бу илнең икътисадында тигезләнеш саклана яисә бу илдә тигезләнеш халәтеннән тайпылулар бик аз икән, димәк, аның икътисадында циклы тайпылышлар кыска вакытлы гына һәм бик үк тирәнгә дә үтеп кермәгән, эшсезлек һәм инфляция нормасы да югары түгел. Мондый ил, тайпылышлары дәвамлы һәм тирәнгә киткән, ә инфляция һәм

эшсезлек торган саен кискенләшә һәм авыррак формалар алган илгә караганда, кагыйдә буларак, тиз үсеш ала. Ә менә икътисади тигезләнеш халәте ныграк бозылган саен, илнең үсеше дә әкренрәк бара.

Моны төрле илләр үсешен чагылдырган статистик мәгълүматлар да раслый.

Мәсәлән, 1960—1985 елларда Германиядә эшсезлек нормасы уртача — 3,5%, ә Бөекбританиядә — 5,7%; ә бу елларга инфляциянең уртача нормасы Германиядә — 3,9%, Бөекбританиядә 7,9% була. Яхшырак балансланган Германия икътисады, Бөекбритания икътисадына караганда, күпкә тизрәк үсеш ала: 1960—1985 елларда ТМП күләме Германиядә 3,4 тапкырга артса, Бөекбританиядә бу күрсәткеч 1,9 тапкыр гына үсеш бирә.

Теләсә кайсы илнең тарихы күрсәткәнчә, икътисад үсеше ТЭП җитештерү һәм милли керем күләмнәрен арттыруга бәйле. Кешелекнең һәр яңа буыны, үзеннән алдагы буыннарга караганда, югарырак реаль табыш ала. Һәм шуның нәтиҗәсендә аның гомуми тормыш дәрәҗәсе дә яхшырырга мөмкин. Һәммәбезгә билгеле булганча, яхшы сыйфатлы һәм күп әйбергә ия булу иң элек фирмаларның ул әйберләрне базарга чыгару мөмкинлегенә бәйле. Моның өчен аерым фирмаларның гына түгел, ә аларның барысының да үсешкә һәм күтәрелешкә ирешүе зарур, фәкать шушы очракта гына барлык икътисад бербөтен буларак үсешкә ирешергә мөмкин.

15.1. ИКЪТИСАДИ ҮСЕШНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Икътисади үсеш төшенчәсе

Икътисади үсеш нәрсәдән гыйбарәт, икътисади теория нәрсәне күздә тота? Гомумиләштереп алганда, бу сорауның җавабы бик гади. Икътисади үсеш ин элек аерым бер илдә ТЭП җитештерү күләмен арттырудан гыйбарәт. Шулай ук саф милли продукт яки милли керем күләмен арттыру да икътисади үсеш күрсәткече булып хезмәт итә ала. Әмма икътисади үсешнең төп мәгънәсен аңлау өчен, мондый гомуми билгеләмә белән чикләнү генә җитәр микән? Бу сорауга җавап бирү өчен, түбәндәге мисалны карап үтик.

Шунысы мәгълүм: АКШның ТЭП күләме 1973 елда 1306,6 млрд доллар белән исәпләнсә, 1975 елда ул 1516,3 млрд доллар тәшкил итә. Америка икътисадының үсеше турында фикер йөртү өчен, бу мәгълүмат кына җитәме соң? Җавап тискәре булачак.

Беренчедән, без әле ТЭПның нинди бәяләрне эченә алуы турында белмибез. 1974—1975 елларда бәяләр күтәрелеп, реаль ТЭП күләме кимергә дә мөмкин. Чыннан да, 1974—1975 елларда бик нык кимү күзәтелә, ТЭП җитештерү 1975 елда 1973 елдагыга караганда кими һәм шунлыктан ТЭП күләмендә үсеш бөтенләй булмый. Икенчедән, 1976 елда ТЭП күләме бераз арта, ләкин илдәге һәр кеше өчен уртача алганда товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү кими, чөнки 1973—1976 елларда халык саны, ТЭП күләменә караганда, зуррак үсеш ала.

Куелган сораулардан һәм икеләнүләрдән котылу өчен, безгә икътисади үсеш төшенчәсен төгәлрәк билгеләргә һәм бу төшенчәгә параграф башында бирелгән билгеләмәнең тиешле дәрәҗәдә булмавын инкарь итәргә туры килә. Икътисади үсеш төшенчәсе түбәндәге моментларны үз эченә алырга тиеш:

1. Номиналь ТЭП турындагы мәгълүматларга яки башка төр номиналь күрсәткечләргә таянып кына, икътисади үсешне билгеләү мөмкин түгел. Без инде 1991—1998 елларда Россиядә, номиналь ТЭПның бик тиз үсеп китүе нәтиҗәсендә, аның реаль үсешенең бик нык кимүен (11 нче бүлекне кара) яхшы беләбез. Хәтта уңышлы үсеш алган Америка икътисадын алсак та (анда бәяләр бик аз күтәрелеп, инфляция күренеше нормаль дәрәҗәдә калырга мөмкин), номиналь ТЭП динамикасы, нигездә, икътисади үсешнең чын картинасын бозып күрсәтәчәк.

15-1 рәсемендә бирелгән графиклар номиналь ТЭПның, реаль ТЭПка караганда, шактый тиз үсүен һәм бу ике күрсәткеч арасындагы өзеклекнең ел саен зурая баруын бик ачык күрсәтәләр. Моның аңлатмасы да ап-ачык. Реаль ТЭП дәрәҗәсе һәм аның динамикасы бәяләргә бәйле түгел. Ул фәкать продукт җитештерүне арттыру нәтиҗәсендә генә күтәрелә. Ә инде номиналь ТЭПка килгәндә, аның үсеше продукция җитештерүне арттыруга да, бәяләр күтәрелүгә дә бәйле.

15-1 нче рәсем. ▷
1987—1998 елларда АКШта номиналь һәм реаль ТЭП үсеше. *Реаль ТЭП 1987 елгы бәяләрдә күрсәтелгән, шуңа күрә ике күрсәткеч тә (номиналь һәм реаль) бер-берсенә туры килә. Әмма шуннан соңгы елларда алар инде туры килми, чөнки бәяләр күтәрелә. Номиналь ТЭП, бәяләр арту аркасында, тизрәк үсә, 1998 елда 1987 елдагыдан 3709 млрд долларга артыграк була. Реаль ТЭП бу вакыт эчендә 1332 млрд долларга гына арта. Беренче карашка, бәяләрнең күтәрелүе бик аз кебек (елга 3,5% кына), әмма шуңа да карамастан номиналь һәм реаль ТЭП дәрәҗәләре арасында аерма 2,4 трлн долларга тигез була.*



Димәк, номиналь ТЭП, СМП яки башка теләсә нинди номиналь күрсәткечкә таянып кына, икътисади үсеш турында фикер йөртергә ярамый. Икътисади үсеш күрсәткече сыйфатында фәкать **реаль ТЭП яки житештерүнең гомуми дәрәҗәсенең башка реаль күрсәткече** генә алына.

2. Инде әйтеп үтелгәнчә (13 нче бүлекне кара), базар икътисады циклы тирбәлешләргә дучар ителә. Шуңа күрә ТЭП дәрәҗәсенең үсешен ике аспектта карарга була: беренчедән, рецессия (төшү) вакытындагы һәм цикл төбендәге ТЭП дәрәҗәсен циклы күтәрелеш барышында ирешелгән дәрәҗәсе белән чагыштырып карарга; икенчедән, циклы күтәрелешләрнең иң югары ноктасында ирешелгән ТЭП дәрәҗәләрен үзара чагыштырырга була.

Бу вариантларның кайсысы кулайрак икәнен белү өчен, 15-2 рәсемен карыйк.

Продукция житештерү циклы тирбәлешләргә дучар ителә, шуңа күрә икътисади үсеш турында циклы күтәрелешләр барышында гына ирешелгән ТЭП дәрәҗәсе күтәрелүгә нигезләнеп кенә фикер йөртергә ярамый. Чөнки күтәрелеш вакытындагы житештерү күләме ТЭП үсешен элек ирешелгән иң югары дәрәҗәгә дә житкерә алмаска мөмкин. Моннан тыш, күтәрелеш вакытындагы житештерү үсешенең билгеле бер өлеше икътисадны элеккеге циклда ирешелгән күрсәткечләр



15-2 нче рәсем. △
1975—2002 елларда АКШта фактик һәм потенциаль ТЭПның үсеше.
Реаль, фактик җитештерелгән ТЭП күрсәткече икътисади үсешне шактый яхшы чагылдыра. Әмма потенциаль (табигый) ТЭП икътисади үсеш тенденцияләрен тагын да ачыграк күрсәтә. Беренчедән, ул циклы тирбәлешләргә дучар ителмәгән. Икенчедән, ул икътисадның җитештерү мөмкинлекләре ничек үсүен, элек барлыгы күпме товар һәм хезмәт күрсәтүләр бирә алганын һәм хәзер шуларның күпмесен бирергә сәләтле икәнлеген чагылдыра.

дәрәҗәсенә генә кайтару була. Шуңа күрә икътисади үсеш чын мәгънәсендә икътисад милли продукт җитештерүнең яңа биеклегенә күтәрелгәндә генә башлана. Ләкин бу очракта без әле кыска вакытлы үсеш турында гына сүз алып барабыз, ә безне хәзер озак вакытлы үсеш кызыксындыра.

Искә төшереп үтик: үсеш циклның иң югары ноктасына җиткәндә, һәр эш урыны һәм җитештерү куәтләре оптималь дәрәҗәдә, тулы куәтенә файдаланыла, җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр потенциаль тулай эчке продукт күләмен тәшкил итә. Димәк, **икътисади үсеш потенциаль ТЭП күләмен арттыруны күздә тота**.

3. Әгәр ТЭП үсеше халык саны артуга туры пропорциональ булса, әлеге илнең һәр кешесенә исәпләгәндә уртача үзгәрешсез микъдарда товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерелгән дигән сүз. Бу очракта ил тулы канлы тормыш алып бармый. Кешеләрнең тормышын яхшырту да мөмкин булмый. Нәрсәнең дә булса берсенең торышы яхшыру, икенчесенеке начарлану хисабына гына була. Мәгарифне, медицина хезмәте күрсәтүне, мәдәният, фән һ. б. ны үстерүгә бирелә торган акчаларны арттыру өчен чыганаклар булмас иде. **Ягъни икътисади үсеш ТЭП дәрәҗәсен күтәрүне генә түгел, ә бу үсешнең илдәге һәр кеше башына уртача җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне арттыруны тәэмин итүен күздә тота.**

Димәк,

> ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ потенциаль тулай эчке продукт күләмен абсолют күрсәткечләрдә дә, шулай ук илдә яшәүчеләрнең һәркайсына уртача исәпләгәндә дә озак вакытларга арттыруны күздә тота.

Икътисади үсешнең әһәмияте

Икътисади үсешнең әһәмияте — иң беренче чиратта халыкның тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуга мөмкинлекләрне киңәйтүдә. Шуның нигезендә ярлылыкны бетерү, фән һәм мәгарифне үстерү, экологик программаларны хәл итү һәм тагын бик күп төрле социаль программаларны тормышка ашыру өчен яңа мөмкинлекләр ачыла.

Икътисади үсеш икътисад карамагындагы тар ресурсларның чикләрен киңәйтә. Аның ярдәмендә ресурсларның яңа төрләре барлыкка килә, һәм икътисадта кулланыла торган традицион ресурсларның күләмнәре арта. Мәсәлән, икътисадның үсеше атом-төш энергиясеннән, спутник (Җирнең ясалма иярчене) элемтәсеннән тагын да күбрәк файдалануны, производствоның һәм көнкүрешнең барлык тармакларында (сфераларында) компьютерлар куллануны һ. б. ны тәэмин итә.

Әмма икътисади үсеш социаль-икътисади, экологик, технологик һәм бүгенге җәмгыятьтә эш итәргә туры килгән башка проблемаларны үзе генә хәл итә дип уйлау дөрес булмас иде. Әйтик, кайсы да булса бер илдә кеше башына туры килә торган милли керем, мисал өчен, 5% ка артты, ди, ләкин бу һич кенә дә ул илдә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсе үзеннән-үзе 5% ка күтәрелә дигән сүз түгел әле. Милли керемнең бу үсеше, кешеләрнең матди байлыкларын арттыру өчен, фәкать *мөмкинлекләрне* генә киңәйтә. Әгәр милли керем үсеше көннән-көн арта барган бюрократик аппарат, хәрби чыгымнар тарафыннан йотылып барса, криминаль элементлар тарафыннан урланып чит илгә чыгарылса, әлбәттә, халыкның күпчелек өлешенә икътисади үсештән берни дә файда булмаячак. Бу очракта ялланып эшләүчеләрнең дә, эшмәкәрләрнең дә икътисади үсеш белән кызыксынулары юкка чыгачак. Икътисади үсеш исәбенә ачылган яңа мөмкинлекләрне тормышка ашыру, нигездә, теге яки бу илдә урнашкан икътисади системадан, дәүләт тарафыннан үткәрелә торган икътисади сәясәттән бәйле.

15.2. ИКЪТИСАДИ ҮСЕШНЕ ҮЛЧӘҮ

Икътисад үсеше, илдәге халык саны артуга караганда, ТЭПның тизрәк үсүе белән бергә барырга тиешлеге турындагы нәтиҗә икътисади үсеш тизлеге төшенчәсен китереп чыгара. Төрле илләрнең икътисади үсешен чагыштырып карасак, без Кытай икътисадының, АКШ икътисадына караганда, тизрәк һәм соңгысының Бөекбритания икътисадыннан кызурак темплар белән үсүен күрербез. Бу очракта шулай ук күрсәтелгән өч илнен икътисади үсеш тизлеге дә чагыштырып карала.

Икътисади үсеш тизлеге булып нәрсә хезмәт итә соң?

Бу сорауга җавап бирү өчен, безгә үткән параграфта чыгарылган нәтиҗәләргә таянырга кирәк: икътисади үсешне үлчәү номиналь күрсәткечләрдән түгел, ә реаль күрсәткечләрдән (ягъни реаль ТЭПтан) алынырга тиеш; икътисади үсешне циклы тирбәлешләр вакытындагы иң түбән күрсәткечтән иң югары күрсәткечкә күтәрелгән кыска вакытлы арадагы нәтиҗәләрдән чыгып түгел, ә потенциаль ТЭП күләменең иң югары күрсәткечләре арасындагы озак вакытлы чорында үлчәргә кирәк.

ТЭПның абсолют үсеше

ТЭПның абсолют артуы буенча гына икътисади үсеш тизлеген билгеләп буламы? Мәсәлән, 1939—1948 еллар эчендә АКШта ТМП 392,1 млрд долларга күтәрелә (15-1 табл.), ә 1948—1957 еллар эчендә бу күрсәткеч 442,4 млрд долларга житә. ТЭПның абсолют үсеше 1948 елдан 1957 елга кадәр тугызъеллыкта, аңа кадәр булган 1939—1948 еллардагы тугызъеллык белән чагыштырганда, кызурак темпта барган дип уйларга була. Әгәр дә без 1939 елда икътисади үсешнең башлангыч дәрәҗәсен ТМПның 716,6 млрд долларга тигез булган күләме тәшкил итүен исәпкә алсак, ә 1948 елда ул 1108,7 млрд долларга тигез була, шулай булгач, икенче тугызъеллыкта ТМПның үсеше артык зур булмавын күрәбез.

15-1 таблицасы

1929—2002 елларда АКШта ТМП үсеше (1982 елдагы үзгәрешсез бәяләрдә)

Ел	ТМП, млрд долл.	ТМП үсеше, млрд долл.	ТМПның үсеш темпы, % ларда	
			барлык чорда	уртача еллык
1929	709,6	—	—	—
1939	716,6	7,0	1,0	0,4
1948	1108,7	392,1	54,7	4,9
1957	1551,1	442,4	39,9	3,8
1969	2423,3	872,2	56,2	3,8
1973	2744,1	320,8	13,2	3,2
1981	3248,8	504,7	18,4	2,1
1990	4236,8	988,0	30,4	3,0
1994	4252,0	325,0	7,4	1,8
2002	5429,5	1177,5	27,7	2,9

1948—1957 елларда илдәге икътисади үсеш, 1939—1948 еллардагы белән чагыштырганда, тизрәк барганмы-юкмы икәнен билгеләү өчен, шул тугызъеллыктагы ТМП үсешен баштагы дәрәҗәсенеке, ягъни 1939 һәм 1948 еллардагы ТЭПларныкы дип карарга кирәк. Шунда инде без 1939—1948 еллар эчендәге тугызъеллыкта ТМПның 54,7% ка үсүен, ә инде аннан соңгы тугызъеллыкта (1948—1957 елларда) фәкать 39,9% ка гына артуын күрербез. Ягъни ТМПның үсеш темпы 1948—1957 елларда ТМП үсешенең әкренрәк баруын чагылдыра. Димәк, икътисадның ни дәрәҗәдә тиз үсүен, аның үсеше әкренәйгәнме яки, киресенчә, тизләтелгәнме икәнлеген белү өчен, ТМП һәм ТЭП үсешләренең абсолют күрсәткечләренә, милли керем һәм башка агрегатлаштырылган күрсәткечләргә нигезләнеп түгел, ә бирелгән күрсәткеч үсешенең аның баштагы дәрәҗәсенә чагыштырмасына нигезләнеп карарга кирәк.

Әлегә кадәр без ТМП үсешенең бертөрле вакыт арасында — тугыз ел эчендәге темпларын чагыштырдык. Әгәр дә без төрле вакыт эчендә ирешелгән үсеш темпларын чагыштырсак, икътисади үсеш тизлеге югары булганмы яки түбәнме дигән сорауның җавабы дөрес булмаячак. 1969—1973 елларда, мәсәлән, ТМП 13,2% үсеш бирсә, 1973—1981 елларда ул 18,4% тәшкил итә. Ләкин беренче очракта бу үсеш — 4 елда, ә икенчесендә 8 елда ирешелә. Димәк, куелган сорауга җавап бирү өчен, безгә ТМПның гомуми үсеш темпын түгел, ә төрле еллардагы үсешенең *уртача еллык* темпларын чагыштырып күрсәтергә кирәк.

> **ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ ТИЗЛЕГЕ ТЭП яки ТМП үсешенең билгеле бер чордагы уртача еллык темпларында чагыла.**

ТЭП үсешенең уртача еллык темпын ничек исәпләргә?

Уртача еллык үсеш темпын, арифметик гамәлдәгечә, билгеле бер чордагы гомуми үсеш темпларын шул чорга кергән еллар санына бүлеп исәпләү бик зур хата булыр иде. Мәсәлән, 1929—1939 елларда, ягъни 10 ел эчендә ТМП 1,0% ка үскән икән, бу әлеге чорда уртача еллык үсеш темпы $\frac{1{,}0\%}{10} = 0{,}1\%$ тәшкил иткән дигән сүз түгел әле. Әш шунда ки, мондый

темпларда барган икътисади үсеш катлаулы процентлар кагыйдәсе буенча бара. Әйтик, 100 трлн сумга тигез булган милли керем ел саен 10% ка үсә, ди. Бу вакытта аның үсеше түбәндәге зурлыклар (трлн сумнарда) тәртибендә бара: башланып киткән вакыты — 100; беренче елы — $100 \times 1{,}1 = 110$; икенче елы — $110 \times 1{,}1 = 121$; өченче елы — $121 \times 1{,}1 = 133{,}1$ һ. б. Үсә баручы милли керем һәр ел саен 10% ка арта. Шуңа күрә 3 ел эчендә 33,1% ка үсеш, $\frac{33{,}1}{3} = 11{,}03\%$ ка тигез булган үсеш темпының нәтиҗәсе булмыйча, безнең тарафтан кабул ителгән 10% лы үсеш темпының уртача еллык нәтиҗәсе булып тора.

Димәк, әгәр безгә ТЭПның башлангыч елдагы зурлыгы (Q_0) һәм аның уртача еллык үсеш темпы (τ) безгә билгеле булса, t еллар эчендә бу зурлык

$$Q_t = Q_0 (1 + \tau)^t \qquad (15.1)$$

формуласы буенча исәпләнгән дәрәҗәгә җитәчәк. Монда Q_t — әлеге чорның соңгы (t) елындагы ТЭП күләме.

Әгәр дә безгә исәпләп чыгарырга тиешле күрсәткеч башлангыч елда Q_0 гә тигез булып t елларга тигез булган чор ахырына ул Q_t дәрәҗәсенә җитсә, һәм без аның шушы t еллар эчендәге уртача еллык үсеше темпын түбәндәге формула буенча исәпли алабыз:

$$\tau = \sqrt[t]{\frac{Q_t}{Q_0}} - 1. \qquad (15.2)$$

Димәк,

> Икътисади үсеш тизлеген исәпләп чыгарырга мөмкинлек бирә торган ТМП, ТЭП яки теләсә кайсы күрсәткечнең **УРТАЧА ЕЛЛЫК ҮСЕШ ТЕМПЫ** билгеле бер еллар эчендәге уртача геометрик үсеш темпларыннан гыйбарәт.

15.3. ҖИТЕШТЕРҮ ФУНКЦИЯСЕ ҺӘМ ҮСЕШ ФАКТОРЛАРЫ

Икътисади үсеш нәрсәгә бәйле? ТЭПны арттыру тизлеген нинди факторлар билгели? Ни өчен аерым бер илләр, икенчеләренә караганда, тизрәк үсеш ала? Икътисади үсешне

тизләтү өчен, нәрсә эшләргә кирәк дигән сораулар икътисади теориядә иң мөһимнәрдән санала. Бу сораулар һәм икътисади үсеш, аның факторлары белән бәйле башка бик күп проблемалар һәр ил өчен актуаль булып кала.

Җитештерү функциясе

ТЭП үсешендә теге яки бу факторларның нинди роль уйнавын билгеләү өчен, *җитештерү функциясе* дигән мөһим икътисади төшенчәне яңадан карап үтик. 6.3 параграфта фирмаларның гомуми, урта һәм чик (соңгы) продуктларын анализлаганда, җитештерү функциясенең иң гади вариантлары белән танышкан идек инде. Анда без аерым фирманың продукция эшләп чыгаруы җитештерү факторларының берсе — хезмәт белән функциональ бәйлелектә булуын ачыклаган идек. Ул вакытта җитештерүнең икенче факторы — капитал — үзгәрешсез калуы күздә тотылды.

Беренчедән, хәзер без продукция эшләп чыгаруны макроикътисади аспектта өйрәнербез: җитештерү күрсәткече сыйфатында ТЭП, милли керем яки барлык милли җитештерү күләменең башка күрсәткече алыначак. Моңа ярашлы рәвештә җитештерүнең теләсә кайсы факторы (мәсәлән, хезмәт) аерым фирмада эшләүчеләр санын түгел, ә икътисадка тартылган (җәлеп ителгән) гомуми эшчеләр санын тәшкил итәчәк.

Икенчедән, тагын да реальрәк шартларга якынаячакбыз: ТЭП күләмен арттыруда җитештерүгә өстәмә көчләр җәлеп итү дә, икътисадта кулланылган капиталны арттыру да йогынты ясауны күздә тотачакбыз.

Өченчедән, икътисади үсешнең төрле факторларының ролен анализлау өчен, билгеле бер вакытта ТЭП, милли керем һ. б. ның уртача еллык үсешенең темплары күрсәткечен файдалану отышлы булачак.

Ниһаять, дүртенчедән, без икътисадның озак вакытлы үсеш чорын карыйбыз, шуңа күрә икътисадка җәлеп ителгән ресурсларның тулысынча файдаланылуы, ягъни тулы мәшгульлек һәм җитештерү куәтләренең эш белән оптималь тәэмин ителеше күздә тотыла. Шуннан чыгып, ТЭП җитештерү дәрәҗәсен күтәрүгә түбәндәгеләр исәбенә ирешергә мөмкин: беренчедән, эшче көчләрне арттыру мәшгульлек дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итә; һәм, икенчедән, капитал салулар (инвестицияләр) файдаланыла торган җиһазларны арттыруга китерә.

Шулай итеп, икътисадта житештерелә торган товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне эшләп чыгару ике үзгәрешленең — хезмәт (L) һәм капиталның (K) — функциясе буларак карала:

$$Q=f(L,\ K). \qquad (15.3)$$

Әйтик, алга таба эшчеләр санын һәм кулланылган капитал күләмен арттыру даими рәвештә үз нәтиҗәсен бирергә сәләтле, ягъни хезмәт һәм капитал x тапкырга арткан икән, продукция эшләп чыгару да x тапкырга арта:

$$xQ=f(xL,\ xK). \qquad (15.4)$$

Житештерү функциясенең иң гади бу варианты мәшгульлек дәрәҗәсен арттыру, пропорциональ рәвештә аларның кулланыуын арттыруны таләп итә, ә капиталны арттыру капитал салуларны арттыруны күздә тота. Анализлауны катлауландырмас өчен, дәүләт ихтыяҗыннан һәм экспорт, импорт товарларыннан, хезмәт күрсәтүләрдән читләшеп торыйк. Ләкин монда шуны истә тотарга кирәк: милли исәп-хисап системасы нигезендә ТЭП капитал салулар һәм шәхси куллану суммасына тигез, шуннан чыгып, ТЭП күләмен арттыру капитал салуларны арттыру белән шәхси куллануны арттыру суммасына тигез була, ягъни

$$\Delta Q=\Delta C+\Delta I. \qquad (15.5)$$

12 нче бүлектә ачыклап үткәнчә, куллану функциясе теориясе нигезендә

$$c+s=1,$$

монда c — куллануга иң чик хирыслык, s — саклыкка куюга иң чик хирыслык. Шулай итеп,

$$\Delta C=(1-s)\Delta Q. \qquad (15.6)$$

15.5 тигезләмәсенә 15.6 тигезләмәсендә бирелгән ΔC кыйммәтен куйсак,

$$\Delta Q=(1-s)\Delta Q+\Delta I$$

килеп чыга һәм үзгәртүләрдән соң

$$\Delta I=s\Delta Q \qquad (15.7)$$

табыла.

15.7 тигезләмәсе балансլы үсеш вакытында капитал салулар ТЭП үзгәрешләренә пропорциональ рәвештә үзгәрүен күрсәтә (монда саклыкка куюга иң чик хирыслык пропорциональлек коэффициенты ролен үти).

15.7 тигезләмәсе икътисади үсешнең тагын бер мөһим үзлеген күрсәтә: **әгәр саклыкка куюга иң чик хирыслык арта икән, балансны үсешне тәэмин итү өчен, ТЭПта капитал салулар (инвестицияләр) өлеше дә артырга тиеш**. 15.4 тигезләмәсе нигезендә хезмәткә чыгымнар һәм капитал даими файда китергән шартларда ТЭП үсеше темпы саклыкка куюга иң чик хирыслык һәм ТЭПта капитал салулар өлеше үзгәрүгә пропорциональ рәвештә үзгәрәчәк.

Инде житештерү функциясен (15.4) ТЭП үсешенә һәр фактор керткән өлешне исәпкә алып тикшереп карыйк. Бу очракта житештерүне арттыру ΔQ 1) эш белән тәэмин ителгәннәрнең санын арттыру исәбенә (ΔQ_L) һәм 2) капиталны арттыру, ягъни саф капитал салулар (ΔQ_K) исәбенә житештерүне арттыру суммасы буларак карала:

$$\Delta Q = \Delta Q_L + \Delta Q_K. \qquad (15.8)$$

Хәзер ТЭП үсеше темпын түбәндәге тигезләмә белән күрсәтәбез:

$$\frac{\Delta Q}{Q} = \frac{\Delta Q_L}{Q} + \frac{\Delta Q_K}{Q}. \qquad (15.9)$$

ТЭП үсеше темпын τ белән билгеләп,

$$\frac{\Delta Q_l}{Q} = \alpha \frac{\Delta L}{L} \text{ һәм } \frac{\Delta Q_K}{Q} = (1 - \alpha)\frac{\Delta K}{K}$$

дип уйлап, ТЭП үсеше темпын түбәндәгечә күрсәтәбез:

$$\tau = \alpha \frac{\Delta L}{L} + (1 - \alpha)\frac{\Delta K}{K}. \qquad (15.10)$$

α һәм $(1-\alpha)$ параметрлары ТЭП үсешендәге һәр факторның өлешен күрсәтә. Аерым алганда, α — ТЭПның гомуми үсешендә хезмәтне арттыру өлешен, ә $(1-\alpha)$ ТЭП үсешендә капиталны арттыру өлешен билгели. Аңлашыла ки, $0 \leqslant \alpha \leqslant 1$. Өстәвенә $\alpha \frac{\Delta L}{L}$ аңлатмасы да, $(1 - \alpha)\frac{\Delta K}{K}$ аңлатмасы да хезмәт һәм капитал чыгымнарыннан килгән файдалы нәтиҗәсе үзгәрешсез калуын күздә тота. Димәк, хезмәт һәм капитал чыгымнарының гомуми файдалы нәтиҗәсе дә үзгәрешсез кала. Ачыклык өчен 15.10 тигезләмәсендә күрсәтелгән житештерү функциясен 15-2 таблицасында бирелгән санлы мисаллар аша карап үтик.

15-2 таблицасы

Җитештерү функциясе: җитештерү факторлары үсеше темпы һәм товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү үсеше темпы, млрд долларда

Ел	Җитештерү факторлары							Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү		
	L (1)	ΔL (2)	$\alpha \frac{\Delta L}{L}$, % (3)	K (4)	ΔK (5)	$(1-\alpha)\frac{\Delta K}{K}$, % (6)	(3) + (6), % (7)	Q (8)	ΔQ (9)	$\frac{\Delta Q}{Q}$, % (10)
1	50			80				100		
2	55	5	6,00	88	8	4,00	10,00	110	10	10,00
3	60	5	5,45	96	8	3,64	9,09	120	10	9,09
4	65	5	5,00	104	8	3,33	8,33	130	10	8,33
5	70	5	4,61	112	8	3,08	7,69	140	10	7,69
6	75	5	2,28	120	8	2,86	7,14	150	10	7,14

Таблицада $\alpha = 0{,}6$ дип бирелә, димәк, $(1-\alpha) = 0{,}4$. Бу ТЭП үсеше хезмәтне арттыру хисабына — 60% ка, ә капиталны арттыру хисабына 40% ка җиткәнне аңлата.

Монда җитештерү факторларының икесенең дә файдалы нәтиҗәсе үзгәрешсез кала: кулланылган хезмәт күләме күпме генә булса да $\frac{Q}{L}$ чагыштырмасы 2 гә тигез була. Башкача әйткәндә, икътисадта хезмәт җитештерүчәнлеге үзгәрешсез кала. Бу капиталдан килгән файдага да кагыла: барлык очракларда да $\frac{Q}{K}$ чагыштырмасы 1,25 кә тигез була.

Таблицада алга таба җитештерү факторларының да, шулай ук товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүнең дә сызыкча үсеше күзәтелә: һәр ел дәвамында хезмәт — 5 берәмлеккә, капитал — 8, продукт эшләп чыгару 10 берәмлеккә арта бара. Бу — продукт эшләп чыгаруның да, җитештерү факторларының да уртача еллык үсеш темплары кими баруын аңлата. Шуның нәтиҗәсе буларак, ТЭП җитештерүдә һәр факторга тотылган кертемнең үсеш темпы да кими. Әмма, 15.10 тигезләмәсеннән күренгәнчә, хезмәт һәм капиталны теге яки бу темпларда Q үсешенә әйләндерүче кертем өлешләренең суммасы Q үсеше темпына тигез булып кала: әйтик, башта бу сумма 6,0% + 4,0% = 10%; аннан соң ул 5,45% + 3,64% = 9,09% ка һ. б. га тигез була. Шуннан чыгып, Q үсеше темпы 10%, 9,09% ка һ. б. га тигез була.

15.10 тигезләмәсе һәм 15-2 таблицасы ТЭПның хезмәт бирәмлегенә һәм капитал бирәмлегенә күчереп исәпләгәндә үзгәрешсез калуын күздә тота. Ахыр чиктә бу — халык санына күчереп исәпләгәндә, ТЭПның үзгәрмәвенә китерәчәк һәм икътисади үсешнең тулы канлы булмавын аңлатачак.

Реаль чынбарлыкта икътисади үсеш, нигездә, чыгымнарның элеккеге күләменнән барлыкка килгән ТЭП белән бара. Бу шуның белән аңлатыла: беренчедән, хезмәт җитештерүчәнлеге үсә һәм, икенчедән, салынган капиталдан файда алу арта. Хезмәт һәм капиталның файдалы нәтиҗәсе турында гомуми характеристика бирүче күрсәткеч **тулай факторлы җитештерүчәнлек** дип атала. Тулай факторлы җитештерүчәнлек үсә икән, продукция җитештерү капитал һәм хезмәт күләме артудан гына түгел, ә хезмәт җитештерүчәнлеге, яки капитал салудан файдалы нәтиҗәсе, яки берьюлы икесенең дә артуыннан күтәреләчәк. Мәсәлән, әгәр хезмәт һәм капитал күләме үзгәрешсез калса, ә тулай факторлы җитештерүчәнлек 1% ка күтәрелә икән, ТЭП күләме дә ел саен 1% ка арта дигән сүз. 15.10 тигезләмәсеннән күренгәнчә, тулай факторлы җитештерүчәнлек үзгәрми.



15-3 нче рәсем. △
ТЭП үсеше темпында хезмәт, капитал һәм тулай факторлы җитештерүчәнлекнең өлеше.
ТЭП үсешенең фаразланган темпы 12% тәшкил итә. Ә хезмәт чыгымнары үсешенең өлеше — 6%, капиталныкы — 4%. ТЭП үсеше темпы, хезмәт һәм капитал чыгымнары үсешенә караганда, югарырак килеп чыга. Бу — я хезмәт җитештерүчәнлегенең артуы, яки капиталдан файдалы нәтиҗәнең артуы, яки берьюлы икесенең дә артуы, ягъни тулай факторлы җитештерүчәнлекнең артуы белән аңлатыла. Тулай факторлы җитештерүчәнлек үсешенең өлеше — 2%. Нәтиҗәдә ТЭП үсеше темпы хезмәт һәм капитал чыгымнары үсеше темпыннан югарырак килеп чыга.

Тулай факторлы житештерүчәнлек үсеше тигезләмәгә икътисади үсештә өченче фактор ролен уйнаган тагын бер элементны кертү юлы белән билгеләнә. Бу очракта ТЭП үсеше темпында һәр факторның ролен (өлешен) билгеләүче тигезләмә түбәндәгечә төзелә:

$$\tau = \alpha \frac{\Delta L}{L} + (1 - \alpha) \frac{\Delta K}{K} + \beta, \tag{15.11}$$

монда β — икътисади үсешнең хезмәт һәм капитал чыгымнарын арттыруга бәйле булмаган өстәмә факторны аңлата.

ТЭП үсеше темпының өч факторга да бәйле булуы 15-3 рәсемендә күрсәтелә.

15.4. ЭКСТЕНСИВ ҺӘМ ИНТЕНСИВ ҮСЕШ ФАКТОРЛАРЫ

15.11 тигезләмәсен һәм 15-2 таблицасын карап үтү безгә үсеш факторларын экстенсив һәм интенсив факторларга бүләргә мөмкинлек бирә.

Экстенсив үсеш факторлары

Экстенсив үсеш факторларына хезмәт һәм капитал керә. Аларның үзенчәлеге шунда: биредә продукция житештерүне арттыру фәкать бу факторларны *күләм*, ягъни *экстенсив* киңәйтү исәбенә генә ирешелә: производствога яңа эшче көчләр җәлеп ителә һәм предприятиеләрдә станоклар саны арттырыла. Монда әле эшчеләрнең квалификациясе һәм аларның хезмәт житештерүчәнлеге үзгәрешсез кала. Җиһазлану дәрәҗәсе дә, технологиясе дә элеккечә кала. Шуңа күрә продукциядән алынган табыш һәм капитал бирәмлегенә туры килгән керем күләме үзгәрми.

Авыл хуҗалыгында экстенсив үсеш ролен эшкәртелә торган җирләрнең (чәчүлекләрнең, көтүлекләрнең) мәйданын арттыру, ә тау токымнарын үзләштерү сәнәгатендә бу рольне файдалы казылмаларның яңа ятмаларын кулланугa кертү уйный.

Интенсив үсеш факторлары

Интенсив үсеш факторларына фәнни-техник прогресс, эшче көчләрнең квалификациясен күтәрү, житештерүне оештыруны камилләштерү һәм яңа технологияләр кертү, яңа төр продукция эшләп чыгара башлауга күчү, иске җиһазларны

яңаларына алмаштыру белән бәйле факторлар куллану кирә. Интенсив үсеш факторларының үзенчәлеге җитештерелә торган продукциянең күләмен арттыру җитештерү факторларының яки эшләп чыгарылган продукциянең *сыйфатын яхшырту* исәбенә ирешелә.

Интенсив үсеш факторлары арасында иң мөһиме — **фәнни-техник прогресс** (ФТП). ФТП — җитештерү, фән, мәгариф өлкәләрендәге, хезмәтне оештыру һәм кеше эшчәнлеге сферасындагы башка бик күп төрле үзгәрешләр белән бәйле шактый катлаулы прогресс. Ләкин һәр очракта да ФТП җәмгыятьтәге яңа белемнәр таләп ителгән фәнни ачышларны һәм уйлап табуларны тормышка ашыру формасы булып хезмәт иткән яңалыкларны белеп-туплап баруга, белемнәрне киңәйтүгә нигезләнгән.

Яңалыкка омтылышны хәрәкәтләндерүче стимул булып зур керемнәр — беренче чиратта табыш алу санала. Конкуренциянең дә роле кечкенә түгел, чөнки җитештерүнең югары күрсәткечле факторларына таянып продукция эшләп чыгаручы фирманың конкурентлык позицияләре, бу күрсәткече түбән булган фирмага караганда, күпкә өстенрәк булып тора. Фән һәм техника прогрессы стимулларын матди якка гына һәм конкурентлык шартларында җиңелү нәтиҗәсендә зыян күрү куркынычына гына кайтарып калдырырга ярамый. Табигать серләренә төшенүгә омтылыш, кешеләргә эш шартларын җиңеләйтү, әлегә кадәр беркайда да кулланылмаган яңа уңайлыклар тудыру кебек мотивлар да зур әһәмияткә ия булырга мөмкин.

Интенсив факторлардан эшче көчләрнең — эшчеләрнең, инженерларның, эшмәкәрләрнең — **квалификациясен күтәрү** аеруча зур әһәмияткә ия. Җитештерүгә җәлеп ителгән кешеләрнең белемнәре һәм осталыклары тирәнәя, камилләшә бармаса, фәнни ачышларны, техник уйлап табуларны тормышка ашыру турында уйлап та булмас иде. Алай гына да түгел, нәкъ менә матди һәм рухи байлыклар тудыручылар, үзләренә белемнәр туплап һәм осталыкларын арттырып, фән, технология үсешенә, икътисадның нәтиҗәсен күтәрүгә алшарт булдыралар. Әмма фән һәм техника үсешен аңа тәңгәл рәвештә белемне күтәрүдән (гомуми һәм махсус) башка фикер дә йөртеп булмый. Белеме җитәрлек дәрәҗәдә булмаган кеше яңа технологияләр куллану буенча кирәкле идеяләрне үзләштерә алмый, ә инде аларны уйлап табу турында әйтеп тә торасы юк.

Интенсив факторлар арасында **ресурсларны бүлү** дә зур әһәмияткә ия. Бу факторның йогынтысы шунда: икътисади үсеш барышында илдәге тармаклар һәм регионнар арасында ресурсларны бүлүне яхшырту бара; капитал һәм эшче көчләр түбән нәтиҗәле тармаклардан һәм регионнардан әкренләп яхшырак нәтиҗәлесенә күчә бара. Моның нәтиҗәсендә уртача хезмәт җитештерүчәнлеге һәм капиталның уртача файдалы нәтиҗәсе ил буенча тулаем алганда күтәрелә.

Җитештерү масштабларыннан чыгып экономияләүне дә интенсив үсеш факторларына кертү каралган. Чөнки эре фирма, үзенең җитештерү масштабларын киңәйтә барып, үз продукциясен сатуны оештыруны яхшыртуга, реклама эшен җанландыруга, тәэмин итүне очсызрак, шул ук вакытта сыйфатлырак чимал һәм ярымфабрикатлар белән оештыруга күбрәк средство сарыф итү мөмкинлегенә ирешә, җитмәсә, бу чыгымнар, җитештерү масштаблары үсешенә караганда, әзрәк күләмдә күтәрелә. Шуңа күрә, продукция берәмлегенә күчереп исәпләгәндә, мондый төр чыгымнар кими.

15-3 таблицасы

1929—1982 елларда АКШның милли керемнең гомуми күтәрелешендә үсеш факторларының өлеше

Икътисади үсеш факторлары	Уртача еллык үсеш темпы, %ларда		
	1929—1969	1948—1973	1973—1982
Экстенсив факторлар	1,82	2,23	2,53
Шул исәптән:			
хезмәт	1,32	1,46	1,86
капитал	0,50	0,77	0,67
Интенсив факторлар	1,59	1,66	0,08
Шул исәптән:			
фән (ФТП),	0,92	1,09	−0,05
мәгариф, квалификация ресурсларны бүлү	0,30	0,30	0,07
масштабтан чыгып экономияләү	0,36	0,32	0,32
башкалар	0,01	−0,05	− 0,15
Милли керемнең уртача еллык үсеш темпы	3,41	3,89	2,61

Практикада экстенсив һәм интенсив үсеш факторларын аерып күрсәтү мөмкин түгел. Чөнки икътисади үсешнең бу ике төркеме үзара бик тыгыз бәйләнгәннәр. Мәсәлән, капиталны экстенсив үстерүгә юнәлдерелгән инвестицияләр техник яктан яңа саналган җиһазларны сафка кертү һәм тагын да камилләшкәнрәк технологияләр куллану белән бергә бара. Мәшгульлек үсеше продукция җитештерүне арттыруның экстенсив факторы булып тора, ләкин җитештерүгә җәлеп ителгән яшь белгечләрнең күбесе, бу өлкәгә моннан 10—15 еллар элек килеп эшли башлаганнар белән чагыштырганда, югарырак белемле булалар. Масштаблардан чыгып экономияләү, интенсив фактор буларак, һәр очракта да эшләп торучы фирмаларны экстенсив киңәйтүне яки алар санын үстерүне күздә тота. Шуңа күрә, икътисади үсешнең теге яки бу факторын бәяләү өчен икътисад үсешенә шактый катлаулы, һәрьяктан җентекле анализ таләп ителә.

15.5. XX ГАСЫР АХЫРЫНДА ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ ТЕМПЛАРЫНЫҢ КИМҮЕ НӘРСӘГӘ БӘЙЛЕ

XX гасырның 70—90 нчы елларында икътисади үсешнең әкренәюе

Бүгенге фәнни-техник прогрессның зур уңышлары, производствода эшләүчеләрнең белемнәре арту һәм квалификациясе күтәрелү һәркайсыбызга да яхшы таныш. Бер карасаң, бу уңышлар бөтен дөньяда икътисади үсеш темпларын тизләтергә тиеш иде. Әмма статистик мәгълүматлар аптырашта калдыра. 15-3 таблицасына тагын бер карагыз әле. АКШның милли кереме үсеше ун ел эчендә (1973—1982), 1948—1973 еллардагы белән чагыштырганда, 1,5 тапкыр диярлек кимегән. Милли керем үсешенә фәкать хезмәт чыгымнары һәм капитал күләмен арттыру исәбенә генә ирешелгән, ә интенсив факторлар өлеше бөтенләй аз булган.

Бәлки, бу, Америка икътисады үзенчәлеге буларак, үсеш темпларының әкренәюедер? Статистика раслаганча, бу — гомуми күренеш. 15—4 таблицасы мәгълүматларыннан күренгәнчә, икътисади үсешнең болай әкренәюе базар икътисады үсеш алган барлык зур илләрдә күзәтелә.

15-4 таблицасы

Дөньяның зур үсеш алган җиде илендә бер кешегә исәпләгәндә ТМП үсеше темпларының кимүе

Илләр	Бер кешегә ТМП күләме үсеше темплары, %ларда		
	1948–1972	1972–1988	1990–2001
АКШ	2,2	1,7	1,2
Япония	8,2	3,3	1,4
Германия	5,7	2,2	1,9
Франция	4,3	2,1	1,6
Бөекбритания	2,4	2,1	1,5
Италия	4,9	2,8	1,5
Канада	2,9	2,6	0,8

Моңа охшаш күренешләр сизелми генә үтми, билгеле. Бу күренешкә төрле илләрнең икътисадчылары үз аңлатмаларын бирергә омтылып карадылар. Иң киң таралган аңлатмалар түбәндәгеләр булды:

1. 70 нче елларда икътисадка җәлеп ителгән эшче көчләрне, гомуми хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүне тәэмин итү өчен, тәҗрибәсе дә, күнекмәләре дә җитәрлек дәрәҗәдә булмаган яшьләр хисабына тулыландыру темплары көчәйде.

2. Әйләнә-тирәлекне дәүләт органнары тарафыннан саклау югары нәтиҗәле, әмма экологик яктан зарарлы җиһазлар куллануны тыюга китерде һәм капитал салулардан файдалы нәтиҗәнең үсешен киметте.

3. ОПЕК[1] составына кергән илләр, нефть табу һәм җитештерү буенча монополистик төркемгә берләшеп, нефтькә дөнья бәяләрен кискен күтәрделәр, бу күп энергия һәм нефть продуктлары кулланучы машиналарның һәм җиһазларның нәтиҗәлелеген киметте. Бу җиһазлар һәм машиналар җитештерүдән алынды.

4. Дөньяда технологияләрне камилләштерү буенча яңа идеяләр азрак туа башлады.

Дөньяда икътисади үсеш темпларының озак вакытка кимүе хакындагы әлеге һәм башка аңлатмалар әле дә бәхәсле булып кала.

---

[1] ОПЕК (организация, объединяющая 13 стран – экспортеров нефти) – читкә нефть чыгаручы 13 илне берләштергән оешма. Россия анда керми.

Әйтик, ни өчен яңа идеяләр тудырырга сәләтле, талантлы белгечләргә кытлык булган? Һәм ул, гомумән, булганмы соң?

Нефтьнең кыйммәтләнүе аркасында күп энергия таләп итүче җиһазлар сүтеп ташланса да, ул капитал салу файдасын күтәрүгә уңай йогынты ясаучы, аз энергия белән эшләүче җиһазларны ашыгыч рәвештә сафка бастыру белән бергә барды, ә бу ТЭП үсеше темпларын арттыруга китерергә тиеш иде. Экологик яктан зарарлы җиһазларны файдаланудан алу, дөньякүләм масштабта исәпләгәндә, артык сизелерлек булмады, һәм ул кыска вакытлы күренеш иде, берничә елда гына, анда да әле бөтен илдә түгел, ТЭП үсешенең гомуми темпларына бик аз йогынты ясады.

Җитештерүгә яшьләрне, тәҗрибәсез хезмәткәрләрне тартуга килгәндә, мондый процесслар элек тә булган, әмма алар һәр очракта да хезмәт җитештерүчәнлеген һәм икътисади үсеш темпларын киметүгә китермәгән.

Озак вакытлы цикллар теориясе

70—90 нчы елларда икътисади үсеш темпларының әкренәюен **озак вакытлы цикллар** яки Кондратьев[1] цикллары теориясе буенча аңлату ышанычлырак булыр. Хәзерге вакытта күп кенә икътисадчылар озак вакытлы циклларның булуы исбатланган дигән фикерне яклыйлар, гәрчә бу күренеш механизмын аңлатуда җитди генә аерымлыклар булса да.

Биредә без әлеге механизмны Н. Д. Кондратьев тарафыннан тәкъдим ителгән һәм әле бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмаган идеяләр позициясеннән чыгып карарбыз.

Белгәнебезчә, базар икътисады тигезләнеш халәтенә омтыла, ләкин ул беркайчан да идеаль тигезләнеш халәтендә булмый. Реаль икътисадның тигезләнеш халәтеннән тайпылышының бер күренеше — дулкынсыман, циклы тирбәлешләре. Алар

---

[1] Н. Д. Кондратьев (1892—1938), статистик анализга нигезләп, озак вакытлы цикллар булуын исбатлый һәм бу феноменның теоретик нигезләмәсен тәкъдим итә. Аның идеяләре кабул ителә һәм шуннан соңгы елларда икътисадчылар хезмәтләрендә тулыландырыла. Н. Д. Кондратьев репрессия корбаны була. Ул 1930 елда «крестьяннар партиясе» эше белән бәйле рәвештә кулга алына, аны «планлаштыруда буржуаз ысуллар кертү»дә, «авыл хуҗалыгын үстерүгә аяк чалу»да гаеплиләр. Ул 8 елга ирегеннән мәхрүм ителә һәм 1938 елда атып үтерелә.

тигезләнешнең кайсы да булса бер дәрәҗәсе тирәсендә барлыкка киләләр.

Икътисадта төрле вакытлар дәвамында үзләренең хуҗалык функцияләрен башкаручы байлыклар житештерелә. Кыска вакытлы файдаланулы күп төрле куллану товарлары (азык-төлек, эчемлекләр һ.б.) һәм чималның да күп кенә төрләре үзләрен житештерү өчен чагыштырмача кыска вакыт таләп итәләр. Икенче бер төркем товарлар озаграк вакыт дәвамында файдаланылалар, аларны житештерү дә озаккарак сузыла һәм чагыштырмача зуррак инвестицияләр таләп итәләр (мәсәлән, житештерү җиһазлары һәм озак файдаланулы куллану товарлары — җиңел автомобильләр, телевизорлар һ. б.). Ниһаять, өченче төркем товарлар — дистәләгән еллар эшләп торучы капитал байлыклар — тимер юллар, каналлар һ. б. Аларны төзү озак елларга сузыла, ә мондый корылмаларга салынган капиталның чыгымнарны каплау вакыты шактый зур. Монда шулай ук квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүне дә кертергә кирәк.

Җитештерү факторларын (капиталны һәм хезмәтне) яңарту һәм киңәйтү даими һәм тотрыклы темплар белән тигез генә бармый, ә сикерешләр белән бара. Озак вакытлы корылмалар төзелешенең тизләтелгән периоды бу корылмаларны төзү интенсивлыгы кимегәндә тынып та кала. Шуның нәтиҗәсендә икътисади үсеш процессы озакка сузыла, ТЭПның фактик дәрәҗәсе, инвестицияләр һәм икътисадның башка элементлары үзләренең тигезләнеш халәтеннән югарыга тайпылалар. ТЭП үсешенең уртача еллык темпы 20—30 еллар дәвамында тигезләнешле үсеш темпыннан югары була. Озак вакытлы яңа төзелешнең интенсивлыгы түбәнәя икән, ТЭП үсешенең уртача еллык темпы да кими, нәтиҗәдә ул тигезләнешле дәрәҗәсеннән түбән була. Беренче чор дәвамында озак вакытлы циклның — күтәрелмә дулкыны, ә икенче чор дәвамында төшмә дулкыны барлыкка килә.

Озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкыны

Беренчедән, озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкыны, икътисадта чыгымы каплану озакка сузылачак кыйммәтле проектлар инвестицияләрен тоткарлыксыз финанслау өчен, акча капиталының күпләп тупланган булуына йөз тота.

Икенчедән, тармактагы дәвамлы төзелешләр өчен тотыла торган озак вакытлы инвестицияләр җитештерү факторларына күп еллар буена тотрыклы сорау тудыралар, һәм ул икътисадның барлык масштабындагы капитал салуларның үсешен стимуллаштыра. Бу процесс элеккеге елларда тупланган фәнни ачышларны һәм уйлап табуларны киң масштаблы яңа төзелешләрдә тормышка ашыруны күздә тота. Шуңа күрә озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкыны интенсив үсеш факторлары ролен үстерү белән характерлана.

Өченчедән, озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкыны башланганда, зур суммада иреклe акча капиталы булу ссуда капиталлары базарында капиталны тәкъдим итүнең, аңа сорауга караганда, тотрыклы рәвештә артуын аңлата.



15-4 нче рәсем. △

Озак вакытлы цикл барышында ТЭП үсеше темплары хәрәкәте.

Абсциссалар үзәгенә параллель рәвештә үткәрелгән тоташ сызык 60 ел эчендә ТЭП үсешенең уртача еллык темпын күрсәтә. ТЭП үсешенең 1,75 % ка тигез булган уртача еллык темпы ТЭП һәм аның барлык элементларының тигезләнеш дәрәҗәсен тәэмин итә. 2 елдан алып 5 елга кадәр булган кыска вакыт аралыгында ТЭП үсешенең уртача еллык темплары озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкыны вакытында 0,8% тан башлап 2,7 % ка кадәр арту, ә аннан соңгы төшмә дулкын вакытында кимү тенденциясе ала һәм цикл ахырына 0,7% ка кадәр кими.

Бу — процент ставкасы дәрәҗәсен төшерүгә, капиталның очсызлануына китерә, һәм шуның белән инвестицияләр күтәрелүгә уңай йогынты ясый.

Икътисад тармакларын торган саен күбрәк колачлаган яңалыкларның киңрәк җәелә баруы җитештерүнең яңа структурасы формалашуга китерә. Мондый шартларда яңалыклар кертүгә омтылыш дулкыны үз-үзен юкка чыгара. Нигездә, озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкынын китереп чыгарган озак вакытлы проектлар тәмамлана. Инвестицияләрнең күтәрелмә дулкыны дәвамында ирешелгән югары дәрәҗәсе процент ставкасы үсешенә китерә. Әлеге шартлар барысы бергә озак вакытлы циклның күтәрелмә дулкыны тәмамлануга якынлашуына һәм аны төшмә дулкын алмаштыруга китерә.

Озак вакытлы циклның төшмә дулкыны

Төшмә дулкын күтәрелмә дулкынны китереп чыгарган түбәндәге процессларның йомшаруыннан барлыкка килә:

- элек башланган кыйммәтле озак вакытлы корылмалар төзелеше проектлары тәмамлана, әмма, процент ставкалары югары булу һәм ирекле акча капиталында зур суммалар булмау сәбәпле, яңа төзелешләр башланмый;
- процент ставкалары югары булганлыктан һәм җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүне һәм яна төр продуктлар эшләп чыгаруны вәгъдә итүче ачышлар һәм уйлап табулар инде файдаланылганлыктан, яңалыклар кертү белән бәйле инвестицияләрнең күләмнәре кыскара;
- күтәрелмә дулкын вакытында ирекле акча капиталының күп өлешен яңа проектларга юнәлдерелгән инвестицияләр йоткан була, процент ставкалары чиктән тыш дәрәҗәгә күтәрелә, һәм болар икътисади үсеш темпларының озак вакытлы гомум кимүе тенденцияләрен китереп чыгаруга сәбәп булалар.

Озак вакытлы циклның төшмә дулкынының яңа күтәрелмә дулкынга күчүенә түбәндәге алшартлар өлгерә:

- инвестицияләр үсеше әкренәю ирекле акча капиталы үсешен тизләтә, аларны капитал базарына чыгаруны арттыра һәм шуның нәтиҗәсендә процент ставкалары киму тенденциясен китереп чыгара;
- инвестицияләр үсеше әкренәю фәнни ачышларның һәм уйлап табуларның чагыштырмача бик аз өлешенең генә

яңа проектларда файдаланылуын чагылдыра; файдаланылмаган белемнәр, яңа технологияләрне үзләштерү буенча файдаланылмаган мөмкинлекләр туплана башлый;
— озак вакытлы төзелешләр һәм зур күләмле капитал салулар таләп итүче яңа проектларны тормышка ашыру зарурлыгы өлгерә, һәм ул торган саен котылгысыз күренешкә әйләнә бара.

Озак вакытлы циклларның үзенчәлекләре

Озак вакытлы циклларның **беренче** үзенчәлеге шунда: ул, урта сроклы цикллар барышындагы кебек, даими рәвештә үсеш фазалары алмашынуны һәм ТЭП, инвестицияләр, мәшгульлек һәм куллану дәрәҗәләре кыскаруны күздә тотмый. 20—30 еллар дәвам иткән озак вакытлы циклның төшмә дулкыны товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр эшләп чыгаруның озакка сузылган артка чигенешен һәм ике-өч дистә еллар дәвамында кулланунын кыскаруын китереп чыгара дип уйлау акылсызлык булыр иде. Җитештерүе, эш белән тәэмин ителгәнлеге һәм куллануы шулкадәр озакка сузылган артка чигенешне кичерергә сәләтле икътисадка ия булган ил юк ул.

> **ОЗАК ВАКЫТЛЫ ЦИКЛЛАР** икътисади үсеш темплары күтәрелү юнәлеше алган (күтәрелмә дулкын) чорлар белән икътисади үсеш темплары төшү юнәлеше алган (төшмә дулкын) чорларның озак вакытларга сузылган ритмлы чиратлашуын тәшкил итәләр.

Озак вакытлы циклларның **икенче** үзенчәлеге урта сроклы цикллар хәрәкәте белән бәйләнгән. Озак вакытлы циклларның күтәрелмә дулкыны урта сроклы цикллар күтәрелешеннән дәвамлырак фазалары һәм чагыштырмача кыска вакытлы, тирән булмаган рецессияләр белән аерылып тора. Озак вакытлы циклларның төшмә дулкыны өчен урта сроклы цикл күтәрелешенең чагыштырмача кыска вакытлы, көчсез фазалары һәм озакка сузылган тирән рецессияләре хас.

Моннан озак вакытлы циклның **өченче** үзенчәлеге килеп чыга. Төшмә дулкын вакытында ТЭП үсеше темплары, инвестицияләр, мәшгульлек, инновацион процессларның активлыгы кимү эзлекле булмый, ә икътисади үсешнең гомум тенденция-

ләре нигезендә бара. Бу икътисади үсеш темплары берничә ел дәвамында күтәрелергә, аннан төшәргә, товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү бик нык кимегәндә, тискәре дә булырга мөмкин. Әмма төшмә дулкын вакытында икътисади үсешнең уртача еллык темпы күтәрелмә дулкын вакытындагы икътисади үсешнең уртача еллык темпыннан түбән була. Икътисади үсеш темплары, күтәрелмә дулкын вакытында да, нәкъ шулай ук өзлексез үсүдән туктап, артуга юнәлеш тота.

Озак вакытлы дүрт цикл

Озак вакытлы дулкыннар күренешен өйрәнүче икътисадчыларның фикере буенча базар икътисады үзенең якынча икейөзьеллык тарихында озын-озын дүрт дулкын узган. Төрле авторларның бәяләре буенча, икътисад үз үсешендә иң югары темпларга ирешкән елларда да ул дулкыннар күпмедер дәрәҗәдә бер-берсеннән аерылып торганнар, әмма бу аерымлыклар бик зур түгел. Әйтик, озак вакытлы циклның башлану һәм тәмамлану чоры үсеш темпларының иң түбән вакытына туры килгән, ди. Бу озын дүрт дулкын чиген, аларның иң югары һәм иң түбән нокталарын 15-5 рәсемендә бирелгән диаграмма рәвешендә күзалларга була.

БМО статистикасы, озын циклларның дүртенчесенең хәрәкәте турында фикер йөртү өчен, шактый кыйммәтле күрсәткечләр бастырып чыгара. Алар 15-5 таблицасында китерелә.

15-5 таблицасы

1929—1999 елларда базар икътисады хөкем сөргән илләрдә ТМП үсеше, сәнәгать продуктлары җитештерү һәм читкә товар чыгаруның уртача еллык темплары

Урта сроклы цикллар, еллар	ТМП, %ларда	Сәнәгать продукциясе, %ларда	Читкә товар чыгару, %ларда
1929—1937	...	1,35	–9,83
1937—1948	...	3,50	0,07
1948—1957	4,42	5,68	7,94
1957—1969	4,63	6,04	7,20
1969—1973	4,60	5,67	10,06
1973—1979	2,73	2,51	4,47
1979—1990	2,59	2,00	3,22
1990—1999[1]	4,2[2]	2,47	6,6

[1] 1990—1999 еллардагы унъеллык урта сроклы циклга керми.
[2] ТЭП.



15-5 нче рәсем. △
Озак вакытлы дүрт цикл.

Диаграммадан күренгәнчә, базар системасы үсеш алган илләрнең икътисады үзләренең күтәрелеш процессында озак вакытлы дүрт цикл үткәннәр. Аларның беренчесе, XVIII гасыр ахырында башланып, күтәрелмә дулкын узган, һәм аның иң югары ноктасы XIX гасырның икенче унъеллыгы урталарына туры килә. Бу циклның төшмә дулкыны XIX гасыр урталарында тәгәлләнә. Аннан озак вакытлы икенче цикл уза, аның иң югары ноктасы — 1869—1875 елларда, ә иң түбән ноктасы 1886—1888 елларда була. Озак вакытлы өченче цикл, XIX гасырның 80 нче еллары ахырында башланып, үзенең күтәрелеш чорын XX гасырның икенче унъеллыгының икенче яртысында кичерә һәм 30 нчы елларның беренче яртысында түбәнлектә тәмамлана. Ниһаять, үткән гасырның 30 нчы елларының беренче яртысында озак вакытлы дүртенче цикл башлана. Аның күтәрелмә дулкыны, 50 нче еллар ахырында башланып, 60 нчы еллар буена дәвам итә. Бу циклның төшмә дулкыны 80 нче еллар ахырыннан 90 нчы еллар башына кадәр бара.

15–5 таблицасыннан күренгәнчә, 1929—1937 елларны эченә алган урта сроклы цикл озак вакытлы өченче һәм дүртенче циклларның чик сызыгы ролен уйный. Ул базар икътисады үсешенең дөньяда (планлы идарә ителә торган илләрдән кала) икътисади үсеш темплары иң түбән дәрәҗәгә төшкән чоры була. Аннан күтәрелмә дулкын башлана, ТМП үсеше темплары һәм ТМПның иң мөһим өлеше — сәнәгать продуктлары җитештерү үсә башлый, аның иң югары ноктасы 1957—1969 еллардагы урта сроклы цикл вакытына туры килә. 1969—1989 елларда озак вакытлы дүртенче циклның төшмә дулкыны хәрәкәтен чагылдырган темпларның түбәнәюе күзәтелә. Ләкин 90 нчы елларның

беренче яртысында инде дөньяда ТМП үсеше темплары сизелерлек күтәрелә. 1990—1994 еллар эчендә ТМП үсешенең уртача еллык темплары — 3,1%, сәнәгатьтә — 2,8%, читкә товар чыгару 4,6% тәшкил итә. Шулай итеп, күргәнебезчә, дөнья икътисады үсешенең киләчәктәге мөмкинлекләре турында борчылырлык нәтиҗәләр һәм өметсез прогнозлар ясарга нигез юк. Иң мөһиме, озак вакытлы дүртенче циклның төшмә дулкыны артта калды, дөнья озак вакытлы бишенче циклның күтәрелмә дулкыны чорына аяк басты.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Кешелек җәмгыятенең күпьеллык тарихы раслаганча, икътисад үсеше ТЭП җитештерүне абсолют һәм җан башына күчереп исәпләгәндә арттыру белән бара. Шуның нәтиҗәсендә һәр буын кешеләре, үзләреннән алдагыларына караганда, югарырак реаль керемнәргә ия. Потенциаль ТЭП күләмен, абсолют күрсәткечләр буенча да, халыкның җан башына күчереп исәпләгәннән чыгып та озак вакытларга күтәрү — ул икътисади үсеш дигән сүз.

Икътисади үсеш тизлеге билгеле бер чор дәвамында ТЭП үсешенең уртача еллык темпларында чагыла. ТЭП үсешенең уртача еллык темпы шушы чордагы еллар дәвамында ТЭП үсеше темпының геометрик уртасын тәшкил итә.

Икътисади теорияләр проблемаларының иң мөһиме ТЭП үсеше темпларын билгеләүче факторларны ачыклаудан гыйбарәт. ТЭП җитештерү күләме, функция буларак, икътисадка җәлеп ителүчеләр саныннан, ягъни хезмәт чыгымнарыннан һәм икътисадта кулланылган капитал суммасыннан чыгып каралырга мөмкин. Бу — ТЭП үсеше җитештерү функцияләре теориясе позициясеннән чыгып каралырга мөмкин икәнлеген аңлата. Әгәр ТЭП күләме хезмәт һәм капитал чыгымнары берәмлегенә күчереп исәпләгәндә үзгәрешсез калса, ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне җитештерү уртача илдәге бер кешегә күчереп исәпләгәндә үзгәрмәячәк.

Реаль чынбарлыкта фәнни-техник прогресс хезмәт җитештерүчәнлеген һәм капиталның нәтиҗәлелеген күтәрү белән бергә бара. Хезмәт җитештерүчәнлеген һәм капиталның нәтиҗәлелеген чагылдырган күрсәткеч тулай факторлы җитештерүчәнлек дип атала. Фәнни-техник прогресс, мәгарифне

үстерү һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү тулай факторлы җитештерүчәнлекнең артуына китерә.

XX гасырның 70—80 нче елларында дөньяда икътисади үсешнең әкренәюе күзәтелде. Бу хәвефле күренешне төрлечә аңлатып карадылар. Иң ышандырганы, мөгаен, озак вакытлы цикллар теориясе позициясеннән чыгып аңлату булгандыр. Бу теория нигезендә базар икътисады үзенең үсеш чорында 50—60 еллык чорны колачлаган циклны уза. Озак вакытлы цикл, икътисади үсеш гомуми тизләнешкә юнәлеш тотканда, күтәрелмә дулкынга кучә, ә икътисади үсештә әкренәю сизелә башласа, төшмә дулкынга борыла. XVIII гасыр ахырыннан башлап хәзерге көнгә кадәр базар икътисады озак вакытлы дүрт цикл кичерә. XX гасырның 70—80 нче елларында ул озак вакытлы дүртенче циклның төшмә дулкынын уза. 1994—1999 елларда икътисади үсешнең дөньякүләм тизләнеше күзәтелә, ул, озак вакытлы дүртенче циклның төшмә дулкыны артта калды һәм дөнья озак вакытлы бишенче циклның күтәрелмә дулкыны чорына аяк басты, дип уйларга нигез бирә.

❓ *Контроль сораулар һәм биремнәр*

1. Ни өчен икътисади үсеш темплары турында номиналь ТЭП үсеше яки икътисад үсешенең башка номиналь күрсәткечләре турындагы мәгълүматлар буенча фикер йөртергә ярамый?
2. ТЭПның циклы күтәрелешләр барышында ирешелгән үсеш темплары ни өчен икътисади үсеш күрсәткече булып хезмәт итә алмый?
3. Икътисади үсешнең әһәмияте нәрсәдән гыйбарәт?
4. ТЭПның башлангыч чордагы (база) дәрәҗәсе һәм бирелгән (агымдагы) елдагы дәрәҗәсе билгеле булса, ТЭП үсешенең уртача еллык темпын ничек исәпләп чыгарырга?
5. Җитештерү функциясенең ТЭП үсеш темпы икътисади үсешнең экстенсив һәм интенсив факторлары белән билгеләнгән тигезләмәсен языгыз.
6. Нәрсә ул тулай факторлы җитештерүчәнлек?
7. Озак вакытлы цикллар теориясе нәрсәдән гыйбарәт?
8. XX гасырның 70—80 нче елларында дөньяда икътисади үсеш темпларының кимүен озак вакытлы цикллар теориясе позициясеннән чыгып аңлатуны нигезле дип буламы?

16 нчы бүлек

ИКЪТИСАД ҺӘМ ДӘҮЛӘТ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җаваплар табарсыз:

- ✦ икътисади тотрыклыландыру буенча дәүләт сәясәте нинди юнәлешләрдә алып барылырга тиеш;
- ✦ дәүләт үзенең икътисади сәясәтен тормышка ашыруда нинди күрсәтмәләрдән файдалана;
- ✦ дәүләтнең бюджет-финанс сәясәте нәрсәдән гыйбарәт;
- ✦ Үзәк банкның кредит-акча сәясәте нәрсәдән гыйбарәт;
- ✦ икътисади үсешне дәүләт нинди ысуллар белән стимуллаштыра;
- ✦ ни өчен, икътисад үсеше белән беррәттән, дәүләтнең бурычы барлыкка килә, һәм ул үсә башлый; дәүләт бурычы үсү икътисади үсеш өчен куркыныч тудырамы.

Алдагы бүлекләрнең кайберләрендә без дәүләтнең икътисади роле мәсьәләләренә тукталып үткән идек инде. 2 нче бүлектә дәүләтнең икътисадка катнашу зарурлыгын һәм мондый катнашуның билгеле бер чиге булырга тиешлеген ачыкладык. Аннан соң без дәүләтнең икътисади сәясәтендәге кайбер бик мөһим юнәлешләрен: монополиягә каршы сәясәттә, тулай эчке продукт җитештерүдә һәм булган шәхси керемне формалаштыруда дәүләтнең роле; дәүләтнең нинди чаралар ярдәмендә мәшгульлекне һәм эшсезлекне җайга салырга омтылуы һәм башка мәсьәләләр турында белдек. Бу бүлектә

без яңадан базар икътисадында дәүләтнең икътисади роле турындагы мәсьәләгә әйләнеп кайтабыз. Әмма монда инде бу роль тирән итеп, базар системасының үсеше һәм эшләве законнарын аңлап каралачак.

16.1. ИКЪТИСАДИ ТОТРЫКЛЫЛЫК СӘЯСӘТЕ

Базар системасы шартларында ТЭП җитештерүнең циклы тирбәлешләре һәм инвестиция күләме, мәшгульлек һәм эшсезлек дәрәҗәсе,— нигездә, котылгысыз күренешләр. Инфляция гомуми һәм ныклы характер ала. Шуның өстенә базар икътисады үсеше тәҗрибәсе күрсәткәнчә, XX гасырның беренче яртысында циклы рецессияләр гаять тирән итеп һәм озак вакытларга эшкә булган активлыкны киметтеләр, ә инфляция хәзерге вакытта да әле, кискен формаларга кереп, икътисади һәм социаль яктан авыр нәтиҗәләргә китерә. Шуңа күрә дәүләт каршындагы иң мөһим проблемаларның берсе булып илнең икътисади үсешен тотрыклыландыру торды һәм тора. Бу проблеманы хәл итү тулы мәшгульлеккә ирешү һәм аны саклауны, ягъни эшсезлекне табигый норма кысаларында тотуны; циклы рецессияләрнең тирәнлеген һәм дәвамлылыгын бетерүне, һич югы, аның төп билгеләрен чикләүне; инфляциянең урталыктан зур сикереш ясап күтәрелеп китүенә (бигрәк тә гиперинфляциягә илтүенә) юл куймаслык инфляциягә каршы юнәлешле чаралар күрүне күздә тота.

Әлеге гади булмаган проблемаларны хәл итү өчен, дәүләтнең тиешле шартлар тудырырга мөмкинлеге бармы соң? Базар икътисады югары үсешкә ирешкән илләр тәҗрибәсе, иътисади сәясәтне дөрес алып барганда, дәүләт чагыштырмача икътисади тотрыклылыкка ирешә ала дип уйларга нигез булып тора. Беренчедән, дәүләтнең икътисадка актив йогынты ясау мөмкинлекләре милли керемнең $\frac{1}{4}$еннән алып $\frac{1}{3}$ өлешенә кадәресе салым сыйфатында дәүләт бюджетына керүе белән ныгытыла. Шуңа күрә дәүләт учреждениеләре һәм оешмалары продукция эшләп чыгару һәм мәшгульлек дәрәҗәсен билгеләүдә зур роль уйныйлар. Икенчедән, дәүләт «уен кагыйдәләре»н гамәлгә кертә — фирмаларның һәм йорт

хуҗалыкларының тәртибен җайга салучы законнар кабул итә. Өченчедән, төп бурычы булып илнең банк, акча һәм финанс системалары эшчәнлегендә тотрыклылыкка ирешүне санаган, Үзәк банк дәүләт карамагында тора. Теләсә кайсы илнең Үзәк банкы, милек формаларында аермалар булуга карамастан, хакимиятнең дәүләт органнары тарафыннан контрольдә тотыла яки дәүләт башлыгы билгеләгән затлар тарафыннан идарә ителә.

Шулай итеп, дәүләт карамагында, законнар чыгару эшчәнлеген исәпләмәгәндә, икътисадны көйләүнең төп ике коралы — дәүләт бюджеты һәм Үзәк банк бар. Моңа бәйле рәвештә икътисадны көйләү турыдан-туры бюджет-финанс һәм кредит-акча сәясәте аша тормышка ашырыла.

Икътисади сәясәт юнәлешләренең үзара бәйләнеше

Хөкүмәт һәм Үзәк банк үз эшчәнлеген куелган бурычларның берсен генә хәл итүгә юнәлдерсә, бу тотрыклыландыру сәясәте булмас иде. Мәсәлән, инфляциягә каршы үткәрелгән чаралар фәкать бәяләрне төшерүгә йогынты ясау белән генә чикләнми. Инде белгәнебезчә, Филлипс кәкресе дәүләтнең үз икътисади сәясәтендә альтернатива каршында калуын күрсәтә: я эшсезлекне кыскартуга ирешергә (ләкин бу юл инфляцияне тагын да көчәйтәчәк); я инфляция нормасын киметергә, ләкин монысы эшсезлек нормасын арттырачак.

Шулай да икътисади сәясәт юнәлешен сайлау «инфляцияне көчәйтүгә яки эшсезлекне арттыруга» дигән дилеммага кайтып калмый. Мәшгульлек һәм эшсезлек хәрәкәтенең икътисади цикллар үсеше белән, аларның берсеннән икенчесенә күчү фазалары белән бәйләнешен искә төшерик. Циклы күтәрелеш ТЭПны потенциаль ТЭПка якын дәрәҗәгә чыгара икән, илдә тулы мәшгульлек урнаша, ә эшсезлек табигый дәрәҗәсенә төшә. Өстәвенә дәүләт үзенең икътисади сәясәтендә Оукен законы нигезендә ТЭП үсешенең тулы булмаган мәшгульлеккә юл куймаслык темпларына ирешергә омтылырга тиеш. Димәк, инфляциягә каршы сәясәт икътисади үсешнең кирәкле темпларына ирешүгә һәм аны саклауга юнәлдерелгән сәясәт белән дә, циклы рецессияләргә юл куймау яки рецессияләрне (аларны читләтеп үтү мөмкинлеге булмаганда) җиңел чыгу чаралары белән дә бәйле икән.



16-1 нче рәсем. △
Икътисади үсешне тотрыклыландыру буенча дәүләт сәясәте.

Дәүләт илнең икътисади үсешен тотрыклыландыруга дәүләт бюджеты белән Үзәк банктан файдаланып ирешә ала. Бюджет-финанс һәм кредит-акча сәясәте уздыру циклы рецессияләрне булдырмауга яки йомшартуга, тулы мәшгульлеккә ирешүгә, аны саклауга һәм кискен сикерешле инфляцияләргә (бигрәк тә гиперинфляциягә) юл куймауга юнәлдерелә. Әгәр шушы проблемалар хәл ителсә, илнең икътисади үсеше оптималь һәм тотрыклы темплар белән барачак.

Болардан түбәндәгеләрне әйтергә була:

> **ИКЪТИСАДИ ҮСЕШНЕ ТОТРЫКЛЫЛАНДЫРУ СӘЯСӘТЕ** өч юнәлешне үз эченә ала: циклылыкка каршы сәясәт, тулы мәшгульлеккә ирешү һәм аны саклау сәясәте, инфляциягә каршы сәясәт. Шуның белән бергә, тотрыклылык сәясәтендәге бу юнәлешләрнең берсе дә икенчеләреннән башка тормышка ашырыла алмый.

16.2. БЮДЖЕТ-ФИНАНС СӘЯСӘТЕ

Икътисади үсешне тотрыклыландыруда икътисади сәясәтнең иң мөһим коралы булып дәүләт бюджеты санала. Ул салымнар сәясәтен һәм шуңа бәйле салым системасын; сәламәтлекне саклау, мәгариф һәм фән кебек тармакларны, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча дәүләт программаларын, социаль программаларны һ. б. финанслау сәясәтен һәм, ниһаять, дәүләт бюджетындагы керемнәр һәм чыгымнар нисбәтен, ягъни бюджет дефициты зурлыгын билгеләү сәясәтен, үз эченә алган бюджет-финанс сәясәтен үткәрүгә хезмәт итә.

Дәүләт бюджеты керемнәре

Салымнар дәүләт бюджетының төп чыганагын тәшкил итәләр. Белгәнебезчә, салымнар төп ике төргә бүленә: **туры салымнар** фирмалар һәм йорт хуҗалыклары тарафыннан алынган керемнән турыдан-туры тотып калыналар (мәсәлән, керемнән түләнә торган салым); **читләтеп алынган салымнар** — болары турыдан-туры фирмаларга салына торган салымнар. Алар фирмаларның җитештерү эшчәнлеге күләменнән чыгып билгеләнәләр һәм фирмалар тарафыннан җитештерелгән һәм базарга чыгарылган продукция бәясенә кертеләләр (мәсәлән, бәягә өстәлгән кыйммәт салымы).

Түбәндә Россия Федерациясенең (РФ субъектлары керемнәрен кертеп) бергә тупланган бюджет керемен чагылдырган мәгълүматлар (млрд сумнарда) китерелә:

Туры салымнар (табыш салымы, физик затлар кеременә һәм милеккә салым)	1738,3
Читләтеп алынган салымнар (бәягә өстәлгән кыйммәт салымы, акцизлар, бердәм социаль салым, табигый ресурслардан һ. б. файдалану салымы)	3197,9
Салымнан тыш керемнәр	421,4
Максатчан бюджет фондлары кереме	40,0
Башка төр керемнәр	29,7
Бергә тупланган бюджетның барлык керемнәре	5427,3

Китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, ТЭПның 31,9% ы дәүләт бюджеты кереме сыйфатында дәүләт карамагына күчә, өстәвенә ТЭПның 29% ын (4936,2 млрд сум) салым өлеше тәшкил итә. Шушы факт үзе генә дә дәүләтнең икътисадны көйләүдә нинди куәтле чарага ия булуын күрсәтә.

Табыш салымы, мәсәлән, хосусый инвестицияләргә көчле йогынты ясый. Табыш, бер яктан, инвестицияләрнең төп чыганакларына хезмәт итсә, икенче яктан, яңа инвестицияләргә хәлиткеч стимул булып тора, чөнки бу керемнең үсеше саф табыш күләмен, ягъни салым тотып калганнан соңгы өлешен киметә. Шуңа күрә дәүләт, табыш салымын кыскартып, яңа инвестицияләр үсешен стимуллаштыра. Ул, табыш салымын арттырып, яңа капитал салулар үсешен тоткарлый.

Халыкның киң катламына түләнә торган хезмәт хакыннан тотылган салымны һәм башка салымнарны үзгәртү дә икътисад үсешенә шундый ук йогынты ясый. Халыкның шәхси кеременә салынган салым үсешенең гомуми нәтиҗәсе, барыннан да бигрәк, аңа тиешле керемнең кимүендә чагыла, бу үз чиратында халык ихтыяҗларына чыгымнар һәм саклык акчалар үсеше темпларының түбәнәюенә китерә. Саклык акчаларның кимүе инвестицияләр өчен саф табыш кыскаргандагы кебек үк нәтиҗәләргә китерә.

Читләтеп алынган салымнар да куллану дәрәҗәсенә һәм инвестицияләргә шундый ук йогынты ясый. Читләтеп алынган салымнар фирмаларның һәм йорт хуҗалыкларының кеременнән турыдан-туры тотып калынмаса да, алар фирмалар җитештереп саткан товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясенә керә.

Шуңа күрә читләтеп алынган салымны арттыру үзе артыннан куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә, шулай ук житештерү факторларына да бәя күтәрелүгә сәбәпче була. Бу хәл шәхси ихтыяж чыгымнарының да, хосусый тулай инвестицияләрнең дә үсеш темпларына яки дәрәҗәсенә карата тискәре йогынты ясый. Аларны киметү, киресенчә, инвестицияләрдә дә, куллануда да уңай чагылыш таба.

Тотрыклылык сәясәтен тормышка ашыруда салымнар механизмы ике яклы тәэсир итә.

Әйтик, илдә керемгә прогрессив салым кертелгән, ди. Прогрессив салым, керем үсешенә карап, салым күләмен арттыруны да күздә тота. Шуңа күрә икътисадның интенсив күтәрелеше шартларында, ягъни табыш һәм хезмәт хакы күләмнәре кызу темплар белән артканда, бюджетка күчерелә торган салым күләме тагын да тизрәк үсә. Шуның белән салым механизмы циклы күтәрелешләр киеренкелеген киметә, ТМП күләме потенциаль ТМП дәрәҗәсеннән артып китүен тоткарлый. Циклы рецессия шартларында салым механизмы кире юнәлештә эшли: керемнәр кимүгә бәйле рәвештә салым күләмнәре дә кыскара. Шуңа күрә салым тотып калуларның да кыскаруы саф табыш һәм хезмәт хакы кимү күренешләрен бераз җиңеләйтә, бу үз чиратында куллану һәм инвестицияләр кимү дәрәҗәсен берникадәргә кыскарта. Димәк, салым системасы циклы тирбәлешләр амплитудасын кыскартучы, икътисадның «чамадан тыш кызуына» да, рецессияләр тирәнлегенә дә каршылык күрсәтүче *автомат рәвештә эшләүче механизм* формалаштырырга мөмкин.

Шул ук вакытта хөкүмәт һәм хакимиятнең закон чыгару органнары, икътисад үсешен тотрыклыландыру өчен, аңлы рәвештә максатка ярашлы салым чаралары яки башка чаралар үткәрергә мөмкин. Аңлы рәвештә максатка ярашлы алып барылган мондый сәясәт — **дискрецион** (хакимиятнең закон нигезендә түгел, үз көченнән файдаланып эшләнә торган гамәле) сәясәт дип атала. Дәүләт, мәсәлән, салым түләнми торган түбән хезмәт хакы билгеләргә яки хезмәткә түләүне күтәрергә мөмкин; өстенлекле (приоритетлы) теге яки бу тармакта инвестицияләргә льготалы салым билгеләргә мөмкин; экологик яктан пычрата торган производство төрләренә югары салым кертергә мөмкин һ. б.

Дәүләт бюджеты чыгымнары

Икътисадны дәүләткүләм җайга салуда ***чыгымнар сәясәте*** белән бәйле чаралар да мөһим роль уйный. Монда да чыгымнарның кайбер төрләре автоматик стабилизаторлар кебек йогынты ясыйлар. Мәсәлән, эшсезлек буенча дәүләт пособиеләре түләүнең артуы циклы артка чигенеш вакытында эшен югалтучы затларның саны арту белән бергә бара. Тулы мәшгульлеккә ирешкән, ә циклы эшсезлек нульгә калган, күтәрелеш фазасында эшсезлек буенча түләнә торган пособиеләргә чыгымнар минималь дәрәҗәгә төшә. Шулай итеп, рецессия вакытында пособиеләр түләүне арттыру күпмедер дәрәҗәдә халык керемнәренең кимүен компенсацияли, ә күтәрелеш вакытында чыгымнарның стабильләштерү йогынтысы кирәгеннән артык сорауның чамасыз үсешен бераз тоткарлауга юнәлдерелә.

2004 елда Россия Федерациясенең (РФ субъектлары чыгымнарын да кертеп) тупланган бюджеты күләме һәм структурасы турындагы мәгълүматларны карап үтик (млрд сумнарда):

Дәүләт идарәсе һәм халыкара эшчәнлек	277,0
Милли оборона	430,0
Хокук саклау эшчәнлеге һәм иминлекне тәэмин итү	381,2
Сәнәгатькә, энергетикага, төзелешкә һәм башка тармакларга капитал салу	898,3
Социаль-мәдәни чаралар	1465,1
Дәүләт бурычларын һәм алар буенча җыелган процентларны түләү	230,4
Максатчан бюджет фондлары чыгымнарын да кертеп, башка чыгымнар	983,4
Дәүләт бюджетының барлык чыгымнары	4665,4
Профицит (керемнәрнең чыгымнардан артып китүе)	761,9

Базар системасы югары үсеш алган шартларда бюджет чыгымнарының күпчелек өлеше циклы тирбәлешләр белән турыдан-туры бәйләнмәгән. Мәсәлән, хәрби чыгымнар, тышкы сәяси чараларны финанслау һ. б. шактый дәрәҗәдә фәкать сәяси факторлардан гына бәйле була; мәгарифкә, фәнгә, сәламәтлекне саклауга, әйләнә-тирәлекне саклауга һ. б. га чыгымнар һич кенә дә цикллар барышына яки сәяси конъюнктурага карап үзгәрергә тиеш түгел. Шуңа да карамастан дәүләтнең бу чыгымнарының шактый югары дәрәҗәдә булуы һәм аларның

систематик рәвештә үсә баруы илнең фәнни-техник һәм мәдәни үсешендә бик зур роль уйнап кына калмыйлар, хәтта үзләреннән-үзләре икътисади һәм социаль вазгыятьне билгеле бер дәрәҗәдә тотрыклыландыралар. Бу тулысы белән базар системасын тормышка ашыручы Россия икътисадына да кагыла.

Шул ук вакытта базар системасы үсеш алган илләрдә дәүләт чыгымнарының кайбер төрләре циклылыкка каршы максатчан юнәлеш алган. Мәсәлән, рецессияләр чорында күп кенә фирмалар бөлгенлек чигендә калалар, һәм дәүләт, субсидияләр һәм субвенцияләрнең суммар күләмен арттырып, кайбер фирмаларга льготалы кредитлар бирә һ. б. Күтәрелеш шартларында мондый чыгымнарга ихтыяҗ я бөтенләй булмый, я аның күләме бик нык кими. Башкача әйткәндә, без монда да дискрецион сәясәт белән очрашабыз.

Тотрыклыландыру чаралары системасында *бюджет дефицитына* карата сәясәт булу мөһим.

Бюджет дефициты

Бюджет сәясәте финанс ресурсларын табу һәм файдалану белән бәйле проблемаларны гына хәл итми, ә дәүләт бюджетының керемле һәм чыгымлы өлкәләре арасындагы бәйләнешләрне дә билгели. Теоретик яктан караганда хакимият органнары бюджетны төп өч вариантта планлаштыра ала: 1) бюджетның кереме чыгымнарга караганда зуррак (бюджет сальдосы уңай); 2) керемнәр һәм чыгымнар тигез (сальдо нульгә тигез, бюджет тигезлек хәлендә); 3) чыгымнар керемнәрдән зуррак (сальдо — тискәре, бюджет дефициты).

Әмма, практика күрсәткәнчә, XX гасырның 30 нчы елларыннан башлап, дәүләт бюджетының уңай, хәтта нуль дәрәҗәсендәге сальдосы тулысынча диярлек бюджет-финанс сәясәтеннән читтә кала һәм, кагыйдә булудан бигрәк, чыгармага әйләнә. Бу очраклы түгел, дәүләт чыгымнары дәрәҗәсе түбән булганда, салымнарның чагыштырмача югары дәрәҗәсе (ә бу бюджет сальдосы уңай булуга шартлар тудыра) икътисади үсешне тоткарлый: зур салымнар инвестицияләр үсешенә ярдәм итми, халыкның керемнәрен һәм аның куллану чыгымнарын чикли, ә дәүләтнең чагыштырмача зур булмаган чыгымнары инвестицияләр үсешенә һәм хосусый секторлар куллануына тоткарлыкны компенсацияләми. 1995 елда Россиядә бюджет дефициты 54,7 трлн сумга тигез була.

Бюджет дефициты товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә дәүләт тарафыннан өстәмә, кирәгеннән артык сорау китереп чыгаруны күздә тота. Моны Россия буенча 1996 ел өчен алынган мәгълүматлардан карап үтик (трлн сумнарда):

1996 елда ТЭП	2265
Дәүләт бюджеты керемнәре	536
Йорт хуҗалыкларын да кертеп, хосусый сектор керемнәре	1729

Әйтик, ТМПның халыктан, шәхси фирмалардан һәм дәүләтнең хосусыйлаштырылмаган предприятиеләреннән тотып калынган салымнар һәм салымнан тыш тартып алулардан калган өлеше тулысынча шушы хуҗалык итүче субъектлар карамагында була. Йорт хуҗалыклары да, барлык фирмалар да бу акчаларны 1996 ел дәвамында сарыф итеп бетерәләр. Ул чакта җәмгыятьтә чыгымнарның гомуми суммасы түбәндәгечә була (трлн сумнарда):

Дәүләт бюджеты чыгымнары	729
Хосусый сектор чыгымнары	1729
Дәүләтнең һәм халыкның чыгымнарының гомуми суммасы	2458

Шулай итеп, бюджет дефициты 193,4 трлн сум тәшкил иткәндә, җәмгыятьтә барлык чыгымнар тулай керемнәр күләменнән нәкъ шушы суммага артып китә һәм 2265 трлн сум урынына 2458 трлн сумга җитә. Шуның белән икътисадта инфляция сәбәпләренең берсе булып кирәгеннән артык сорау килеп туа.

Бюджет дефицитын каплауның нинди чыганаклары бар? Беренчедән, Финанс министрлыгы яки башка дәүләт органнары дәүләт кыйммәтле кәгазьләре (дәүләт облигацияләре яки кыска вакытлы бурыч йөкләмәләре) сата, аларга фирмалар һәм йорт хуҗалыклары үзләренең саклык акчаларын кертәләр. Икенчедән, дәүләт билгеле бер күләмдә банкнотлар (акча функциясен үти торган кредит билетлары) чыгара, моның белән ул акча әйләнеше каналларына күп кенә өстәмә акчалар кертә.

Беренче очракта дәүләт җитәкчеләре дәүләтнең эчке бурычын арттыруга баралар, чөнки дәүләтнең облигацияләрен һәм башка төрле бурыч йөкләмәләрен сатып алган затлар дәүләткә кредит бирә һәм билгеле бер вакыттан соң дәүләт үзенең кредиторларына ул акчаларны кайтарырга тиеш була. Әгәр фирмалар һәм йорт хуҗалыклары үзләренең барлык

саклык акчаларын яңа төзелешкә, җиһазга, запас туплауга һ. б. га инвестицияләр кертергә җыенмасалар яки аңа мөмкинлекләре булмаса, бу очракта дәүләт заемнары икътисадка файда китерә. Монда бюджет дефициты хосусый инвестицияләр үсеше кыскаруны яки әкренәюне компенсацияләүче дәүләт чыгымнарын финанслау белән бәйле була. Бу сәясәт **дефицитлы бюджет финанславы** дип атала.

Дефицитлы бюджет финанславы хосусый инвестицияләрнең һәм кулланунын кимүенә, шулай ук мәшгульлек кимүгә каршы мөһим чара булып хезмәт итә. Табигый ки, циклы күтәрелеш шартларында дефицитлы бюджет финанславының күләме минимумга (хәтта нульгә) төшәргә тиеш, чөнки үсеп торучы хосусый инвестицияләр һәм куллану фирмаларның, йорт хуҗалыкларының саклык акчаларын тулысынча үзләштереп бетерәләр.

Тотрыклыландыру сәясәтенең төп үзенчәлеге — цикллылыкка каршы чараларның үзара тыгыз бәйләнеше һәм үзара бәйлелектә булуы, тулы мәшгульлеккә ирешү һәм инфляциянең кискен формаларына юл куймау. Шуңа күрә, циклы рецессияләрне йомшарту өчен, дәүләт кулланган чаралар бер үк вакытта эшсезлек үсешен тоткарлау һәм тулы мәшгульлеккә ирешү чаралары да булып тора. Әмма бу чаралар, кагыйдә буларак, бәяләр күтәрелүгә китерә һәм шунлыктан ул инфляциягә ишарәләүче нәтиҗә бирә. Мәсәлән, дәүләт чыгымнары һәм бюджет дефициты товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә өстәмә сорау китереп чыгара, күреп үткәнебезчә, ТЭП кимүгә һәм эшсезлек үсүгә каршы чара булып хезмәт итә, әмма бер үк вакытта инфляцияне дә көчәйтә. Сәяси лидерлар фикеренчә, әгәр дә инфляция куркыныч янау дәрәҗәсенә җитсә, бюджет чыгымнарын ашыгыч рәвештә кыскартырга, бюджет дефицитын киметергә туры килсә, әлеге дискрецион чараларның нәтиҗәсе булып рецессия һәм эшсезлек үсү булырга мөмкин.

Бюджет профициты

Россиядә 2004 елда 761,9 млрд сумга җиткән бюджет профицитын һәм 2004 елда 76,8 млрд сумга тигезләшкән федераль бюджет профицитын ничек бәяләргә? Бу сорауга җавап бирү өчен, РФ икътисады үсешенең түбәндәге факторларына игътибар итәргә кирәк:

1. 1999 елда башланган реаль ТЭП үсеше 2004 елда шактый (6,4% ка җитә) тизләшә. Аның алга таба да күтәрелүе кętелә. Шуңа күрә дефицитлы бюджет ысуллары белән ТЭП җитештерүне арттыруны стимуллаштыру зарурлыгы көчен югалта.

2. Узган унъеллыкта инфляция нормасы, даими кимеп, 2004 елда 12% тәшкил итә һәм уртача инфляциянең югары чиген (10%) фәкать ике процентка гына узып китә, ләкин алга таба инфляция нормасы кимү һәм аның табигый нормага (5%) җитү проблемасы үз көчендә кала. Бюджет профициты инфляциягә каршы сәясәтнең нәтиҗәле чарасы булып тора һәм шунлыктан инфляция нормасын киметү ягына билгеле бер дәрәҗәдә басым ясый. Инфляция нормасының уртача дәрәҗәгә төшүе һәм аның табигый дәрәҗәгә якынлашуы икътисади үсешне тотрыклыландыруга ярдәм итә (14.3, «Нормаль инфляция» пунктын кара). Әгәр икътисадның тотрыклы һәм озак вакытлы үсешенә ирешүне икътисади сәясәтнең, төп бурычларыннан берсе буларак һәм аерым алганда бюджет-финанс сәясәтенең бу бурычны хәл итү юнәлешләренең берсе итеп караганда, инфляциянең табигый нормасына ирешүне икътисадның озак вакытлы үсешенең тотрыклылыгын тәэмин итүче иң мөһим шарты итеп санарга кирәк.

3. XXI гасыр башында нефть һәм башка энергия чыганакларына дөньякүләм бәяләр күтәрелү Россиянең икътисади хәле яхшыруга ярдәм итте. Ләкин тышкы икътисади факторның бу ярдәменә таянырга кирәкми. Бу товарларга бәя якын киләчәктә кими башларга да мөмкин. Мондый очракта экспорт кереме кимүгә һәм шуңа бәйле рәвештә, дәүләт бюджетына салым керемнәре үсеше әкренәеп, алга таба дәүләтнең икътисади үсешне стимуллаштыру мөмкинлекләре чикләнүгә дучар булачак. Шуңа күрә хәзер профицитның билгеле бер өлеше эчке икътисадта да, тышкы икътисадта да көтелмәгән күренешләрнең тискәре йогынтысын булдырмый калуга ярдәм итүче валюта резервларын тулыландыруга тотыла.

Бюджет дефициты шул чакта уңай нәтиҗәгә китерә, кайчан да ки инвестицияләр, мәшгульлек, куллану чыгымнары кими, ягъни тулаем сорау ТЭП эшләп чыгаруны киметүгә китерә. Дәүләт акчаны үзе алганга караганда күбрәк тотып, өстәмә базар соравы китереп чыгара һәм шуның белән

икътисади рецессияне булдырмый кала. Ләкин озакка сузылган бюджет дефициты сәясәте иртәме-соңмы барыбер инфляция тууга һәм аның кискенләшүенә китерер иде. Бюджет профицитына килгәндә, ул диаметраль капма-каршы шартларда (ТЭП житештерү, тулаем сорау, куллану чыгымнары һәм инвестицияләр үсеше бәяләрнең уртача инфляция сикерешле инфляциягә әверелүенә китерәчәк темплар белән үсүе шартларында) уңай нәтиҗә бирә. Мондый шартларда хөкүмәт, инфляция нормасы кими башлаганчы һәм үзенең табигый дәрәҗәсенә ирешкәнче, даими рәвештә бюджет сальдосының уңай торуына ирешергә тиеш. Әгәр алга таба илнең икътисади үсеше идеаль шартларда (гомуми макроикътисади тигезләнешкә ирешелгән, икътисади үсеш темпы оптималь, инфляция дәрәҗәсе табигый һәм тулы мәшгульлек хөкем сөрә) бара икән, дәүләт бюджеты балансы булырга, ягъни бюджет сальдосы нульгә тигез булырга тиеш. Бу вакытта инде икътисади үсеш, циклы тирбәлешләрсез, инфляция давылларыннан һәм табигый эшсезлектән тыш, идеаль тотрыклылыкка ирешергә мөмкин дигән сүз. Әлегә мондый идеалга бер генә илнең дә ирешкәне юк.

Икътисади стабильләшү сәясәтен эзлекле тормышка ашыруның төп киртәсе булып түрәләрнең тар күңеллелеге, коррупция (ришвәтчелек), лоббизм санала. Бюджет акчалары еш кына икътисади үсешнең стратегик бурычларын тормышка ашыру өчен түгел, ә сайлау алды кампанияләрендә теге яки бу сәяси лидерларның яки төркемнең популярлыгын арттыру белән бәйле кыска вакытлы сәяси файда алу өчен кулланыла.

16.3. КРЕДИТ-АКЧА СӘЯСӘТЕ

Коммерция банкларының эшен көйләү

Дәүләт бюджетын үз карамагында тоткан хөкүмәт белән беррәттән, икътисадка Үзәк банк та актив йогынты ясый ала. Хөкүмәт тарафыннан алып барыла торган бюджет-финанс сәясәте турыдан-туры фирмаларның, йорт хуҗалыкларының керемнәрен һәм чыгымнарын көйләүгә, дәүләт чыгымнарын киңәйтүгә һәм кыскартуга юнәлдерелә, ә Үзәк банк сәясәте, хөкүмәттән аермалы буларак, коммерция банклары эшчән-

леген һәм алар аша тулаем икътисадны көйли. Банклар эшчәнлеге акча, кыйммәтле кәгазьләр, заем һәм ссудалар операцияләре белән бәйле булганлыктан, Үзәк банк үткәргән чаралар да базар системасының шушы элементларына юнәлдерелә. Шуңа күрә Үзәк банк үткәргән чаралар, тулаем сорау, инвестицияләр, мәшгульлек һәм бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үзгәрешләрендә сизелгәнче, банклар һәм кредит-акча системасы чылбырында бер-бер артлы импульслар китереп чыгаралар. Ул чылбыр биш буыннан тора:

1) Үзәк банк коммерция банкларының мәҗбүри резервлары күләменә йогынты ясый;

2) мәҗбүри резервлардагы үзгәрешләр коммерция банкларындагы гомуми акча күләме үзгәрешләренә китерә;

3) акча күләменең артуы яки кимүе шуңа тәңгәл рәвештә кредит күләмнәрен дә арттыра яки киметә;

4) зур яки аз күләмле кредит алу мөмкинлеге фирмаларга үзләре планлаштырган теге яки бу проектларын финанслау өчен капитал салырга ярдәм итә яки ул аны тоткарлый;

5) инвестицияләрнең үзгәрүе тулаем сорау, ТЭП күләме, мәшгульлек һәм бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үзгәрүгә китерә.

Үзәк банк коммерция банкларының мәҗбүри резервлар күләменә өч ысул белән йогынты ясый:

1) резерв таләпләре нормасын үзгәртү юлы белән;

2) кыйммәтле кәгазьләр базарында (ачык базарда) кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр ярдәмендә;

3) исәпләү ставкасын үзгәртү юлы белән.

Коммерция банкларының резерв нормаларын үзгәртү

Белгәнебезчә, теләсә кайсы коммерция банкы Үзәк банкта резервлар депозиты булдырырга тиеш. Үзәк банк мәҗбүри резервлар күләмен, ягъни коммерция банклары тарафыннан кертелгән кертемнәр суммасына карата резервлар чагыштырмасын билгели. Үзәк банкның күтәрелүгә таба да, кимү ягына да резервлар нормасын яңадан карарга хакы бар (16-2 рәс.).

Әйтик, икътисад рецессия кичерә, ди, инвестицияләр кыскара, ТЭП күләме кими, эшсезлек үсә. Бу тискәре күренешләр базарда товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә сорау кимү нәтиҗәсе булып инфляция йомшаруга һәм хәтта бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе бераз түбәнәюгә китерә.



6-2 нче рәсем. △
Үзәк банкның кредит-акча сәясәте схемасы.

Үзәк банк, коммерция банклары эшчәнлеген җайга салып, барыннан да элек, аларның мәҗбүри резервлары күләменә йогынты ясый. Бу биш баскычлы системаны хәрәкәткә китерә, шуның нәтиҗәсендә товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем сорауның, ТЭПның, мәшгульлекнең дәрәҗәсе һәм бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үзгәрә.

Мондый шартларда Үзәк банк нәрсә эшләргә тиеш соң? Банк идарәсе резерв таләпләре нормасын киметү турында карар чыгара ала. Әгәр элек резерв нормасы 25% күләмендә куелган булса, әйтик, ул хәзер 20% тәшкил итәргә мөмкин. Шулай итеп, элек коммерция банкларындагы керемнәр суммасы резервларга карата 4 : 1 чагыштырмасында булса, хәзер ул 5 : 1 гә тигез. Шуны искәртеп үтәргә кирәк: резерв нормаларын болай үзгәртү барлык банклар өчен дә мәҗбүри һәм коммерция банклары бу карарны кичекмәстән үтәргә тиеш. Резерв нормаларын үзгәртүгә банкларның реакциясе нинди була соң? Беренчедән, аларның резерв суммасы мәҗбүри резерв суммасыннан зуррак булып чыга. Әйтик, резерв нормасы 25% һәм кертем күләме 1 млрд сум булганда, коммерция банкы Үзәк банкта 250 млн сум резерв тотарга бурычлы. Хәзер инде резерв нормасы 20% булганда, аның 200 млн сум резервы булырга тиеш, ягъни коммерция банкының Үзәк банкта 50 млн сум резервы артык булып чыга. Ул аны, Үзәк банкта тотмыйча, шәхси фирмаларга зур процентлар белән кредитка бирүдә файдалана ала.

Икенчедән, банк, Үзәк банктагы элеккеге резерв суммасын калдырып, пассив һәм актив операцияләрне 1 млрд сумнан 1,25 млрд сумга киңәйтә ала. Башкача әйтсәк, банк, үз клиентларының агымдагы счетларын арттырып, фирмаларга 250 млн сумлык яңа кредитлар бирә ала.

Резерв нормалары барлык коммерция банклары өчен дә бертөрле булгач, үзгәрешләр барлык банкларга да тарала, шуңа күрә, без карап үткәнчә, резерв нормаларын киметүгә коммерция банкларының һәркайсы (бернинди чыгармасыз) кушылырга тиеш. Димәк, резерв нормаларын киметү акча мультипликаторын хәрәкәткә китерә һәм акча массасы, резерв нормалары кимү сәбәпле, резерв суммасын дүрт тапкырга түгел, ә биш тапкырга артып китә.

Акча массасы арту банкларга үзләренең актив операцияләрен киңәйтергә — фондлар биржасында кыйммәтле кәгазьләрнең яңа пакетларын сатып алырга; сәнәгатькә, сәүдәгә һәм башка фирмаларга яңа кредит линияләре ачарга; йорт хуҗалыкларына йорт һәм автомобильләр сатып алырга ссудалар бирергә һ. б. мөмкинлек тудыра. Кредитларны киңәйтү өчен, банкларга ссудалар буенча процент күләмнәрен киметергә туры килә, ә бу акчаларны очсызландыра.

Өстәмә кредит алган фирмалар һәм йорт хуҗалыклары, яңа биналарга, корылмаларга, машиналар һәм җиһазларга, чималның һәм материалларның яңа запасларына капитал салулар һәм куллану чыгымнары арту белән бәйле рәвештә, базарда товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә югары таләп куялар. Болар барысы да рецессияләрне җиңеп чыгарга, ТЭП житештерүнең үсешенә, мәшгульлекне күтәрүгә һәм эшсезлекне киметүгә ярдәм итә. Ләкин товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә сорау арту, акчаның очсызлануы, бер үк вакытта бәяләрнең гомуми дәрәҗәсен, ягъни инфляция нормаларын күтәрүгә дә китерәчәк.

Инде икътисадның цикллы күтәрелеш фазасындагы тулы мәшгульлеккә ирешелгән, фирманың җитештерү куәтләре эш белән оптималь тәэмин ителгән шартлардагы очракны карап үтик. Мондый шартларда алга таба товар базарында сорауның артуы һәм ТЭП үсеше темпларының артуы икътисадны «чамадан тыш кыздыру»га, сорауның бик нык күтәрелүенә китерә, шуның нәтиҗәсендә ТЭП үсеше темплары алга таба бу сорауны канәгатьләндерә алмый һәм инфляция кискенләшә башлый. Бу очракта Үзәк банк мәҗбүри резервлар нормасын күтәрә ала. Табигый ки, аның нәтиҗәсе резерв нормаларын киметкәндәгенең капма-каршысы була. Һәм банклар, үз активларының бер өлешен Үзәк банк хисабына күчереп, резерв суммаларын арттырырга яки, элекке резерв күләмен саклап калган хәлдә, бер яктан, фирмаларның һәм йорт хуҗалыкларының депозитларның суммаларын кыскартырга; икенче яктан, актив операцияләрнең күләмен киметергә, ягъни яңа кредитлар бирүдән, акцияләр һәм облигацияләрне сатып алудан баш тартырга мәҗбүр булалар. Фирмалар һәм йорт хуҗалыклары ягыннан акчага сорау канәгатьләндерерлек булмаса, коммерция банклары, ссудаларга процент ставкасын арттырып, акчаны тагын да кыйммәтләндерә алалар.

Үзәк банкның мондый сәясәте кулланучыларның инвестицияләре һәм чыгымнары үсешен тоткарлый, бу товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү темпларын акрынайтуга, эш белән тәэмин ителгәнлекнең әкрен баруына, хәтта кимүенә китерәчәк. Резерв нормаларының артуы шул ук вакытта инфляциягә каршы нәтиҗә дә бирергә мөмкин: бәяләр күтәрелү акрынаячак, хәтта туктарга да мөмкин.

Резерв нормаларын үзгәртү — бик көчле тәэсир итүче чара. Аны куллану бер очракта шактый куркыныч инфляция баш-

лануга, икенче очракта кискен һәм тирән рецессияләргә китерергә мөмкин. Үзәк банк, резерв нормаларын күтәргәндә, билгеле бер дәрәҗәдә коммерция банклары өчен отышлы булмаган «уен кагыйдәсе» куллана. Күп кенә банклар авыр хәлдә калырга һәм хәтта банкротлыкка чыгарга мөмкин, үз чиратында банклар белән бәйле фирмалар һәм йорт хуҗалыклары да зур югалтуларга дучар ителә. Шуңа күрә икътисадка йогынты ясаучы бу ысул бик сирәк кулланыла, һәм ул соңгы чик буларак бәяләнә.

Ачык базар операцияләре

Үзәк банкның икътисадка йогынты ясаучы чагыштыргысыз даими кулланыла торган коралы — фондлар базарында кыйммәтле кәгазьләрне сату һәм сатып алу операцияләре. Коммерция банклары барлык төр кыйммәтле кәгазьләр белән эш итсәләр дә, бу очракта сүз дәүләт (дәүләткүләм) кыйммәтле кәгазьләре, дәүләт облигацияләре һәм кыска сроклы йөкләмәләр турында бара. «Ачык базар» дигәннән, кыйммәтле кәгазьләрне теләсә кайсы сатып алучыга — фирмага, физик затка, чит ил кешесенә — ирекле сату күздә тотыла.

Бу очракта Үзәк банк коммерция банкларына мәҗбүри резерв күләмнәрен арттырырга яки киметергә мөмкинлек калдырмый. Әмма ул, дәүләткүләм кәгазьләр сатуны арттырып яки киметеп, резервлар суммасына читләтеп йогынты ясый. Моңа ничек ирешелүен карап үтик.

Мәсәлән, икътисад тагын «чамадан тыш кызу» һәм инфляция көчәю белән бара торган интенсив циклы күтәрелеш чоры кичерә, ди. Үзәк банк портфелендә, мондый очракта фондлар базарында күпләп сатуны башлау өчен, дәүләт кыйммәтле кәгазьләре була. Әйтик, «Лимон» фирмасы 100 млн долларга кыска сроклы дәүләт йөкләмәләре (КСДЙ) пакеты сатып ала. «Орел» банкында депозиты булган бу фирма Үзәк банкка «Орел» банкы түләргә тиеш булган КСДЙны чеклар яки вексельләр белән түли. Үзәк банк, «Орел» вексельләрен алгач, аларны түләүне «Орел» банкыннан таләп итә. Без КСДЙны шактый фирмалар һәм аерым физик затлар сатып алачагын исәпкә алырга тиеш. Шуңа күрә «Орел» банкы һәм башка коммерция банклары Үзәк банкка бурыч йөкләмәләренең шактый зур суммасын түләргә тиеш булалар. Ә бу коммерция банклары, үзләреннән таләп ителгән барлык вексельләрне түләү өчен, акчаны каян алачак соң? Беренчедән,

алар үзләренең Үзәк банктагы резервларының бер өлешен сарыф итәргә мәҗбүр булалар. Икенчедән, коммерция банклары, клиентларына бирелгән ссудалар кире кайтарылгач, яңа кредитлар бирүне туктатып, ул акчаларны Үзәк банк тарафыннан таләп ителгән вексельләр суммасын түләүгә тоталар.

Шулай итеп, без тагын биш буыннан торган чылбыр килеп чыгуын билгели алабыз, ягъни ачык базарда дәүләт кыйммәтле кәгазьләре сату коммерция банкларының Үзәк банктагы резервын киметүен, шуның нәтиҗәсендә инвестицияләр һәм ТЭП үсеше тоткарлануын һәм хезмәткә сорау туктатылуын күрәбез.

Әгәр Үзәк банк дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен үзе сатып алса, нәтиҗә капма-каршы булачак. Үзәк банк дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен иң элек турыдан-туры коммерция банкларыннан сатып алырга мөмкин, аларны түләп, ул коммерция банкларының үзендәге резервын арттыра. Мәсәлән, коммерция банкы Үзәк банкка 100 млн долларлык дәүләт облигацияләрен сата. Үзәк банк исә, аңа түләү рәвешендә, әлеге коммерция банкының резервын 1 млрд доллардан 1100 млн (1,1 млрд) долларга арттыра.

Моннан тыш, Үзәк банк дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халыктан да сатып алырга мөмкин. Бу очракта кеше яки фирма кыйммәтле кәгазьләр сатудан килгән акчасын коммерция банкындагы үз счетына күчерә, ә коммерция банкы үз чиратында шушы акчалар исәбенә Үзәк банктагы резервын арттыра һәм моңа бәйле рәвештә, үзенең пассив һәм актив операцияләрен киңәйтә ала. Ә коммерция банкларында кредит бирү үсеше яңа инвестицияләргә, ТЭП үсешенә, мәшгульлеккә һәм куллануга йогынты ясый.

Димәк, Үзәк банк кыйммәтле кәгазьләрне икътисад рецессиягә дучар булганда, ТЭП күләме кимегәндә һәм эшсезлек артканда гына сатып ала. Шуның белән бергә, Үзәк банк җитәкчеләре дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен сатып алу сорауны арттыруга һәм акча массасы күбәюгә китерүен һәм моның инфляциягә илтүен дә онытмыйлар; һәм бәяләр кызу темплар белән күтәрелә башлауга, дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен сатып алуны киметергә яки бөтенләй туктатырга мәҗбүр булалар.

Ачык базар операцияләре икътисадны тотрыклыландыруда шактый зирәк чара булып санала. Үзәк банк дәүләт кыйммәтле кәгазьләре сатуны теләсә кайсы вакытта киңәйтә яки киметә, максатка ярашлы дип исәпләгәнгә, теләсә нинди күләмдә

үткәрә ала. Шунлыктан ул вазгыятьтәге үзгәрешләрне бик тиз тотып ала. Базар системасы үсеш алган илләрдә Үзәк банк сәясәтенең бу коралы даими файдаланыла.

Кыйммәтле кәгазьләр белән барган операцияләрне карап үткәннән соң, шундый сорау туа: ни өчен халык Үзәк банктан мондый кәгазьләр пакетларын күпләп сатып алырга һәм, Үзәк банк сатып ала башласа, бик теләп аларны кире сатарга да әзер? Бу шуның белән аңлатыла: дәүләт кыйммәтле кәгазьләре номиналдан түбәнрәк бәягә сатыла һәм номиналдан югарырак бәягә сатып алына. Ләкин кыйммәтле кәгазьләрне сату һәм сатып алу бәяләрендәге мондый үзгәрешләр бу кәгазьләр буенча процент ставкаларының да тиешле үзгәрүен аңлата. Әйтик, КСДЙның (кыска сроклы дәүләт йөкләмәсе) номиналь бәясе 100 долларга тигез, КСДЙның процент ставкасы 6% күләмендә билгеләнгән. Үзәк банк бу очракта һәр 100 долларлы кәгазь өчен 6 доллар түли. Алга таба Үзәк банк идарәсе КСДЙны сатарга уйлый һәм шушы максат белән сату бәясен 96 доллар итеп билгели, ди. Бу очракта КСДЙны сатып алучы зат 96 доллар күләмендәге капитал өчен 6 доллар керем ала, ягъни процент ставкасы $\frac{6 \text{ долл.}}{96 \text{ долл.}} = 6{,}25\%$ ка кадәр арта. Әгәр КСДЙны сатып алырга карар кылынып, аның бәясе, әйтик, 108 долларга күтәрелсә, бу процент ставкасы кимүен күрсәтә, ягъни $\frac{6 \text{ долл.}}{108 \text{ долл.}} = 5{,}56\%$ ка кала. Билгеле булганча, ачык базарда кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр үткәрелгәндә, Үзәк банк процент ставкалары белән билгеле бер хәйләгә бара.

Исәпләү ставкасын көйләү сәясәте

Үзәк банк коммерция банклары эшчәнлеген коммерция банкларына үзе биргән ссудаларның процент ставкасын турыдан-туры үзгәртү, ягъни үзенең исәпләү ставкасын үзгәртү юлы белән дә көйли ала. Үзәк банкның коммерция банкларына мондый ссудалар бирүе бердәнбер максатны — аларга үз резервларын арттыруга яки ахыр чиктә аларның кыскаруына юл куймау максатын күздә тотып эшләнә. Яки, киресенчә, Үзәк банк коммерция банкларының резервларын чикләүгә һәм хәтта кыскартуга юнәлдерелгән сәясәт уздырырга мөмкин.

Үзәк банк үзенең исәпләү ставкасын киметә икән, димәк, ул коммерция банкларына резервларын арттырырга һәм шуның нигезендә үзләренең пассив һәм актив операцияләрен киңәйтергә мөмкинлек бирә. Табигый ки, исәпләү ставкасын күтәрү капма-каршы нәтиҗә бирә, ягъни резервларның артуы файдага булмый, коммерция банкларының пассив һәм актив операцияләре киңәюдән туктый. Шуңа күрә исәпләү ставкасын күтәрү инфляциягә каршы йогынты ясый, ләкин аны торгынлык һәм рецессия шартларында кулланырга ярамый. Исәпләү ставкасын киметү, киресенчә, торгынлык һәм рецессия күренешләрен җиңеп чыгарга ярдәм итә, әмма ул инфляцияне көчәйтергә мөмкин.

«Очсызлы» һәм «кыйммәтле» акчалар сәясәте

Үзәк банк тарафыннан резервларның мәҗбүри нормасына ачык базарда дәүләт кыйммәтле кәгазьләре белән эш итү һәм исәпләү ставкасына карата уздырылган чараларны карау Үзәк банкның кредит-акча сәясәтен, нигездә, ике юнәлештә алып баруын күрсәтә.

Беренче юнәлеш шуннан гыйбарәт: Үзәк банк әйләнештәге акча массасы артуга ярдәм итә, кредитларны киңәйтүне стимуллаштыра, процент ставкаларын киметә. Болар барысы да үзләре артыннан бәяләр күтәрелүне, инфляция көчәюне һәм шуңа бәйле рәвештә акчаның очсызлануын, аның сатып алу сәләте кимүен китереп чыгара. Бу сәясәт «очсызлы акчалар» сәясәте («*cheap money*») дип атала.

Үзәк банкның кредит-акча сәясәтенең икенче юнәлеше әйләнештәге акча массасы үсешен чикләүне, кредитларның киңәюен тоткарлауны, процент ставкаларын күтәрүне күздә тота. Мондый сәясәт бәяләр үсеше акрынаюга һәм хәтта аларның кимүенә китерә. Дефляциягә күчәргә мөмкин булган **дезинфляция** (инфляция дәрәҗәсенең әкренләп кими баруы) барлыкка килә. Бу очракта акчаның очсызлануы акрыная һәм ул аның сатып алу сәләте күтәрелү процессына әйләнә. Процент ставкалары югары булганлыктан, кредитлар кыйммәткә төшә һәм алардан файдалану мөмкинлеге кими. Шул ук вакытта акчаларны саклык депозитларына салу һәм кыйммәтле кәгазьләргә кертү зур керемнәр китерә. Мондый сәясәтне «кыйммәтле акчалар» («*dear money*», «*right money*») сәясәте дип атыйлар.

16.4. ИКЪТИСАДИ ҮСЕШНЕ СТИМУЛЛАШТЫРУДА ДӘҮЛӘТНЕҢ РОЛЕ

Без икътисадны тотрыклыландыруга дәүләтнең ничек ярдәм итүен, ягъни тулы мәшгульлеккә ирешергә, циклы тирбәлешләр амплитудасын кыскартырга һәм көчле инфляциягә юл куймаска омтылуын ачыкладык. Дәүләтнең икътисади тотрыклылыкка юнәлдерелгән бурычларының иң мөһиме — ТЭПның тиешле дәрәҗәдәге югары һәм тотрыклы икътисади үсешенә ирешү. ТЭП үсеше темплары, кешеләрне мул тормыш шартлары белән тәэмин итү өчен, халык саны арту темпларын узып китәргә тиеш. Ләкин шул ук вакытта бу темпларны икътисади ресурсларның мөмкинлекләре үзләре үк чикләләр дә. Икътисади үсешнең билгеле бер дәрәҗәдәге оптималь үсеш темпы булып торучы уртача еллык темплары бар дип уйларга да нигез бар. ТЭП үсеше темпларының оптимальлек критерие илдә җитештерелә торган ахыргы товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең файдалылык дәрәҗәсен, Голландия икътисадчысы Я. Тинберген билгеләп үткәнчә, максимальләштерүдән гыйбарәт булырга тиеш. Шуның белән бергә, икътисади үсеш темпларының оптимальлеге проблемасы әлегә чишелмәгән хәлдә кала бирә.

Икътисади үсешне стимуллаштыру сәясәтенең бурычлары

Шулай да дәүләт, икътисади үсешне стимуллаштыру сәясәтен үстергәндә, һич югы, түбәндәге бурычларны хәл итәргә тиеш:

1) тулы мәшгульлеккә ирешү һәм эшсезлекне табигый нормасыннан арттырмау;

2) ТЭПның фактик дәрәҗәсе аның потенциаль дәрәҗәсенә тигезләшүенә, һич югы, аңа якын булуына ирешү;

3) ТЭП дәрәҗәсенең, инвестицияләрнең һәм мәшгульлекнең циклы тирбәлешләренә юл куймау яки аны минимумга җиткерү.

Әлеге бурычлар комплексын хәл итү өчен, дәүләтнең икътисади сәясәте, бер яктан, инвестицияләрнең тигез һәм тотрыклы үсеше өчен кирәкле шартлар тудыруга; икенче яктан, шуңа тәңгәл рәвештә саклык акчаларының тигез һәм тотрыклы артуына юнәлдерелергә тиеш. Бу — дәүләтнең

икътисади үсешкә йогынтысы шофер сыман двигательне әле бер тизлеккә, әле икенчесенә даими рәвештә күчереп торуны аңлатмый. Әлеге чагыштыру күбрәк кыска вакытлы процессларны (инфляция, урта сроклы цикллар, валюта курслары) көйләүгә якын тора. Икътисади үсешкә килгәндә, биредә озын сроклы икътисади сәясәт үткәрү зарур. Безнең очракта ул икътисади үсешнең бөтен дәвамында сакланырлык, уңайлы инвестицион климат булдыруга юнәлдерелергә тиеш.

Дәүләт икътисади үсешнең оптималь һәм тотрыклы темпларын саклауны нинди юллар белән хәл итә ала?

Бюджеттан финанслауны стимуллаштыру

Икътисадта уңайлы инвестицион климат тудыруда һәм аны саклауда иң зур рольне (хәтта төп рольне) бюджет финанславын стимуллаштыру уйный.

Икътисади үсешкә йогынты ясау буенча бюджеттан финанслау чаралары өч состав өлештән тора:

— салым сәясәте;

— икътисади үсешне стимуллаштыру буенча бюджеттан финанслау;

— бюджет дефицитына карата сәясәт.

Икътисади үсешкә ярдәм итүче **салым сәясәте** түбәндәге юнәлешләрдә уздырыла:

1) керемнең саклана торган өлеше керем салымыннан азат ителергә, һич югы, керемнең бу өлешенә салым күләме күпкә киметелергә мөмкин;

2) инвестицияләргә, аеруча фәнни-тикшерену һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре белән бәйле, фәнгә нигезләнгән өлкәләрдәге инвестицияләргә, салымны киметү максатка ярашлы;

3) фәнни-тикшерену оешмаларына һәм уку йортларына салымны льготалы шартларда билгеләүне кертү зур әһәмияткә ия булып тора.

Фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләр, тәҗрибә-конструкторлык эшләре, гомуми һәм махсус белем бирүне үстерүдә, салым сәясәте белән беррәттән, **дәүләт финанславының** да роле аз түгел, хәтта күбрәктер дә әле.

Безгә билгеле булганча, хәзер уку өчен түләү кертелгән менә дигән уку йортлары аз түгел, гадәти дәүләт мәктәпләре

һәм университетларындагыга караганда, аларда заманча җиһазлар белән тәэмин ителеш тә, учредительләргә һәм укытучыларга түләү дә, гомуми белем бирү сферасы белән чагыштырганда, күпкә югарырак. Хосусый характердагы мондый уку йортлары белем бирүне күтәрүдә һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә зур һәм файдалы өлеш кертәләр.

Ләкин Россиядә генә түгел, уртача җан башына исәпләгәндә чагыштырмача югары керемле саналган башка илләрдә дә күпчелек гаиләләр үз балаларын мондый урта һәм югары уку йортларында укыта алмыйлар. Шуңа күрә белем бирүне финанслау чыгымнарының төп өлешен дәүләт үз өстенә алырга тиеш. Бу шулай ук фундаменталь, гомумтеоретик тикшеренүләрне финанслауга да кагыла. Фундаменталь, гомумтеоретик фән теге яки бу керем формасында турыдан-туры файда китерми. Фән һәм мәгариф безнең киләчәктә кайчан да булса бер файдаланылачак (өстәвенә аерым бер конкрет фирмалар рәвешендә түгел) белемнәребезне киңәйтә. Бу белемнәр, гомуми байлыкка әйләнеп, теләсә кайсы фирма тарафыннан кулланылырга, файда китерергә мөмкин. Шуңа күрә фән һәм уку йортларының күпчелеге капиталны арттыру сферасы булып саналмый. Барлык бу очракларда да дәүләт бюджеты мәктәпләр һәм югары уку йортлары төзелешен, фәнни комплекслар төзелешләрен финанслауның төп чыганагы булырга тиеш; академик институт хезмәткәрләре, мәктәп укытучылары һәм университет профессорлары хезмәте дәүләт бюджетыннан түләнергә тиеш. Фән һәм мәгариф үсешенең уңышлары шактый дәрәҗәдә өлеге ил парламентының фәнни тикшеренүләрне финанслауга, үз халкының белем дәрәҗәсен күтәрүгә, икътисад, фән һәм мәдәният өчен белгечләр әзерләүгә нинди сумма бүлеп бирүенә бәйле.

Берничә дистә еллар дәвамында безнең илнең административ планлаштыру системасы хакимлегендә дәүләт бюджетын бүлүдә калдык принцибы өстенлек итте. Ул түбәндәгедән гыйбарәт иде: беренче чиратта хәрби-сәнәгать комплексы (ХСК) ихтыяҗлары канәгатьләндерелде, аннан ХСК белән турыдан-туры бәйләнмәгән матди житештерү тармаклары һәм фәкать соңгы чиратта гына мәгариф, медицина һәм мәдәният финансланды. Бу принцип беркайда да һәм беркайчан да игълан ителмәде, формаль яктан гына булса да (һәм объектив) тәнкыйтьләнде, ләкин шуңа да карамастан ул һаман дәвам

итте. Дәүләт бюджетын бүлүдә ул әле хәзер дә өстенлек итә. Аның шундый тормышчанлыгы нәрсә белән аңлатыла соң? Калдык принцибының яшәүчәнлеге берничә сәбәптән бәйле.

Дәүләт һәм партия җитәкчеләре, сәяси отышка ирешү өчен, тиз вакыт эчендә файда алу максатыннан чыгып эш итәләр; мәсәлән, тышкы сәүдәгә юнәлгән инвестицияләр нәтиҗәлелекнең югары коэффициентына ия һәм, Россия тарафыннан читкә чыгарыла торган чималга дөньякүләм бәяләр белән аны табуга чагыштырмача түбән булган чыгымнар арасында аерма шактый зур булу сәбәпле, тиз вакыт эчендә керем китерәләр. Белем бирүгә юнәлдерелгән чыгымнарның нәтиҗәсен дистә ярым-ике дистә еллар көтәргә туры килә. Мәсәлән, квалификацияле эшче хәзерләү өчен, 10—11 ел урта мәктәптә укырга, 1—2 ел теге яки бу белгечлеккә өйрәнергә һәм әлеге эшче, уку процессында алган белемнәрен практикада куллана алсын өчен, әле тагын производствода берничә ел эшләргә тиеш була. Белем бирүгә тотылган чыгымнар бик аз сизелә.

Мәгариф медицина, фундаменталь фән һәм мәдәният белән беррәттән җитештерми торган, ягъни, эшчәнлек сферасы файдалы булса да, милли керем барлыкка китерми торган тармак булып исәпләнә. Шуңа күрә укытучылар һәм табиблар, галимнәр һәм мәдәният хезмәткәрләре бернәрсә дә барлыкка китерми торган кулланучы хезмәткәрләр исәбендә йөри. Табигый ки, монда риторик сорау туа: илнең дәүләт башлыклары фикеренчә, халык хуҗалыгында тагын да мөһимрәк әһәмияткә ия объектлар булганда, түләү өчен яңадан-яңа средстволар бирә-бирә мондый үзенчәлекле әрәмтамаклар санын арттыруның кирәге бар микән соң?

Энергетика, транспорт, металлургия кебек производство тармакларының нәтиҗәсе икътисадның гомуми торышына турыдан-туры һәм бик тиз йогынты ясый. Әйтик, забастовкалар аркасында коточкыч нәтиҗәләр килеп туарга — икътисад параличланып калырга мөмкин. Шуңа күрә шахтерлар һәм транспортчыларның забастовка белән янавы гына да хөкүмәтне аларга ташламаларга барырга мәҗбүр итә. Ә укытучыларның һәм югары уку йортлары хезмәткәрләренең забастовкасын хөкүмәт әгъзалары гадәттә игътибарсыз калдыра. Югары һәм урта белем системасы белән җитәкчелек итүче

министрларга килгәндә, салым һәм финанс сәясәте мәсьәләләрен хәл итүдә аларның йогынтысы, хәрби сәнәгать яки энергетика комплексы җитәкчеләренекенә караганда, шактый йомшаграк.

Бюджет дефицитына карата сәясәт

Икътисади үсешкә фирмалар һәм йорт хуҗалыкларыннан җыеп алынган салым зурлыгы гына, фән һәм мәгарифне дәүләт финанславы күләме генә түгел, ә дәүләт бюджетының керемнәре белән чыгымнары арасындагы аерма, ягъни **бюджет дефициты** зурлыгы да билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясый.

9 нчы бүлектә карап үткән И. Фишер тигезләмәсеннән күренгәнчә, ТЭП үсеше һәм бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе күтәрелүгә бәйле рәвештә, икътисадның акча массасына ихтыяҗы арту күзәтелә. И. Фишер тигезләмәсен үзгәртеп, без акча күләменә ихтыяҗны түбәндәгечә чагылдыра алабыз:

$$M = \frac{Q \times P}{v}. \qquad (16.1)$$

16.1 тигезләмәсе нигезендә икътисадта әйләнештә йөри торган акча массы ТЭП күләменә (үзгәрешле Q) һәм бәяләрнең гомуми дәрәҗәсенә (үзгәрешле P) пропорциональ була. Әлбәттә, шуны да игътибарда тотарга кирәк: икътисад үсешенә бәйле рәвештә, әйләнештәге акчалар тизлеге (v) арта, ләкин алар бик әкрен арта, шуңа күрә $Q \times P$ тапкырчыгышы v га караганда тизрәк арта.

Икътисадның акча массасына үсә баручы ихтыяҗы ничек канәгатьләндерелергә мөмкин? Бу проблема зур булмаган бюджет дефициты барлыкка килү юлы белән хәл ителә. Әгәр дәүләтнең чыгымнары керемнәреннән артып китә икән, чыгымнарның керемнәрдән артуын, ягъни бюджет дефицитын акча эмиссиясе юлы белән, яки фирмаларга һәм йорт хуҗалыкларына дәүләт бурыч йөкләмәләре сатып капларга була. Фирмалар һәм йорт хуҗалыклары үз чиратында, дәүләт бурыч кәгазьләрен залогка куеп, кредит алырга мөмкин, һәм ул Үзәк банк тарафыннан банкнотлар эмиссияләүгә китерә. Һәр ике очракта да әйләнештәге акча массасы арта һәм гомумикътисади үсешкә ярдәм итә.

Монда дәүләткә бюджет дефициты белән артык мавыгып китәргә ярамавын ассызыклап үтәргә кирәк. Инде күреп үткәнебезчә, аның артык зур күләмнәре инфляцияне кискенләштерергә — зур сикерешле инфляциягә һәм хәтта гиперинфляция кебек авыр формаларга да китерергә сәләтле. Инфляциянең ике формасы да, икътисадка тискәре һәм хәтта җимергеч тәэсир итеп, аның үсешенә түгел, ә үсеш темпларын әкренәйтергә йогынты ясаячак.

Лаффер кәкресе

Икътисади үсешне стимуллаштыруга карата бюджет финанславы сәясәте турындагы мәсьәләнең куелышы үзе үк каршылык китереп чыгара. Икътисади үсешне стимуллаштыру өчен, бер яктан, икътисади тармакларның тулы комплексына теге яки бу төр салым ташламалары ясарга; икенче яктан, шушы ук тармакларны даими һәм шактый зур күләмдә финансларга кирәк. Болар икътисадның аерым тармакларына гына түгел, ә барлык халык хуҗалыгына кагыла. Салымнарны ниндидер минимумга кадәр киметеп, дәүләт сәнәгать, сәүдә, авыл хуҗалыгы, мәгариф, фән һ. б. өчен уңайлы инвестицион климат тудыра. Ләкин салымнарны киметү фән һәм мәгариф кайсы тармак хисабына финанслана, фәнни тармакларга ярдәм кайдан күрсәтелә, авыл хуҗалыгы кебек тармакларга кирәге чыкканда кайдан дотация бирелә — шул чыганакларны ярлыландыра. Шуның өстенә әгәр дәүләт үз бюджетын, аның керемнәре белән исәпләшмичә, сарыф итә һәм зур күләмле бюджет дефицитына юл куя икән, инфляция көчәячәк һәм, күргәнебезчә, икътисади үсешкә тискәре йогынты ясаячак.

Димәк, дәүләт җитәкчеләре салым сәясәтендә дәүләт бюджетына югары керем китерерлек һәм, шуның белән бергә, икътисади үсеш өчен яхшы шартлар тудырырлык «алтын урталык»ны, салым күләмнәренең оптималь дәрәҗәсен табарга тиешләр. Салым ставкаларының мондый дәрәҗәсен ничек билгеләргә соң? Бу сорауга җавап табуда безгә **Лаффер кәкресе** ярдәм итә.

Лаффер кәкресе төзү өчен, ике чиктәге шартларны күз алдына китерик.

Әйтик, башта дәүләт фирмалар эшләп тапканның барысын да йотып бара торган гадәттән тыш югары салым билгели, ди.

Бу очракта дәүләт бюджетына максималь керемнәр килер дип уйланыла. Әмма ул һич тә алай түгел. Баштагы бер-ике ай эчендә дәүләт бюджеты керемнәре артырга да мөмкин. Ләкин алга таба алар кискен кимеп, нульгә төшәргә мөмкин. Ни өчен? Бу сорауның җавабы бик гади: үзенең бөтен керемен дәүләткә түләү өчен беркем дә эшләмәячәк. Әгәр фирмалар — табыш, яллы эшчеләр хезмәт хакы алмаса, тегеләренең дә, боларының да эшкә стимулы булмаячак. Моның нәтиҗәләре теләсә кайсы илне һәлакәткә илтәчәк. Табигый ки, акыллы дәүләт җитәкчесенең берсе генә дә (хәтта икътисад һәм финанс мәсьәләләрен бик үк яхшы белмәгәннәре дә) мондый «салым сәясәте» алып бармаячак.

Инде икенче чик шартны карап үтик: барлык төр салымнар да бетерелә. Бу очракта фирмаларның чәчәк атуы өчен иң яхшы шартлар тудырыла; күздә тотылган керемнәр (бигрәк тә халыкның югары түләнә торган категорияләренең) бик нык артачак. Ләкин бу очракта да эшмәкәрләрнең һәм яллаиып эшләүчеләрнең шатлыгы озакка бармаячак. Дәүләтнең армияне, хокук саклау органнарын, идарә аппаратын, уку йортларын, фәнни-тикшеренү институтларын һ. б. ны тотарга акчасы булмаячак. Илнең яклаучысыз һәм җинаятьчелек белән көрәшергә сәләтсез калуын әйтеп тә тормастан, икътисад үзенә икътисади үсешне тормышка ашыру өчен зарур булган таянычсыз, ярдәмсез калачак; белем туплау, яшь белгечләр әзерләү тукталачак, галимнәр башка илләргә күчеп китәчәк.

Шулай итеп, дәүләт бюджетына салым түләү шәхси фирмалар өчен котылгысыз афәт булып калса, тулаем икътисад өчен табигый ихтыяҗга әверелә: алар күздә тотылган керемне киметәләр, әмма һәр илдә барлык гражданнарны нормаль яшәү шартлары белән тәэмин итәләр. Мәсьәлә шунда: дәүләт фирмалар кеременең нинди өлешен һәм гражданнарның шәхси кеременең күпмесен салым рәвешендә алырга тиешлеген ачыклауда.

Бу сорауга җавап бирү өчен, табыштан салым күләменең үзгәрүенә бәйле рәвештә фирмаларның үзләрен ничек тотуы һәм дәүләт бюджетында аның ничек чагылуы хакындагы мисалны карап үтик.

16-3 рәсеменә игътибар итик. Әйтик, илдә табышка 10%лы салым кертелә. Бу дәүләткә 200 млн сум керем бирә. Ләкин

мондый түбән керем фирмалар эшчәнлегендә сизелмәскә дә мөмкин: алар, саф табышның беркадәр кимүенә карамастан, элекке күләмдә продукция җитештерәчәк. Әгәр 20% лы салым кертелсә, фирмаларның күпмедер өлеше үзләре җитештерә торган продукция күләмен кыскартырга мәҗбүр булачак, чөнки әлеге фирмаларда җитештерү факторларынын ин аз нәтиҗәле өлеше табыш бирмәячәк (рентабельле булмаячак). Шулай да икътисадта продукция җитештерүенең гомуми күләме кимемәячәк, барлык фирмалар табышынын суммасы да



16-3 нче рәсем. △
Лаффер кәкресе.

Рәсемдә күрсәтелгән график дәүләт бюджетына кергән салым күләменең (T_p) табышка салым ставкасына (T') бәйлелеген күрсәтә. Әгәр $T' = 0$ булса, бөтен табыш фирмаларның үзләрендә калдырыла, дәүләт бюджетына бернәрсә дә керми. Әгәр табышка бәйле салым ставкасы 10% булса, бюджетка 200 млн сум керем керә. Табышка бәйле салым ставкасының алга таба үсеше (салым күләме үзенең «критик дәрәҗәсе»нә җиткәнче) дәүләт бюджеты кеременең артуы белән бергә бара. Безнең мисалда ул 50% ка тигез. Салым ставкасы 50% булганда, бюджет кереме, үзенең иң югары дәрәҗәсенә күтәрелеп, 600 млн сум тәшкил итә. Табышка бәйле салымның алга таба үсеше фирмаларда продукция эшләп чыгару кыскаруга һәм аларның керемнәре кими башлауга китерә. Ягъни салым ставкасы күтәрелгән саен, фирмалар продукцияне азрак җитештерәчәк, шуннан чыгып, аларның табышлары кимеячәк һәм дәүләт бюджетына табыштан керә торган салым ставкасы да кыскарачак. Дәүләткүләм финанс җитәкчеләре, үйламыйча эш итеп, табышка бәйле салым ставкасын 100% ка җиткерсәләр, фирмалар товар һәм хезмәт күрсәтүләр эшләп чыгаруны туктатачак, аларның табышы нульгә төшәчәк һәм бюджет кеременең бу статьясы да нульгә тигез булачак.

кимемәячәк һәм бюджет керемнәре артачак. 30%лы салым салу фирмаларга басымны көчәйтәчәк, аларның кайберләре үзләренең житештерү эшчәнлеген дә туктатырга мөмкин, шуңа да карамастан дәүләт бюджетына керемнәр артуы дәвам итәчәк. Табышка бәйле салымның 50% лы ставкасы критик чик булып тора, чөнки аны шуннан да югары күтәрсәң, фирмаларның күбесе житештерүне кыскартырга, күпләре продукция эшләп чыгаруны, гомумән, туктатырга мәжбүр булачак. Илдә барлыкка китерелә торган табыш күләме бик нык кимеячәк, салым күләмен арттыру гына аны компенсацияли алмаячак. Әлеге мисалдан күренгәнчә, салым күләмен 50% лы чиктән арттыру салым базасының кысылуына, дәүләт бюджеты керемнәренең иң мөһим чыганакларының берсе ярлылануына китерә. Шуның белән бергә, 50% лы салым ставкасы кертелгәндә, бюджет кереме иң югары дәрәҗәгә житүен дә әйтеп китәргә кирәк.

> ЛАФФЕР КӘКРЕСЕ дәүләт бюджетына салым керемнәре күләменең салым ставкасы дәрәҗәсенә функциональ бәйлелеген күрсәтә; Лаффер кәкресендә күрсәтелгән функцияләрнең экстремаль кыйммәте дәүләт бюджетына салымнардан кергән максималь сумманы чагылдыра.

Салым ставкалары белән бюджет керемнәре арасындагы үзара бәйлелек теге яки бу илдәге күп кенә конкрет шартлардан тора. Шуңа күрә урыннан яки вакыттан бәйсез рәвештә салым ставкаларын билгеләүдә нинди дә булса бердәм рецепт биреп булмый. Әмма дәүләтнең салым сәясәте принцибы шуңа кайтып кала, ул икътисади үсеш өчен оптималь шартлар тудырырга тиеш, ягъни:

— фирмалар конкуренция шартларында үз үсешләре өчен житәрлек күләмдә саф табыш алырга тиеш;

— йорт хужалыклары үз илләрендәге икътисади үсеш дәрәҗәсенә туры килгән керемгә ия булырга тиеш;

— дәүләт бюджетына кергән керемнәр хөкүмәткә икътисади үсеш өчен уңайлы шартлар тудыруны тәэмин итәрлек булырга тиеш.

16.5. ДӘҮЛӘТ БУРЫЧЫ

Дәүләт бурычы каян барлыкка килә?

Дәүләт бурычы барлыкка килүнең турыдан-туры сәбәбен дәүләт бюджеты дефициты тәшкил итә. Әгәр дәүләт бюджеты чыгымнары аның керемнәреннән артып китә икән, бюджет дефициты барлыкка килә, ягъни дәүләт тарафыннан сатып алына торган товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә, бюджетта каралган трансферт түләүләргә акча средствосы җитми. Бюджет дефицитын каплау өчен, кирәкле акчаларны дәүләт кайдан алырга мөмкин? Бу проблеманы чишүнең ике ысулы бар.

Беренче ысул кәгазь акчалар бастыруга кайтып кала, алар корал һәм сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итүче хәрби ведомстволарга түләү яки хезмәт хакы һәм чиновникларга, хәрби хезмәткәрләргә, дәүләт хезмәтендәге башка затларга эш хакы түләү өчен файдаланыла. Бу ысул икътисадка өстәмә акча массасы кертүне күздә тота.

Әгәр бу ысулны дәүләт бурычы барлыкка килү һәм аның үсеше ягыннан карасаң, ул бик уңышлы кебек тоела. Монда дәүләт бюджет дефицитын каплау проблемасын акча бастыру станоклары аша гына хәл итә, болай эшләгәндә дәүләт банкларга, шактый зур финанс ресурсларына ия булган иминият (страховка) компанияләренә яки башка фирмаларга бурычка керми. Акча эмиссиясе дәүләт бурычы барлыкка килүгә һәм аның үсешенә этәрми. Шуңа күрә дәүләтнең еш кына, үз бурычларын каплау өчен, шушы юлны сайлавы һич гаҗәп түгел. Бөекбритания, мәсәлән, Наполеон белән сугыш вакытында үз чыгымнарын каплау өчен, акча эмиссиясеннән файдалана. Акча басу станогы Франциядә дә бик интенсив эшли: әйләнешкә чыгарылган, ассигнатлар дип аталган акча күләме 1790 елда 400 млн ливр булса, 1796 елда 46 млрд ливрга җитә. Россиядә 1769 елда 1 млн сумлык ассигнацияләр әйләнешкә чыгарыла. Ассигнацияләр эмиссиясе, Төркия белән барган сугыш аркасында чыгымнар арту нәтиҗәсендә, 1775 елга кадәр дәвам итә. Соңрак, Наполеонга каршы сугыш белән бәйле рәвештә, ассигнацияләр шул чор өчен (1817 ел) гаять зур саналган суммага — 836 млн сумга җитә. Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларында катнашкан державаларның чыгымнары, нигездә, акча эмиссиясе хисабына каплана. Әйтик, Гер-

маниядә 1913 елда акча массасы 6,6 млрд марка булса, 1923 елда 496 квинтильон маркага житә. Япониядә 1937 елда әйләнештәге акча массасы (M1 агрегаты) — 6,7 млрд иенга, 1945 елда 92,7 млрд иенга тигез була.

Бюджет дефицитын акча эмиссиясе хисабына каплау хөкүмәткә дәүләт бурычы күтәрелешеннән качарга ярдәм итә, һәм бу житми торган акчаларны бик жайлы табу ысулы кебек тоела. Әмма бу алым базар системасы законнарына һәм беренче чиратта акча әйләнеше законнарына каршы килә. Белгәнебезчә, артык акчалар эмиссиясе инфляциягә, аның да әле сикерешле һәм гиперинфляция кебек иң кискен формалары килеп чыгуга сәбәп була. Шуңа күрә теге яки бу илнең хөкүмәте, кагыйдә буларак, сугыш кебек гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда гына, акча сугу станокларын эшләтүгә бара.

Базар системасы югары үсешкә ирешкән шартларда һәм икътисадта хәлләр билгеле бер дәрәҗәдә тотрыклы барганда акча эмиссиясе дәүләт бюджеты дефицитын каплау чарасы буларак кулланылмый. Хәзерге заманда бюджет дефициты дәүләт облигацияләре эмиссиясе, кыска сроклы дәүләт бурыч йөкләмәләре һәм дәүләтнең башка кыйммәтле кәгазьләре исәбенә каплана. Бу очракта халык саклык акчаларының бер өлешен шәхси фирмаларның акцияләре белән облигацияләренә һәм коммерция банкларының саклык кертемнәренә түгел, ә дәүләт кәгазьләренә инвестицияли. Саклык акчаларын болай инвестицияләү чамадан тыш сорау китереп чыгармый һәм инфляция дә тудырмый. Ләкин ул халыкта дәүләт бурыч йөкләмәләре тупланугa китерә.

> Йорт хуҗалыкларында, банкларда һәм шәхси фирмаларда булган дәүләт кыйммәтле кәгазьләренең гомуми суммасы ДӘҮЛӘТ БУРЫЧЫН тәшкил итә.

Барлык илләрнең хөкүмәтләренә дә күп еллар дәвамында, бюджет дефицитын каплау өчен, кагыйдә буларак, үзләренең бурыч йөкләмәләрен сатарга туры килгәнлектән, дәүләт бурычлары артты һәм арта бара. 16-4 рәсемендә бирелгән диаграммадан күренгәнчә, 1929—1997 еллар эчендә АКШның дәүләт бурычы 16,9 млрд доллардан 4515,3 млрд долларга житә, ягъни ул 267 тапкырга арта.

16-4 нче рәсем. ▷
АКШның дәүләт бурычы үсеше.

Диаграммада АКШның эчке бурычы үсеше (млрд долларларда) бирелгән. Бурыч бик тиз үскән. 1997 елда ул 1929 елдагы дәрәҗәдән 267 тапкырга арткан. Ләкин дәүләт бурычы күләмен аның абсолют зурлыгы белән генә билгеләп булмый. Бурыч ТМП белән нинди чагыштырмада булуын һәм илнең ТМПысында дәүләт кыйммәтле кәгазьләренең ияләренә түләнә торган процентларның өлеше нинди булуын игътибарга алырга кирәк. Соңгы ике диаграмма да дәүләт бурычы үсешенең катастрофик хәлдә түгеллеген күрсәтә.

Дәүләт бурычы үсүенең сәбәпләре

Дәүләт бурычы ни өчен үсә? Дәүләт бурычы дәүләт бюджетыннан уңай сальдоны тотып калганнан соңгы дәүләт дефициты суммасына тигез булганлыктан, аның барлыкка килүенең һәм үсүенең дә төп сәбәпләре шул ук бюджет дефициты сәбәпләре:

1. **Хәрби чыгымнар**. Сугыш алып бару дәүләттән гаять зур чыгымнар таләп итә, һәм алар дәүләт бюджеты исәбенә финанслана. Хәрби чыгымнар халыкара хәлнең кискенләшүе һәм «салкын сугыш» шартларында да үсәргә мөмкин, чөнки алар ашкынып коралланута этәрәләр.

2. **Циклы рецессияләр һәм циклы күтәрелеш вакытында ТЭП үсешенең түбән темплары**. Циклы төшүдән күтәрелү һәм икътисади үсеш темпларын стимуллаштыру өчен, хөкүмәт Үзәк банк ярдәмендә хосусый милекчеләр һәм фирмалар кулында тупланган дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен сатуны арттыра.

3. **Популизм**. Теге яки бу катлаулы икътисади проблемаларны хәл иткәндә, дәүләт җитәкчелеге, хөкүмәт һәм вәкиллекле органнар еш кына бюджетны баланслауга юнәлдерелгән популяр булмаган чараларны (халыктан җыела торган салымны күтәрү, социаль максатларга чыгымнарны киметү һ. б.) читләтеп үтәләр. Шул ук вакытта, бюджет дефицитының артык үсеп китүеннән, инфляция кискенләшүдән һәм кыйммәтчелек аркасында гомуми канәгатьсезлек килеп туудан куркып, хөкүмәт өстәмә облигацияләр һәм башка бурыч йөкләмәләре эмиссиясе турында карар кабул итә.



16.5. Дәүләт бурычы

Дәүләт бурычы үсү куркынычлымы?

1997 ел ахырында АКШның дәүләт бурычы 4,5 трлн доллардан узып китә. Бу — искиткеч зур сан. Әгәр бу санны күрсәтү өчен, 100 долларлык купюраларны өеп куйсаң, аларның биеклеге мең километрдан да артып китәр иде. Ә мондый күләмдәге дәүләт бурычын АКШ икътисады өчен күтәрә алмаслык йөк дип санарга буламы соң?

Бу сорауга җавап бирү өчен, бурычны илдә житештерелә торган ТЭП белән чагыштырып карарга кирәк. Бу нинди дә булса бер гаиләнең бурычын аның кереме белән чагыштыруга тиң. Әгәр аена 1 мең сум хезмәт хакы алып эшли торган эшче, фатир сатып алу өчен, 50 мең доллар бурыч алса, ул ел саен 5 мең доллар шуның процентын түләргә тиеш була. Бу очракта аның хезмәт хакы бурычның процентларын түләү өчен дә житмәячәк. Эшче өчен бу — хәлдән килмәстәй бурыч. Әгәр инде еллык кереме 1 млн доллар тәшкил иткән «яңа рус» 50 мең доллар бурыч алса, ул аны хәтта бер ай эчендә түли ала. Шуңа күрә икътисадта ТЭП никадәр күбрәк житештерелсә, бу илнең халкы шулкадәр бай була, һәм бу ил зур күләмле дәүләт бурычы алудан да курыкмый. 16-4 рәсеменнән күренгәнчә, сугыштан соңгы беренче еллардан кала, АКШның дәүләт бурычы илдә житештерелгән ТЭПның $\frac{2}{3}$ сеннән артмаган. Күрәсең, америкалылар үзләре өчен мондый бурычны авыр йөк дип санамыйлар.

Бурыч авырлыгының икенче бик мөһим критерие — бу бурычның сиңа хезмәт итүе өчен билгеләнгән процентын түләү. 1997 елда АКШ дәүләт бурычының процентлар суммасы 257,4 млрд доллар тәшкил итә. Россия өчен бу сумма бөлдергеч булып, аның хөкүмәте банкротлыкка дучар ителер иде. АКШта исә дәүләт бурычы буенча процентлар өлеше ТЭПның фәкать 1,9%ын гына тәшкил итә. Әлбәттә, бу да аз түгел, әмма дәүләт банкротлыгы турында уйларлык дәрәҗәдә түгел.

Дәүләт үз бурычын түләп бетерергә тиешме? Бу сорауга җавап уңай гына була ала. Әмма бурычын түләүгә, үзенең бурыч йөкләмәләрен алып, дәүләт шунда ук яңа облигацияләр сата, ягъни үз бурычын рефинанслый башлый. Бурыч йөкләмәләрен үз вакытында һәм бернинди шартлар куймыйча түләү дәүләт кыйммәтле кәгазьләренә карата халыкның ыша-

нычын яулауның мөһим шарты булып тора. Әгәр дәүләт җитәкчесе, премьер-министр, финанс министры, нинди дә булса сәбәпләр табып, бурыч йөкләмәләрен түләүдән читләшә икән, халыкның саклык акчаларын урнаштыруның иң ышанычлы формасы итеп караган дәүләт кыйммәтле кәгазьләре белән кызыксынуы бетәчәк. Бурычлар дәүләтнең элеккеге җитәкчеләре тарафыннан эшләнгән дип акланулар да кешегә тәэсир итмәячәк.

Әгәр дәүләт үзенең кыйммәтле кәгазьләренә һәм аларның процентларына түләүдә халык каршында барлык бурычларын вакытында һәм каршылыксыз үти икән, йорт хуҗалыклары һәм фирмалар дәүләт облигацияләрен һәм кыска сроклы йөкләмәләр алуны үзләренең капиталларын инвестицияләүнең ышанычлы формасы буларак карыйлар.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Илнең икътисади үсешен тотрыклыландыру дәүләт каршындагы иң мөһим бурычларның берсе булып тора. Аны хәл итү тулы мәшгульлеккә ирешүне, цикллы тирбәлешләрне йомшартуны, инфляциянең сикерешле һәм гиперинфляция формаларына юл куймауны күздә тота. Дәүләт кулында икътисадны көйләүнең төп ике коралы — дәүләт бюджеты һәм Үзәк банк.

Дәүләт бюджетын икътисадны тотрыклыландыру максатында файдалану бюджет-финанс сәясәте уздыруны күздә тота. Бюджет-финанс сәясәте исә салым сәясәтен, кайбер тармакларны һәм дәүләт программаларын бюджет исәбенә финанслау сәясәтен һәм бюджет дефицитына карата сәясәтне үз эченә ала. Дәүләтнең икътисади сәясәтенең бу юнәлешләре барысы да, беренчедән, уйлап эшләнгән, максатчан характердагы билгеле бер дискрецион чараларны; икенчедән, автомат рәвештә тотрыклыландыру системасын тормышка ашыруны күздә тота.

Үзәк банк аша турыдан-туры коммерция банклары эшчәнлеген җайга салучы акча-кредит сәясәте тормышка ашырыла. Үзәк банк коммерция банклары эшчәнлеген аларның мәҗбүри резерв нормаларын, ачык базарда дәүләт кыйммәтле кәгазьләре белән операцияләрне һәм исәпләү ставкасын үзгәртү юлы

белән көйли. Бу чаралар мәҗбүри резервлар күләмен, әйләнештәге акча массасын, коммерция банкларының фирмаларга кредитларын һәм ТЭП дәрәҗәсен, мәшгульлекне һәм инвестицияләрне үзгәртүгә китерә. ТЭП үсешенә һәм мәшгульлеккә йогынты ясаучы, ләкин инфляцияне көчәйтүче «очсызлы акчалар» сәясәтен яки инфляциягә каршы нәтиҗә бирүче, әмма ТЭП үсешен һәм мәшгульлекне тоткарлаучы, «кыйммәтле акчалар» сәясәтен тормышка ашыру да шушы чаралар аша эшләнә.

Икътисади тотрыклылык сәясәте үткәреп, дәүләт икътисади үсешкә йогынты ясый. Салым ставкаларының оптималь дәрәҗәсен билгеләү һәм икътисади үсешне билгеләүче табышсыз тармакларга (мәгариф, фән һ. б.) җитәрлек күләмдә акча бүлеп бирү икътисади үсешнең тотрыклы темпларына ирешүдә зур роль уйный.

Озакка сузылган бюджет дефициты дәүләт бурычы (дәүләтнең йорт хуҗалыклары, фирмалар кулында тупланган бурыч йөкләмәләренең гомуми суммасы) барлыкка килүнең һәм аның арта баруының сәбәбе булып тора. Икътисадта дәүләт бурычының роленә бәя бирү өчен, аның зурлыгын һәм абсолют күләменең үсешен белү генә җитми, ә дәүләт бурычының ТЭПка чагыштырмасын, шулай ук ТЭПта бурыч буенча түләнә торган процентларның өлешен дә исәпкә алырга кирәк. Әгәр соңгы ике күрсәткеч зур булмаса һәм артмаса, аларның икътисад үсешенә тискәре йогынтысы булмаячак.

❓ *Контроль сораулар һәм биремнәр*

1. Икътисади тотрыклылык сәясәте нинди проблемаларны хәл итәргә тиеш?
2. Икътисадны тотрыклыландыру буенча дәүләт сәясәте юнәлешләре ни өчен бер-берсе белән үзара бәйләнештә булырга тиеш?
3. Нәрсә ул бюджет-финанс сәясәте?
4. Дәүләтнең дискрецион сәясәте нәрсәдән гыйбарәт?
5. Икътисадны автомат рәвештә тотрыклыландыру системасы нәрсәдән гыйбарәт?
6. Мәҗбүри резерв нормаларын үзгәртү ни өчен коммерция банкларына һәм фирмаларга бирелә торган кредит күләмнәрен арттыра яки киметә?

7. Ачык базарда дәүләт кыйммәтле кәгазьләре белән үткәрелә торган операцияләр ничек итеп коммерция банкларының мәҗбүри резервлары күләменә йогынты ясый?
8. «Кыйммәтле акчалар» сәясәте һәм «очсызлы акчалар» сәясәте нәрсәдән гыйбарәт?
9. Икътисади үсешне стимуллаштыруда дәүләт сәясәтенең бурычлары нинди?
10. Лаффер кәкресен тасвирлагыз.
11. Дәүләт бурычы ни өчен барлыкка килә һәм үсә?
12. Дәүләт бурычы арту куркынычлымы?

17 нче бүлек

ХАЛЫКАРА СӘҮДӘ ҺӘМ ВАЛЮТА БАЗАРЫ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җавап табарсыз:

- нәрсә ул бөтендөнья хуҗалыгы һәм анда илнең хәлен ничек итеп характерларга мөмкин;
- илләр арасындагы тышкы икътисади бәйләнешләр системасында сәүдә нинди урын алып тора һәм халыкара сәүдәдә катнашучы илләргә аның нинди файдасы бар;
- халыкара сәүдәдә абсолют өстенлек һәм чагыштырмача өстенлек принциплары нидән гыйбарәт;
- үз илләренең милли мәнфәгатьләрен яклау максатында дәүләтләр нинди тышкы сәүдә сәясәте алып баралар;
- халыкара сәүдәдә илләр үзара исәп-хисапны ничек алып баралар, һәм валюта базары ничек эшли;
- дәүләтләр нинди валюта сәясәте алып баралар.

Алдагы параграфларда илнең икътисады башлыча йомык система буларак өйрәнелде. Без илнең тышкы дөнья белән бәйләнешләрен җентекләп тикшермәдек. Әмма бу бәйләнешләрнең гаять күптөрле булуы һәм тотрыклы икътисади үсеш өчен аның әһәмияте зур икәнлеге барыбызга да яхшы билгеле. Сатып алучылар кибетләрдә дөньяның барлык почмакларыннан китерелгән товарлар сайлап ала. Предприятиеләр, үз продукцияләрен эшләп чыгару өчен, чит илдән алынган җиһазлар һәм чимал куллана, ә бу продукциянең бер өлеше үз чиратында шулай ук читкә (экспортка) җибәрелә. Уннарча миллион кеше чит илләрдә хезмәт итә. Әлеге һәм

башка мисаллардан күренгәнчә, бердәм бөтендөнья хуҗалыгы кысаларында илләрнең икътисадлары торган саен ачыграк һәм үзара бәйләнгәнрәк була бара.

17.1. БӨТЕНДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫ

> **БӨТЕНДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫ** — аерым илләрнең үзара халыкара икътисади мөнәсәбәтләр системасы белән бәйләнгән барлык икътисадлары бергәлеге.

Бу системаның төп элементлары булып товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән халыкара сәүдә, капитал һәм эшче көчләрнең халыкара хәрәкәт итүе, валюта һәм финанс-кредит мөнәсәбәтләре тора.

Бөтендөнья хуҗалыгының үсеше — дәвамлы процесс, ул XIV гасыр ахыры — XV гасыр башында Бөек географик ачышлар нәтиҗәсендә дөнья базары формалаша башлагач җәелеп китә. Халыкара сәүдә эре завод-фабрикалар сәнәгате барлыкка килгәннән соң тизрәк үсә башлый. Транспорт һәм элемтәнең хәзерге заман чаралары халыкара икътисади мөнәсәбәтләрнең, бигрәк тә капитал чыгаруның яңа формаларын китереп чыгарды һәм үстерде.

Халыкара хезмәт бүленеше

Бөтендөнья хуҗалыгы халыкара хезмәт бүленешенә нигезләнә. Илнең халыкара хезмәт бүленешендә катнашуы ул аның теге яки бу продукцияне җитештерүгә специальләшүе һәм әлеге продукциянең үзенең эчке ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен таләп ителгәннән күбрәк эшләп чыгаруын аңлата. Билгеле бер продукция илдә артыгы белән туплана. Башка илләрдә башка төр продукция шулай ук артык эшләнә. Товарлар алмашу зарурлыгы килеп туа, һәм бу илләрнең икътисадлары үзара бәйләнешкә керә.

Илләрнең теге яки бу төрдәге продукция әзерләп чыгаруга юнәлеш алуын илнең табигать шартлары (климаты, географик урыны, файдалы казылмалары), ирешелгән икътисади һәм

фәнни-техник дәрәҗәсе, теге яки бу төр продукция җитештерүдәге традицияләре билгеле.

Ил икътисадның кайсы да булса эре секторын — сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын, хезмәт күрсәтүләр сферасын үстерү буенча специальләшергә мөмкин. Сәнәгатьнең яки авыл хуҗалыгының төрле тармаклары да, шулай ук продукциянең теге яки бу төрләре, аныңниндидер өлешләре һәм хәтта детальләре дә специальләшү юнәлеше була ала. Ил шулай ук җитештерүнең аерым технологик этапларын үтәүгә дә специальләшергә мөмкин.

Икътисадның ачык булуы

Халыкара хезмәт бүленешендә катнашу масштаблары милли икътисадның ачык булуы дәрәҗәсен билгели. Ябык (автаркич) икътисад өчен җитештерүчеләрнең эчке чимал чыганакларына, җиһазларга һәм сату базарларына йөз тотуы хас. Халык хуҗалыгы шунсыз яши алмый дигән әйберләр генә читтән кертелә, ә экспортка бары тик импорт өчен кирәкле чыгымнарны каплау максатында гына чыгарыла. Ачык икътисадка халыкара специальләшү өстенлекләреннән тулысы белән файдаланып калу омтылышы хас. Шул ук вакытта экспорт һәм импортка артык бәйләнгән булуның икътисади системаны тотрыксыз хәлгә төшерү куркынычы бар. 1995 елның башында АКШ администрациясе илгә нефть кертү зарурлыгы үсешенең ил куркынычсызлыгына янавын таныды. XXI гасыр башында АКШта нефтькә булган ихтыяҗның 65% ы импорт хисабына тулыландырыла.

Икътисадның ачыклыгы дәрәҗәсен бәяләү өчен, экспорт һәм импорт өлешләре күрсәткечләрен кулланалар. **Экспорт өлеше** — экспорт бәясенең тулаем милли продуктка процентларда алынган чагыштырмасы. **Импорт өлеше** импорт бәясенең эчке куллану күләменә процентларда алынган чагыштырмасы белән билгеләнә, эчке куллану исә илдә җитештерелгән, запастагы һәм импорт товарлар суммасын тәшкил итә. Шулай ук илдәге бер кешегә исәпләнгән тышкы сәүдә әйләнеше (ягъни товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең экспорт һәм импорты суммасы) күрсәткече дә кулланыла.

Әгәр дә тышкы сәүдәдәге товар әйләнешенә генә түгел, ә тышкы сәүдә статистикасы билгеләп бармый торган хезмәт күрсәтүләр алмашуга һәм капитал агымнарына да игътибар итсәк, икътисадның ачыклыгы күрсәткечләре тагын да үсә

төшәчәк. Тагын шунысын билгеләп үтәргә кирәк: эре икътисади потенциалы, нык үскән эчке базары һәм табигый ресурслар запаслары булган илләрнең тышкы сәүдә әйләнеше чагыштырмача кимрәк булырга мөмкин.

Бөтендөнья хуҗалыгы үсешенең хәзерге этабы *глобальләшү* процессы җәелү белән үзенчәлекле.

> ГЛОБАЛЬЛӘШҮ — ул бөтендөнья хуҗалыгының акрынлап товарлар, хезмәт күрсәтүләр, капитал, эшче көчләр һәм белемнәрнең бердәм базарына әверелүендә чагылучы милли икътисадның үзара бәйлелеге һәм үзара йогынтысы көчәюе.

Глобальләштерү факторлары (хәрәкәткә китерүче көчләр) күптөрле. Аларга түбәндәгеләр керә:

— икътисади: товар, хезмәт күрсәтүләр, капитал, эшче көчләр базарларының либеральләшүе, икътисади сәясәт алып баруда кораллар һәм алымнарның бер төрлегә әверелүе (унификациясе);

— фәнни-техник һәм мәгълүмати: житештерү масштабларының кискен артуы, транспорт, элемтә һәм мәгълүмат алмашу чараларының үсеше, фәнни технологияләргә күчү;

— оештыру: трансмилли корпорацияләрнең дөнья икътисадындагы әйдәп баручы хуҗалык субъектларына әверелүе, халыкара икътисади оешмаларның роле көчәю;

— социомәдәни: төрле илләрдәге кулланучыларның зәвыклары һәм ихтыяжлары тигезләшү, яшәү рәвешләре һәм кыйммәтләренең якынаюы, сәяси-икътисади системаларның унификациясе.

Галимнәр глобальләшү процессының капма-каршылыклы булуын искәртәләр. Бер яктан, ул халыкара хезмәт бүленешенең тагын да тирәнәюенә, илләр арасында ресурсларның тагын да эффектив бүленүенә, конкуренция үсүгә һәм фәнни-техник прогресска, илләрне үстерү өчен зарури булган финанс ресурсларын чит илләрдән күпләп кертүгә алып бара. Болар барысы да гомуми байлыкны үстерүгә ярдәм итә.

Икенче яктан, глобальләштерү дөньяда керемнәрнең тагын да полярлашуына, күп илләрнең технологик артталыгы,

кечәюгә һәм аларның дөньядагы товар һәм финанс базарлары конъюнктурасына бәйлелеге артуга, милли хуҗалыкларда күпчелек тармакларның конкурентлык сәләте төшү аркасында, икътисадта кискен структур тайпылышлар барлыкка килүгә һәм шуның нәтиҗәсендә эшсезлек артуга илтә.

Бөтендөнья хуҗалыгы үсешенең хәзерге этабында әле тагын бер үзенчәлек бар: глобальләшү процессы производствоның тирәнрәк интернациональләшүе белән бергә бара.

ПРОИЗВОДСТВОНЫҢ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛӘШҮЕ — халыкара хезмәт бүленеше нигезендә илләр арасында тотрыклы икътисади бәйләнешләр формалашу процессы ул.

Хезмәтнең халыкара бүленеше, аерым алганда, автомобильләр төзү сәнәгатендә, суднолар һәм авиация төзелешендә, электротехникада аеруча кызу темплар белән бара. Мәсәлән, АКШ һәм Бөекбританиянең машиналар төзелеше продукциясе белән тышкы сәүдәсендә машина детальләре һәм узелларының өлеше 60% дип бәяләнә. Япониядә яки Швециядә җитештерелгән судно бәясенең 70% ка кадәре чит илләрдән кертелгән компонентларга туры килә. БМОның Европа комиссиясе мәгълүматлары буенча, мондый хезмәт бүленеше һәм аның белән бәйләнгән халыкара производство кооперациясе нәтиҗәсендә яңа производствоны үзләштерү вакыты 14—20 айга кыскара һәм чыгымнар 50—70% ка кими.

Бөтендөнья хуҗалыгында илләрнең төркемнәре

200 дән артык ил һәм территория катнашкан бөтендөнья хуҗалыгында эшләрнең торышын яхшырак күзаллау, халыкара багланышлар системасында аерым дәүләтләр төркеменең ролен дөрес бәяләү өчен, икътисадчылар илләрнең классификацияләрен эшлиләр. Бу вакытта күрсәткечләр комплексы игътибарга алына:

1) илнең икътисади потенциалы, ул ТЭП һәм милли байлык күрсәткече, табигать һәм хезмәт ресурсларының күләме, фәнни-техник үсеш дәрәҗәсе белән билгеләнә;

2) илнең социаль-икътисади үсеше, ул бер кешегә туры килүче милли керемнең күләме, икътисадның тармак струк-

турасы үзенчәлекләре, производствоның эффективлыгы, халыкның яшәү муллыгы дәрәҗәсе кебек күрсәткечләр белән характерлана;

3) илнең бөтендөнья хуҗалыгында тоткан урыны, бу турыда без экспорт һәм импорт өлеше күрсәткечләре, халыкара капитал хәрәкәтендәге торышы һәм хезмәт миграциясе масштаблары буенча әйтә алабыз.

Хәзерге чорда илләрне халыкара квалификацияләүнең берничә варианты бар. Халыкара валюта фонды (Международный валютный фонд — МВФ) икътисадчылары тарафыннан эшләнгән вариантны карап үтик. Бу вариант буенча квалификацияләгәндә, барлык илләр өч төркемгә бүленә: 1) югары икътисади үсеш алган илләр (28): аларга 7 эре индустриаль ил (АКШ, Япония, Германия, Франция, Италия, Бөекбритания һәм Канада) керә; 2) үсеп килүче илләр (128); 3) икътисады көчеш хәлендәге илләр (28). 17-1 рәсеменнән күренгәнчә, 2000 елда югары икътисадка ия булган илләр төркеме ТЭП күләме буенча да, товар һәм хезмәт күрсәтүләр экспорты күләме буенча да дөньяда өстенлек иткән. Дөньякүләм экспортта бу төркемнең өлеше аеруча зур. Башкача әйткәндә, бу илләрдә җитештерелә торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр



17-1 нче рәсем. △
ХВФ бәяләмәсе буенча 2000 елда илләр төркемнәренең дөньякүләм ТЭПындагы (а) һәм товарлар һәм хезмәт җитештерүләр экспортындагы (б) өлеше (% ларда).

үсеп килүче илләрнең дә, базар системасына күчеш ясаучы яки инде бу күчешне тәмамлап өлгергән илләрнең дә эчке базарлары конъюнктурасына сизелерлек йогынты ясый.

Россия, шулай ук Үзәк һәм Көнчыгыш Европа илләре планлы-административ системадан базар системасына күчеш ясап бетергәнлектән, ХВФ экспертлары бу классификациягә тиешле төзәтмәләр кертер дип көтелә.

Халыкара реконструкция һәм үсеш банкы (Международный банк реконструкции и развития — МБРР) экспертлары исә башкачарак классификация уйлап тапкан. Бу классификациянең үзенә җентекләп тукталмабыз. Аның критерийлары буенча безнең илебез — башлыча сәнәгать товарлары экспорты һәм уртача тышкы бурычка ия булган дәүләт. Россия Федерациясе хөкүмәтенең тышкы бурычы соңгы елларда күпкә кимеде һәм 2004 елның ахырына 92,8 млрд сумга тигезләште. Әлеге ике күрсәткеч югары икътисади үсеш алган илләргә хас. Базар мөнәсәбәтләренең үсеш дәрәҗәсе, сәнәгать производствосының күләме һәм аның чагыштырмача тоткан урыны, сәнәгать товарларын экспортлаудагы роле буенча Россия югары икътисадлы илләр күрсәткечләренә якын тора. Әлегә кадәр күчеш икътисады илләре дип классификацияләнә торган башка илләр (мәсәлән, Чехия, Словения һ. б.) турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

17.2. ХАЛЫКАРА СӘҮДӘ

Халыкара икътисади мөнәсәбәтләрнең иң мөһим формаларыннан берсе булып халыкара сәүдә тора. Тышкы сәүдәнең анда катнашучыларга нинди файдасы бар соң? Илләр арасындагы тышкы сәүдә агымнарының юнәлешләре ничек билгеләнә?

Бу проблема инде XVI—XVII гасырдагы икътисади фикер юнәлеше — меркантильлек кысаларында ук өйрәнелгән. Бу юнәлешнең иң күренекле вәкиле булып инглиз Т. Мани (1571—1641) исәпләнә. Меркантильләр илгә тышкы сәүдә алтын туплау өчен кирәк дип исәпләгәннәр, чөнки ул милләтнең төп байлык чыганагы булып саналган. Әгәр дәүләтнең читкә саткан товары (ул аның өчен алтын ала) читтән алтын түләп алган товарына караганда күбрәк икән, ил алтын белән тәэмин ителә дигән сүз. Шуңа күрә меркантильләр экспортны киңәйтү һәм импортны һәрьяклап кысуны яклап чыкканнар.

Әмма XVIII гасырның икенче яртысында Англиядә сәнгать революциясе монархчы яшәп килгән күзаллауларны яңадан карап чыгуны таләп итә. Бер яктан, сату проблемасы кискенләшә, чөнки милли базарлар гына эрләү һәм туку производствосы продукциясе өчен кысанга әверелә. Икенче яктан, бик тиз үсә баручы шәһәрләр өчен чимал һәм азык-төлекне читтән кертү кирәклеге ачыклана.

XVIII гасырның икенче яртысы — XIX гасыр Англиясе протекционизм сәясәтеннән ирекле сәүдәгә күчүнең классик үрнәге булып тора. Ирекле сәүдә сәясәте беренче тапкыр күренекле инглиз икътисадчысы А. Смит тарафыннан аның «Халыклар байлыгының табигатен һәм сәбәпләрен тикшерү» (1776) хезмәтендә формалаштырылып бирелә. А. Смит, импортны либеральләштерүнең һәм таможня чикләүләрен киметүнең зарурлыгын нигезләп, бөтендөнья сәүдәсенең яңа теориясен тәкъдим итә. Смит теориясе «абсолют өстенлек принцибы» дигән исем ала.

АБСОЛЮТ ӨСТЕНЛЕК ПРИНЦИБЫ һәрбер илнең уртача чыгымнары башка илләрдәге уртача чыгымнардан кимрәк булган товарлар житештерү буенча специальләшергә тиешлегеннән гыйбарәт.

Теге яки бу товар буенча абсолют өстенлек тиешле ресурсларның булу-булмавы белән билгеләнә. Мондый товарларның бер өлешен экспортлаудан килгән акчага ил икенче төрле — үзендә житештерү кыйммәткәрәккә төшкән һәм башка бер ил абсолют өстенлек иткән товарлар сатып ала. Смит шундый сәүдәнең барлык катнашучылары өчен дә отышлы булуын исбатлый.

Абсолют өстенлек принцибын күрсәтү өчен, бер мисал карап үтик.

Бөтендөнья базары А һәм Б илләре арасындагы сәүдә мисалында күрсәтелсен. А иле Б иленә караганда бодай житештерүдә азрак чыгымнар тота, ягъни бирелә ресурслар чыгымының бер берәмлегенә Б иленә караганда күбрәк бөртек алына. Шул ук вакытта ресурслар чыгымының бер берәмлегенә



17-2 нче рәсем. △
Абсолют өстенлек принцибы.

Графиктан күренгәнчә, А иленең — бодай үстерүгә, Б иленең нефть җитештерүгә специальләшүе ике илдә дә нефть һәм бодай кулланунның үсешенә һәм бодай белән нефтьне тулаем җитештерүнең артуына китерә.

Б илендә А га караганда күбрәк нефть чыгарыла. Мәсәлән, А илендә чыгым берәмлегенә я 50 т бодай, яки 25 т нефть, яки AA_1 сызыгы белән бирелгән чикләрдә теләсә нинди күләмнәрдә бөртек һәм нефть чыгарыла. Б да чыгым берәмлегенә яки 40 т бодай, яки 100 т нефть, яки аларның BB_1 сызыгы чикләрендәге теләсә нинди күләмнәре җитештерелә (17-2 рәс.).

Эчке базарда сорау һәм тәкъдимнең үзара тәэсире нәтиҗәсендә А иленең производство структурасы S_1 ноктасы, ә Б иленеке S_2 ноктасы белән бирелгән, дип уйлыйк. S_1 ноктасының координаталары — 20 т бодай һәм 15 т нефть, S_2 ноктасыныкы — 12 т бодай һәм 70 т нефть.

Хәзер ил эчендә һәм илләр арасында бартерлы алмашу, ягъни турыдан-туры товар алмашу бара дип уйлыйк. Ул чагында 1 т бодай бәясе А иленең эчке базарында 0,5 т нефтькә, Б иле базарында 2,5 т нефтькә тора. Тәгәлрәге, бу очракта сүз җитештерүнең альтернатив чыгымнары, ягъни

бодай житештерүне бер берәмлеккә арттырып, шушы күләмдәге нефть чыгарырлык чыгымнар турында бара.

Илләр арасында сәүдә мөнәсәбәтләре урнашкач (транспорт чыгымнары нульгә тигез дип уйлыйбыз), сәүдәгәрләргә А илендә 1 тоннасын 0,5 т нефть бәясеннән бодай сатып алу, аны Б иленә экспортлау һәм анда 2,5 т нефть бәясенә сату отышлы булачак, чөнки бодайның һәр тоннасы 2 т нефть күләмендә табыш китерә. Һәм киресенчә, Б иленнән нефть чыгару файдалы, анда нефтьнең 1 тоннасын 0,4 т бодай бәясеннән сатып алу һәм, аны А иленә илтеп, 2 т бодай бәясенә сату отышлы. Сатылган нефтьнең һәр тоннасы 1,6 т бодай бәясендәге табыш ясый.

Тышкы сәүдә процессында бөтендөнья сәүдә бәяләре, мөгаен, 1 т бодай өчен 0,5—2,5 т нефть булыр. Дөрестән дә, әгәр 1 т бодайның дөньякүләм бәясе 0,2 т нефть чамасында гына куелса, аны А иленнән чыгаруның файдасы булмаячак һәм ашлык эчке базарда гына сатылачак. Әле шунысы бар: бәяләр мондый булганда, А иленнән бодай түгел, ә нефть чыгару файдалырак, чөнки дөнья базарында 1 т нефть өчен 5 т бодай, ә эчке базарда бары 2 т бодай кирәк булачак.

Ләкин Б иле дә үзенең 5 т бодаен 1 т нефтькә алыштырмас, чөнки аның эчке базарында шул ук нефтьне 0,8 т бодай бәясенә алып булачак. Шунлыктан тышкы сәүдә барып чыкмаячак.

Әгәр инде 1 т бодайга дөньякүләм бәя 2,5 т нефть бәясеннән артык куелса, алдагыча фикер йөртеп, ике илгә дә бодайны читкә чыгару һәм нефтьне читтән алу файдалы дип табарбыз.

Әйтик, тышкы базар килешүләре нәтиҗәсендә дөньякүләм бәяләр алда күрсәтелгән аралыкта урнаша һәм 1 т нефть өчен 1 т бодай исәбенчә була, ди. Бу очракта А иле, бодай житештерүгә специальләшеп, 50 т бодайның, мәсәлән, 20 тоннасын 20 т нефтькә алыштыра икән, ул файдага эшли булып чыга. Бу вакытта А да бодай һәм нефть куллану AA_2 турысындагы C_1 ноктасы белән билгеләнер (17-2 рәс.). Күренгәнчә, А иленең специальләшүе нәтиҗәсендә анда бодай куллану да, нефть куллану да арта.

Нәкъ шуның кебек Б иле нефть житештерүгә специальләшә һәм аны чыгым берәмлегенә 100 т күләмендә чыгара.

Нефтьнең бер өлеше, мәсәлән, 20 тоннасы 20 т бодайга алыштырыла. Нәтиҗәдә бодай һәм нефть куллану B_1B_2 пунктир сызыгындагы C_2 ноктасы белән билгеләнер һәм ул BB_1 турысында яткан S_2 ноктасындагыга караганда, һичшиксез, күбрәк.

Ниһаять, ике илдә дә чыгым берәмлегенә җитештерелгән бодайның гомуми күләме 32 тоннадан (20 + 12) 50 тоннага, ә нефтьнеке 85 тоннадан (15 + 70) 100 тоннага кадәр арта. Димәк, специальләшүнең эффекты ике илнең дә үсеп баручы җитештерү потенциалы эффектына тигез була.

Ләкин кайбер илләр бер генә товар буенча да абсолют өстенлеккә ия түгел, ягъни теләсә кайсы товар берәмлегенә тотылган чыгымнары башка илләрнекеннән югарырак. Шулай булса да алар тышкы сәүдәдә катнашалар.

Чагыштырма өстенлек принцибы

Аларның тышкы сәүдәдән килгән табышы нидән гыйбарәт соң? Бу сорауга җавапны үзенең «Сәяси икътисад һәм салым салу башлангычлары» дигән китабында Д. Рикардо бирә.

> **ЧАГЫШТЫРМА ӨСТЕНЛЕК ПРИНЦИБЫ** илнең җитештерелгән товарларының башка илләрдә шундый ук товарларны җитештерүгә караганда чагыштырмача отышлыракларын эшләп чыгаруга специальләшергә тиешлегеннән гыйбарәт.

Бу принципны аңлатыр алдыннан гади генә бер очракны карап үтик. Әйтик, сезнең әниегез — уңышлы эшләүче адвокат һәм, өстәвенә, шәһәрнең иң яхшы машинисткасы да, ди. Үзенең эш кәгазьләрен ул үзе баса. Аңа үзеннән күпкә акрынрак эшләүче машинистканы эшкә алу һәм судта җиңүләре бәрабәренә алынган табышын аның белән бүлешү файдалы микән? Рикардо, әйе, дияр иде. Машинистка бик акрын эшләсә дә, ул әниегезнең күпмедер вакытын азат итә, ә әниегез, шушы вакытта өстәмә эшләр алып барып, машинисткага түләгәннән күпкә артык гонорар эшли алачак.

Бу мисалның шартларын беркадәр үзгәртеп, анализыбызны катлауландырабыз.



17-3 нче рәсем. △
Чагыштырма өстенлек принцибы.

Графиктан күренгәнчә, А иленең нефть җитештерүгә караганда чагыштырмача файдалырак булган бодай җитештерүгә специальләшүе ике илдә дә бодай һәм нефть куллану күләме артуны һәм бодай белән нефть җитештерүнең тулаем күләме үсүне тәэмин итә.

Әйтик, А илендә чыгым берәмлегенә яки 50 т бодай, яки 25 т нефть, яки AA_1 сызыгы белән бирелгән бу товарларның теләсә кайсы комбинациясе җитештерелә. Б иле чыгым берәмлегенә 60 т бодай яки 100 т нефть, яки BB_1 сызыгы белән бирелгән бу товарларның башка төрле комбинациясен җитештерә (17-3 рәс.).

Шулай итеп, А илендә бодай җитештерүгә дә, нефтькә дә тотылган чыгымнар Б иленнән югарырак, ләкин бодай буенча азрак калыша. Бу А иле бодай җитештерү буенча чагыштырма өстенлеккә ия дигәнне аңлата.

Тышкы сәүдә булмаганда, А илендә бодай һәм нефть куллану S_1 ноктасы белән (20 т бодай һәм 15 т нефть) бирелгән, ди. Тиндәшле рәвештә Б илендә куллану S_2 ноктасы белән (15 т бодай һәм 75 т нефть) бирелә.

Сәүдә бәйләнешләре урнашканнан соң, сәүдәгәрләр А илендә 1 т бодай өчен 0,5 т нефть бәясеннән бодай сатып ала һәм аны Б илендә 1 т бодай өчен 1,66 т нефть бәясеннән сата башлаячак, табыш бу очракта бодайның һәр тоннасына 1,61 т нефть күләмендә була. Алда китерелгән мисалдагыча фикер йөртеп, бөтендөнья базары бәяләренең чагыштырмасы 1 т бодай өчен 0,5—1,66 т нефть туры килгәнен табабыз. Шул ук вакытта А иле 1 т бодай өчен якынча 1,66 нефть һәм, һич югында, 0,5 т нефтьтән югарырак бәя куярга теләр иде. Б иле бодайга алмашка мөмкин кадәр азрак нефть бирергә омтыла. Агымдагы дөньякүләм бәя бодай һәм нефтьнең дөнья базарлары конъюнктурасына бәйле рәвештә билгеләнәчәк. Әгәр ул 1 т бодайга 1 т нефть дәрәҗәсендә билгеләнсә, А иле, бодай житештерүдә специальләшеп, чыгымнарның бер берәмлегенә 50 т ашлык житештерәчәк һәм аның 20 сен 20 т нефтькә алыштырып читкә чыгарачак. Б иле нефть чыгаруда специальләшер, чыгым берәмлегенә 100 т житештереп, аның 20 сен дөнья базарында 20 т бодайга алмаштырачак.

Ул чагында бодай һәм нефть куллану А илендә 30 т бодай һәм 20 т нефтькә (17-3 рәсемендә C_1 ноктасы), Б илендә тиндәшле рәвештә 20 һәм 80 гә (C_2 ноктасы) житәчәк. Чыгым берәмлегенә бодай житештерүнең гомуми күләме 35 тән (20 + 15) 50 т га, нефтьнеке 90 нан (15 + 75) 100 т га кадәр артачак. Илләр арасында товар күчерүгә чикләүләр булмаганда, бу товарларның эчке бәяләре тигезләшүгә барачак.

Д. Рикардоның чагыштырма өстенлек принцибы соңга таба башка икътисадчылар тарафыннан үстерелә, алар аны, капиталны да кертеп, житештерүнең барлык факторларына күчерәләр. Илләрнең житештерү процессында чагыштырмача артык һәм шунлыктан чагыштырмача арзанрак факторлар интенсив кулланыла торган товарларны читкә чыгаруы исбатланды. Дөрестән дә, күп кенә үсеп килүче илләрнең экспорт товарлары хезмәт сыйдырышлы товарлардан гыйбарәт, чөнки ул илләрдә квалификациясез арзан эшче көчләр артыгы белән, ә импорт капитал һәм фән сыйдырышлы товарлардан тора (машиналар, җиһазлар, транспорт чаралары һ. б.), боларны үзендә житештерү, капитал һәм квалификацияле хезмәт житешмәү сәбәпле, чагыштырмача зур чыгымнар таләп итәр иде.

Әмма соңга таба халыкара сәүдәнең башка теорияләре килеп чыга. Чөнки Рикардо принцибы нигезендә, мәсәлән, нык үскән илләр арасында тармак эчендә һәм аерым детальләр буенча специальләшү кысаларындагы сәүдәнең сәбәпләрен аңлатып булмый.

Нык үскән илләр экспортының иң зур өлеше тышкы сәүдәгә туры килә, ул, җитештерү факторларының төзелеше һәм техник характеристикалары шактый охшаш булса да, шушы илләрнең үзләре арасында бара. Мәсәлән, XX гасырның 80 нче елларында Бөекбритания экспортының $\frac{2}{3}$ өлеше Төньяк Америка һәм Көнбатыш Европа илләренә, ягъни җитештерү факторлары якынча шундый ук булган илләргә туры килә.

Тышкы сәүдә агымнарын аңлатуга заманча якын килүләрдә яңа, өзлексез үсә баручы техника һәм технология мөмкинлекләре исәпкә алына. Эре серияле махсус производстволар чыгарылган товар берәмлегенә тотылган чыгымнарның радикаль кимүен тәэмин итәләр. Мондый производстволарны төзегәндә, продукцияне тышкы базарларда сәнәгать кооперациясе кысаларында сату мөмкинлеге исәпкә алына.

Икътисадчылар шулай ук фирмалар тарафыннан тышкы базарларда конкурентлык өстенлегенә ирешү максаты белән алып барыла торган өзлексез технологик үзгәрешләргә игътибар итәләр. Фирмалар үз кулларындагы производство факторларын камилләштерәләр, аларны оста үзгәртеп коралар һәм еш кына дәүләт ярдәме белән эффектив тышкы икътисади стратегия үткәрә беләләр.

Берничә мисал карап үтик. Климаты бик үк яхшы булмаган Голландия чит илләргә елына 1 млрд доллардан артык суммага чәчәк сата, моның өчен электр яки табигый газ белән җылытыла торган камилләштерелгән теплицалар, товарны кулланучыга вакытында җиткерү өчен авиатранспорт кулланыла. Япониядә җир бәясе һәм эшчеләрнең хезмәт хакы искиткеч югары, арзанлы табигый ресурслар юк. Ләкин, склад урыннары кирәкми торган «*just in time*» системасын кулланып, җитештерүне автоматлаштыру һәм ресурс саклаучы технологияләрне үстерү хисабына, япон фирмалары фән сыйдырышлы өр-яңа продукция төрләре буенча дөньякүләм әйдәп баручы экспортерларга әверелделәр.

Шулай итеп, тышкы сәүдә агымнарының юнәлешен икътисад фәнендәге барлык караш-тәгълиматлар нигезендә генә аңлатырга мөмкин.

Дөньякүләм сәүдә үсешенең закончалыклары

Озак вакытлар эчендә дөньякүләм сәүдәнең товар һәм географик төзелешен анализлаганда берничә закончалыкны аерып күрсәтергә мөмкин. Дөнья сәүдәсе үтә кызу темплар белән үсә, һәм илләрнең тулай эчке продукты (ТЭП) күләмендә экспорт өлешләре арта. Әгәр 1950 елда товар һәм хезмәт күрсәтүләрне дөньякүләм экспортлау бөтендөнья ТЭПының 13,0% ын тәшкил итсә, 2000 елда ул 17,1% ка җитте, ә 2015 елда 18,7% булыр дип фаразлана. Әзер продукциянең, бигрәк тә югары технологияле, фән сыйдырышлы продукциянең өлеше арта бара. Бер үк вакытта дөньяның әйдәп баручы илләре тарафыннан эшләп чыгарыла торган машина һәм җиһазларга экспорт бәяләре дә арта. Ресурслар аз тотыла торган технологияләр куллану һәм үз-үзенең тәэмин ителешен арттыру аркасында, нык үскән илләрнең чималга һәм азык-төлеккә соравы чагыштырмача түбәнәя, һәм үсеп килүче илләр җитештерә торган күпчелек чимал товарларына экспорт бәяләре киму дәвам итә. Нәтиҗәдә дөньякүләм сәүдәдә «өченче дөнья» («яңа индустриаль» илләрне исәпләмәгәндә) дәүләтләренең хәле начарая. Киресенчә, нык үскән илләр өчен тышкы сәүдәнең файдасы арта төшә.

Халыкара сәүдәнең ил өчен файдасын бәяләүдә икътисадчылар **сәүдә шартлары индексын** кулланалар. Ул экспорт һәм импорт бәяләре динамикасы нисбәтен күрсәтә.

СӘҮДӘ ШАРТЛАРЫ ИНДЕКСЫ — илнең аерым бер вакыт аралыгындагы уртача экспорт бәяләре индексын уртача импорт бәяләре индексына бүлүдән чыккан өлеш.

Бер ил эчендә уртача экспорт бәяләре 5% ка, ә импорт бәяләре 10% ка арткан, дип алыйк. Ул чагында сәүдә шартлары индексы түбәндәгечә исәпләнә:

$$J = \frac{105}{110} \cdot 100\% = 95{,}25\%.$$

Аның кимүе, бер берәмлек импорт товары сатып алу өчен, экспорт товарларын торган саен күбрәк сатарга кирәк икәнен күрсәтә.

Халыкара алмашуда хезмәт күрсәтүләр, бигрәк тә туризм, транспорт, финанс, инжиниринг, шулай ук технологияләр тапшыру сферасындагы хезмәт күрсәтүләрнең дөньякүләм базары үсү тенденциясе әһәмияткә ия. Бу базарның әйдәп баручылары (лидерлары) — нык үскән илләр.

Россиянең тышкы сәүдәсе

Соңгы елларда Россия икътисады өчен тышкы сәүдә әһәмиятлерәк төс ала бара. 2003 елда товарлар экспорты 135,9 млрд долл. тәшкил итә һәм 2002 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда 26,2% ка арта; импорт 23,6% ка үсә һәм 75,4 млрд долларга җитә. ТЭПта экспортның өлеше үсә. Россия тагын да рациональрәк элемтәләргә күчә, һәм Германия, АКШ, Италия кебек нык үскән илләр аның эре партнерларына әверелә.

Шул ук вакытта дөнья сәүдәсендә Россиянең өлеше түбәнәя. Аның тышкы сәүдә әйләнеше 80 нче елларның икенче яртысында дөньякүләм сәүдә әйләнешенең 3% ын тәшкил итсә, хәзер 1% чамасын гына алып тора. Сәүдә балансының уңай сальдосы, ягъни экспортның импорттан артык булуы импортның кимүе белән аңлатыла.

Тышкы сәүдәнең товарлар структурасы да уңайлы түгел. Экспортның яртысыннан артыгын яңадан тутырыла алмый торган, эшкәртелмәгән чимал товарлары (нефть, газ, алмаз, алтын, платина), төсле һәм кара металлар, электр энергиясе, минераль ашламалар алып тора. Ташкүмер һәм бүрәнә материалларының да экспорт күләме зур. Машина һәм җиһазлар экспортның 5% ын тәшкил итә. Алыштырылучы валюта кеременең 70—75% ы икътисадның чимал секторы хисабына туры килә. Илнең валюта резервларын арттыруга энергия чыганаклары базарындагы уңайлы конъюнктура һәм илнең сәүдә шартлары индексы үсү ярдәм итә. 2003 елда Россия экспортының уртача бәясе якынча 10% ка артса, энергия чыганаклары бәясе 20% ка, кара металларныкы 16% ка, никельнеке 36% ка арткан.

Россиягә исә машиналар һәм җиһазлар (импорт бәясенең өчтән бере тирәсе), азык-төлек, авыл хуҗалыгы чималы,

кием-салым, тукыма, аяк киеме, медикаментлар һәм башка шундыйлар кертелә.

Үзенең тышкы сәүдәсе структурасын Россия химия, атом, электротехника, саклану сәнәгатьләренең конкурентлыкка сәләтле продукциясе, приборлар, суднолар, автомобильләр экспортын үстерү хисабына яхшырта ала. Транспорт, төзелеш, туризм хезмәтләрен, программалар системаларын сатудан да шактый зур табыш алырга мөмкин. Әмма моның өчен дәүләт тарафыннан максатчан ярдәм һәм көнбатыш илләренең Россия товарларына карата кискен протекцияле сәясәтләреннән баш тартуы таләп ителә.

Халыкара сәүдәнең формалары һәм методлары

Халыкара сәүдә берничә формада алып барыла. Турыдан-туры коммерция экспорт-импорт операцияләре төп урынны били, алар китерелгән товар өчен валюта белән түләүне күздә тота. Әмма дөньякүләм сәүдәнең 25—30%ы кара-каршы сәүдәгә — товар өчен товар белән түләүгә туры килә. Кара-каршы түләүне, гадәттә, товарлар өчен түләүгә валютасы булмаган импортер тәкъдим итә. Бартер һәм компенсация килешүләре кара-каршы сәүдәнең төп төрләре булып санала.

> БАРТЕР — акча катнашыннан башка гына товарлар белән натуралата алмашу килешүе.

1993 елда Россия экспортында бартер 11,7%, импортында 13,8% тәшкил иткән. Иң эре бартерлы әйләнешләр Кытай, Германия, Швейцария, Венгрия белән барган. Экспортта туңдырылган балыкның бартер өлеше — 37%, ташкүмернең — 36%, чуенның — 46%, тимер рудасының 37% була. Шикәр импортында бартерга — 38%, ит консервларында — 48%, җиңел машиналарда 30% туры килә. Әгәр бартер килешүе күбрәк вакытка озайтылып, товарлар «кәрҗинен» дә күздә тотса, **клиринг** килешүләре турында сүз алып барырга мөмкин. Товарларны кара-каршы китерүне эченә алган башка төрле компенсация килешүләре **офсетлы** килешү дип атала.

Бай-бэк тибындагы компенсация килешүләре җиһазларны кредит шартларында, аны шушы җиһазлар ярдәмендә эшлән-

гән продукция белән каплауга нигезләнгән. **Толлинг** тибы килешүләре чималны чит илдә эшкәртүне һәм аңа җитештерелгән әзер продукциянең бер өлеше белән түләүне күздә тота.

Халыкара сәүдәнең күп төрле методлары бар.

Чит ил кулланучысына товарлар экспортер белән турыдан-туры элемтә кысаларында да, арадашчылар (дилерлар, дистрибьюторлар, комиссионерлар, консигнаторлар, агентлар) аша да килеп керә. Чимал һәм азык-төлек товарларын масса-күләм сатуның бик зур өлеше халыкара товар биржаларында башкарыла.

Дөнья базарларын үстерүдә әһәмиятле роль уйнаганлыктан, биржа сәүдәсен җентеклөбрәк тикшереп үтик. Халыкара биржа сәүдәсенең объектлары сыйфатында 70 ләп төрдәге товарны атап була, алар өлешенә дөньякүләм сәүдәдәге товар әйләнешенең 30% ка кадәре туры килә. Болар — авыл хуҗалыгы, урман, ягулык товарлары, кыйммәтле һәм төсле металлар. Биржа товарының үзенчәлеге — сыйфаты бер үк төрле һәм кайбер аерым берәмлекләрнең бер-берсен алыштыра алуында, чөнки биржада товарлар, билгеле бер стандартлар һәм үрнәкләргә туры китереп, сыйфатны һәм китереп җиткерү срокларын төгәл регламентлаучы махсус конкретлар нигезендә сатыла.

Биржада төп ике төрдәге: реаль товарга һәм сроклы вакыты билгеләнгән (фьючерс) килешүләр төзелә.

> **РЕАЛЬ ТОВАРГА КАРАТА КИЛЕШҮЛӘР** — товарны кичекмәстән, ягъни бер көннән 15 көнгә кадәр (кэш, яки спот килешүе) вакыт эчендә, яки киләчәктә (форвард килешүе) китереп җиткерү турында килешүләр.

Форвард килешүе очрагында реаль товарны контракт төзегән моментта куелган форвард бәясе буенча һәм контрактта билгеләнгән (мәсәлән, 3 айдан соң) вакытка китереп җиткерү карала. Форвард бәясе спот бәясеннән беркадәр аерыла, чөнки базарларда әле булган товар конъюнктурасы киләчәктә китереләсе товарларныкыннан үзгә булырга мөмкин.

СРОКЛЫ (ФЬЮЧЕРС) КИЛЕШҮЛӘР — аларда якларның реаль товарны китерү һәм кабул итү бурычлары күздә тотылмый, ә товарны сату һәм сатып алу хокуклары турында, ягъни фьючерс контрактлары төзелә. Мондый килешүләр нигезендә контрактның аны төзегән көндәге бәясе белән үтәлү көнендәге бәясе аермасын түләү яки кабул итеп алу ята.

Шулай итеп, биржада килешүләр төзүче яклар түбәндәге максатларны алга куеп эшли:

1) реаль товарны сатып алу яки сату;

2) бәяләр аермасы хисабына спекулятив табыш алу;

3) реаль товарга карата форвард килешүләре төзегәндә, базар бәяләре үзгәргән очракта туачак югалтулардан фьючерс килешүе ярдәмендә сакланып калу.

Спекулятив килешүләр һәм югалтулардан саклану килешүләре дөньяның әйдәп баручы товар биржалары операцияләренең төп өлешен алып тора. Мондый саклану **хеджирлау** дип атала.

Хеджирлауга бер мисал карап үтик. Әйтик, фермер өч айдан соң биржада бер партия бодай сатарга тели, ди. Ул биржада бер партия бодайны өч айдан соң сату турында фьючерс контрактының хәзерге бәясе 5000 долл. икәнлеген белешә, һәм бу бәя аны канәгатьләндерә. Шуннан соң фермер биржада агымдагы бәясе буенча фьючерс контракты сата.

Әгәр 3 айдан соң бодай партиясенә бәя 4000 долларга кадәр төшсә, аны сату турындагы фьючерс контракты бәясе дә 4000 долларга калачак. Ул очракта фермер бодаен 4000 долларга сатар, ләкин 1000 долл. зыянны фьючерс позициясендәге табыш, ягъни фермер сатарга мөмкин булган контракт бәясе (5000) һәм хәзерге бәя арасындагы аерма (4000) каплаячак.

Ә инде 3 айдан бер партия бодай бәясе 6000 долларга житә икән, фермер, фьючерс контрактын өзеп, 1000 долл. оттыра, ләкин бодаен базарда сатып, 1000 долл. отачак.

Алда әйтелгәннәр шуны күрсәтә: реаль товар сату турында биржадан тыш контрактлар төзү өчен нигез булып торган дөньякүләм бәяләрне формалаштыру һәм фаразлауда да халыкара биржалар гаять мөһим роль уйный.

Төзелеш хезмәте, билгеле бер техник-икътисади параметрларга ия булган катлаулы һәм кыйммәтле җиһазлар базарында тендер процедуралары (халыкара сатулашу) файдаланыла. Бу заказ аны башкару өчен иң уңайлы шартлар тәкъдим итүче фирмага бирелә.

Биржа товарларыннан аермалы буларак, индивидуаль үзлекләргә ия булган әйберләр (кыйммәтле мех эшләнмәләр, сәнгать әсәрләре һ. б.) халыкара аукционнарда сатыла. Тиз бозыла торган товарлар да (чәчәкләр, җиләк-җимеш, яшелчә, балык) аукцион аша уза. Аукционда сатыла торган товарлар, биржанықыннан аермалы буларак, һәрвакыт булып тора, һәм потенциаль сатып алучылар аларның сыйфатын һәм кулланылыш үзлекләрен бәяли алалар.

Глобальләшү шартларында халыкара сәүдәнең электрон коммерция дип аталучы формасы киңрәк колач ала. Эффектив эшләүче электрон сәүдәгә мисал итеп Лондондагы халыкара нефть биржасында, Нью-Йорк һәм Гонконг фьючерс биржаларында энергия чыганаклары сатуны китерергә мөмкин.

17.3. ТЫШКЫ СӘҮДӘ СӘЯСӘТЕ

Алдарак әйтеп үтелгәнчә, тышкы сәүдәнең үсеше барлык илләр өчен дә отышлы. Әле 1947 елда ук тарифлар һәм сәүдә буенча Генераль килешү төзелә, аның кысаларында бу килешүдә катнашучы илләр арасындагы сөйләшүләр барышында да сәүдә шартлары системалы рәвештә камилләштерелә. Тышкы сәүдәнең ирекле үсешенә ориентлашкан тышкы сәүдә сәясәте «фритредерлык» (ингл. *free trade* — ирекле сәүдә) исеме алган.

Әмма барлык илләр дә экспортны стимуллаштыру, милли һәм региональ базарларны тышкы конкуренциядән саклау өчен күп төрле чаралар комплексы кулланалар. Протекцион тышкы сәүдә сәясәтенең эчтәлеге әнә шуннан гыйбарәт.

Таможня пошлиналары

Протекционлыкның классик коралы булып импортка таможня пошлиналары салу тора.

17-4 нче рәсем. ▷
Импортка таможня пошлиналары кертүнең нәтиҗәләре.

Таможня пошлинасын билгеләү эчке бәяләрнең күтәрелүенә һәм кулланучылар отышының кимүенә китерә, соңгысын дәүләтнең һәм җирле җитештерүчеләрнең кеременәре үсү белән каплап булмый.



ТАМОЖНЯ ПОШЛИНАЛАРЫ — дәүләт тарафыннан илнең чиге аша кертелә торган товарлардан таможня тарифлары нигезендә һәм товарның эшкәртелү дәрәҗәсенә, ул җитештерелгән илгә һәм башка хәлләргә бәйле рәвештә алына торган акча.

17-4 рәсемендә импортка таможня пошлиналар кертүнең нәтиҗәләрен тикшерик.

Биредә S һәм D — X товарына эчке тәкъдим һәм сорау кәкреләре. Дөнья базары бәясе P_w 100 долларга тигез. Таможня пошлиналары булмаса, товар шушы бәя белән импортлана (транспортка, страховкалауга һ. б. булган чыгымнарны исәпләмичә). Ирекле сәүдә шартларында җирле җитештерүчеләр дөнья бәясенә тигез булган бәя куярга тиешләр (товарның сыйфаты шундый ук булганда). Ул вакытта эчке базарда сорау — $O\ D_0$, җирле җитештерүчеләр ягыннан тәкъдим — OS_0, импорт S_0D_0 булыр. Графиктан күренгәнчә, күп кенә сатып алучылар товарны 100 доллардан кыйммәткә дә сатып алырга әзер. Моны сорау кәкресе D күрсәтә. Сатып алучыларның товарны 100 доллардан сатып алуыннан килгән файда (отыш) LBH өчпочмагының мәйданы белән бәяләнә.

Импортка пошлина (20 долл.) кертү бәяне 120 долларга җиткерә. Бу хәл товарга сорауны OD_1 гә кадәр төшерә, кулла-

нучыларның табышын *CBHK* зурлыгында югалта, шулай ук импортны киметә. Нәтиҗәдә товарның эчке бәяләре күтәрелә, җирле җитештерү OS_1 гә кадәр арта. Милли җитештерүчеләр *CBNE* зурлыгында табыш, ә пошлиналардан дәүләт бюджетына кергән керемнәр *EIGK* фигурасының мәйданы белән үлчәнер. Әмма бу кулланучылар файдасына булган кимүне каплый алмый.

Шулай итеп, бер яктан, бәяләр күтәрелү белән бәйле рәвештә, ил югалтулар кичерә. Тышкы конкуренциядән саклау җирле предприятиеләрнең технологик артта калганлыгын бетерми, аларга җитештерү чыгымнарын киметү өчен стимуллар юк. Пошлиналарны саклау халыкара сәүдә үсешенә комачаулый. Бөтендөнья сәүдә оешмасы бәяләмәләре буенча, 1986—1993 елларда дәүләтара сөйләшүләре нигезендә импортка таможня пошлиналарын киметү 1995—2005 елларда дөнья сәүдәсенең 12% ка үсүенә китерәчәк, шул исәптән кием-салым сәүдәсе — 60% ка, текстиль товарлары — 34% ка, авыл хуҗалыгы продукциясе сәүдәсе 20% ка артачак.

Икенче яктан, пошлиналар милли икътисадның яңа тармаклары үсешенә, яңа хезмәт урыннары булдыруга ярдәм итә. Дәүләт таможня салымнарыннан тотрыклы керемнәр ала һәм алар исәбенә халыкның аз керемле төркемнәре тәэмин ителә.

Россиядә импортка пошлиналар уртача Европа тарифларыннан ике тапкыр тирәсе югарырак. Киләчәктә пошлиналар кимергә тиеш, ләкин милли җитештерүнең эффективлыгы артмый икән, пошлина кимегәндә предприятиеләрнең бик күп өлеше банкротлыкка чыгачак, эшсезлек үсәчәк. Дәүләт бюджетында зур югалтулар булачак.

Импортка пошлиналарның бер төре — демпингка каршы пошлиналар. Алар хөкүмәт тарафыннан демпинг белән көрәш максатында билгеләнә.

> ДЕМПИНГ — тышкы базарларда конкурентлык сәләтенә ирешү өчен, экспорт товарларына ясалма рәвештә түбән бәяләр кую ул.

Кайбер илләрдә шулай ук экспорттан да таможня пошлиналары алына. Алар эчке бәяләре дөнья бәяләреннән шактый түбән булган товарларга салына. Мондый пошлиналар эчке базарларга ярдәм итә. Җитештерүчеләрдә үз продукциясен эчке

базарда сатуга кызыксыну арта. Дәүләт бюджетына өстәмә керемнәр керә. Аерым алганда, Россиядә нефть, нефть продуктлары, табигый газ һәм башка товарлар чыгарудан экспорт пошлиналары алына.

Тышкы сәүдә сәясәтенең тарифлы булмаган кораллары

Протекционизм сәясәтендә тарифлы булмаган кораллар — пошлиналар кую белән бәйләнмәгән көйләү алымнары да кулланыла. Импортка квоталар кую, ягъни билгеле бер товарларны читтән кертүнең санын билгеләп куеп та импорт товарын чикләргә мөмкин.

Протекция максатларында дәүләт шулай ук импорт товарларының катгый стандартларга һәм техник шартларга җавап бирүен таләп итә. Мәсәлән, азык-төлек товарларының төргәгендә ризыкның химик составы, консервантларның булу-булмавы, энергетик кыйммәте турында белешмә булырга тиеш. Төргәкләр үзләре утильләштерү вакытында әйләнә-тирәгә зыян китерергә тиеш түгел. Автомобильләрнең тавышланып эшләвенә һәм эшкәртелгән газларындагы зарарлы матдәләр составына катгый чикләүләр куела.

Күп кенә очракларда чит ил җитештерүчеләренә экспортны үз теләге белән чикләүләр дип атала торган көчләп тагу сәясәте дә кулланыла.

Экспортны стимуллаштыру өчен, экспортка бәйле дәүләт субсидияләре экспортлаучыга һәм чит ил сатып алучысына өстенлекле кредитлар, коммерция тәвәккәллеген иминиятләү кебек эшләр дәүләт хисабыннан түләнә.

Протекцияләү чаралары куллану нәтиҗәсендә даими төстә «корыч», «автомобиль», «тавык боты», «шәраб», «сөт» исеме белән сәүдә сугышлары кабынып ала.

Сәүдәне халыкара көйләү

Халыкара сәүдәне барлык илләр дәрәҗәсендә көйләү хезмәтен Бөтендөнья сәүдә оешмасы (БСО, Всемирная торговая организация — ВТО) алып бара, 1995 елдан ул Тарифлар һәм сәүдә буенча Генераль килешү оешмасын алыштырып, аның эшен алып бара. 140 тан артык дәүләт БСО әгъзалары булып тора, һәм алар аның кысаларында 20 ләп килешү шартларында эшләргә әзер.

БСОның төп принциплары — күпьяклы сөйләшүләр нигезендә таможня пошлиналары ставкаларын даими төшерә барып, сәүдәне либеральләштерү, тарифсыз чикләүләрдән баш тарту, сәүдәнең дискриминациясез булуына ирешү, ягъни илләрнең бер-беренә иң мул яшәүче халыклар режимын тәэмин итүе, интеллектуаль милек хезмәте һәм объектлары белән сәүдә итү кагыйдәләрен үтәү.

Хәзерге вакытта Россия БСОга кушылу турында сөйләшүләр алып бара, бу оешма әгъзасы булуның отышлы яклары кызыктырмаслык түгел. Сәүдәдә иң кулай, уңайлы режим алу, халыкара хокук нормаларына күчү һ. б. экспортның үсүенә, валюта резервлары артуга, Россия товарларына карата демпингка каршы процедураларның туктавына, чит ил инвестицияләре үсүгә, импорт пошлиналары төшүгә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, импорт товарларына бәяләр төшүгә китерәчәк. Ә болар үз чиратында кулланучыларның реаль керемнәре үсүгә китерә.

Шул ук вакытта БСОга керү таможня пошлиналары һәм җыемнарыннан килгән бюджет керемнәрен киметә, Россия икътисадының кайбер әһәмиятле секторлары өчен субсидияләрне азайта, импорт товарына пошлиналарны киметү һәм хезмәт күрсәтүләр базарын либеральләштерү нәтиҗәсендә эчке базарда товар һәм хезмәт күрсәтүләргә конкуренцияне үстерә. Ә бу исә Россия икътисадының бик күп тармакларында җитештерүнең кискен кимүен һәм мәшгульлек дәрәҗәсе төшүне китереп чыгарырга мөмкин. Россиянең БСОга керүеннән нинди файда һәм нинди югалтулар булачагы турында фәнни һәм эшлекле даирәләрдә зур бәхәсләр бара.

17.4. ВАЛЮТА БАЗАРЫ

Халыкара исәп-хисап алып бару валюта куллануны күздә тота. Беренчедән, **валюта** — теләсә нинди милли акча берәмлеге (Россия сумы (рубль), Америка доллары, немец маркасы). Икенчедән, «валюта» термины чит илләрнең акча билгеләрен һәм халыкара исәп-хисапта кулланыла торган теге яки бу милли акча берәмлекләрендәге түләү чараларын (акча күчерү кәгазьләре (переводлар), чеклар, вексельләрне) аңлату өчен кулланыла.

Әйтик, Америка фирмасы автомобильләрен Германиягә экспортка чыгара, ди. Немец импортеры аңа долларлар белән түләргә тиеш, чөнки машиналар сатучы долларларда чимал сатып ала, үз эшчеләренә хезмәт хакын, салымнар түли. Шунлыктан импортер немец маркаларын долларларга алмаштыра. Үз чиратында автомобильләр җитештерүче япон роботларын куллана һәм Япониядән китерелгәсе товарны түләп алу өчен иеннарга мохтаҗ. Шунлыктан ул долларын иенга алыштырырга тиеш. Италиягә ялга җыенучы француз туристы, анда товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен, франкларын лираларга алмаштыра. Барлык бу очракларда теге яки бу валютага сорау һәм тәкъдим барлыкка килә, ягъни валюта базары формалаша.

> **ВАЛЮТА БАЗАРЫ** — чит ил валютасын сату-сатып алу барышында туган тотрыклы икътисади һәм оештыру мөнәсәбәтләре системасы ул.

Валюта базары дөньядагы барлык илләрдә дә мәҗбүри кабул ителергә тиешле бердәм акча булмаганлыктан яшәп килә.

Дөньякүләм, региональ һәм милли валюта базарларын аерып йөртәләр. Дөньякүләм валюта базарлары 25 тән артык халыкара финанс үзәкләрендә урнашкан, алар арасында Лондон, Нью-Йорк, Токио, Париж, Цюрих, Франкфурт-Майн, Гонконг, Сингапур, Бахрейн аеруча әһәмияткә ия. Халыкара финанс үзәкләре төрле вакыт поясларында урнашкан, берберсе белән электрон һәм телекоммуникация системалары аша тоташканлыктан, глобаль валюта базары өзлексез эшли.

Халыкара валюта базарында иң әһәмиятле операторлар — банклар, бигрәк тә, чит илләрдә бүлекчәләре булган транснациональ банклар. Алардан тыш, биредә валютаны тышкы икътисади эшчәнлек алып баручы предприятиеләр, дәүләтнең валюта органнары, аерым затлар сатып ала.

Халыкара валюта базары зур масштабларда эшли. Аның агымдагы әйләнеше көненә 1 трлн доллардан артык дип бәяләнә, һәм ул башлыча товар һәм хезмәт күрсәтүләр сату белән түгел, ә финанс алыш-бирешләр үткәрү белән шөгыльләнә.

Региональ валюта базарларында операцияләр шактый ук чикләнгән сандагы билгеле бер валюталар белән алып барыла. Милли валюта базарында шушы ил территориясе чикләрендәге операцияләр башкарыла. Бу базарның иң мөһим үзенчәлеге булып әлеге операцияләрнең шушы ил кануннары нигезендә алып барылуы тора. Милли банкка әле тагын шунысы хас: җирле Үзәк банк, кагыйдә буларак, үз илендә милли валютаның чит илләр валютасына карата рәсми курсын билгеләп куя. Мәсәлән, Россия банкы 2004 елның 19 ноябренә сумга (рубльгә) карата доллар курсын 1 долларга 28,5387 сум нисбәтендә билгеләгән иде.

Россиядә валюта алыш-бирешләренең төп өлеше биржадан тыш банкара һәм биржа аша банкара валюта базарларында алып барыла.

Валюта курсы

Теге яки бу валютага булган сорау һәм тәкъдимнең нисбәте бу валютаның курсын билгели.

> ВАЛЮТА КУРСЫ — бер илдәге акча берәмлеге бәясенең чит илләрнең акча берәмлекләрендә яки халыкара исәп-хисап берәмлекләрендә чагылышы ул.

Валюталарга сорау һәм тәкъдим өзлексез үзгәреп торганлыктан, валюта курсы да тотрыклы түгел. Аны банклар һәм валюта биржасы тарафыннан билгеле бер датада билгеләп тору котировка дип атала. Күпчелек илләрдә *туры котировка* — чит ил валютасы берәмлегенә теге яки бу сандагы милли акча берәмлеген тигезләп кую кулланыла. Мәсәлән, 2004 елның 23 августында Бөекбританиядә АКШ доллары 0,5491 фунт стерлинг дип бәяләнгән. Туры булмаган котировка — милли валюта берәмлеген билгеле бер сандагы чит ил валютасына тигезләү ул. Безнең мисалда Бөекбританиядә илнең милли валютасы фунт стерлинг 1,8210 АКШ долларына тигезләнгән.

Кайбер илләрдә валюта курсын хөкүмәт тарафыннан билгеләп кую кулланыла, һәм бу курслар төрле тышкы икътисади операцияләр өчен төрлечә булырга мөмкин. Күп кенә очракларда бу хәл «кара» базарда валюталарның параллель котировкасын тудыра.

Валютага котировка ясап, банклар аны сату һәм сатып алу курсларын күрсәтәләр. Валютаны сату һәм сатып алу бәяләре аермасы хисабына банклар үзләренең операция чыгымнарын каплый һәм табыш ясый.

Валюта операцияләре арасында валюта алыш-бирешләре иң күп туры килә торган бик мөһим төре — спот алыш-бирешләре (аларны касса хезмәте дип тә атыйлар). Спот алыш-бирешләре ярдәмендә банклар, мәсәлән, экспортерларның һәм импортерларның ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр. Мондый алыш-бирешләр буенча валюта сатып алучыга алыш-бирешкә кул куйганның икенче эш көнендә кул куелган көн бәясе белән тапшырыла. Россиядә валюта еш кына шул ук көнне яисә «иртәгесе»н җибәрелә. Ләкин мондый алыш-бирешләрнең база курсы булып спот курсы тора.

Икенче төр алыш-бирешләр — вакыты билгеләнгән (форвард) алыш-бирешләр дип йөртелә, бу очракта валюта алыш-бирешкә кул куйган көн курсы белән билгеле бер вакыттан соң (гадәттә 1, 2, 3, 6, 12 ай) җибәрелә. Бу алыш-бирешләр курс аермалары хисабына спекулятив табыш алу һәм курсларның начар якка үзгәрү куркынычыннан саклау өчен эшләнә. Шунысын искәртик: форвард килешүдә валютага споттагыга караганда кыйммәтрәк (премия белән) яки арзанрак (дисконт белән) котировка ясала. Премия белән дисконт арасындагы аерма төрле илләрдәге кертемнәр буенча процент ставкалары аермасына бәйле. Әгәр А илендә процент ставкалары Б илендәгегә караганда югарырак икән, А илендәге банк валютаны вакытын билгеләп сатканда, аны җибәрү вакытына кадәр процентлар белән күбрәк керем алып өлгерә. Шунлыктан ул аны ташламалар ясап сатарга риза, чөнки процентлан килгән керем югалтуларны каплый.

Форвард алыш-бирешенең спекулятив табыш алу максатында эшләнгән очрагын алып карыйк. Спекулянт Америка долларының спот курсы 12 ай эчендә 1 долларга 0,816 евродан 0,850 еврога кадәр үсәр дип фаразлый. Аның фаразы туры килә дип уйлыйк һәм табышын исәплик. 12 айга форвард курсы 1 долларга 0,810 евро, ягъни евро дисконт белән котировкалана.

Бу очракта спекулянт 12 айдан 0,810 еврога 1 доллар курсы белән долларлар сатып алу турында вакыты билгеләнгән килешү төзи, ә бер елдан, долларларны шушы бәягә сатып

алып, 0,850 шәр евродан сата. Аның табышы — һәр долларга 0,04 (0,850—0,810) евро.

Күтәрелүгә уйнаучы спекулянтлар («үгезләр») үзләре форвард алыш-биреш кысаларында сатып алган валютаның курсы күпмедер вакыттан соң күтәрелер дип көтәләр. Шунлыктан, үзләренә форвард контрактында әйтелгән түбән бәяләрдән валюта килеп ирешкәч, алар аны спот базарында табыш белән сатуга исәп тоталар.

Түбәнәюгә уйнаучы спекулянтлар («аюлар») алар форвард контракты белән саткан валютаның курсы кайчандыр төшәчәк дип көтә. Алар уенча, сатып алучыга контракттагы валютаны җибәрү алдыннан гына спот базарында аны арзанга сатып алырга һәм форвард контрактындагы югары бәя белән сатарга мөмкин.

Форвард операцияләре валюта тәвәккәллеген иминиятләр өчен дә кулланыла. Әйтик, фирма чит илдән, түләүне 3 айга кичектереп, кредитка җиһазлар ала, ди. Аның валюта тәвәккәллеге — өч айдан соң түләнергә тиешле чит ил валютасы кыйммәтләнә һәм хәзергә караганда күпкә артык итеп милли валюта бирергә туры киләчәк дигән сүз. Бу очракта кредит килешүе төзегән көнне үк банк белән аңа өч айдан чит ил валютасын бүгенге форвард курсы белән алу турында форвард контракты төзү отышлы булачак.

Валюта курсы үзгәрешләре белән кызыксынучылар валюта спекулянтлары гына түгел. Хуҗабикә өчен милли валюта курсы төшү — чит илдән китерелгән азык-төлек, кер юу порошогы, кием-салым һәм башка товарлар кыйммәтләнә дигән сүз. 50 долларлык Америка джинсылары 1 долл. = 20 сум курсы буенча 1000 сум торса (импорт пошлиналарын һәм салымнарны исәпләмичә), 1 долл. = 25 сум курсы буенча инде 1250 сум торачак.

Импорт чималын куллана торган Россия предприятиеләре өчен рубль курсының төшүе — чималның кыйммәтләнүен, димәк, әзер продукция бәясенең дә артуын аңлата. Ә бу исә әлеге продукциягә сорауны киметергә мөмкин.

Аның каравы рубль курсы төшү экспортерлар өчен отышлы, чөнки чит илдә аларның продукциясе конкуренциягә сәләтле була башлый. Доллар курсы 1 долл. = 20 сум булганда, 10 сумлык Россия товары дөнья базарында 0,5 долл., ә 1 долл. = 25 сум булганда, 0,4 долл. торачак. Курс төшү

шундый ук продукция эшләп чыгара торган чит ил җитештерүчеләре белән ярышучы предприятиеләр өчен файдалы.

Шулай итеп, валюта курсы илнең халыкара хезмәт бүленешендә катнашуы эффективмы-түгелме икәнен бәяләүдә мөһим роль уйный. Милли чыгымнар һәм бәяләр башка илләрдәге шундый ук күрсәткечләр белән аның нигезендә чагыштырып карала. Җитештерүчеләр кайсы базарда — милли базардамы, халыкара базардамы — чимал сатып алу һәм товар сату яхшырак икәнен билгели. Инвесторлар ирекле акчаларын (средстволарын) кайда — үз илендәме, әллә чит илдәме урнаштыру кулай икәнен хәл итә.

Валюта курслары ни өчен үзгәрә

Валюта курслары үзгәрүнең төп сәбәпләрен карап үтик. Барыннан да элек, курсның динамикасы валюталарның сатып алу сәләте үзгәрешләре, ягъни эчке базарларда бер үк товар «кәрзиннәре» бәяләре нисбәтләрендәге тайпылышлар белән билгеләнә.

Әйтик, бер долларның курсы 0,75 евро һәм бу очракта товарлар кәрзине ролен үтәүче компьютер бәясе — АКШта 1000 долл., ә Германиядә 750 евро булсын.

Әгәр Германиядә компьютерлар 800 еврога кадәр кыйммәтләнсә, аларны АКШтан Германиягә экспортлау файдалы булачак, чөнки 0,75 евро = 1 долл. курсы буенча компьютерны Германиядә 800 еврога сатарга һәм акчаны 1066 долларга әйләндерергә мөмкин. Транспорт һәм башка чыгымнарны исәпләмәгәндә, табыш 66 долл. булачак.

Ә бу АКШта компьютерлар сатып алу өчен долларга сорауны арттыра, һәм доллар курсы, мәсәлән, 0,85 еврога җитә. Тик бу очракта инде компьютерларны Германиядән экспортлау файдалырак, чөнки аларны анда 800 еврога сатып алып, АКШта 1000 долларга сатканда, бу долларны 850 еврога әйләндерергә һәм һәр алыш-биреш өчен 50 евро файда ясарга мөмкин. Хәзер инде Германиядә компьютерлар сатып алу өчен еврога сорау һәм аның долларга карата курсы арта башлый. Валюта базарында тигезләнеш, мөгаен, бер долларга 0,80 евро булган очракта урнашыр. Әлеге курс АКШта һәм Германиядә компьютер бәяләренең яңа нисбәтен чагылдырачак.

Мондый тигезләү механизмы һәрвакыт һәм барлык товарлар өчен дә эшләми, ләкин охшаш кулланy «кәрзиннәре»нең

бәяләрен күздә тотып, валюталарның сатып алу сәләте паритетын исәпләп табарга мөмкин.

Шулай итеп, валюта курсы илдәге инфляция темпларына бәйле дигән нәтиҗә ясый алабыз. Башка шартлар бертөрле булганда эчке бәяләрнең үсүе валюта курсының төшүенә китерә.

Курсның динамикасы илнең экспорт һәм импорт динамикасындагы үзгәрешләр белән билгеләнә. Мәсәлән, экспорт күбрәк булган саен, бу экспортны түләп алу өчен чит илләрдә шушы ил валютасына сорау арта һәм валюта курсы да үсә. Импорт үсеше, халыкның үсә баручы керемнәре нәтиҗәсе буларак, импортны түләп алуга кирәкле чит ил валютасына сорауны арттыра, милли валютаның дәрәҗәсе төшә.

Ләкин, импорт товарының бәяләренә карап, сорауның сыгылмалы булуын да истән чыгармаска кирәк. Әгәр доллар курсы 0,75 тән 0,80 еврога үсә икән, АКШта 133 долл. торган 100 евролык Германия товары 125 долларга кадәр арзаная. Товарга бәясе буенча сыгылмалы сорау булганда, бу хәл еврога алыштыру өчен долларга тәкъдим артуны һәм еврога карата доллар курсы төшүне стимуллаштыра. Ә инде товарга сорау бәя буенча сыгылмалы түгел һәм, әйтик, атнага 100 дән алып 105 данә генә икән, немец экспортерының сату кереме атнага 13 300 (133 × 100) доллардан 13 125 (125 × 105) долларга кадәр кими, һәм бу еврога сорау түбәнәюгә, аның долларга карата курсы төшүгә китерә.

Валюта курсын билгели торган тагын бер мөһим фактор — процент ставкаларындагы аермалыклар. Әгәр вклад буенча керем долларларда елына 6%, ә япон иеннарында 5% еллык икән, иеннарның хуҗалары аларны долларга алыштырырга һәм Америка банкында сакларга тырышачак. Бу — долларга сорауны һәм иенга карата доллар курсын арттыра. Мәсәлән, әгәр АКШ банкы иеннарда 5% еллык белән ссуда алып, аны долларга алыштырса һәм 6% еллык белән счетка урнаштыра икән, аның өстәмә кереме елына 1% булачак. Түләү вакыты җиткәч, доллар иеннарга сатылачак. Мондый процедура **валюталы-процентлы арбитраж** дип атала.

Ставкалар үзгәрү үз чиратында монетар факторлар тәэсире нәтиҗәсе булып тора. **Монетар караш** процент ставкалары акчага сорау һәм тәкъдимнең балансланy барышында үзгәрә дип өйрәтә. Без инде алдарак акчага тәкъдимне Үзәк банк

билгеләвен, ә аңа сорау реаль керемнәргә, бәяләр дәрәҗәсенә туры, ә процент ставкаларына кире пропорциональ бәйләнештә булуын күреп узган идек. Ставкалар югарырак булган саен, байлыкларны керем китерә торган кыйммәтле кәгазьләрдә саклау кулайрак. Бирелгән реаль керем һәм бәяләрдә тигезләнеш ставкасы акчага сорау һәм тәкъдим кәкреләре кисешкән урында билгеләнә. Акча тәкъдиме арту һәм ставкалар киму чит илдә депозитка урнаштыру өчен чит ил валютасына сорауны арттыра, ягъни капиталның читкә чыгуына, милли валютаның бәясе төшүгә китерә.

Валюта курсына акчалы кешеләрнең киләчәктә курсның динамикасына карата өметләре дә йогынты ясый. Алар көчсезләнгән валютадан, арзанаер дип уйлап, котылырга тырышалар. Нәтиҗәдә мондый ышанычсыз валютаның хәле, аңа сорау һәм тәкъдим үзгәрү аркасында, тагын да начарая. Шулай итеп, валютага ышану дәрәҗәсе, аның халыкара статусы бик зур роль уйный.

Валюта сәясәте

ВАЛЮТА СӘЯСӘТЕ — валюта мөнәсәбәтләрен көйләү өлкәсендә дәүләт органнары, үзәк банк учреждениеләре, халыкара финанс оешмалары тарафыннан кабул ителә торган икътисади, хокукый һәм оештыру чаралары җыелмасы ул.

Юридик яктан валюта сәясәте тиндәшле закон актлары белән формалаштырып куела (мәсәлән, Россиядә РФның «Валюта көйләнеше һәм валютаны тикшерү турында»гы законы). Дәүләтара дәрәҗәдә валюта проблемалары буенча ике- һәм күпьяклы килешүләр төзелә.

Агымдагы һәм озак вакытлы валюта сәясәтләрен аерып йөртәләр. Агымдагы сәясәт кысаларында, мәсәлән, илдәге валюта курсын һәм валюта базарын тулысынча оператив көйләү тормышка ашырыла. Бөтендөнья валюта системасын камилләштерүгә юнәлтелгән чаралар җыелмасы (халыкара исәп-хисаплар тәртибен, валюта курсын билгеләү алымнарын үзгәртү, халыкара валюта-кредит оешмаларының эшчәнлегендә регламентлар кую) озак вакытлы валюта сәясәтендә каралырга тиеш.

Гамәлгә ашыру формаларына карап, дисконтлы һәм девизлы сәясәтләр аерып йөртелә. **Дисконтлы сәясәт** процент ставкаларын көйләүгә юнәлтелә, белгәнебезчә, валюта курсын шактый ук дәрәҗәдә алар билгели. **Девизлы сәясәт** — валюта курсын көйләү. Бу вакытта билгеләп куелган, ирекле йөзүчән һәм нәрсәгәдер бәйле курсларны аерып йөртәләр.

Билгеләп куелган курсларны тотып тору валюта интервенцияләре белән тәэмин ителә.

> ВАЛЮТА ИНТЕРВЕНЦИЯЛӘРЕ — Үзәк банкның милли валюта курсын тотып тору өчен чит ил валютасын сату-алу буенча эшчәнлеге ул.

Валюта интервенцияләре курс ясаучы фундаменталь фактор үзгәреп беткәнче дәвам ителергә мөмкин. Ул чагында валюта интервенцияләре валюта резервысының кискен кыскаруына китерә һәм валюта девальвациясе яки ревальвациясе үткәрү таләп ителә.

> ВАЛЮТА ДЕВАЛЬВАЦИЯСЕ — милли валютаның курсын чит ил валюталарына карата рәсми рәвештә төшерү ул.

> ВАЛЮТА РЕВАЛЬВАЦИЯСЕ — милли валютаның курсын чит ил валюталарына карата рәсми рәвештә күтәрү ул.

Ирекле йөзүчән курслар базар көчләре белән билгеләнә. Аларны билгеләүнең күп кенә өстенлекләре бар. Инфляция шартларында курслар туктатылган очракта *А* иленең халкы *Б* иленнән арзанлырак товарлар сатып алырга тырыша. Бу *А* илендә — җитештерүнең төшүен эшсезлек, ә *Б* илендә кирәгеннән зур сорау (инфляция экспорты) арасында инфляция китереп чыгарырга мөмкин. Гамәлдә ирекле йөзүчән курслар булса, *Б* илендә товарларга сорауның үсүе автоматик рәвештә аның валютасы курсы үсешен, А иле халкы өчен бу товарларның кыйммәтләнүен һәм *Б* иле товарларына сорауның кимүен китереп чыгара. Валюта режимы болай автоматик төстә үзгәрә алганда, Үзәк банкка аның курсын

валюта интервенцияләре ярдәмендә тотып тору кирәкми. Икенче яктан, туктатылган (билгеләп куелган) курслар еш кына инфляциягә каршы чара (якорь) буларак кулланыла, чөнки валюта бәясе төшү импорт бәяләре үсешен китереп чыгара.

Идарә ителүле йөзүчән курслар сәясәте курска даими рәвештә валюта интервенцияләре юлы белән йогынты ясауны күздә тота.

Хәзерге вакытта Халыкара валюта фондына кергән илләрнең яртысында диярлек валюта курсы — ирекле йөзүчән, 20%ында — билгеләп куелган, калган илләр идарә ителүле йөзүчән валюта курсларын һәм катнаш валюта режимнарын куллана.

Валюта сәясәтенең коралы — валюта чикләүләре.

> ВАЛЮТА ЧИКЛӘҮЛӘРЕ — валюта курсын тотып тору һәм башка максатлар өчен милли һәм чит ил валютасы белән барган операцияләргә регламент урнаштыру чаралары ул.

Мәсәлән, чит ил валютасының җитешмәве түбәндәге чараларны күздә тота: аның белән барган операцияләрне үзәкләштерү, чит ил валютасы алганда импортерга рөхсәтнамәләр бирү, валюталарның кайтмалыгын (алыштырыла алуын) чикләү, экспорттан килгән валюталардагы сату керемен тулысы белән яисә өлешчә Үзәк банкка яки ҮБның валюта лицензиясен алган коммерция банкларына сату, күп төрле валюта курслары билгеләү һ. б. Нәтиҗәдә чит ил валютасына тәкъдим үсә һәм бу милли валюта курсы төшүне туктатып тора.

Россиядә валюта чикләүләре дәрәҗәсе «Валюта көйләнеше һәм валютаны тикшерү турындагы Федераль закон (2004 ел редакциясе) нормалары белән билгеләнә. Бу Законның әлеге редакциясенә валюта бәйләнешләре сферасын шактый ук либеральләштерү хас. Бу бигрәк тә ОЭСР әгъзалары булган дәүләтләр территориясендәге чит ил банкларында резидентлар тарафыннан счетлар ачуга, РФ резидентларының чит ил кыйммәтле кәгазьләре белән операцияләрне һәм исәп-хисапны чит ил валютасында үткәрә алуларына кагыла. 2007 елның 1 гыйнварыннан валютадагы сату кеременең бер өлешен

мәҗбүри сату, резидентларның чит ил банкларындагы үз счетларына акча күчерүенә чикләүләр, аларның эчке базарда валюта сатып алуына чикләүләр һ. б. бетереләчәк.

Валюта проблемалары буенча дәүләтләр арасындагы килешүләр халыкара түләү средстволарының статусын билгеләү, валюта паритетлары режимын, ягъни валюталарның үзара үлчәнешлелеген билгеләү, валюта курсларын формалаштыру принципларын эшләү кебек төп мәсьәләләргә кагыла. Бу килешүләр шулай ук валюталарның үзара кайтмалыгы шартлары, дөньякүләм валюта базарлары һәм алтын базарының кагыйдәләре, валюта бәйләнешләрен дәүләтара көйләүне тормышка ашыручы халыкара оешмаларның статусы турында да алып барыла.

Дөньякүләм валюта системасы

Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрнең барысы буенча да килешүләр нәтиҗәсендә дөньякүләм валюта системасы барлыкка килә. Аны формалаштыруның беренчел нигезе милли валюта системалары булган. Аларның үзара бәйләнеше 1867 елда Париж конференциясендә беркетелгән.

Алтын монеталы стандарт исеме алган Париж валюта системасының төп үзенчәлекләре түбәндәгеләр:

1) алтын монеталарның һәм банкнотларның параллель әйләнеше;

2) билгеле бер курс буенча банкнотның алтынга алыштырылуы һәм валюталарның, анда алтын күпме булуына карап, алтын паритетларын урнаштыру;

3) алтынны илгә ирекле кертү һәм чыгару.

Бу стандарт шартларында исәп-хисап барышын бер мисалда карап үтик. Америка фирмасы Бөекбританиядән 10 ф. ст. торучы йон сатып ала. Долларда алтын микъдары $\frac{1}{20}$ троя унциясенә тигез, фунт стерлингта — $\frac{1}{4}$ троя унциясе, ягъни 1 долл. = 0,2 ф. ст. Фирма 50 долларны фунтларга алыштыра һәм товар өчен 10 ф. ст. түли. Әгәр инглиз товарларына сорау артса, фунтларга да сорау арта, ә доллар курсы төшәчәк, әйтик, 0,1 ф. ст. 1 долларга тигезләшә, ди. Ул вакытта йон өчен 100 долл. түләргә туры киләчәк. Моннан котылу өчен, фирма АКШта унциясе 20 шәр доллардан алтын сатып ала

(чөнки банкнотлар алтынга билгеле бер курс буенча алыштырыла), аны Англиягә җибәрә һәм унциясен 4 әр ф. стерлингтан сата, ягъни фунтларны ул 1 долл. = 0,2 ф. ст. курсыннан ала. Димәк, ул элеккечә үк товары өчен 50 долл. түли.

Шулай итеп, алтын монеталы стандарт валюталар курсының үзеннән-үзе көйләнүен тәэмин итә. Мәсәлән, доллар курсының төшүе Англиягә алтын алып чыгуның үсешенә, АКШның алтын резервлары кимүгә, бу илдә алтын акчалар саны азаюга, товарларга үз илендә сорау кимүгә, бәяләр төшүгә һәм процент ставкалары күтәрелүгә илтә. Ә болар нәтиҗәсендә долларның курсы үсә башлаячак.

Алтын монеталы стандартның өстенлекләре, шул рәвешле, аның җитештерүне һәм халыкара исәп-хисапны көйләүче ролен уйнавында була. Әмма алтын стандарт ил эчендә акча массасының алтын микъдарына бәйлелеген тудыра һәм автоном рәвештә финанс сәясәте алып баруны кыенлаштырган. Дәүләт чыгымнарын (бигрәк тә сугыш чыгымнарын) финанслау өчен алтын запаслары югалуга китергән. Нәтиҗәдә Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Европа илләре алтын стандарттан баш тарталар. Аннан соңгы елларда халыкара түләүләр системасы гаять дәрәҗәдә тотрыксыз була.

Бреттон-Вуд валюта системасы

1944 елда БМОның Бреттон-Вуд шәһәрендә (АКШ, Нью-Хемпшир штаты) узган валюта-финанс конференциясендә халыкара зур килешү нигезендә Бреттон-Вуд валюта системасы формалаштырыла. Ул түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) халыкара акча сыйфатында алтын һәм резерв валюталар (доллар һәм фунт стерлинг) кабул ителә. АКШ доллары валюта кыйммәте эталоны буларак алтынга тигезләнә һәм рәсми бәясе буенча алтынга алмаштырыла ала (1 троя унциясе өчен 35 доллар);

2) валюта курслары рәсми валюта паритетлары базасында билгеләп куеп кабул ителә, ягъни валюталарның нисбәтләре закон тәртибендә билгеләнә;

3) дәүләтләр курслар тирбәлешен валюта интервенцияләре юлы белән төзәтергә йөкләмә алалар;

4) валюта бәйләнешләрен дәүләтләр арасында көйләү институты — Халыкара валюта фонды төзелә. Бу — БМОның

махсус, дөньякүләм сәүдә һәм халыкара исәп-хисаплар үсешенә ярдәм итү органы. Аның озак вакытлар буе иң әһәмиятле функциясе булып валюта интервенцияләре өчен валюта резервын тулыландыруга мохтаҗ илләрнең үзәк банкларына заем бирү тора.

Бреттон-Вуд системасы Икенче бөтендөнья сугышы ахырына АКШның чагыштыргысыз икътисади өстенлеген чагылдыра. АКШка капиталистик дөньяның 75% алтын запасы экспортының $\frac{1}{3}$ е, сәнәгать җитештерүенең $\frac{2}{3}$ се туры килә. Чирек гасыр буена Бреттон-Вуд системасы килешү буенча билгеләнгән курслар системасы җитештерүнең һәм дөньякүләм сәүдәнең кызу темплар белән үсешенә ярдәм итә. Әмма Көнбатыш Европа илләре һәм Японияиең АКШтан калышуы кимү, долларның инфляция нәтиҗәсендә арзанаюы, чит ил банкларында долларның артык күплеге Бреттон-Вуд системасының кризисын тудыра. Ул долларны алтынга алыштыруның кимүендә, доллар девальвациясендә, күп кенә башка валюталар ревальвациясендә һәм валютаның билгеләнгән курсларыннан йөзүчән курсларга күчүдә ачык ачыла. Халыкара яңа валюта системасы элементлары 1976 елда эшләнеп бетә. Алар ХВФка кергән илләрнең Кингстон (Ямайка) шәһәрендәге килешүендә рәсмиләштерелә.

Ямайка валюта системасы

Ямайка валюта системасы түбәндәге төп принципларга нигезләнә:

1) алтынның рәсми бәяләре һәм валюталарның алтын паритетлары гамәлдән чыгарыла, димәк, алтын монета булудан туктый;

2) валюталарның билгеләнгән курслары гамәлдән чыгарыла. Илләр йөзүчән яки башка валюталарга бәйле валюта курсларын саклау хокукы ала, ә үзәк банклар валюта курсларына ярдәм йөзеннән валюта интервенциясе үткәрергә мәҗбүр ителми;

3) ХВФ функцияләре, валюта көйләнеше институты буларак, формаларын үзгәртә.

Хәзерге валюта системасының мөһим үзенчәлеге — валюта чикләүләрен йомшарту һәм валюталарның җитәрлек кадәр

югары дәрәҗәдә алыштырылуына ирешүдә. Валютаның алыштырылуы аны башка валютага алмаштыру мөмкинлеген күздә тота. Тышкы һәм эчке, тулысынча һәм өлешчә алыштыру аерылып йөртелә. Валютаның тышкы алыштырылуы — бу валюта белән алыш-биреш бары тик чит ил кешеләренә генә рөхсәт ителә дигән сүз (мәсәлән, табышны һәм капиталны репатриацияләү өчен). Эчке алыштырылу — мондый валюта белән алыш-биреш бары тик бу илнең юридик затларына (мәсәлән, импорт контрактын түләп алу өчен) һәм шушы ил гражданнарына (мәсәлән, туристик сәяхәт өчен чит ил валютасы сатып алу өчен) гына рөхсәт ителә. Өлешчә алыштырылу — валюта алыштыру кайбер операцияләр үткәрү өчен генә (мәсәлән, тышкы сәүдә, чит илгә капиталдан алынган керемнәрне күчерү белән бәйле) мөмкин дигәнне аңлата.

Валютаның тулы алыштырылуы — бу илнең һәм башка илләрнең физик һәм юридик затлары бу ил валютасы белән теләсә нинди операцияләр үткәрергә мөмкин, мәсәлән, чит ил кешеләренә кредитлар бирү, чит ил фирмаларының акцияләрен сатып алу, күчемсез милек алу һ. б. АКШ, Көнбатыш Европа илләре, Япония, Канада, Яңа Зеландия, Согуд Гарәбстаны һәм кайбер башка илләрнең валюталары тулысынча алыштырыла.

Россия, 1992 елда ХВФка әгъза булып кереп, хәзерге заман халыкара валюта системасында тулы хокуклы катнаша. Россия рубле өлешчә алыштырыла, идарә итүле йөзүчән курска ия. Рубльне ирекле алыштырыла торган валютага әйләндерү хәзерге вакытта капитал катнашында бары тик Үзәк банк рөхсәте белән генә үткәрелә торган операцияләрне либераллаштыруны күздә тота. Шул ук вакытта моның төп максаты — илдә хуҗалык итүнең заманча тармак структуралы, инфляциясе түбән, банк системасы нык үскән, алтын-валюта резервлары тулы булган тотрыклы икътисад булдыру.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Бөтендөнья хуҗалыгы — аерым илләрнең үзара халыкара икътисади мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән икътисадлары җыелмасы ул. Ул халыкара хезмәт бүленешенә нигезләнә.

Милли икътисадның ачыклыгы дәрәҗәсен аның халыкара хезмәт бүленешендә катнашу масштаблары билгели. Дөнья хуҗалыгы үсешенең хәзерге заман этабы милли икътисадлар ачыклыгының бик тиз үсүе белән характерлана.

Бөтендөнья хуҗалыгына 200 дән артык ил һәм территория керә, алар, икътисади мөмкинлекләрен, икътисади үсеш дәрәҗәсен, тышкы сәүдә характеристикаларын һ. б. исәпкә алып, төрле критерийлар буенча классификацияләнә. Дөнья хуҗалыгында индустриаль илләр, үсеп килүче илләр һәм күчеш икътисады илләре дәүләтләрнең төп өч төркемен төзи.

Халыкара икътисади мөнәсәбәтләр системасының бик әһәмиятле элементы булып халыкара сәүдә тора. Товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең тышкы сәүдә агымы юнәлешләре һәм илләрнең дөнья сәүдәсендә катнашудан алган отышлары абсолют һәм чагыштырма өстенлекләр белән билгеләнә. Дөньядагы дәүләтләр алып барган актив тышкы сәүдә сәясәте яки тышкы сәүдәнең ирекле үсешенә (фритредерлык), яки экспортны стимуллаштыру һәм милли базарны тышкы конкуренциядән саклауга (протекцияләр сәясәте) юнәлтелгән.

Халыкара исәп-хисапка валюта базары арадашлык итә. Валюта базарын күп төрле операцияләр билгели: спот, форвард һ. б. Валюта базарында милли валюта курслары эшләнә, курсларның үзгәрешләре исә валютаның сатып алучанлыгы динамикасына, экспорт һәм импорт күләменә, процент ставкаларындагы аерымлыкларга һ. б. бәйләнгән. Дәүләт, агымдагы һәм озак вакытлы валюта сәясәте алып барып, валюта курсларына йогынты ясый.

Валюта проблемалары буенча дәүләтара килешүләр нәтиҗәсендә дөньякүләм валюта системасы барлыкка килә. Хәзерге валюта системасы курслар формалаштыруның төрле режимнары, валюта чикләүләренең йомшаклыгы белән характерлана.

Контроль сораулар һәм биремнәр

1. *А* иле ресурслар берәмлегенә — 1 т бодай яки 100 капчык кофе, *Б* иле 3 т бодай яки 200 капчык кофе җитештерә ала. Кайсы ил бодай экспортеры булыр? Илләрнең специальләшүе нәтиҗәсендә бодай һәм кофе җитештерү артымы нинди булачак?

2. Халыкара товар биржасында форвард һәм фьючерс алыш-бирешләре нәрсә белән аерыла?
3. Чит ил автомобильләренә таможня пошлиналарын арттыруның нәрсә бирәчәген бәяләгез: Волга автомобиль заводы өчен; бай гаилә өчен; уртача гаилә өчен; дәүләт бюджеты өчен.
4. Милли валюта курсы төшү илнең экспорт һәм импорт күләмнәренә нинди йогынты ясый?

18 нче бүлек

КАПИТАЛЛАРНЫҢ ХАЛЫКАРА ХӘРӘКӘТЕ. ТҮЛӘҮ БАЛАНСЫ. ИКЪТИСАДИ ИНТЕГРАЦИЯ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җавап табарсыз:

- капиталларның илләр арасында хәрәкәте нинди формаларда бара;
- халыкара ссуда капиталлары базарының структурасы нинди;
- эшмәкәрлек капиталын кертүче һәм чыгаручы илләр өчен экспортның әһәмияте нидән гыйбарәт;
- нәрсә ул илнең түләү балансы һәм аның структурасы нинди;
- халыкара икътисади интеграция нинди формаларда тормышка ашырыла һәм интеграцион төркемчәләрдә катнашучы илләргә ул нинди файда бирә.

Алдагы бүлектә без илләр арасында товар хәрәкәтен карадык, ә товар житештерү факторларының үзләрен, һәм барыннан да элек, капитал күчерү мөмкинлегенә әлегәчә игътибар ителмәде. Капиталы кирәгеннән дә артык булган ил капитал сыйдырышлы товарлар экспортлау белән туктап калмый. Чит илләргә капиталның үзен чыгару да керем китерергә мөмкин. Илләр арасында капитал хәрәкәте белән бәйләнгән кредит һәм финанс операцияләре халыкара икътисади мөнәсәбәтләрдә әһәмиятле урын алып тора. Алар елына триллионлаган доллар белән бәяләнә һәм дөньякүләм сәүдә әйләнешеннән күпкә артып китә. Мәсәлән, әгәр АКШның 2000 елда барлык тышкы сәүдә әйләнеше 2030 млрд долл. булса, чит илләрдәге

Америка активлары 2800 млрд доллардан, ә АКШта чит ил активлары 3500 млрд доллардан артык булган.

Капитал катнашындагы операцияләрне дә кертеп, илнең барлык тышкы икътисади операцияләрен исәпкә алу аның түләү балансында гамәлгә ашырыла.

18.1. КАПИТАЛЛАРНЫҢ ХАЛЫКАРА ХӘРӘКӘТЕ

Капиталларның халыкара хәрәкәтенә чит илләргә кредитлар, акцияләр өчен кертем рәвешендә средстволар, башка төрле кыйммәтле кәгазьләр алып чыгу, керем алу максатында күчемсез милек сатып алу һ. б. керә.

Капиталны читкә чыгару формалары күптөрле. Ул ссуда яки эшмәкәрлек формасында, кыска яки озак вакытка, шәхси компанияләр, банклар, рәсми кредитлар (дәүләтләрнең финанс учреждениеләре һәм халыкара финанс оешмалары) тарафыннан экспортланырга мөмкин.

Ссуда капиталларының халыкара базары

Илләрнең халыкара кредит мөнәсәбәтләренә торган саен күбрәк катнашуы ссуда капиталларының халыкара базары оештырылуга сәбәп була.

Ссуда капиталларының халыкара базары кыска сроклы капиталлар базары (акча базары) белән уртача һәм озак сроклы ссуда капиталлары базарыннан (капиталлар базары) тора.

Акча базарында чит ил хөкүмәтләренә һәм фирмаларына кыска сроклы (бер елга кадәр) банк ссудалары, кыска сроклы заемнар һәм казначылык яки коммерция вексельләре исәбеннән кредитлар бирелә.

Капиталлар базарын 10 елга кадәр срокка халыкара банк кредитлары, шулай ук хөкүмәтләр һәм шәхси корпорацияләр чыгарган кыйммәтле кәгазьләр исәбенә бирелә торган заемнар тәшкил итә.

Формасы буенча коммерция кредитларын (тышкы сәүдәдә куллану өчен) һәм башка максатларны күздә тотучы финанс кредитларын аерып йөртәләр. Кредитларны шулай ук товар (экспортерның үз сатып алучысына түләүне кичектерү рәве-

шендә бирә торган ссудасы) һәм валюта (банклар тарафыннан акча формасында бирелә) кредитларына бүләргә мөмкин.

Кулланылышы буенча халыкара кредитлар бәйле һәм бәйсез булырга мөмкин. Бәйле кредитлар максатчан характерда була һәм кредит килешүендә күрсәтелгән товарларны финанслау өчен кулланыла. Бәйсез кредитлар гадәттә тышкы бурычны тәртипкә китерү, валюта интервенцияләре, кыйммәтле кәгазьләрдә инвестицияләр һәм ил үзе мөстәкыйль хәл итә торган башка максатларга тотыла.

Кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясен һәм алар белән икенчел базардагы операцияләрне кайвакыт ссуда капиталларының халыкара базарында аерым сегментка бүлеп чыгаралар, ул **финанс базары** дип йөртелә. Ләкин бик киң кулланып килүче секьюритлаштыру (*securities* (англ.) — кыйммәтле кәгазьләр), ягъни банк кредитларын заемщикның кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе белән бирүе һәм шуның нәтиҗәсендә чыгарылма финанс кораллары барлыкка килү, шулай ук, кыска сроклы кредитларны озайтып, озак сроклыга үзгәртү кредит һәм финанс базарларының якынаюына китерә.

Урта һәм озак сроклы халыкара эре кредитларның һәм заемнарның бик зур өлеше синдикатлашканга керә, ягъни аларны банклар төркеме (синдикаты) бирә. Синдикатлар үзләре, чит ил заемщикларына бик зур кредитлар бирү өчен, еш кына бер банкның гына ресурслары җитмәү аркасында барлыкка киләләр. Синдикатлашкан кредитларның 2000 елда барлык заемщиклардагы гомуми бөясе 964 млрд долл. дип бәяләнгән, шул исәптән югары үскән икътисадлы илләр заемщикларында 893 млрд долл., аның 575 млрд доллары — Америка заемщикларында.

Тышкы кредит ресурсларына мөрәҗәгать итү зарурлыгы берничә сәбәп аркасында туарга мөмкин. Заем алучы корпорацияләр үзләренең төп капиталын үстерүгә, кушылулар һәм йотылуларны финансларга, тышкы сәүдә контрактларын түләү өчен средстволар табарга омтыла. Илләрнең хөкүмәтләре, валюта резервларын тулыландыру һәм дәүләт чыгымнарын финанслау өчен, кредит алырга мәҗбүр. Банклар заемга алынган финанс ресурсларын төрле илләрдәге процент ставкалары аермасыннан керем ясау өчен файдалана.

Ссуда капиталының халыкара хәрәкәте милли валюта, хокук һәм салым көйләнеше объекты булып тора. Дәүләт көйләве төрле алынмаларның мөмкинлекләрен тарайта һәм шартларын начарайта. Әйтик, чит ил заемщиклары тарафыннан милли капитал базарына чыгарылган облигацияләр теркәү һәм әйләнеш режимы буенча җирле фирмалар облигацияләреннән күпкә аерыла. Шунлыктан 50 нче еллар ахыры — 60 нчы еллар башында ссуда капиталларының чыннан да ирекле, күләмле һәм сыгылмалы халыкара базары — Евробазар дөньяга килә.

> **ЕВРОБАЗАР — АКШ** долларларында, Европа, Азия илләре һәм ссуда капиталы сыйфатында милли чикләреннән тыш та гамәлдә йөрүче һәм валюта эмитенты илләренең милли финанс тикшерүенә эләкми торган башка валюталардагы акча средстволары белән операцияләр җыелмасы ул.

Евробазар операцияләренең төп өлеше дөньяның якынча 25 финанс үзәгендә, шул исәптән Европаның 13 үзәгендә гамәлгә ашырыла. Евробазар барлыкка килү чит илләрдәге, бигрәк тә Европадагы банк счетларында (евробанкларда), алыштырылган валюта (барыннан да элек, доллар) туплану белән бәйләнгән һәм исеме дә шуннан алынган. Тагын бер нәрсә әһәмиятле: депозитлаучы банкның бу валюта хуҗасы булган илдә, ягъни валюта эмитентында түгел, чит илдә урнашуы шарт. Банкның кайсы илнеке булуы мөһим түгел. Мәсәлән, Америка банкының Бермуд утрауларында урнашкан филиалында Америка компаниясенең долларлы средстволары евродолларлар булып исәпләнә. Шул ук вакытта Нью-Йорк банкының долларлы депозитындагы средстволар, француз фирмасыныкы булсалар да, евродолларларда түгел.

Евродолларлар, евроиеннар һәм башка евровалюта белән операцияләрне банклар барлык илләрдә дә, шул ук валюта эмитенты илендә дә үткәрә. Евробазарда барлык халыкара ссудаларның 80% ыннан артыгы халыкара банк ссудаларына туры килә. Евробазар процент ставкаларының башка илләрнең кредит базарларындагы ставкалардан күпкә файдалы булуы

белән ссуда алучыларны үзенә җәлеп итә. Бу шуның белән аңлатыла: чит ил валютасындагы депозитларга резерв таләпләр куелмый һәм евробазарда кредит чыгымнары да түбәнрәк. Нәтиҗәдә, мәсәлән, евродоллардагы заем ставкасы АКШта шундый ук доллар заемыннан кимрәк. Бу ставкалар гадәттә йөзүчән була, ягъни дөньякүләм кредит базарында конъюнктура үзгәрешләрен чагылдыра. Уртача сроклы кредитлар һәм евровалюта базары облигацияләре ставкасының нигезе итеп, Лондонның банкара депозит базары (ЛИБОР) ставкасы алына. ЛИБОРның базис ставкасына, ә ул кредитка сорау һәм тәкъдимгә бәйле рәвештә үзгәреп тора, билгеләп куелган өстәмә (спред) өстиләр. Ул кредитның суммасын, срогын, түләнү сыйфатын һәм кредит тәвәккәллегенең башка якларын исәпкә ала.

Кредит бәясе, барыннан да, элек заемщикның кредит рейтингыннан тора, ә аны халыкара рейтинг агентлыклары Moody's Investor Servicies h. б. билгели. Заемщикның рейтингы түбәнрәк булган саен, процент ставкасы югарырак, чөнки аңа кредиторларның процентларны түләмәү яки кредитны вакытында кайтармау куркынычы салына.

Үсеп килүче илләрнең тышкы бурычы

Хәзерге заманда дөньяның кредит базарында төп үзенчәлек — заемщикларның структурасы үзгәреше. Электән калган тышкы бурычларын түләүдә кыенлыклар кичерүче элекке социалистик һәм үсеп килүче илләрнең өлеше кискен кыскарды.

Үсеп килүче илләрнең зур күләмле тышкы бурычлары туплану күп кенә факторлар комплексы белән бәйләнгән. 70 нче еллар уртасында алга киткән илләрдәге кризис һәм нефтькә бәяләр арту нәтиҗәсендә, нефть экспортлаучы илләрнең керемнәре арту әйдәп баручы финанс үзәкләрендә ссуда капиталына тәкъдимне арттыра һәм процент ставкаларын киметә. Ә үсеп килүче илләр ягыннан, үзләренең икътисади артталыгын җиңеп чыгу өчен, тышкы ресурсларга кредитлар һәм заемнар формасындагы сорау арта башлый.

Ләкин тышкы ресурсларны эффектив файдаланмау, процент ставкаларының үсүе, бу илләрдә хуҗалык конъюнктурасы начараю (экспорт керемнәре киму, чит илләрдән алына торган энергия чыганакларына бәяләр арту h. б.) тышкы бурычның кискен артуына китерә. Бу хәл үсеп килүче илләрне

80 нче еллар башында бурыч түләүне туктатып торырга һәм аңа реструктура ясарга, ягъни кредит һәм заемнарның кайтарылу вакытын күчерергә мәҗбүр итә. Бурыч кризисын 70 тән артык үсеп килүче ил кичерә, алар өлешенә «өченче дөнья» дип аталып йөртелүче барлык дәүләтләрнең 60%тан артык тышкы бурычы, товар һәм хезмәт күрсәтүләр экспортының өчтән бере тирәсе туры килә. Үсеп килүче илләрнең кредиторларына — эре шәхси банкларга банкротлык яный, нәтиҗәдә Көнбатыш шәхси һәм дәүләт заемнары буенча түләүләрне күчерергә, бурычлар буенча түләнми килгән процентларны каплау өчен, яңа кредитлар бирергә мәҗбүр була.

Бурыч кризисын хәл итү максатында, бик күп илләрдә тышкы бурыч предприятиеләр акцияләре итеп алыштырыла һәм кредиторларга җир һәм күчемсез милекне озак сроклы түләүсез арендалау хокукы бирелә. Коммерция банкларының бурыч йөкләмәләре шулай ук облигацияләргә алыштырыла һәм кыйммәтле кәгазьләрнең икенчел базарында сатыла. Үсеп килүче илләрнең, бигрәк тә иң түбән үсешлеләренең, тышкы бурычлары кредиторлары тарафыннан күпләп гамәлдән чыгарыла.

Хәзерге вакытта бурыч кризисының кискенлеге кимеде. Үсеп килүче илләрнең тышкы бурычы 2 млрд доллардан артып китсә дә, аларның түләү сәләте күрсәткечләре (тышкы бурычның ТЭПка, товар һәм хезмәт күрсәтүләр экспортына чагыштырмасы, бурыч түләү буенча түләү процентларының ТЭПка, товар һәм хезмәт күрсәтүләр экспортына чагыштырмасы һ. б.) яхшырды.

Бурыч кризисы нәтиҗәсендә үсеп килүче илләргә тышкы финанс ресурсларының төп өлешен банк кредитлары рәвешендә түгел, ә алга киткән илләр бюджеты кредитлары һәм үсешкә рәсми ярдәм, ягъни кайтарып бирелми торган субсидияләр, бүләкләр һәм аеруча өстенлекле кредитлар (30 елга кадәр 3% еллык ставка белән) формасында җәлеп итәргә туры килә. Гадәттә, ярдәм бәйләнешле характерда була һәм икътисадның төп тармакларын үстерү һәм социаль программаларны тормышка ашыру өчен бүлеп бирелә.

Халыкара финанс оешмалары

Халыкара валюта системасының эшләве һәм үсүендә, кредитлар бирүдә халыкара финанс оешмалары зур роль уйный. Алар исәбенә Халыкара валюта фонды (ХВФ), Бөтендөнья

банкы һәм Бреттон-Вуд килешүе нигезендә төзелгән берничә региональ банк керә.

ХВФ бары тик рәсми дәүләт органнарына гына (башлыча үзәк банкларга яки финанс министрлыкларына) гадәттә 5—10 ел срокка кредит бирә. Бу кредитлар максатчан характерда була. Алар түләү балансындагы дефицитны каплау өчен, илдәге структур үзгәртеп коруларны тормышка ашыру өчен, дөнья базарларындагы уңайсыз конъюнктура китереп чыгарган югалтуларны каплау өчен бирелә. Халыкара валюта фондыннан кредит алучы үз икътисадын стабильләштерүгә юнәлтеп эшләнгән программа тәкъдим итәргә тиеш: инфляциягә каршы чаралар үткәрү, дәүләт бюджетында дефицитны киметү, тышкы икътисади эшчәнлекне либеральләштерү һ. б. ХВФ тарафыннан куелган шундый шартлар еш кына хөкүмәтнең предприятиеләргә дотацияләр бирүен, халыкка акчалата пособиеләр түләвен туктатуны, социаль программаларны кыскартуны күздә тота һәм шунлыктан халыкның тормыш дәрәҗәсе тагын да төшәргә мөмкин. ХВФның кредит бирүе гадәттә бу илнең кредитка сәләтлелеген күрсәтә һәм аңа шәхси кредиторлардан өстәмә заемнар алуны җиңеләйтә.

Бреттон-Вуд килешүләре нигезендә 1946 елда икенче бер эре финанс оешмасы — Бөтендөнья банкы да төзелә. Хәзерге вакытта ул аерым бер төркем — Бөтендөнья банкы төркеменнән гыйбарәт, аңа Халыкара реконструкция һәм үстерү банкы (Международный банк реконструкции и развития (ХРҮБ), Халыкара үсеш ассоциациясе, Халыкара финанс корпорациясе, Инвестицияләрне гарантияләү буенча күпьяклы агентлык һәм Инвестиция бәхәсләрен көйләү буенча халыкара үзәк керә.

ХРҮБ ны еш кына Бөтендөнья банкы дип йөртәләр, чөнки ул Бөтендөнья банкы төркеменең үзәге һәм аның төп кредит учреждениесе булып тора. Ул облигацияләрен финанс базарларында урнаштыру юлы белән средстволарны эшкә җигә. Нигездә ул үсеп килүче илләрдә конкрет проектларны кредитлый (кагыйдә буларак, хөкүмәт гарантиясе белән). Мондый проектлар көчле тармаклар барлыкка китерү һәм икътисадны структур үзгәртеп корулар белән бәйләнгән. Халыкара үсеш ассоциациясе өстенлекле шартларда иң начар үскән илләрне финанслый, 35—40 елга (еллык 0,75% белән) кредитлар тәкъдим итә. Халыкара финанс корпорациясе үсеп килүче илләрдәге рентабельле предприятиеләрне кредитлый һәм, мондый

предприятиеләрнең акцияләрен финанс базарларында арттырып сатып, шәхси инвестицияләргә ярдәм итә. Инвестицияләрне гарантияләү буенча күпьяклы агентлык чит ил инвесторларына үсеп килүче илләрдә капитал салу белән бәйләнгән көтелмәгән хәлләрдән (милекне экспроприацияләү, борылышлар һ. б.) гарантияләр бирә.

Инвестиция бәхәсләрен көйләү буенча халыкара үзәк хөкүмәтләр һәм чит ил инвесторлары арасында үзара килештерү сөйләшүләре алып бару өчен шартлар тудыра. Моннан тыш ул, инвесторларга тиешле рекомендацияләр биреп, чит ил инвестицияләре буенча законнар турында мәгълүмат тарата. Шуның нәтиҗәсендә әлеге финанс оешмасы чит ил инвестицияләре агымын киңәйтергә булыша.

Россия — ссуда капиталының бөтендөнья базарында

Тышкы ресурсларга, үсешне финанслауның инфляцион булмаган әһәмиятле чыганагы буларак, Россия еш мөрәҗәгать итә. Тышкы ресурслар башлыча халыкара финанс оешмаларыннан һәм рәсми финанслау кысаларында ике яклы нигездә керә. Россиянең төп кредиторлары — Германия, АКШ һәм Италия. 1992 елдан Россия — ХВФ һәм Бөтендөнья банкы төркеменең һәм Европа реконструкция һәм үстерү банкы әгъзасы. Әлеге халыкара оешмаларга кергән беренче ел эчендә Россиягә 3,5 млрд долл. тирәсе суммада финанс һәм товар кредиты бирелгән. Бу алган кредитларның төп өлеше бәйле характерда була.

Россиянең тышкы бурычы кредитлау күләмен тагын да арттырырга мөмкинлек бирми, 2004 ел ахырында ул, элекке СССР бурычларын да исәпләп, 192,1 млрд долл. тәшкил итә. Россия бурычының 67% ы — чит ил валютасында исәпләнгән кыйммәтле кәгазьләр, 17% ы — халыкара финанс оешмаларына бурыч, 12% ы — хөкүмәтара кредитлар буенча бурыч. Икътисадның барлык секторларындагы тышкы бурычның ТЭПка чагыштырмасы 42% була һәм 2003 ел белән чагыштырганда (44%) кими, ә дәүләт идарәсе секторында 30 дан 24% ка төшә.

Россиянең түләү сәләте түбән булу берничә фактор белән аңлатыла. Аңа элекке Советлар Союзының барлык бурычларын түләргә туры килә. Моннан тыш, валютада кергән акчаны үзәкләштерү барып чыкмый һәм, бурычны эффектив түләп бару өчен, средстволар җыелмый. Валютаның бик зур өлеше — экспортерлар һәм банкларныкы, ә бер өлеше чит илләрдә ка-

лып килә. Бары тик 90 нчы елларда гына Россиядән 200 млрд долларга кадәр суммада капитал чыгарылган.

Мондый шартларда Россия халыкара финанс оешмалары, рәсми кредиторлар һәм коммерция банклары (элекке СССР кредиторлары) белән бурыч түләү вакытларын кичектерү турында уңышлы сөйләшүләр үткәрде.

Шул ук вакытта үсеп килүче илләрнең Россиягә бирәсе бурычы 160 млрд доллар (шул исәптән 52 млрд долларның срогы күптән чыккан) исәпләнә. Бу илләрнең бурычлары аларга кредитка чимал, җиһазлар бирү, төзелеш хезмәте күрсәтү белән бәйле. Бурычны түләү мөмкинлекләре: бу илләр предприятиеләренең акция пакетларын Россия милкенә күчерү (бурыч түләү исәбенә), бурычларны озак сроклы облигацияләргә алыштыру һәм соңыннан финанс базарларында сату. Әмма кайбер илләрнең (Әфганстан, Никарагуа, Эфиопия һ. б.) бурычлары кире кайтыр дигән өмет тә юк.

Россия үсә баручы илләргә һәм БДБ дәүләтләренә сәүдә һәм финанс кредитлары бирүен дәвам итә. Россиядән чит илләргә ссуда капиталы андагы банкларга кертемнәр ясау, чит ил валютасын акчага сатып алу юлы белән экспортлана.

Эшмәкәрлек капиталы экспорты һәм дөнья икътисадында ТНКларның роле

Икътисадның интернациональләшүе үсү ссуда капиталын гына түгел, эшмәкәрлек капиталын да экспортлауда чагыла. Аны читкә чыгару турыдан-туры һәм портфельле чит ил инвестицияләре аша бара.

> **ЧИТ ИЛДӘ ТУРЫДАН-ТУРЫ КАПИТАЛ САЛУЛАР** — чит илдә фирма-инвестор контроль астына күчә торган предприятие төзү яки фирманың эшләп торучы чит ил предприятиесе милкенең зуррак өлешен алу.

АКШта әгәр инвестор чит ил фирмасының 10% һәм аннан күбрәк милкенә хуҗа икән, ул инвестор турыдан-туры чит илдә капитал салучы дип исәпләнә.

> **ПОРТФЕЛЬЛЕ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР** — чит илләрдә зур булмаган акция пакетларына тикшерүләр таләп итми торган капитал салулар ул.

Чит илдә турыдан-туры инвестицияләр — халыкара капитал хәрәкәтенең аеруча мөһим формасы ул. XXI гасыр башына турыдан-туры чит ил инвестицияләре импорты 6,3 трлн доллардан артык күләмдә туплана, ә 1989—1994 елларда елына уртача 200 млрд долл. тәшкил иткән агымдагы капитал чыгару 2001 елда 735 млрд долларга җитә. Турыдан-туры инвестицияләр экспортерлары арасында әйдәп баручы илләр — АКШ, Бөекбритания, Япония, Германия һәм Франция.

Әгәр Беренче бөтендөнья сугышына кадәр турыдан-туры чит ил инвестицияләренең төп өлеше (63% тан артык) үсеп килүче илләрдә тупланган булса, хәзер бу илләрнең өлеше уртача 31% ка кадәр төште.

Үсеп килүче илләрнең, чит ил капитал салулары импортеры буларак, роле төшү сәбәпләре: алга киткән илләрдә базарларның зур булуы һәм уңайлы инвестиция климаты, инвестицияләрне заманча технологияләргә салуның отышлылыгы.

Үсеп килүче илләргә чит ил капитал салулары башлыча Азиядә (19% тирәсе) һәм Латин Америкасында (10% тирәсе) тупланган (18-1 рәс.).

Дөньяда турыдан-туры инвестицияләүнең иң әһәмиятле субъекты булып **транснациональ компанияләр (ТНК)** санала. Гарвард бизнес мәктәбе икътисадчылары билгеләмәсе буенча, ТНК — биш яки аннан да артыграк илдә филиаллары булган компанияләр.

ТНКның чит илдәге филиаллары бер ел эчендә 5 трлн доллардан артык капитал сата, ә дөньякүләм экспорты, филиаллар арасындагы сәүдәне исәпләмәгәндә, ике тапкыр кимрәк. Шулай итеп, төп компанияләре, аларның филиаллары, фирмаара һәм фирма эчендәге бәйләнешләре белән берлектә ТНК халыкара җитештерү системасы дөнья икътисадында әһәмиятле роль уйный. ТНК җитештерү чыгымнарына экономия ясау, зур күләмле базарларда ныгып калу, хезмәтнең берәмләп бүленеше өстенлекләреннән файдалану, реаль чыгымнардан шактый аермалы булган эчке бәяләр куллану юлы белән салымнар түләүдән качу, табышын минималь салым салына торган илләрдә күрсәтү юлы белән максималь табыш алып баралар.

Шул ук вакытта капитал импортлаучы илләр күп кенә сәбәпләр аркасында ТНКның турыдан-туры инвестицияләре белән кызыксына. Һәрвакытта да эффектив кулланып бетереп



18-1 нче рәсем. △
1991—1993 елларда үсеп килүче илләргә турыдан-туры саф чит ил инвестицияләре кертелү (млрд долл.).

Диаграммадан күренгәнчә, чит илләр капиталы чагыштырмача квалификацияле һәм тәртипле эшче көчләре, уңайлы географик урыны һәм инвестиция климаты яхшырак булган илләргә юнәлтелә.

булмый торган чит ил кредитларыннан аермалы буларак, турыдан-туры инвестицияләр капитал, яңа технологияләр, алдынгы идарә алымнары, эш урыннары бирә, экспорт үсешен тәэмин итә. ТНК белән хезмәттәшлек итүче дәүләтләр ТНКның да, кабул итүче илнең дә мәнфәгатьләре балансын сакларга тырышалар.

Турыдан-туры чит ил инвестицияләренең тармак һәм географик структурасының гомуми күренеше 18-1 таблицасында бирелә.

18-1 таблицасы

1999 елда тупланган турыдан-туры чит ил инвестицияләре күләменең тармак һәм географик структурасы, %

Икътисад секторлары һәм тармаклары	Бөтендөнья икътисады	Алга киткән илләр	Үсеп килүче илләр	Үзәк һәм Көнчыгыш Европа илләре
Барлыгы	100,0	100,0	100,0	100,0
Беренчел сектор	5,5	5,7	5,4	2,5
Шул исәптән:				
тау чыгару сәнәгате	5,0	5,5	4,1	2,0
Икенчел сектор	41,6	36,4	54,5	43,5
Шул исәптән:				
химия продуктлары житештерү	6,7	7,6	4,6	4,3
электротехник һәм электроника сәнәгате	3,6	3,2	4,5	2,2
транспорт машиналары төзү	3,0	3,7	1,2	1,6
металлургия	3,0	3,1	2,8	3,8
машиналар төзү һәм жиһазлар житештерү	2,5	2,9	1,4	4,4
Өченчел сектор	50,3	55,5	37,3	43,9
Шул исәптән:				
финанслар	15,9	20,6	4,2	16,3
сәүдә	15,9	20,6	4,2	16,3
бизнес инфраструктурасы	10,4	8,2	16,8	7,6
транспорт, склад хужалыгы һәм коммуникацияләр	5,5	6,2	3,4	9,8

Таблицадан күренгәнчә, әгәр бөтен дөнья күләмендә турыдан-туры чит ил инвестицияләренең роле икътисадның финанс, сәүдә, бизнес инфраструктурасы, химия, электротехника һәм электроника сәнәгате кебек секторларында һәм тармакларында гаять зур булса, югары үсеш алган илләрдә

чит ил капиталы финанс һәм сәүдә секторына күбрәк агыла, ә үсеп килүче илләрдә бу агым химия, электротехника һәм электроника сәнәгатенә, бизнес инфраструктурасына күбрәк юнәлтелгән. Хуҗалыкның чимал табу секторы турыдан-туры чит ил инвестицияләре өчен әһәмиятле объект түгел. Хәзерге заман сәнәгатендә җитештерүнең автоматлашкан һәм механикалашкан булуы күп кенә үсеп килүче илләрдәге арзанлы, әмма түбән квалификацияле хезмәтнең бәясен төшерә.

18-1 таблицасындагы саннарны тикшергәндә, чит ил инвестицияләре структурасына ТНКның йогынтысы искиткеч зур икәнен исәпкә алырга кирәк. Чит илләрдә ТНКның турыдан-туры инвестицияләрен нинди төп максатлар белән урнаштыралар соң?

Беренчедән, чимал, эшче көчләр (квалификациясе җитәрлек югары булганда), энергия, табигатьне саклау чаралары өчен түләүләр белән бәйле чыгымнарга экономия ясау мөмкинлеге.

Икенчедән, капитал салынасы илләрнең эчке базарларында, бигрәк тә алар сыйдырышлы, таможня барьерлары белән сакланган, һәм анда потенциаль конкурентлар саны аз булса, ныгып калу теләге белән.

Өченчедән, хезмәт бүленешенең транснациональ вертикаль һәм горизонталь системасын төзү. Бу очракта чимал китерү, җитештерү, финанслау, техник тәэминат, консультацияләр һәм башка хезмәт күрсәтүләрне ТНК үзе гамәлгә ашыра.

Дүртенчедән, үз филиалларын минималь салым салу системасы булган илләрдә урнаштыру яки, «табыш» үзәге дип аталучы илләрдә табышларын теркәү юлы белән, салымнардан качу һәм максималь табыш алу максатында. Бу очракта реаль чыгымнардан аерылып торган эчке (трансферт) бәяләр кую механизмы файдаланыла.

Бишенчедән, уңайлы инвестиция климаты өстенлекләреннән файдаланып калу теләге белән. Моңа илләрнең югары инвестиция потенциалы, аерым алганда, ресурслар, инфраструктура, сыйдырышлы эчке базар булу кирәк, шул ук вакытта илдәге сәяси һәм икътисади шартлар, милек хокукын яклау өчен нык үскән хокук системасы, заманча салым салу законнары мөһим роль уйный.

Халыкара икътисади оешмалар турыдан-туры чит ил инвестицияләренең еллык күләме 2007 елда 1,1 трлн долларга җитәр

дип фаразлыйлар, ә алга киткән илләр икътисадына инвестицияләр 815 млрд доллардан артып китәр дип уйланыла. Үсеп килүче илләр икътисадына инвестицияләр 340 млрд доллардан артык кертелер, һәм аларның 45% тирәсе бу төркемдәге иң зур илләрдә — Кытай, Мексика, Бразилия, Һиндстанда, шулай ук Россиядә тупланыр дип көтелә.

Шул ук вакытта үсеп килүче илләр һәм күчеш икътисады илләре берничә сәбәп аркасында турыдан-туры чит ил инвестицияләре белән кызыксыналар. Бу илләрнең үз капиталы аз, заемга алынган финанс средстволары эффектив кулланылмый, тышкы бурычлары зур. Чит ил инвестицияләреннән файдаланып, алар заманча техника һәм технологияләр алырга, экспортны үстерергә, эчке базарны туендырырга, яңа эш урыннары булдырырга тырышалар.

Әмма чит ил инвестицияләрен җәлеп итүдә чит илләр катнашы кергән предприятиеләр эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудыруны, чит ил капиталын җәлеп итүнең социаль-икътисади нәтиҗәләре турында хөкүмәтнең алдан, төрле яклап уйлап эшләве таләп ителә.

Россия — эшмәкәрлек капиталы импортеры һәм экспортеры

Россиянең турыдан-туры чит ил инвестицияләрен җәлеп итү өчен мөмкинлекләре күп: сыйдырышлы эчке базар, нык үскән фәнни-техник потенциал, куәтле җитештерү базасы, чагыштырмача арзан һәм җитәрлек дәрәҗәдә квалификацияле эш көче, табигатьне саклау законнарының йомшак булуы белән табигый ресурсларның гаять күп булуы. Ләкин чит ил инвестицияләре СССРга 1987 елдан башлап уртак предприятиеләр төзү рөхсәт ителгәч кенә кертелә башлый (1990 елдан тулысы белән чит ил предприятиеләре төзү рөхсәт ителә). 2002 елда Россиягә 2,6 млрд долл. тирәсе турыдан-туры чиста инвестиция кертелде. Тупланып килгән турыдан-туры инвестицияләр 1914 елда 1 млрд долл. яки дөньядагы гомуми күләмнең 7% ын тәшкил итсә, 1991—2002 еллар эчендә (рубль өлешен дә исәпләп) 33 млрд долларга җитте һәм хәзерге дөнья-күләм инвестицияләрнең бары тик 0,3% ын гына алып тора.

Турыдан-туры чит илләр катнашы булган предприятиеләр 2002 елда җитештерелгән продукция һәм хезмәт күләме буенча ТЭП ның 24% тирәсен тәшкил итә. Биредә илнең икъти-

садында катнашучыларның 2,9% ы эшли. Турыдан-туры инвестицияләр кертелүнең тармак структурасы камил түгел. 1995—2002 елларда бу инвестицияләрнең сәнәгатьтәге өлеше уртача 45,3%, шул исәптән азык-төлек тармагында 17,9%, ягулыкта 12,9%, машиналар төзүдә 4,6% иде. Сәүдә һәм җәмәгать туклануында инвестицияләрнең 16,5% ы — финанс, кредит, страховкалау (иминият), пенсия хезмәтендә — 9,9% ы, транспортта 8,3% ы тупланган.

Россиядә турыдан-туры чит ил инвестицияләренең житешмәве бездәге инвестиция климатының житәрлек дәрәҗәдә уңайлы булмавы белән аңлатыла: салым законнары камил түгел, җитештерүче һәм эшлекле инфраструктура үсеше түбән, суд системасы йомшак, милек хокукын яклап чыгарлык түгел, коррупция ныгый бара.

Ирекле икътисади зоналар (ИИЗ) Россия икътисадына чит ил капиталын җәлеп итүнең әһәмиятле формасы була алыр иде.

> **ИРЕКЛЕ ИКЪТИСАДИ ЗОНАЛАР** — үзенчәлекле анклавлар ул, биредә салым салу, товар һәм ярымфабрикатларны пошлинасыз кертү һәм чыгару өлкәсендә чит ил капиталына өстенлекләрнең киң спектры тәкъдим ителә, дөнья стандартлары дәрәҗәсендәге җитештерүче һәм эшлекле инфраструктура эшли.

Хәзерге вакытта дөньяда 400 дән артык ИИЗ исәпләнә. Россиядә берничә комплекслы ИИЗ гына («Янтарь», «Находка») үсеп килә, шулай да зур булмаган берничә экспорт җитештерү зонасы һәм ирекле таможня зоналары бар.

Россия — дөньяда эшмәкәрлек капиталының импортеры гына түгел, экспортеры да. Әле узган гасырның 20 нче елларында Советлар Союзында катнаш акционерлык җәмгыятьләре төзелгән, алар финанс, транспорт өлкәсендә, сәүдә-сату эшчәнлегендә оешкан һәм капиталларының зуррак өлеше безнең илнеке булган.

Хәзерге вакытта эшмәкәрлек капиталын «ЛУКОЙЛ» һәм «АЛРОСА» ААҖләре һәм башка берничә эре корпорация экспортлый. Россиянең чит илләргә турыдан-туры инвестицияләре башлыча минераль ресурслар чыгару һәм эшкәртү сферасында тупланган.

18.2. ТҮЛӘҮ БАЛАНСЫ

Илнең тышкы икътисади операцияләренең барлык төрләре аның түләү балансында чагыла.

Түләү балансының эчтәлеге һәм структурасы

ТҮЛӘҮ БАЛАНСЫ — илнең билгеле бер вакыт эчендә (гадәттә, календарь ел) барлык төрдәге алыш-бирешләр буенча керемнәре һәм түләүләре чагылдырылган гомуми статистик документ.

Түләү балансы төзегән вакытта барлык икътисади субъектларның, үзебезнең һәм чит ил оешмаларының, предприятиеләрнең һәм шәхси затларның эшчәнлеге катгый бүленгән булырга тиеш. Илләрнең закон системасы резидент һәм резидент булмаган дигән төшенчәләр билгеләп куя. Россиядә «Валюта көйләнеше һәм валютаны тикшерү» законы нигезендә **резидент** төшенчәсе түбәндәгеләрне белдерә:

— даими яшәү урыны Россиядә булган, шул исәптән вакытлыча аннан читтә яшәүче физик затлар;
— Россия законнары нигезендә Россия җирлегендә төзелгән юридик затлар һәм юридик зат булмаган предприятие һәм оешмалар;
— Россиянең аннан читтә урнашкан дипломатик һәм башка рәсми вәкиллекләре;
— югарыда күрсәтелгән резидентларның Россиядән читтә урнашкан филиаллары һәм вәкиллекләре.

Резидент булмаган дигәннән түбәндәгеләрне аңлыйбыз:

— даими яшәү урыны Россиядән читтә булган, шул исәптән вакытлыча Россиядә яшәүче физик затлар;
— чит илләрнең законнары нигезендә Россиядән читтә төзелгән юридик затлар һәм юридик зат булмаган предприятие һәм оешмалар;
— чит илләрнең Россиядә урнашкан дипломатик һәм башка рәсми вәкиллекләре, шулай ук халыкара оешмалар, аларның филиаллары һәм вәкиллекләре.

Түләү балансын төзегәндә шулай ук шушы вакыт эчендә гамәлгә ашырылган тышкы икътисади алыш-бирешләрне, аларның бәяләрен төгәл билгеләү мәҗбүри. Бу очракта товарларга яки финанс активларына милек хокукы тапшырыла торган алмашу алыш-бирешләре (сату, сатып алу, бартер) генә түгел, товар, хезмәт күрсәтүләр һәм активларга кире кайтаруларсыз ия булу да (чит илләргә пенсияләр, гуманитар ярдәм, иммигрантларның хезмәт хакын башка илдәге туганнарына күчерү һ. б.) исәпкә алынырга тиеш. Түләү балансында шулай ук керемнәрнең алыш-биреш нәтиҗәсендә түгел, ә башка хәлләр аркасында керүе дә исәпкә алына. Әйтик, әгәр алтынга һәм резервта торучы валюталарның курсларына дөньяда бәяләр артса, илнең алтын-валюта резервы бәясе артырга мөмкин.

Түләү балансы төзүнең төгәллеген **бухгалтерның икеле язма принцибы** тәэмин итә. Ил балансында бәянең чыгышы (аның өчен бу ил читтән түләүләр ала) (кредит) һәм бәянең кереше (аның өчен ил түләргә тиеш) (дебет) күрсәтелә. Баланста билгеләнергә тиешле бер операция буенча бертөрле ике күрсәткеч язып куелырга тиеш.

Россиядән чит илгә товар экспортлауны исәпкә алырга кирәк булды, ди. Балансның кредиттагы күрсәткече читкә экспортланган һәм аннан түләү рәвешендәге керем китерә торган товарның бәясен чагылдыра. Дебеттагы күрсәткеч бу операцияне финанслый торган средстволар хәрәкәтен күрсәтә. Әгәр, мәсәлән, чит илгә 3 ай срок белән кредитка товар сатылган булса, дебетта резидент булмаганнарны кредитлау чагылдырыла, ягъни чит илдән кыска сроклы халыкара кредит түләүләре «импорты» өчен капитал чыгымы күрсәтеләчәк, соңыннан алар кредит өчен процент рәвешендә керем китерә.

Хәзер АКШның түләү балансында Америка туристының Париж кунакханәсе номерын арендалау өчен чыгымнарын карап узыйк. Бу чыгымнар балансның дебетында исәпкә алына, ләкин кредитта да АКШның кыска сроклы йөкләмәләре үсеше буларак язылып куела. Парижда түләнгән долларлар Франциягә бирелгән һәм Америка товарлары яки хезмәт күрсәткечләре белән ныгытылган кыйммәтле кәгазь кебегрәк роль үти. Димәк, бу алыш-биреш АКШка кыска сроклы капитал керүе дип карарга кирәк.

Баланс төзүнең мондый методикасы, билгеләмәсе буенча, кредитның гомуми суммасы белән дебетның гомуми суммасына тигезлеген тәэмин итә, ягъни түләү балансының сальдосы нульгә тигез. Шуңа күрә әлеге статистик документ баланс («тигезләнеш») дип атала да.

Әмма чынбарлыкта бер-берсен сүндерә торган кыйммәтләр агышын туры китерү шактый кыен. Шунлыктан балансжа, килеп чыккан төгәлсезлекләрдән котылу өчен, «Хаталар һәм төшереп калдырулар» дигән махсус статья кертелә.

Россия, ХВФ әгъзалары булган башка илләр кебек үк, түләү балансы төзегәндә, ХВФ тәкъдим иткән төзелеш схемасын куллана (18-2 табл.).

18-2 таблицасы

Түләү балансы схемасы (ХВФ методологиясе буенча)

A. 1) Агымдагы операцияләр

Товар һәм хезмәт күрсәтүләр импорты

Инвестицияләрдән керемнәр

Башка хезмәтләр һәм керемнәр

Берьяклы шәхси акча күчерүләр

2) Агымдагы операцияләр балансы

B. Турыдан-туры инвестицияләр һәм башка озак сроклы капитал

Турыдан-туры инвестицияләр

Портфельле инвестицияләр

Башка озак сроклы капитал

C. Кыска сроклы капитал

D. Хаталар һәм төшереп калдырулар

E. Компенсацияләүче статьялар (алтын-валюта резервларын яңадан бәяләү һ. б.) һәм махсус алып тору хокукларыннан файдалану

F. Гадәттән тыш финанслау

G. Чит ил рәсми органнарының валюта резервын төзүче йөкләмәләр

H. Резервларның йомгаклау үзгәреше

СДР

ХВФта резерв позициясе

Валюта активлары

Башка таләпләр

ХВФ кредитлары

Түләү балансы схемасын өлешләп карап чыгарбыз.

Түләү балансы статьяларына характеристика

Агымдагы операцияләр балансын (*А* блогы) төзү товарлар, хезмәт күрсәтүләр хәрәкәтеннән һәм берьяклы акча күчерүләрдән саф керем бармы-юкмы икәнен белергә мөмкинлек бирә. Бу балансның нигезен товарлар экспортын һәм импортын күрсәтүче статьялар төзи. Товарларның экспорты белән импорты аермасы сәүдә балансының сальдосын бирә. Хезмәт күрсәтүләр балансы резидентлар тарафыннан чит илләрдә һәм резидент булмаганнар тарафыннан илдә күрсәтелгән транспорт, туристлык, страховкалау, телекоммуникатив, укыту, эшлекле һәм техник хезмәтне билгели. Бу хезмәт күрсәтүләрдә җитештерү факторларын — капитал һәм хезмәтне сату — сатып алу операцияләре булмаганлыктан, аларны факторларсыз хезмәт күрсәтүләр диләр. Инвестиция керемнәре балансы резидентларга чит илдә салынган капитал өчен, түләнгән яки чит ил инвесторларына илдә салынган капитал өчен күчерелгән процентлар һәм дивидендларны эченә ала. Балансның бу өлеше факторлы хезмәт күрсәтүләрне, ягъни капитал һәм хезмәт факторларын билгели.

Берьяклы шәхси акча күчерүләр балансы илдә эшләүче иммигрантларның чит илгә шәхси акча күчерүләрен яки илнең гражданнарына читтән мирас, пенсияләр һәм башка төрле керемнәр керүне билгели.

Озак һәм кыска сроклы капитал хәрәкәте балансы (*В* һәм *С* блоклары), мәсәлән, турыдан-туры һәм портфельле инвестицияләр кысаларында чит илдә сатып алынган яки илдә сатылган матди һәм финанс активлары, хөкүмәт һәм банкларның озак яки кыска сроклы кредитларын бирү һәм түләү белән бәйләнгән капитал агымын күрсәтә.

Нәкъ менә капитал хәрәкәте хисабына агымдагы операцияләр балансы дефициты финанслана, чөнки чит илгә милек сату илгә капитал агымын юнәлтә, һәм киресенчә, чит ил активларын сатып алу, чит ил формасына ссуда бирү, чит ил банкларына акча кертү капиталны илдән чыгара.

Моны мисалда аңлатыйк. Әйтик, бу елда А иленнән Б иленә чыгарылган нефть Б иленнән алынган торбалар бәясен капларга җитми. Ул вакытта А иле В иленә үзендәге нефть промыселлары акцияләренең бер өлешен тәкъдим итәргә яки бурычны күрсәткән кыйммәтле кәгазьләр бәрабәренә торбаларны кредитка алырга мөмкин.

E, F, G блокларында алтын-валюта резервларын кабат бәяләү, түләү балансы дефициты туган очракта халыкара финанс оешмаларыннан заемнар алу, башка илләр тарафыннан дәүләт органнарының кыйммәтле кәгазьләрен сатып алуы (сатуы) буенча операцияләр чагылдырыла.

A дан *G* га кадәрге блокларга кергән статьялар рәсми исәп-хисаплар балансы сальдосын характерлый. Сальдо тигезләнешкә килсен өчен, илнең резервларына гомуми үзгәреш (*H* блогы) кертелә, ягъни хөкүмәт һәм Үзәк банк карамагындагы чит ил валютасы, алтын һәм башка валюта активлары сатыла яки сатып алына.

Алдагылардан күренгәнчә, илнен түләү балансы бик күп төрле факторлар — тышкы сәүдә динамикасы, илне үстерү өчен чит ил капиталына ихтыяж, валюта базарындагы хәлләр, илнең тышкы бурычының торышы белән билгеләнә.

Дәүләт үзенең түләү балансын көйләргә тырыша. Әйтик, дефицит шартларында товар экспортына ярдәм итү һәм импортын чикләү буенча чаралар үткәрелә. Чит ил капиталын җәлеп итү стимуллаштырыла һәм илдән капитал чыгару чикләнә (мәсәлән, валюта чикләүләре кертелә). Ил чит илләрдән заемнар һәм кредитлар ала, алар да җитмәсә, алтын резервларын һәм алыштырылган валютасын тотуга керешә.

Россиянең түләү балансы

Россиянең 1996—1998, 2001 һәм 2003 еллардагы түләү балансларында төп бүлекләрне чагыштырып карыйк (18-3 табл.).

Таблицадан күренгәнчә, Россиядә валюта керемнәренең иң зур чыганагы — товарлар экспорты. Ул товар һәм хезмәт күрсәтүләр импорты өчен түләүне, чит ил инвестицияләренә процентлар һәм дивидендлар формасындагы керемнәрен түләүне, шулай ук капитал чыгаруны да капларга җитә.

1997—1998 елларда товар экспортыннан алынган керемнәрнең кыскаруын күрәбез, чөнки бу чорда дөнья базарларында Россия товарлары конъюнктурасы начарайды һәм Россия валютасының курсы, бу вакыттагы көчле инфляция шартларында номиналь курс билгеләнеп куелу сәбәпле, күпкә кыйммәтләнде.

1996—1998, 2001 һәм 2003 елларда Россиянең түләү балансы, млрд долл. (төп позицияләр буенча, саннар түгәрәкләп алынган)

Түләү балансы статьясы	1996	1997	1998	2001	2003
Агымдагы операцияләр счеты	10,8	−0,08	0,2	24,6	35,9
Сәүдә балансы	21,6	14,9	16,4	36,0	60,5
Товар экспорты	89,7	86,9	74,4	75,6	135,9
Товар импорты	−68,1	−72,0	−58,0	−39,5	−75,4
Хезмәт күрсәтүләр балансы	−5,4	−5,9	−4,1	−4,3	−11,1
Хезмәт күрсәтүләр экспорты	13,3	14,1	12,4	9,1	16,0
Хезмәт күрсәтүләр импорты	−18,7	−20,0	−16,5	−13,4	−27,1
Инвестицияләрдән керемнәр	−5,0	−8,4	−11,6	−7,9	−13,0
Хезмәткә түләү	−0,4	−0,3	−0,2	0,2	−0,1
Агымдагы трансфертлар	0,07	−0,4	−0,3	0,6	−0,4
Капитал һәм финанс инструментлары белән операцияләр счеты	−3,1	8,9	9,6	−16,1	−28,7
Турыдан-туры инвестицияләр	1,7	1,7	1,5	1,1	−3,0
Портфельле инвестицияләр	4,4	45,8	8,6	−0,9	−4,9
Башка инвестицияләр	−11,6	−35,8	−5,4	−14,1	5,9
Резерв активлары	2,8	−1,9	5,3	−1,8	−26,4
Хаталар һәм төшереп калдырулар	−7,7	−8,8	−9,8	−8,6	−7,2
Гомуми сальдо	0	0	0	0	0

Экспорттан килүче керемнәр азаю һәм шуның нәтиҗәсе буларак, агымдагы операцияләр счетының кискен начараюы дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләре өчен портфельле инвестицияләр рәвешендә гаять зур заемнар җәлеп итү зарурлыгын тудырды. Ләкин финанс кризисыннан бу гына коткара алмады.

Чит ил инвесторлары Россиядән үз средстволарын чыгарырга кереште, һәм шушы шартларда милли валюта курсын тотып калырга тырышу резерв активларының зур өлешен югалтуга китерде. Таблицада резервларның кимүе «плюс» тамгасы белән күрсәтелгән, чөнки алтын-валюта резервларының тотылуы үзенә күрә алтын һәм чит ил валютасы экспортын хәтерләтә.

Россиянең түләү балансына «Хаталар һәм төшереп калдырулар» статьясының шактый зур булуы характерлы. Бу исә статистик базаның камил түгеллеген һәм шул ук вакытта чит илгә күчерелгән валюта кеременең исәпкә алынмавын, һәм илдән капиталның башка төрле теркәлмәслек юллар белән «качу» процесслары барлыгын чагылдыра.

Таблицада 2003 ел күрсәткечләре соңгы вакытта Россиянең түләү балансында уңай үзгәрешләр барын аңлата. Нефтькә дөнья бәяләре арту һәм 1998 елгы финанс кризисы нәтиҗәсендә рубль девальвациясе агымдагы операцияләр счетының бик тиз уңайлануына китерә. Моның төп сәбәбе — уңайлы тышкы сәүдә конъюнктурасы шартларында сәүдә балансында уңай сальдо үсә һәм Үзәк банкның алтын-валюта резервлары арта бара. Соңгылары 2004 елның 1 ноябренә, тышкы бурычның шактый өлешен түләүгә дә карамастан, 107 млрд доллардан артып китте. Шул ук вакытта актив төстә чит илләрдән ссуда һәм заемнар формасында капитал җәлеп иткән предприятиеләр тарафыннан читкә саф капитал чыгару күзәтелә (финанс предприятиеләреннән тыш).

Россиянең түләү балансында «Хаталар һәм төшереп калдырулар» статьясы һаман да бик зур калып килә. Ул валюта кереме күчерелүнең исәпкә алынмыйча дәвам итүен, капитал чыгаруның башка төрле, теркәлүсез юллары булуын һәм статистиканың йомшаклыгын чагылдыра.

18.3. ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДИ ИНТЕГРАЦИЯ

Хуҗалык итүнең интернациональләшүе, халыкара хезмәт бүленешенең тирәнәюе һәм милли икътисадларның берберсенә бәйлелеге, шулай ук XX гасырның икенче яртысында халыкларның үзара хезмәттәшлеккә омтылуы халыкара икътисади интеграциягә алып килә. Күп санлы интеграцион төркемнәр дөньяның төрле регионнарындагы илләрне берләштерә.

Халыкара икътисади интеграциянең эчтәлеге һәм формалары

ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДИ ИНТЕГРАЦИЯ — төрле илләрнең милли икътисади һәм сәяси структуралары якынаю һәм шул нигездә региональ хуҗалык комплекслары формалашу процессы ул.

Шушы комплекслар кысаларында башта икътисади сәясәт турында килешүләр үткәрелә, ә аннан соң икътисад, финанс, валюта мөнәсәбәтләре, региональ үсеш өлкәләрендә, социаль һәм тышкы сәясәт сфераларында бердәм сәясәт үткәрү башлана.

Икътисади интеграциянең төп дүрт төрен аерып йөртәләр. **Ирекле сәүдә зоналары** кысаларында илләр үз араларындагы сәүдә барьерларын алып ташлый, ләкин һәрберсе үз таможня пошлиналарын өченче илләргә карата саклый.

Таможня берлеге кысаларында илләр үзара сәүдәдә һәртөрле чикләүләрне бетереп кенә калмый, өченче илләргә карата бердәм тышкы сәүдә тарифын да билгелиләр.

Гомуми базар әгъзалары товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең ирекле күчешен генә түгел, җитештерү факторлары — хезмәт һәм капиталның да ирекле күчүен тәэмин итә.

Икътисади берлек илләре икътисади, салым, кредит-акча, финанс-валюта һәм социаль сәясәтләрен унификациялиләр (бертөрле ясыйлар). Бу стадия шулай ук сәяси интеграцияне дә күздә тота.

Интеграцион процессларны җәелдерү нәтиҗәсендә халыкара специальләшүне тагын да тирәнәйтү, продукция җитештерү масштабларын үстерү, чыгымнарны кимету һәм дөнья базарында товарларның конкурентлык сәләтен күтәрү өчен яна мөмкинлекләр ача. Интеграция капитал салуларны үстерүгә, яңа технологияләр кертүгә һәм мәшгульлекне күтәрүгә, шулай ук социаль һәм региональ проблемалар комплексын бергәләп хәл итүгә ярдәм итә.

Европа берлеге

Интеграция процесслары барлык континентларны да биләп алды. Хәзер дөньяда 10 икътисади берлек исәпләнә. Ләкин

хәзерге вакытта иң эре һәм алга киткән интеграцион төркем — Европа берлеге (Европейский союз — ЕС), ул Көнбатыш Европаның 15 илен берләштерә.

1957 елда Римда Европа икътисади бергәлеген (Европейское экономическое сообщество — ЕЭС) теркәү турында килешүгә кул куела, аңа ГФР, Франция, Италия, Бельгия, Нидерландия һәм Люксембург керә. 1973—1995 елларда Европа берлегенә Бөекбритания, Дания, Ирландия, Греция, Испания, Португалия, Австрия, Швеция һәм Финляндия кушыла. XX гасыр ахырында берлеккә Көнбатыш һәм Үзәк Европа илләренең күбесе, Балтыйк илләре, Кипр һәм Мальта керә.

1987 елда гамәлгә кергән бердәм Европа акты Европа берлеге илләренең сәяси хезмәттәшлеге базасына әверелә. 1993 елда Маастрихт (Нидерландиядәге шәһәр) килешүләре нигезендә Европа бергәлекләре сәяси, икътисади һәм валюталы Европа берлеге итеп үзгәртелә. 1994 елда үз эченә Европа берлеге илләрен һәм Лихтенштейн һәм Норвегияне алган Европа икътисади пространствосы турындагы килешү үз көченә керә.

Хәзерге вакытта Көнбатыш Европа интеграцион төркеменә бөтендөнья ТЭПның 20%ы һәм дөньякүләм экспортның 40,3%ы туры килә. Европа берлеге илләре арасында 1958—2000 еллар эчендә үзара сәүдә 50 тапкырдан күбрәк үскән.

Европа берлегендә аның эшчәнлеге белән идарә итә торган түбәндәге дәүләтара органнар бар:

— Министрлар советы — закон чыгару органы, берлекнең бердәм хокукый пространствосын формалаштыра торган законнар кабул итә;
— Европа бергәлекләре комиссиясе — башкаручы орган. Ул закон проектларын Министрлар советына раслау өчен тәкъдим итә, бердәм икътисади сәясәтнең үтәлешен тикшерә, Европа берлеге бюджеты белән идарә итә;
— Европа парламенты — Комиссия эшчәнлеген тикшерү органы, Европа берлегенең бюджетын раслый;
— Европа бергәлекләре суды (мәхкәмәсе) — Европа берлегендә хокукый нормалар үтәлешен тикшерү органы.

Европа берлеге эшчәнлегенең матди нигезе — бергәлекнең бюджеты. Бюджет керемнәре таможня пошлиналары кер-

түдән, салымнардан, ә 1988 елдан башлап әгъза-дәүләтләр ТЭПы җыемнарыннан алына торган чигерүләр хисабына туплана.

Бюджет средстволары авыл хуҗалыгына һәм берләлекнең начаррак үскән регионнарына субсидияләр түләү, фәнни тикшеренүләрне субсидияләү, үсеп килүче илләргә ярдәм итү өчен тотыла. Европа берлеге интенсив уртак структур сәясәт алып бара (барыннан да элек, аграр һәм региональ). Аграр сәясәт бердәм бәяләр системасына нигезләнә, бу система үз эченә гарантияләнгән сатып алу бәяләрен һәм лимитлаштырылган импорт бәяләрен ала. Җитештерүчеләр авыл хуҗалыгы продукциясен азык-төлек базары конъюнктурасына бәйләнмәгән сатып алу бәяләре буенча сата. Лимитлаштырылган импорт бәясе — Европа берлеге илләренә читтән кертелә торган авыл хуҗалыгы продуктлары өчен минималь бәя. Бу бәяләр дөнья бәяләреннән шактый югары һәм Европа берлеге илләренең авыл хуҗалыгын конкуренциядән саклый. Импорт продукциясе бәясенә махсус өстәмәләр Европа берлеге бюджетына күчерелә.

Үз чиратында экспортерлар, Европа берлеге бюджетыннан субсидияләр алып, продукцияләрен дөнья базарында сата алалар.

Бердәм эчке базар оешу, Европа берлеге кысаларында капитал һәм эшче көченең иркен хәрәкәт итүе, бердәм икътисади сәясәт үткәрелү халыкара бердәм валюта системасы төзү кирәклеген күрсәтә. Мондый система төзелә һәм 1979 елда эшли башлый. Европа берлегенең 15 әгъзасыннан аңа Австрия, Бельгия, Германия, Ирландия, Испания, Италия, Люксембург, Нидерландия, Португалия, Финляндия, Франция керә. Баштарак акча ролен халыкара акчасыз валюта — ЭКЮ (european currency unit аббревиатурасы) үти. ЭКЮ «валюта кәрзине» методы буенча, ягъни Европа валюта системасына (ЕВС) керүче илләрдәге валюта курсларының уртача үлчәме буларак билгеләнә. 1999 елда ЭКО һәм милли валютаның акчасыз әйләнештә йөргән өлеше ЕВСның яңа валютасы — евроларга алмаштырыла, ә 2002 елның 1 гыйнварыннан евро милли акчаны да алыштыра. ЕВСка керүче илләрнең акча әйләнешендә маркалар да, франклар да, башка милли банкнотлар да калмады. Хәзер ЕВС чикләрендә акча функциясен бары тик евро гына үти.

ЕВС белән беррәттән Европа Үзәк банклар системасы (Европейская система центральных банков — ЕҮБС) да төзелә, аның әйдәп баручы үзәге — Европа Үзәк банкы (ЕҮБ). Бу банкның төп бурычлары — евро зонасы чикләрендә бердәм кредит-акча сәясәте үткәрү, банк системасының тотрыклылыгын тәэмин итү, бәяләрнең һәм евро валюта курсының стабильлеген саклау. ЕҮБ — уникаль икътисади-хокукый институт ул, суверен дәүләтләр аңа евро эмиссиясенә эксклюзив хокук, коммерция банклары эшчәнлегенә тикшерүләр үткәрү вәкаләте, халыкара валюта резервлары белән идарә итүне ышанып тапшыра. Кредит-акча сәясәтенә кагылышлы карарлар кабул иткәндә, ЕҮБ милли һәм гомумевропа хакимияте органнарына бәйле түгел.

Милли үзәк банклар үз автономияләрен югалтты һәм ЕҮБ агентлары буларак эш итәләр. Шуңа күрә ЕҮБ сәясәтенә бернинди милли мәнфәгатьләр дә йогынты ясый алмый. ЕҮБнең һәм тулаем ЕҮСБның да кредит-акча сәясәте коммерция банклары эшчәнлеген көйләүнең моңарчы билгеле методлары ярдәмендә тормышка ашырыла: мәҗбүри резервларның минималь базарындагы операцияләр, исәпләү ставкалары үзгәрешләре. Мондый сәясәт Европа берлегенең барлык илләрендә икътисади үсешне стабильләштерүгә һәм тизләтүгә, дөнья базарларында АКШ, Япония һәм башка илләр фирмалары белән ярышырга сәләтле яңа куәтле сәнәгать-финанс берләшмәләре төзүгә юнәлтелгән, ә тотрыклы гомумевропа валютасы чит ил инвестицияләрен күбрәк җәлеп итәргә тиеш. Болар барысы бергә тулысынча мәшгульлек һәм эшсезлекне табигый дәрәҗәсенә төшереп җиткерүне тәэмин итә.

ЕВС һәм ЕҮСБ оешу Европа берлеген ныгытты, аның нигезен тәшкил иткән бердәм икътисади система хәзерге вакытта АКШның икътисади куәтеннән калышмый. Хәзер дөньяның күпчелек илләренең үзәк банклары, үзләренең валюта резервларын формалаштырганда, евродан файдалана. Шулай итеп евро, АКШ доллары белән беррәттән, халыкара резерв валютасы ролен үти һәм, ЕҮСБга ышаныч арта бару белән, евро тагын да әһәмиятлерәк роль уйнаячак.

Интеграция процессында уртак фәнни-техник сәясәт мөһим урын алып тора. Европа берлеге илләре күп кенә өр-яңа тармакларны үстерүдә әйдәп бара. Ләкин фән сыйдырышлы продукция белән тышкы сәүдә балансы тискәре. Европа

сәнәгате продукциясенең конкурентлык сәләтен тәэмин итү өчен, фәнни-техник прогресс өлкәсендә зур масштаблы күпьяклы хезмәттәшлек программалары тормышка ашырыла (ЭСПРИТ, Эврика, РАСЕ һ. б.).

БДБда интеграция проблемалары

СССР таркалганнан соң, аның республикалары арасында традицион хуҗалык элементләре өзелә, зур территориялардәге бердәм икътисади пространство бүлгәләнә һәм күбесенчә шулар аркасында элекке союздаш республикаларда икътисади кризис тирәнәя бара. Әлеге шартларда милли икътисадларны яңадан торгызу зарурлыгы ачыклана. 1993 елда Россия һәм тагын тугыз дәүләт (БДБ әгъзалары) икътисади берлек турында килешүгә кул куялар, килешүнең асылында ирекле сәүдә зонасы (үзара тарифлы һәм тарифсыз чикләүләрне бетереп) кысаларындагы хезмәттәшлектән — БДБ дәүләтләренең таможня берлегенә, ә аннан гомуми базарга күчү һәм шуның белән интеграцияне тирәнәйтә бару ята.

1994 елда БДБ дәүләтләре тарафыннан түләү һәм таможня берлекләре төзү турында карар кабул ителә. Беренчесе валюталарның башта ике яклы, ә аннан күпьяклы алыштырылуына ирешүне күздә тота. Клиринг нигезендә ике яклы һәм күпьяклы исәп-хисап системалары төзү турында тәкъдимнәр әйтелә (клиринг — үзара таләпләр һәм йөкләмәләр тискәре сальдоның бер өлешен — кредитлар хисабына гомуми валюта фондыннан, ә икенче өлешен ИАВ (СКВ) да түләп компенсацияләү дигән сүз). Таможня берлеге кысаларында Россия, Белоруссия һәм Казахстан таможня тикшерүен дәүләтләрнең тышкы чикләренә күчерә һәм тышкы икътисади эшчәнлекне көйләүнең бердәм тәртибен кабул итә. 1994 елда Россия һәм Белоруссия Икътисади берлек төзү турында килешүгә кул куялар, ә 2002 елда киләчәктә рубльнең ике ил өчен дә бердәм валюта булачагы турында килешәләр. Россия, Белоруссия, Үзбәкстан һәм Казахстан хөкүмәтләре арасында бу илләрнең хәлиткеч проектларына уртак инвестицияләр ясаучы транснациональ сәнәгать-финанс төркемнәре формалаштыру турында күп кенә килешүләр төзелә.

Ләкин интеграциягә килү юлында шактый катлаулы проблемаларны хәл итәргә туры килә. Үзара сәүдә өлешенә БДБ

илләрендәге гомуми тышкы сәүдә әйләнешенең бары 40% ы гына туры килә. Кредит-акча, салым, валюта-финанс өлкәсендә дә аермалар шактый. Ерак чит илләр белән сәүдә итүгә күбрәк тартылу сизелә. Үзара хезмәттәшлек механизмын, һичшиксез, камилләштерергә кирәк.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Илләр арасында капиталның ссуда һәм эшмәкәрлек формаларында хәрәкәт итүе халыкара икътисади мөнәсәбәтләрнең иң мөһим өлеше булып тора.

Ссуда капиталының дөнья базары кыска сроклы капитал, урта һәм озак сроклы капитал базарларына бүленә.

Хәзерге халыкара ссуда капиталы базарында әһәмиятле сегмент — евробазар.

Халыкара кредит базарында заем алучылар — компанияләр, банклар, хөкүмәтләр. Моңарчы тупланып килгән тышкы бурычны түләүдә кыенлыклар булу сәбәпле, үсеп килүче һәм элеккеге социалистик илләр кредитка азрак мөрәҗәгать итә. Алар тышкы ресурсларны күбесенчә халыкара финанс оешмаларыннан алырга тырышалар.

Россиянең тышкы бурычы шактый күләмдә, һәм ул аны түләү буенча кыенлыклар кичерә. Шул ук вакытта ул БДБ дәүләтләренә һәм үсеп килүче илләргә үзе кредит биреп тора.

Эшмәкәрлек капиталы экспортын чит илләрдә турыдан-туры һәм портфельле капитал салулар тәшкил итә, һәм хәзер бу экспорт киңәя бара. Алга киткән илләр иң төп инвесторлар һәм инвестиция алучылар булып тора. Россия башлыча чит ил капиталын импортлаучы ролен үти. Уңайсыз инвестицион климаты Россиягә эшмәкәрлек капиталын күпләп җәлеп итү мөмкинлеге бирми.

Түләү балансы — билгеле бер период эчендә илнең тышкы икътисади операцияләре йомгакларын исәпкә ала торган статистик документ. Ул агымдагы операцияләр счетын, озак һәм кыска сроклы капиталлар белән барган операцияләр счетын үз эченә ала, алтын-валюта резервлары үзгәрешләрен һәм баланс төзү барышындагы хаталарны исәпкә ала.

Халыкара икътисади мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсендә милли хуҗалыкларның үзара бәйләнгәнлеге арту интеграцион

төркемнәр төзелүгә китерә. Төп интеграция формалары — ирекле сәүдә зонасы, таможня берлеге, икътисади берлек.

Иң нык үскән интеграцион төркем — Европа берлеге. БДБ илләренең интеграцияләшү процессы әле башлана гына.

Контроль сораулар һәм биремнәр

1. Россиянең үсеш максатында чит илләрдән ресурслар алуы сезненчә дөресме? Бәлки, илнең эчке мөмкинлекләренә ориентлашу яхшырактыр?
2. Тышкы кредитлар һәм чит илдән турыдан-туры инвестицияләр җәлеп итүнең файдалылыгын чагыштырып бәяләгез.
3. Сезнең шәһәрдә чит ил яки чит илләр белән төзелгән уртак предприятиеләр булмы? Аларның эшчәнлегенең нәтиҗәләрен аңлатып карагыз.
4. Россиянең түләү балансы статистикасында Америка фирмасы тарафыннан Россиядәге металлургия комбинаты акцияләре пакеты алынуны ничек күрсәтергә?
5. А иленә товар һәм хезмәт күрсәтүләр экспорты —120 акча берәмлеге, А иленең товар һәм хезмәт күрсәтүләр импортлавы — 100 акча берәмлеге, А иле резидентларның чит ил фирмаларының кыйммәтле кәгазьләре сатып алуы — 50 акча берәмлеге; А иле фирмаларының кыйммәтле кәгазьләрен чит ил гражданнары тарафыннан сатып алынуы — 60 акча берәмлеге, башка илләрдән А иленә акчалата кредитлар бирелү — 30 акча берәмлеге, А иленә алтын кертелү — 60 акча берәмлеге. А иленең түләү балансын төзегез.
6. Сез БДБ дәүләтләре белән интеграция үсешенең Россия өчен нинди файдасы булыр дип уйлыйсыз?

19 нчы бүлек

ХӘЗЕРГЕ РОССИЯ ИКЪТИСАДЫ

Бу бүлектә сез түбәндәге сорауларга җавап табарсыз:

- хәзерге Россия икътисадының төп характеристикалары нинди;
- ни өчен XX гасырның 90 нчы елларында Россиядә радикаль базар реформалары башлана;
- базар икътисады нигезләрен төзү этабында гамәлгә ашырыла торган системалы үзгәртеп корулар җыелмасының төзүчеләре нинди;
- базарга күчү процессында макроикътисади стабильләшү ничек тормышка ашырылган;
- Россия икътисадында хосусый сектор ничек формалашкан;
- институциональ реформалар нәрсәдән гыйбарәт;
- базар икътисадына күчү процессында социаль сәясәтнең асылы нәрсәдә;
- Россиянең хәзерге икътисады үсешенең мөһим юнәлешләре нинди.

19.1. XX ГАСЫРНЫҢ 90 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА РОССИЯДӘ БАЗАР ҮЗГӘРТЕП КОРУЛАРЫ

XX гасырның 90 нчы еллары башына таба үзәктән планлаштырулы икътисад яшәгән шартларда, СССРда матди һәм рухи байлыклар җитештерүне шуннан да югарырак үстереп булмаслыгы көн кебек ачык була. Икътисад белән идарә итүнең административ методлары фәнни-техник прогресс казанышларын гамәлгә кертү өчен тиешле шартлар тудыра

алмый, халыкның тормыш дәрәҗәсе һәм житештерүнең эффектив үсешен тәэмин итми. Мондый хәл административпланлы системадан базар системасына күчүгә юнәлтелгән радикаль үзгәртеп коруларга әзерләнү һәм аларны үткәрү зарурлыгын объектив дәлилли. Икътисад үзәктән идарә ителә торган барлык илләрдә диярлек базар реформалары үткәрелә башлый. Практика базар реформаларының төрле илләрдә төрле уңыш белән үтүен күрсәтә. Мәсәлән, Венгрия, Чехия, Польша, Эстония, Словения, Литва, Латвиядә базар икътисадына нигез чагыштырмача тиз салына. Безнең илдә бу процесс бик озакка сузыла һәм авырлыклар белән бара.

Базар системасына күчүнең тизлеге бик күп факторлар комплексы белән билгеләнә. Аерым алганда, тулы масштаблы реформаларны башлау алдыннан халыкта базар һәм базар мотивлары элементлары бармы әллә юкмы икәнен билгеләү мөһим. Әйтик, Үзәк Европаның күпчелек илләрендә планлы система кысаларында һөнәрчелек житештерүе һәм жиргә шәхси милекчелек сакланып килгән. Аларда XX гасырның 60—80 нче елларында төрлечә уңышлылык белән базар экспериментлары үткәрелгән. Болар базарга чагыштырмача тиз күчү өчен нигез әзерләгәннәр. Шул ук вакытта Советлар Союзында планлы икътисад күптән һәм тулысынча формалашкан, базар секторының өлеше минималь булган, ә базар мотивлары гомумән булмаган. Шуңа күрә базарга күчү гаять авыр үтә һәм озак вакытлар дәвам итә.

Планлы системадан базар системасына бик тиз күчү юлына басып, бер үк вакытта халык хуҗалыгының һәм сәяси корылышның барлык сфераларында да үзгәртүләр ясарга тотынган илләр идарә итүнең дәүләти инструментларын кулланудан баш тарта. Реформалар үткәрү барышында барлык көч предприятиеләр һәм оешмаларның эшчәнлеген планлаштыру һәм үзәктән торып идарә итү рычагларыннан кичектергесез баш тартуга һәм базар механизмын формалаштыру өчен барлык тиешле шартларны тудыруга юнәлтелә. Башка илләрдә базар системасына акрынлап күчү сәясәте үткәрелә. Бу очракта дәүләт, прагматик һәм сак реформатор ролен ә кереп, базар системасына күчүнең төгәл эзлеклелеген тәэмин итәргә һәм икътисад белән дәүләти идарә инструментларыннан акрынлап баш тарта барырга тиеш була.

Россиянең базар системасына күчүендә кыенлыклар тудырган тагын бер специфик сәбәп — ил халкының бик зур өлешендә социалистик стройга лояль мөнәсәбәт, аерым алганда, дәүләт патернализмына, дәүләтнең һәрвакыт «аталарча кайгыртуып торуына» өмет итү гадәте, көнкүрешваклыгы, эшкә урнашу кебек проблемаларны дәүләт оешмалары хәл итәргә тиеш дип ышану яшь. Кешеләрнең аңына планлы икътисад нормалары һәм традицияләре йогынтысы үтә тирән эз салган.

Дәүләт идарәсе системасы һәм дәүләтнең барлык институтлары икътисадны тулысы белән колачлап алган планлы модель буенча төзелгән булган. Дәүләт институтлары базар үзгәртеп коруларына әзер булсыннар һәм аларны эзлекле, эффектив рәвештә уздыра алсыннар өчен, аларның үзләрен реформалау күпмедер вакыт таләп итә.

Реформа үткәрүче илләр тәҗрибәсе шуны күрсәтә: базар икътисады нигезләрен салу этабында үткәрелә торган системалы үзгәртеп коруларның иң әһәмиятле һәм зарури өлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү;
— макроикътисади стабильләштерү;
— структур үзгәртүләр;
— институциональ реформалар;
— социаль сферада үзгәртүләр.

XX гасырның 90 нчы елларында безнең илдә базар реформаларының беренче этабы тәгәлләнде һәм Россиядә базар икътисады нигезләре төзелеп бетте. Хәзерге вакытта җәелдерелгән яңа этапка тотрыклы икътисади үсеш шартларында базар үзгәртеп коруларын икътисадның төрле сфераларында тирәнәйтү хас. Ләкин ил үсешенең хәзерге этабындагы үзенчәлекләрне аңлау өчен, 1990 еллардагы базар үзгәртеп коруларының асылына төшенергә кирәк, чөнки аларның шул чорда башланып киткән төп юнәлешләре дәвам итәлергә тиеш.

Хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү

Хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү дәүләтнең икътисадка катнашуын сизелерлек чикләүне һәм икътисад белән административ идарәдән дәүләтнең базар механизмын көйләвенә күчүне күздә тота. Без инде алдарак карап узганча

(3 нче бүлек), базар механизмы, барыннан да элек, ирекле базар бәяләре хәрәкәте нигезендә эшли башлый. Шунлыктан, базар системасына күчү өчен, иң беренче, житештерүчеләрнең үз продукциясенә үзе бәя кую хокукын бирү кирәк. Планлы төстә куелган бәяләр базардагы продукциягә сорау һәм тәкъдим үзгәргәнгә карап арта яки кими алмый, ә ирекле бәяләр сорауның да, тәкъдимнең дә тирбәнешләренә тиз реакция ясый. Шуның белән алар житештерүчегә шушы моментта нәрсә житештерергә кирәген күрсәтә. Ирекле базар бәяләре системасы конкуренцияне тудыра, ә конкуренция товар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле чыгымнарны киметүгә, аларның сыйфатын күтәрүгә, продукциянең планда каралганын түгел, ә сорау тудырганын эшләп чыгаруга стимул бирә.

Ирекле базар бәяләре ясалу — предприятие хужалары (аерым шәхси затлар, акционерлык компанияләре һ. б.) мөстәкыйль рәвештә теге яки бу карарларны кабул итү, эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару хокукына ия дигән сүз.

Россиянең базар системасына күчешендәге үзенчәлекләрнең берсе — әле хосусыйлаштыру турында карар юридик яктан эшләнеп беткәнгә кадәр, 80 нче еллар ахыры — 90 нчы еллар башында, дәүләт предприятиеләре хужалык итү мөстәкыйльлеге алган була. Алар, шуннан файдаланып, үз продукцияләренә бәя күтәрергә керешә. Мондый шартларда, куллану бәяләренең үсешен компенсацияләү өчен, дәүләт субсидияләрен шактый арттырырга туры килә.

Нәтижәдә дәүләт бюджеты чыгымнары арта һәм шактый ук бюджет дефициты барлыкка килә, дефицит акча эмиссиясе белән каплана. Болар кирәгеннән артык сорау туута, котырынган инфляциягә һәм акча әйләнешенең житди үк бозылуына китерә. Шулар нәтижәсендә товарлар дефициты күрелмәгән дәрәжәгә житә һәм хужалык таркала. Коточкыч төс алган товар дефицитын йомшарту өчен, төп товарларны карточкалар буенча нормалап бүлү кертелә, ә бу товарларны читтән кертү (хәтта кирәкле минималь күләмдә) өчен, алтын запасының бик зур өлешен сатарга туры килә.

Менә бөйле рәвештә 1991 елның декабрендә бәяләрне либеральләштерү турында Президент указы чыга һәм ул 1992 елның 2 гыйнварыннан эшли башлый. Шулай ук 1992 елның гыйнварыннан, базарны тизрәк туендыру максаты белән, ирекле сәүдә рөхсәт ителә. Предприятиеләр һәм гражданнарга, бернин-

ди махсус рөхсәтнамәләр алмыйча, сату-алу һәм арадашчылык эшчәнлеге алып бару мөмкинлеге бирелә. Шулай итеп, 1992 елны безнең илдә базарны үзгәртеп кору дәверенең башы дип исәпләргә мөмкин.

Бәяләрне либеральләштерү хезмәт хакына һәм башка керемнәргә чикләмәләрне бетерү белән бергә бара, шул ук вакытта дәүләт минималь хезмәт хакын көйләү хокукын үзендә калдыра.

Дәүләтнең тышкы сәүдәгә монополиясе бетерелә. Предприятиеләргә тышкы икътисади эшчәнлекләрен махсус теркәлүләрсез алып бару рөхсәт ителә. 1992 елдан башлап импортны квоталау бетерелә, аны лицензияләү чикләнә. Импорт, нигездә, кертү пошлиналары белән көйләнә. Экспорт, киресенчә, каты квоталар (бәясенең 80% ына кадәр) чикләрендә лицензияләнә, һәм аңа таможняның чыгару пошлиналары (1996 елның уртасына кадәр) салына башлый (экспортның 75% ына кадәр). Пошлиналар һәм дәүләт көйләнешенең башка чаралары булмаса, товарлар эчке базардан дөнья базарына китәр иде, чөнки Россиянең күп кенә экспорт товарларына эчке һәм дөнья бәяләре арасындагы аерма бик зур була. Ә бу Россиянең эчке базарында базар тәкъдиме кимүгә китерер һәм нәтиҗәдә инфляцияне авызлыклар иде.

Юридик затлар һәм гражданнар валюта счетлары ачу һәм тышкы сәүдә операцияләрендә ирекле катнашу мөмкинлеге ала. Агымдагы операцияләр буенча рубльнең эчке алыштырылуы һәм аның бердәм базар курсы кертелә. Бердәм курс Мәскәү банкара валюта биржасындагы (акчасыз) банкара валюта операцияләре нәтиҗәсенә карап билгеләнә, һәм 1991 елның ахырына Россия банкы шуның нигезендә рубльнең рәсми курсын билгели башлый.

Валюта курсын либеральләштерү һәм валюта базарын формалаштыру дөнья базарларында Россия товарларының конкурентлык сәләтен тәэмин итә һәм импорт товарлары алу өчен кирәкле валютаны легаль юл белән табу мөмкинлеге бирә.

Нәтиҗәдә милли житештерүнең кризисы шартларында импорт халыкның һәм предприятиеләрнең соравын һаман да күбрәк дәрәҗәдә канәгатьләндерә башлый, ә экспорт, жирле кулланучыларның түләп алу сәләте булмаганлыктан, күп кенә тармакларның (салымнар аша) һәм бюджетның керемнәрен

тәэмин итеп, җитештерүне аяктан екмаучы факторларның берсе булып кала.

Товар бәяләрен һәм җитештерү факторларын либеральләштерүнең логик нәтиҗәсе — ирекле эшмәкәрлек өчен стимуллар тудыру. 1992 ел эчендә генә кече бизнес предприятиеләре саны ике тапкырдан күбрәк арта, тышкы икътисади операцияләр сферасында кече предприятиеләр аеруча тиз төзелә башлый.

Икътисадның ачыклыгы халыкның төп ихтыяҗларын ашыгыч төстә канәгатьләндерүгә китерә, ә эчке базарга импорт товарын күпләп кертү конкурент мохит тудыра һәм монопольләшкән Россия икътисады шартларында эчке бәяләр үсүенә табигый тоткарлык ясый.

Ләкин бәяләрне либеральләштерү һәм икътисадның кинәттән ачылуы тискәре нәтиҗәләргә дә китерә.

Бәяләрне либеральләштерү аркасында халыкның җыйган акчалары һәм предприятиеләрнең тупланган средстволары берничә мизгел эчендә үзенең бәясен югалта. Гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсе артка тәгәри. Икътисадчыларның күбесе саклык акчаларын индексларга кирәк иде дип исәпли, бу сәяси яктан да, икътисади яктан да бик әһәмиятле, чөнки киләчәктә халыкка хосусыйлаштыруда катнашу мөмкинлеге бирер һәм икътисади үсешкә ярдәм итәр иде. Ә предприятиеләр салымнар һәм эшләүчеләренә хезмәт хакы түләү сәләтен югалта, җитештерүне үстерә яки элекке дәрәҗәсендә генә дә тота алмый.

Икътисадның ачыклыгы аркасында әйбәт сыйфатлы җитештерү средстволары яки халык куллану товарлары җитештерә торган күп кенә тармаклар чит ил конкуренциясенә бирешә һәм эшләп чыгаруны кискен киметәләр. Нәтиҗәдә озак вакытлар буе эчке куллануда импортның өлеше, илнең икътисади куркынычсызлыгын саклау һәм ныгыту күзлегеннән караганда, гаять зур булып кала.

Бик күп куллану товарларының (телевизорлар, сәгатьләр, аяк киеме) гомуми товар ресурсларында импорт өлеше 60—80% ка җитә. Кайбер товарлар импорты артуга аларны эчке җитештерүнең төшүе яки гаять акрын үсүе сәбәп була.

Валюта базарын либеральләштерү һәм рубльнең эчке алыштырылуы, импорт товарларын түләп алу һәм чит ил инвесторларының керемнәрен репатриацияләү мөмкинлеге

бирсә дә, икътисадны долларлаштыруга сәбәп була һәм законсыз рәвештә капитал чыгаруны кискен арттыра. 1994 елда товарлар экспорты вакытында валюта контроле системасы, валюта керемен Россиягә үз вакытында кайтаруны тәэмин итәргә тиеш булса да, эффектив булып чыкмый.

Макроикътисади стабильләштерү

Базар системасына күчә баручы икътисадта макроикътисади стабильләштерү сәясәте гадәттә җитештерүнең озак вакытлар дәвамында төшүе, эшсезлек, инфляция кебек тискәре күренешләрне җиңеп чыгуга юнәлтелә.

Җитештерүнең күпкә төшүе — базар реформаларының беренче этабындагы системалы үзгәрешләргә икътисадның гадәти реакциясе ул. Ул базар системасына күчкән барлык илләрдә дә күзәтелгән һәм икътисадның бер генә секторына да кагылмый калмаган. Бу процессны аңлату кыен түгел: реформаларның беренче этабында бәяләрнең либеральләшүе котылгысыз рәвештә инфляциягә һәм сорауларның кимүенә китерә, ә инфляциягә каршы тору сәясәте процент ставкалары үсүгә алып бара. Моның нәтиҗәсендә кредитлар кыйммәтләнә, дәүләт бюджеты чыгымнары һәм инвестицияләр кими, шунлыктан ТЭП һаман да тирәнгәрәк тәгәри.

Системалы кризис күренеше буларак, җитештерүнең түбәнәюе әле моннан тыш та берничә сәбәпкә бәйләнгән. Барысыннан да элек, хәрби-сәнәгать комплексы тармакларында җитештерү күләме кыскартыла. Россиядә ТЭП күләменең Үзәк һәм Көнчыгыш Европа илләренә караганда бик күпкә күбрәк кимүе шуның белән аңлатыла, чөнки нәкъ менә бездә дөньядагы ике системаның капма-каршы торуы чорында, элекке социалистик илләрнең оборона сәләтен ныгыту максатында коралларның төп өлеше җитештерелә.

Икътисадның ачыклыгы да — түбән тәгәрәү сәбәпләренең берсе. Күп кенә тармаклар түбән сыйфатлы продукция җитештерсә дә, ул үзенең сатып алучысын таба иде. Бу күбрәк җиңел сәнәгать эшләнмәләренә һәм дәвамлы файдаланыла торган куллану товарларына кагыла (автомобильләр, телевизор, магнитофоннар һ. б.). Ә инде илгә чит ил товарлары кертелә башлагач, бу тармаклар продукциясенең конкуренциягә сәләтсез икәне ачыклана.

Икътисади түбәнәюне туктату юлында төп тормоз — котырынган инфляция була. Ул икътисади үсешне басып тора, чөнки инвестицияләрне нәтиҗәсез итә, хезмәт хакының, пенсияләрнең һ. б. реаль үлчәмнәрен киметеп, керемнәрнең бәясен төшерә, ә болары куллану товарларына һәм хезмәт күрсәтүләргә сорауны күпкә кимәтә.

Шулай итеп, базар системасына күчү гомуми сорауның төп өч элементына: инвестицион һәм куллану товарларына, дәүләт сатып ала торган продукциягә сораулар кимү белән бергә бара. Сорау кимүнең турыдан-туры сәбәбе инфляция булганлыктан, макроикътисади стабильлеккә ирешү өчен, инфляциянең тагын да көчәюен туктатырга һәм инфляция нормасын акрынлап төшерүгә ирешергә, ягъни тотрыклы дефляциягә ирешергә кирәк була. Бу бурычны хәл итү өчен, түбәндәгеләрне башкарып чыгу мәҗбүри:

— базар реформаларының беренче этабында дәүләт чыгымнарын чикләү һәм бюджет керемнәренең төп чыганагы сыйфатында турыдан-туры салымнарны куллану юлы белән бюджет дефицитын җиңеп чыгу;
— акча массасы күләменең үсешен чикләү юлы белән катгый кредит-акча сәясәте үткәрү;
— әйләнештәге акча массасы үсешен чикләү белән бер үк вакытта дәүләт облигацияләре сатуны киңәйтү һәм коммерция банкларының мәҗбүри резервлары нормасын арттыру;
— табигый монополияләрнең бәяләр кую сәясәтенә катгый тикшерү үткәрү, чөнки инвестицион һәм куллану товарларын җитештерү чыгымнары арту — шушы сәясәт нәтиҗәсе.

1990 елларда Россиядә шушы алымнарны куллану аларны яклаучылар белән аларга каршы килүче яклар арасында кискен каршылыклы шартларда барды. Инфляциягә каршы сәясәтне яклаучылар уйлавынча, бирелгән продукция өчен түләүнең сәбәбен акча җитмәүгә сылтаучы предприятие җитәкчеләре, түләү сәләте булган сорауны эзләп табып, продукцияләрен шуңа яраклы итеп үзгәртергә теләми. Бу сәясәткә каршы килүчеләр Үзәк банк тарафыннан бюджет дефицитын кредитлауны дәвам итү кирәк дип саный, катгый бюджет чикләүләре һәм кыйммәтле дәүләт кәгазьләре эмиссиясе юлы белән бюджетны инфляцион булмаган финанслау курсын якламыйлар.

Катгый кредит-акча сәясәте белән бергә барган бюджетны стабильләштерү сәясәте Россиядә 1990 елларның беренче яртысында эзлекле уздырылмый. Базар системасына күчкәндә Россиядә салым системасының авырлык үзәге читләтеп алынган салымнар ягына авыша, бигрәк тә өстәлгән бәягә куелган салым арта, чөнки ул бердәм ставка буенча исәпләнә, җинел җыела һәм инфляция шартларында үз бәясен сакларга сәләтле. Ләкин, билгеле булганча, мондый салымнар товарның бәясенә кертелә, димәк, читләтеп алынган салымнарны күтәрү бәя күтәрелүгә китерә, ягъни инфляция көчәя генә дигән сүз. Шул ук вакытта фирмалар эшчәнлегенә дәүләт контроле камил булмаганлыктан, эшмәкәрләргә җитештерүне дә, керемнәрне дә соры икътисадка күчерү һәм шуның белән керемнәрен салымнан яшереп калдыру мөмкинлеге туа. Шуның нәтиҗәсендә бюджет керемнәре акрын үсә һәм бюджет дефицитын инфляция темпларын киметү өчен кыскарту бары тик бюджет чыгымнарын киметү хисабына гына мөмкин була. Ә финанслау приоритетлары әле билгеләнеп җитми: зыянга эшләүче дәүләт предприятиеләре һаман да ярдәм ала, дәүләт аппаратын тоту чыгымнары үсә. Шулай да бюджет сәясәтенең йомшаклыгы күбрәк сәяси сәбәпләр белән аңлатыла. 1996 елгы президент сайлаулары алдыннан базар үзгәртеп коруларыннан баш тарту һәм икътисад белән өстән кушулар буенча идарәгә кайту куркынычы туа.

Мондый хәлдә Үзәк банк кредитларыннан башка гына өстәмә финанс ресурсларын эшкә кушарга тырышып, хөкүмәт, эчке һәм тышкы финанс базарларында дәүләт кәгазьләрен (ДКО (ГКО), еврооблигацияләр һ. б.) урнаштырып, алар өчен акча алып тора башлый. 1997 елда, бу базарларның эчке мөмкинлекләре тулысынча сарыф ителеп беткәч, кыйммәтле кәгазь базарлары тулысы белән чит ил финансистлары өчен ачыла. Нәтиҗәдә дәүләт секторының тышкы базардан үзләштергән средстволары — 2 тапкыр, дәүләт кәгазьләренә портфельле инвестицияләр 8 тапкыр арта, болар барысы да Россиянең тышкы бурычы үсүгә китерә.

Бу процессларга реакция күз ачып йомганчы була. 1997 елда ук Россиядән чит ил капиталы күпләп чыгарыла башлый, дәүләт облигацияләре Россия банкына аларны АКШ долларына һәм башка валюта алыштыру таләбе белән кайтарылалар. Хөкүмәт һәм Үзәк банк үзләренең бурычлар түләргә сәләтсез

икәнен белдерергә мәҗбүр була, ягъни дефолт игълан ителә. Кискен финанс кризисы хөкем сөрә: рубль девальвацияләнә, бик күп финанс фирмалары юкка чыга, чит ил инвесторларының Россиягә ышанычы югала. Аның эпицентры 1998 елга туры килә.

Шулай да 1998 елгы финанс кризисының каршылыклы характерын да билгеләп үтәргә кирәк. Девальвация бер үк вакытта макроикътисади стабильләшү факторы да була. 1998 елдан соң импортның кимүе милли сәнәгатьнең үсеп китүенә сәбәп була, чөнки тышкы конкурентның басымы үз көчен югалта. Дөньяда нефть бәяләренең кискен ыргылуы белән экспорт товарларының конкурентлык сәләте үсү дә бюджет керемнәрен (бигрәк тә энергия чыганакларын таможнядан чыгару пошлиналарыннан) һәм алтын-валюта резервларын арттыра. 1992 елдан соң беренче тапкыр предприятиеләргә инвестицияләр үсә, инфляция темплары кими, халыкның реаль керемнәре арта.

Структур үзгәртеп корулар

Базар системасына күчүнең беренче этабында, макроикътисади стабильләштерүгә юнәлтелгән чаралар белән бергә, структур үзгәртеп корулар да үткәрелә. Аларның асылы, беренчедән, икътисадның тармак структурасын камилләштерү, икенчедән, милек өлкәсендә үзгәртеп корулар, базар системасын төзү һәм үстерүнең нигез ташы булган шәхси милекне формалаштыру мәсьәләләрен хәл итә торган чаралар комплексы ята.

Әле хәзергә кадәр Россиядә тармак структурасы яшәп килә, аңа нефть, газ һәм башка файдалы казылмалар чыгару сәнәгатенең югары рентабельле тармаклары (алар үз продукциясен күбрәк экспорт өчен әзерли), шулай ук экспортка йөз тотучы металл һәм химикатлар җитештерү тармаклары керә. Металлургия һәм химия сәнәгатенең конкурентлык сәләте аларның арзанлы электр энергиясен куллануы белән аңлатыла. Машиналар төзү комплексына кергән күпчелек предприятиеләрнең (станоклар төзү, автомобильләр сәнәгате, көнкүреш техникасы җитештерү һ. б.) продукциясе конкурентлык сәләтенә ия түгел. Ә инде хәрби сәнәгать комплексына килсәк, аның продукциясенә дөнья базарларында сорауның зур булуын бәяләрнең

арзанлыгы гына түгел, сугыш техникасының югары сыйфаты да билгеле.

Икътисадның тармак структурасындагы моннан соңгы үзгәртүләр илне үстерүнең халык хуҗалыгы планнары базар механизмы нигезендә алып барылырга тиеш. Шунлыктан структур үзгәртеп коруларның иң әһәмиятле юнәлешләреннән берсе булып дәүләт милкен хосусыйлаштыру тора.

Хосусыйлаштыруның төп бурычлары: конкурент мохит тудыру, рациональ хуҗалык итәргә һәм житештерүчәнлекне күтәрергә омтылган хосусый милекче тәрбияләү; дәүләт зыянга эшли торган предприятиеләргә ярдәм итүдән коткару, хосусыйлаштырудан килгән средстволар һәм хосусыйлаштырылган милеккә салым хисабына бюджет керемнәрен үстерү, инвесторлар (шул исәптән чит илләрдән) җәлеп итү.

Россиядә кече хосусыйлаштыру дип аталган хәл сәнәгатьтә, төзелеш, сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәтендәге кечерәк предприятиеләргә кагылды. Ул күбесенчә, милекне коммерция һәм инвестиция конкурсларында һәм аукционнарында сатып алып, ябык акционерлык җәмгыятьләре яки индивидуаль хосусый предприятиеләр оештыру, шулай ук арендага алынган мөлкәтне сатып алу юллары белән гамәлгә ашырыла.

Россиянең күчеш икътисадында урта һәм эре дәүләт предприятиеләрен хосусыйлаштыру барышы югары үскән илләрдәге (мәсәлән, Англиядә хөкүмәт башында М. Тэтчер торганда) дәүләт секторы предприятиеләрен хосусыйлаштырудан күпкә аерыла. Күп кенә алга киткән һәм үсеп килүче илләрдә предприятиеләр башта дәүләт хисабына тернәкләндереп һәм реаль базар бәяләре буенча сатыла, еш кына сатып алучыларга кредитлар да бирелә. Безнең илдә предприятиеләргә реаль базар бәясе дә куелмый, сату алдыннан дәүләт хисабына тернәкләндерү дә булмый кала. Шулай ук дәүләт милкенең эре объектларын сатып алырлык средстволарга ия булган сатып алучылар да күренми. Дәүләт предприятиеләрен башта акцияләргә бүлеп, аннан соң бу акцияләрне сату перспективасыз эш дип карала, чөнки инфляция халыкның керемен арзанайтып бетергән була инде.

Шунлыктан урта һәм эре предприятиеләрне хосусыйлаштыру (эре хосусыйлаштыру) аларны ачык акционерлык җәмгыятьләре итеп үзгәртүгә кайтып кала. Предприятиенең

хезмәт коллективы әгъзаларына хосусыйлаштыруның берничә схемасы тәкъдим ителә, һәм аларга акцияләр шуның кысаларында гына бирелә. Моннан тыш, Россия халкына бушлай ваучерлар — хосусыйлаштыру чеклары таратыла. Махсус чек аукционнарында ваучер ияләре аларны теләсә кайсы урта һәм эре предприятие акцияләренә алыштыра алалар. Бу эшне әлеге предприятие акцияләренең билгеле бер өлешен анда эшләүчеләргә бүлеп биргәннән соң гына эшләргә рөхсәт ителә, шулай да акцияләрнең кимендә өчтән бере ваучерларга алыштырылырга тиеш була. Бер ваучерга бирелә торган акцияләр саны хосусыйлаштыру чекларын нәкъ менә шушы предприятие акцияләренә салырга теләүчеләр саны һәм ваучерга алышу өчен бүлеп бирелгән акцияләр пакетының күләме белән билгеләнә.

Хосусыйлаштыру чекларын акцияләргә генә түгел, инвестиция фондларының кыйммәтле кәгазьләренә дә алыштырырга мөмкин була. Бу фондлар хосусыйлаштырылган предприятиеләрнең шактый зур акция пакетларын җыйнау һәм фондлар базарында алар белән идарә итү өчен төзелгән була. Ваучерларын инвестиция фондлары акцияләренә салган гражданнар шушы предприятиеләр түләгән дивидендларга исәп тоталар. Ниһаять, хосусыйлаштыру чеклары, аларны сатып алып, алдагы елларның берәрсе буенча урнаштырырга теләүче теләсә кемгә акчага сатып җибәрергә мөмкин була.

1994 елда чеклар буенча хосусыйлаштыру тәмамлана, һәм ТЭПның 70% чамасы хосусый секторда яки акцияләренең бер өлеше дәүләт кулында калган предприятиеләрдә җитештерелә.

Россиядә үткәрелгән хосусыйлаштыруга хас булган күп санлы тискәре күренешләрне әйтми калу мөмкин түгел. Мондый хосусыйлаштыруга каршы килүчеләр түбәндәгеләрне аерып күрсәтә:

- хосусыйлаштыру икътисади эффективлылыкны исәпкә алмыйча үткәрелә. Предприятиеләр артык түбән бәяләнә, һәм аларны сату дәүләт бюджетына зур керемнәр китерми;
- предприятие директорлары үз кулларында бик зур акция пакетлары туплап кала. Башта 10% тирәсе акция алып, соңыннан зур пакетлар, шул исәптән предприятиедә эшләүчеләрнең (аларда 50% лап акция була) акцияләрен

дә сатып алырга өлгерәләр, шунлыктан акционерларның төп массасы алар өстеннән күзәтчелек итә алмый. Шул ук вакытта аларның күбесеннән эффектив милекче чыкмый, күбесе предприятиенең үсеше турында кайгырта белми.

— хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә халыкның күпчелеге, шул исәптән хосусыйлаштырылган предприятиеләрдә эшләүчеләр дә, элегрәк дәүләтнеке саналган милекнең реаль хуҗалары була алмыйлар;
— массакүләм мәгълүмат чараларында актив реклама алып барылса да, ваучерларны инвестиция фондындагы кыйммәтле кәгазьләргә салу эффектлы булмый;
— хосусыйлаштыру технологик модернизациягә һәм инвестицияләрне үстерүгә алып килми;
— кече хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән кече бизнесның үсеше эффектив булмаган салым системасы һәм дәүләт ярдәме булмау нәтиҗәсендә тоткарланып тора.

Ваучер хосусыйлаштыруы яклылар шул шартлардагы Россиядә реаль альтернатива, асылда, юк иде, диләр. Әле 1980 еллар ахырыннан бирле предприятиеләр җитәкчелеге, нигездә, предприятие эшчәнлеген контрольдә тотты, әмма алар күбесенчә зыянга эшләгәнлектән, формаль яктан дәүләтнеке булуларын һәм дәүләт бюджетыннан субсидияләр алуын дәвам иттеләр, ә инфляция белән көрәш шартларында бу болай озак бара алмас иде дип аңлаталар.

Ваучер хосусыйлаштыруы яклылар аның беренче этабында финанс аспекты мөһим түгел, һәм эффектив милекчеләр барлыкка килү — дәвамлы процесс, ул — конкурентлык нигезендә милекне яңадан бүлү һәм, акрынлап, капитал туплану нәтиҗәсе дип исәплиләр. Кагыйдә буларак, ул вакыттагы предприятие җитәкчеләре дә, анда эшләүчеләр дә эффектив милекче була алмыйлар иде, чөнки алар җитештерүне инвестицияләүгә түгел, керемнәрне «ашап бетереп» барырга омтылдылар дип аңлаталар.

Сәүдәдә, җәмәгать туклануында һәм көнкүреш хезмәтендәге кече хосусыйлаштыруга килгәндә, халыкның бик күп өлеше моннан файда таба, чөнки кече бизнес үсеше күп сандагы гаиләләрнең керемнәре үсүгә һәм яңа эш урыннары барлыкка килүгә, шулай ук товар базарын туендыруга ярдәм итә.

1994—1995 елларда, бюджет дефицитын киметү өчен, дәүләт акцияләрен акчага сату җәелеп китә. Акцияләр инвестицияләр һәм коммерция конкурсларында инвестиция шартлары белән, ягъни сатып алучының инвестицияләр кертелер дигән вәгъдәсе, нигездә, сатыла (еш кына бу вәгъдәләр үтәлми кала). Моннан тыш, дәүләт бюджетының дефицитын каплау өчен, хөкүмәт залог аукционнарын — коммерция банкларыннан, аларга эффектив предприятиеләрнең дәүләт карамагындагы акция пакетларын биреп торып (залог), кредитлар алуны практикага кертә («Норильский никель», ЮКОС, «Сибнефть» һ. б.). Кредит срогы узганнан соң, хөкүмәт, биреп торылган акцияләрен сатып, банкка кредитын кайтарырга тиеш була. Кредит кайтарылмаса, акцияләр банк мөлкәте булып кала.

Залог аукционнарын тәнкыйтьләүчеләр мондый алыш-бирешләрне күз буяу дип саный, чөнки аукционнар формаль уза, һәм предприятиеләрнең акцияләре искиткеч түбән бәяләнә, ә кредитор-банкларда кредит ресурслары акцияләр өчен алынган средстволарны шушы ук банклардагы бюджет счетларына күчергәннән соң барлыкка килгән, диләр. Моннан тыш, икенче ел бюджетында, банк кредитларын каплау өчен, средстволар каралмый. Нәкъ менә залог аукционнары нәтиҗәсендә илдә олигархия структуралары — чамасыз байлар, Россия икътисадының тулы секторлары монопольләштергән һәм тышкы базар операцияләрендә актив катнашучы эре предприятие хуҗалары төркемнәре барлыкка килә. Җәмгыять бу алыш-бирешләрнең социаль гаделсезлеген үзендә тоя, һәм бу олигархияләр мөлкәтен хокукый һәм мораль яктан тотрыксыз итә. Мондый тотрыксызлык эре милекчеләрнең капиталны читкә чыгарырга омтылуы, капиталын предприятие үсешенә салырга теләмәү, салымнардан качу кебек күренешләрне китереп чыгара.

Структур реформаларның һәм конкурентлы мохит формалаштыруның әһәмиятле элементы — икътисадны демонопольләштерү. Советлар Союзы шартларында эчке базарга сыйдырышлы һәм масштабларда экономияләү мөмкин булганлыктан, эре предприятиеләр һәм хуҗалык комплекслары үзләрен икътисади яктан аклаган. Әмма алар дәүләт хакимиятенең каты куллы идарәсе астындагы дәүләт монополияләре булган.

Хосусыйлаштыру барышында дәүләт монополияләре дәүләтнеке булмаган монополистик структуралар итеп үзгәртелә, алар, базарда үз урыныннан файдаланып, монополь югары табыш алырга һәм керемнәрен яшереп калырга мөмкиннәр. Трансферт бәя куюлар һәм эшчәнлекнең аерым төрләрен базарның башка сегментларындагы югары табыш хисабына төрле яклап субсидияләү шикелле юллар белән компания финансларын бутап күрсәтергә була.

Монополизм белән көрәшү өчен, түбәндәге чаралар эшләнелә: бәйсез житештерүчеләргә бүленү (мәсәлән, РАО ЕЭСны реформалау барышында генераль компанияләрне мөстәкыйль конкурент җитештерүчеләргә һәм реаль электр энергиясе базары булдыру күздә тотыла), тимер юл транспортында дәүләт һәм хуҗалык функцияләре бүленеше, күрсәтелгән тармакларда конкурент секторларны аерып алу, төрле яклап субсидияләү юлы белән тотылып торган социаль сфера учреждениеләрен, ярдәмче һәм хезмәт күрсәтү предприятиеләрен хосусыйлаштыру. Болар барысы да бизнесның үтә күренмәлелеген арттырырга һәм, нәтиҗә буларак, инвестицияләргә юл ачарга мөмкин.

Шулай да 1990 еллар тәҗрибәсе эре предприятиеләрне демонопольләштерү һәм формаль яктан ваклауның бик еш үзен акламавын күрсәтә, чөнки зур масштабларда экономияләү югала, компанияләрнең финанс яктан тотрыклылыгы кими, дөнья базарларында предприятиеләрнең конкурентлык мөмкинлеге кими, бердәм җитештерү циклын тикшереп тору күздән ычкына.

Институциональ үзгәртүләр

Институциональ үзгәртүләр — яңа хокукый институтлар төзү ул, ягъни хуҗалык итүче субъектлар өчен үз-үзен тоту кагыйдәләре һәм нормаларын эшләү, шулай ук базар икътисады субъектларының хокукый нормаларны үтәвен тәэмин итүче учреждениеләр, ягъни базар инфраструктурасын формалаштыру. Планлы-административ системаның идарә органнары һәм институтлары әлеге базар системасының боларны алыштырырлык органнарын формалаштырганчы ук юкка чыгарыла. ТЭП һәм мәшгульлекнең, базар реформаларын башлап җибәргәннән соң ук, бик түбән тәгәрәве һәм бу реформалар-

ның сүлпән баруы нәкъ менә шуңа бәйле. Институциональ үзгәртүләрнең бик әһәмиятле өлеше товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарын оештыру, фирмалар эшчәнлегенә чикләнмәгән мөмкинлекләр тудыру була; финанс ресурслары базары, кыйммәтле кәгазьләр, күчемсез милек, шулай ук җир һәм хезмәт базарлары кебек өр-яңа базарлар барлыкка килә.

Югары үсеш алган банк системасыннан башка да базар системасына күчү мөмкин булмас иде. Планлы-административ система шартларында финанс ресурслары базары, кыйммәтле кәгазьләр, күчемсез милек һ. б. төрле базарлар бетерелгән, ягъни банкларның роле һәм эшчәнлек даирәләре бик нык чикләнгән була. СССРда банк системасы дәүләт милке булып саналучы өч банкка кайтып калган була: СССР Дәүләт банкы (Госбанк) үзәк банкның кайбер функцияләрен үтәгән; Стройбанк икътисадның барлык тармакларында капиталь төзелешне финанслаган; Внешторгбанк (Тышкы сәүдә банкы) тышкы сәүдә операцияләренә хезмәт күрсәткән. Саклык кассалары челтәре дә банк системасына керә дияргә мөмкин, аның төп бурычы халыкның җыелган акчаларын үзенә җәлеп итү һәм аны Госбанк карамагына тапшыру була. Мондый гадиләштерелгән система берничек тә базар икътисады ихтыяҗларына җавап бирми.

Россиядәге базар икътисадына күчү процессында, алга киткән икътисадлы илләрдәге кебек үк, ике баскычлы банк системасы (9 нчы бүлек, 9.3 һәм 9.4) барлыкка килә.

Шул ук вакытта институциональ үзгәрешләр барышында банк системасын эшләтү һәм үстерү буенча барлык мәсьәләләр дә хәл ителеп бетми. Иң әһәмиятлесе шул: Россия Банкын да кертеп, илнең барлык банкларында тупланган капитал үзенең зурлыгы буенча Россия икътисады масштабларына туры килми, бу бигрәк тә икътисади үсеш һәм эре предприятиеләрнең җиһазланышын модернизацияләү өчен бик зур инвестицияләр кирәк булганда ачык беленә.

Тагын бер җитди проблема бар: кредитларны кире кайтару механизмының булмавы, ә инвестиция проектлары ышанычлы залог белән тәэмин ителмәү сәбәпле, банклар еш кына предприятиеләрне кредитлаудан баш тарталар. Озак вакытлы кредитлар бирү банклар өчен җитди куркынычлар тудыра, һәм шунлыктан алар югары процент ставкасы куялар, ә бу исә яңа предприятиеләр төзү һәм булганнарын реконструкцияләү өчен

инвестицияләр бирүне тоткарлый, күп очракларда инвестицияләрнең кыскаруына да китерә (12 нче бүлек, 12.4, «Процент ставкасы һәм инвестицияләр»).

Ниһаять, банк системасына 1998 елгы дефолт бик зур йогынты ясый. 1998 елгы финанс кризисы нәтиҗәсендә банк системасы зур зыян күрә, һәм 1990 елларның ахырына банк секторына инвесторлар һәм халыкның ышанычы күп тапкырлар кими.

Икътисади реформаларның башында ук, әле хосусыйлаштыру процессы җәелеп китеп, ачык акционерлык җәмгыятьләре төзелә башлауга, Россиядә фондлар базары барлыкка килә. Дәүләт һәм корпорацияләр акцияләре һәм облигацияләре базарында банклардан тыш эш йөртүче финанс институтлары — инвестиция компанияләре, инвестицион пай компанияләре, страховкалау (иминият) компанияләре бик тиз үсә башлый. Финанс базарының либеральләшү дәрәҗәсе инде банкара кредит һәм валюта базарында, дәүләтнең һәм корпоратив кыйммәтле кәгазьләре базарында операцияләр үткәрү өчен мөмкинлекләр тудыра. Әмма Россиянең финанс базары әле начар үскән була, чөнки эмитентларның финанс хәле кыенлашу яисә дивиденд сәясәтенең астыртын алып барылуы (дивидендлар түләнергә тиешле табыш күрсәтелми) нәтиҗәсендә, корпоратив облигацияләрнең һәм акцияләрнең 80% ка кадәре хәрәкәтсез ята яисә аз керемле була.

Базар реформаларының башлангыч этабында ук хезмәт базарында да радикаль институциональ үзгәрешләр булып уза. Планлы-административ икътисад шартларында шактый кысылып килгән хезмәткә тәкъдим иреге киңәя. Эшләүчеләр беренче административ чикләүләрсез акча эшләү мөмкинлеге ала. Товар дефициты артта кала барган саен, матди байлык бик күп кешеләрнең эшчәнлеген хәрәкәткә китерүче стимулга әверелә бара. Акрынлап торак базары үсә башлый, чит илләрдә эшләү мөмкинлекләре киңәя. Эшмәкәрләр, товар базары конъюнктурасына, файдаланыла торган технологияләргә һәм предприятиенең базарда торган урынына карап, үзләренең хезмәткә соравын ирекле формалаштыра. Хезмәт хакы үсеше чикләнми, югары һәм урта уку йортларын тәмамлаучыларның эшкә җибәрелүе үзәкләштерелми, файдасыз хезмәткәрләрне эштә тотарга мәҗбүр итә торган штатлар расписаниесе юкка чыгарыла һ. б.

Шул ук вакытта җитештерү түбәнәйгән чорда хезмәт базарын либеральләштерү бик зур масштабларда озакка сузылган эшсезлеккә сәбәп була. Ә бу — хезмәт базарында дәүләт эшчәнлегенең активлашуына, шушы базарда аның көйләүче сыйфатында активлыгы үсүгә китерә. Дәүләт эш белән тәэмин итү хезмәте төзелеп, аның төп функцияләре билгеләнә: эшсезләрне теркәү, вакансияләр турында мәгълүмат җыйнау һәм аны тәкъдим итү, эш сайлап алуда арадашлык итү, эшләүчеләргә профессиональ белем бирү һәм яңа эшкә әзерләү, эшсезлек буенча пособиеләр һәм эштән азат ителүчеләргә компенсацияләр түләүне оештыру. Дәүләт минималь хезмәт хакын, гадәти эш атнасын һәм отпусклар озынлыгын, хезмәт шартларын билгели һ. б.

Акрынлап социаль партнерлык — эшләүчеләр, эш бирүчеләр һәм дәүләт хакимияте органнары арасында үзара мөнәсәбәтләр системасы үсә, һәм ул эшләүчеләр белән эш бирүчеләр мәнфәгатьләре килешүен тәэмин итә.

Шул ук вакытта хезмәт базарының бик күп институтлары хәзерге көнгә кадәр төзелеп бетмәгән яисә начар үскән, мәсәлән, эффектив булмаган, ләкин шәһәр тотучы предприятиеләрне ябу проблемасының кискенлеге күбесенчә эш көченең җитәрлек дәрәҗәдә мобиль булмавына бәйләнгән, ягъни икътисадның базарга катнашы булмаган секторы бюджет субсидияләре хисабына тотыла.

Авыл хуҗалыгында институциональ реформалар эффектив җир базары булдыру, җиргә милекчелек хокуклары системасын формалаштыру, авылда эффектив хуҗалык оешмалары оештыру белән бәйләнгән.

СССРда барлык җир дәүләтнеке була, ә авыл хуҗалыгы предприятиеләре (колхозлар һәм совхозлар) аннан бушлай һәм сроксыз файдаланалар. Дәүләт җитештерүне планлаштыра, колхоз һәм совхозларга техника һәм ашламалар бүлә, ә алар бу ресурсларны арзанлы дәүләт кредитлары исәбенә сатып ала. Дәүләт шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясенең төп өлешен үзе сатып ала. Бәяләр табигать һәм климат шартларына карап билгеләнә: авыл хуҗалыгы предприятиесе урнашкан урында бу шартлар начаррак булган саен, сатып алу бәяләре югарырак куела.

Колхоз һәм совхозлар эшчәнлеген дәүләт карамагында тоту һәм эшләүчеләрне җирдән читләштерү теләге хезмәткә карата

стимулны юкка чыгара, һәм аграр сектор, дәүләтнең субсидияләр, арзан кредитлар югары сатып алу бәяләре рәвешендә ярдәм итүенә карамастан, бик тиз артка китә. Илдә авыл хуҗалыгы продуктлары дефициты арта. Ул шулай ук азык-төлекнең бюджет дотацияләре хисабына арзан тотылуы белән дә бәйләнгән.

Базар системасына күчү аграр секторда радикаль үзгәрешләр ясауны таләп итә. Предприятиеләр җирләренең һәм мөлкәтенең зуррак өлешен колхоз һәм совхозларның хезмәт коллективына коллектив-өлешчә милек итеп тапшыра, ә ул эшләүчеләр арасында пайлар рәвешендә бүленә. Бу — эшләүче кешегә авыл хуҗалыгы предприятиесеннән үз өлешен алып чыгу мөмкинлеге бирә. Алар кооперативлар, ширкәтләр, коллектив милекнең башка формасындагы предприятиеләр оештыра башлый яки фермерлар булып китә.

Фермерлар пайга алган үз җирен эшкәртү белән чикләнергә дә, башкаларның җир пайларын арендаларга яки сатып алырга да мөмкиннәр. Авыл хуҗалыгы җирләренә дәүләти булмаган милек өлеше инде 1995 елга — 70%, ә сөрү җирләре 80% ка җитә. Хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы продукциясенең иң күп өлешен дәүләт, шулай ук шәхси эшкәртү һәм арадашлык итү компанияләре сатып ала. Авылда кооператив кредит оешмалары да төзелә. Дәүләт, гарантияләнгән сатып алу бәяләренең дәрәҗәсен билгеләү, шулай ук азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы чималы импортын көйләү юлы белән, авыл хуҗалыгы секторына ярдәм итәргә тырыша.

Әмма авыл хуҗалыгының үсеш темпларын радикаль тизләтү өчен, җир әйләнеше, ягъни аны сатып алу-сату турында, аренда һәм залог турында законнар кабул итәргә кирәк, шуннан соң гына җир турындагы килешүләр һәм алыш-бирешләр хокукый көченә керә.

Социаль сферадагы үзгәртүләр

Базар икътисадының үсеше, әле реформаларның башлангыч этабында ук, хезмәткә сәләтле халыкның социаль җаваплылыгын күтәрә, ул хәзер дәүләт ягыннан патернализм иллюзияләреннән акрынлап арына бара. Үз керемнәренне үзең үстерү мөмкинлеге (һәм зарурлыгы) туа. Үзәктән планлаштырыла торган икътисадка хас булган тигезләп бүлү юкка

чыга; дәүләт хисабына түгел, күбрәк шәхси керемнәр хисабына гаиләнең муллыгын арттыру мөмкин була. Бу матди ихтыяҗларны гына түгел, белем алу, сәламәтлекне ныгыту, пенсия яшендә лаеклы тормыш дәрәҗәсен гарантияләү кебек социаль ихтыяҗларны да канәгатьләндерүгә карый.

Ләкин базар икътисадына күчү, нәкъ көтелгәнчә, халыкның керемнәрендә аеруча кискен аермалар (дифференциаллаштыру) китереп чыгара. Бер яктан, халыкның күпчелегенең, бигрәк тә дәүләт бюджетыннан финанслана торган предприятие һәм оешмаларда эшләүчеләрнең, пенсионерларның, күп балалы гаиләләрнең, инвалидларның реаль керемнәре бөтенләй азая. Бәяләрне ычкындыру аркасында саклык акчаларының бәясе юкка чыга, һәм ул хәтта иң кирәкле, социаль яктан әһәмиятле товар һәм хезмәт күрсәтүләргә булган ихтыяҗны да кискен киметә. Базарга күчү реформаларының беренче стадиясендә үк ярлылар саны бик күпкә арта, аларның кереме яшәү минимумыннан да түбәнәя. Кайвакытларда дәүләтнең һәм шәхси фирмаларның эш хакын вакытында түләмәве ситуацияне тагын да катлауландыра.

Бер үк вакытта кайбер төркемнәрнең байлыгы бик тиз артып китә. Алар арасында икътисадның экспорт һәм югары монополияләштерелгән секторлары кебек урыннарда аеруча эффектив эшләүче эшмәкәрләр һәм ялланып эшләүчеләр генә түгел, баю өчен, законнар системасының йомшаклыгыннан файдаланып, керемнәрен күләгәдәге икътисадтан алучылар да бар. Әгәр 1991 елда 20% иң бай гаиләгә акчалата керемнәрнең 30,7% ы туры килсә, 1999 елда бу 46,9% тәшкил итә, ә инде 20% иң ярлы гаиләнең өлеше 5,5% була.

Мондый ситуациядә дәүләтнең иң начар тәэмин ителгән халык катлауларына — пенсионерлар, инвалидлар, эшсезләргә ярдәм итү зарурлыгы кискен көчәя. Ләкин салымнарның начар җыйналуы, бюджет дефициты, социаль страховкалау фондына взносларның кимүе реформаларның беренче этабында гаилә пособиеләрен, пенсияләрне арттырырга, торак-коммуналь хезмәтенә, җәмәгать транспортына түбән бәяләр һәм тарифлар тоту өчен субсидияләр түләргә мөмкинлек бирми. Шуңа күрә бәяләр һәм тарифлар күтәрелүгә канәгатьсезлек көчәеп китмәсен өчен, натураль өстенлекләр саны бик тиз артып китә (җәмәгать транспортында бушлай йөрү хокукы, торак-коммуналь хезмәткә түләү буенча өстенлекләр, шифаханәләрдә

дәвалану һ. б.). Әйтергә кирәк, алар бик еш сүздә генә кала, бюджет финанславы җитәрлек дәрәҗәдә булмый. Шуның өстенә мондый өстенлекләрдән халыкның барлык катлаулары да файдалана алмый. Бюджет финанславының җитәрлек булмавы җәмәгать транспортының тиз тузуына, торак-коммуналь хезмәтенең түбән төшүенә китерә.

Шулай да реформаларның беренче этабында ук социаль сәясәт өлкәсендә эшләнгән кайбер чаралар дәүләтнең халыкка билгеле бер күләмдә ярдәм итүе белән социаль байлыкларның күпмедер өлешен базар принциплары буенча бирүне бергә кушарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, сәламәтлекне саклау өлкәсендә реформаларның беренче этабында ук медицина хезмәтен страховкалау системасына күчү башлана, аңа гомуми мәҗбүри медицина страховкасы, шулай ук гражданнарның һәм эш бирүчеләрнең страхование компанияләренә кертелгән взнослары хисабына ирекле страховкалау керә, ә бушлай медицина хезмәте формасындагы дәүләт гарантияләре барыбер сакланып кала. Пациентлар билгеле бер минимум күләмендәге медицина хезмәтен бушлай ала һәм медицина учреждениесе сайлап алу хокукына ия, бу очракта страхование компанияләре дәвалау өчен акчаларны шунда җибәрә.

Торак-коммуналь хуҗалыкта бюджет дотацияләре өлеше акрынлап кими һәм гаиләләрнең торак-коммуналь хезмәткә түләү буенча чыгымнары арта, бер үк вакытта аз керемле гаиләләргә компенсацияләр бирелә. Аз керемле гаиләләргә һәм халыкның кайбер катлауларына хәзергә әле муниципаль торак бирү гарантияләнә, ләкин торакны гражданнарның акчалары һәм банк кредитлары хисабына төзү үсеш алып бара.

Мәгариф өлкәсендә Россиядә дәүләт бушлай һәм конкурс нигезендә гомуми урта һәм югары профессиональ белем алу мөмкинлеген гарантияли. Шул ук вакытта әле реформаларның беренче этабында ук гаиләләр өстәмә, төп укыту планнары кысасыннан тыш, гимназияләр, лицейлар һәм тирәнтен белем бирүче башка мәктәпләр хезмәтен финанслау, шулай ук югары һәм урта махсус уку йортларында түләп укыту мөмкинлеге алды.

Гомумән, социаль ярдәм итү системасы адреслы принцип нигезендә вәгъдә ителә, бу вакытта, бюджет мөмкинлекләреннән чыгып, социаль мохтаҗлык кичерүче, ягъни керемнәре һәм куллану дәрәҗәләре яшәү минимумыннан түбән булган,

гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтелергә тиеш. Бер үк вакытта социаль яктан якланмаган өстенлекләр бетерелә. Һәм ул, яхшы тәэмин ителгән гаиләләргә ярдәмне киметеп, социаль мохтаҗлык кичерүче төркемнәрне яхшырак яклауга китерәчәк.

19.2. РОССИЯНЕҢ ИКЪТИСАДИ ҮСЕШЕНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ЭТАБЫНДА БАЗАР ҮЗГӘРТҮЛӘРЕ

Россия үсешенең хәзерге этабы узган гасыр ахырында башланган базар үзгәртүләре дәвам итү һәм тирәнәйтү белән характерлана. Бу яңа этапның башлангычы макроикътисади стабильләштерү, базар икътисады нигезләренең төзелүе, инвестицияләр артуы нигезендә җитәрлек дәрәҗәдә кызу һәм тотрыклы икътисади үсеш стадиясенә күчү белән билгеләнә. 2003—2004 елларда еллык артым темплары ТЭПның — 7% тан, ә төп капиталга инвестицияләрнең 12% тан артып китә.

Стабильләштерү процессын тәгәлләү факторлары

XXI гасыр башында Россиядә, макроикътисади стабильләштерү процессын тәгәлләп, тотрыклы икътисади үсешкә керешүнең нигезен тәшкил итүче эчке һәм тышкы факторлар арасында түбәндәгеләр бар:

— рубльнең валюта курсы төшә, һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, экспорт товарларының конкурентлык сәләте көчәя, җиһазлар һәм куллану товарлары импортына бәяләр арта, эчке базарда импортны алыштыру мөмкинлеге үсә (мәсәлән, азык-төлек сәнәгате тармакларында);

— уңайлы тышкы икътисади конъюнктура — Россиянең төп экспорт товарларына бәяләр арту (барыннан да элек, энергия чыганакларына);

— инвестицион климатның беркадәр яхшыруы һәм чит ил капитал салуларының үсеше;

— предприятиеләрнең табышлары һәм инвестицияләр өчен мөмкинлекләре арта, чөнки аларның хезмәт хакына һәм энергия ресурсларына тотылган чыгымнарының реаль бәясе зур түгел, гомуми материаль чыгымнарда кыйммәтле чит ил чималының өлеше аз (билгеле булганча, Россиянең табигый байлыклары чиксез күп);

— предприятиеләр ярышып эшли белә башлый, бигрәк тә җиңел һәм азык-төлек сәнәгатьләрендә чит ил җитештерүчесе белән дә, үзебезнекеләр белән дә ярышырга туры килә. Предприятиеләр үсеш мөмкинлекләреннән файдаланырга өйрәнә. Алар күбесенчә гадәти акча әйләнешенә ориентлаша, бартер алыш-биреше, продукция өчен вексельләр белән түләү арттa кала.

Макроикътисади стабильләштерү һәм икътисади үсеш

Икътисади үсеш акча массасы арту белән бергә бара. Базар икътисады нигезләрен төзү этабында макроикътисади стабильлеккә ирешү һәм инфляция белән көрәшү катгый кредит-акча сәясәте ярдәмендә алып барыла. Хәзерге вакытта акча массасының артуы 90 нчы елларда күзәтелгән бәяләр артуга алып бармый. Акча тәкъдименең үсүе халыкка номиналь керемнәре үсү, Россия банк системасының ышанычын арттыру юнәлешендә реформалау, халыкның саклык акчаларын инвестицияләргә кертүдә банкларның роле арту кебек процесслар белән билгеләнә.

Ләкин икътисадта инфляция көчәю куркынычы саклана әле. Беренчедән, Россия товарларына экспорт бәяләренең үсүе валюталы акча кереме артуга китерә, аның бер өлешен экспортер предприятиеләр эчке валюта базарында сатарга тиешләр. Нәтиҗәдә илнең алтын-валюта резервлары үсә, һәм 2004 елның ахырына алар инде 120 млрд доллардан артып китә. Валютаның артыклыгы рубльнең реаль курсы үсүгә китерә. Бу экспортерлар мәнфәгатьләренә туры килә, дөнья базарында аларның продукциясе кыйммәтләнә бара. Шуңа күрә Үзәк банк валютаны валюта базарында икътисадка керүче рубльләргә сатып ала, һәм, әгәр алар стерильләштерелмәсә (мәсәлән, стабилизация (тотрыклылык) фондына җибәрелмәсә яки дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләре тәкъдиме белән бәйләнмәсә), бәяләр үсүне китереп чыгарырга мөмкин. Шулай итеп, Үзәк банк бер үк вакытта капма-каршы ике мәсьәләне хәл итәргә тиеш: инфляцияне киметү һәм шул ук вакытта милли валютаның көчәюенә тоткарлык ясау.

Икенчедән, бәяләр артымынын күпмедер өлеше (якынча 20—30%) элеккечә икътисадта монополияләштерелү дәрәҗә-

сенең югары булуына, табигый монополияләрнең бәяләр һәм тарифларны арттыруына бәйле.

Макроикътисади стабильләшүгә ирешү шартларында хөкүмәт икътисади үсеш темпларын тагын да тизләтү бурычын куя. Шунлыктан базар үзгәртүләрен элеккечә дәвам итәргә генә түгел, тагын да активлаштырырга тиешләр.

Беренче чиратта дәүләт структураларының фирмалар хуҗалык эшчәнлегенә бюрократик катышуын җиңәргә кирәк. Хәзергә кадәр бизнесны оештыру, бигрәк тә эшмәкәрлек, предприятиене теркәү, аның эшчәнлегенә лицензия бирү, җитештерелгән товарларын сертификацияләү һ. б. кебек ясалма рәвештә катлауландырылган һәм кыйммәткә төшә торган бик күп процедуралар үтүне таләп итә.

Икътисади үсешнең тышкы икътисади конъюнктурага бәйлелеген булдырмауда дәүләтнең ролен күтәрү зарурлыгы икътисадта либеральләштерүне тагын да дәвам итү кирәклеген раслый. Нефтькә дөнья бәяләре һәрвакыт югары булып тормаячак. Моннан тыш, икътисади үсештә төп финанслау чыганагы буларак чимал секторына таяну — озак сроклы, перспективада нигезсез чара, чөнки бу, чимал секторының гадәттән тыш үсүенә китереп, ил икътисадындагы структур үзгәрешләрне тоткарлаячак. Шуның өстенә экспорт структурасы үзе үк диверсификациягә, ягъни читкә чыгарыла торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең ассортиментын киңәйтүгә мохтаҗ. Аеруча зур рольне фән сыйдырышлы продукция җитештерү һәм экспортлау уйнарга тиеш. Хәзергә яңа товарлар эшләп чыгара торган югары технологияле сәнәгать тармаклары, капитал салулар җитмәгәнлектән, түбән темплар белән үсә. Россия, нигездә, түбән һәм уртача технологияле продукция экспортлый.

Шул ук вакытта алда әйтелгәннәр Россиянең чагыштырмача өстенлекләреннән һәм аның ягулык-чимал ресурслары экспорты буенча специальләшүеннән баш тартуны аңлатмый. Киресенчә, чимал табуда һәм транспортлауда югары технологияләр куллану һәм аның тирәнтен эшкәртелешен тәэмин итү, машиналар һәм приборлар төзүнең, яхшы сыйфатлы металлургия, химиянең тиндәшле тармакларын үстерү көнүзәк мәсьәләләр булып тора.

Соңгы вакытта төп капиталга инвестицияләр зур темплар белән артып бара. Ләкин дәүләт инвестицион процесска ярдәм итә торган сәясәт булдырырга һәм шуны үткәрергә тиеш.

Икътисади үсешнең инновацион нигезләрен салу өчен, аерым алганда, кече һәм урта бизнеска инновацион эшчәнлекләрендә ярдәм оештырыла, дәүләт средстволарын җәлеп итеп, технопарклар, фәнни шәһәрчекләр, инновацион эшчәнлек өчен уңайлы климат тудырылган махсус икътисади зоналар оештырыла. Кече һәм урта инновацион бизнеска карата салым сәясәтенең йомшару ихтималы бар. Инновацион фирмаларның эшчәнлеге, фәнни эшләрне тизрәк гамәлгә кертү максатында, фәнни учреждениеләр эше белән ешрак бәйләнешкә керә бара.

Прокуратура һәм суд органнары вәкилләре фикеренчә, салым системасын оптимальләштерүнең законсыз юлларын куллана торган базар эшлеклеләре бар, һәм аларга карата административ чараларны кискенрәк куллану таләп ителә. Шуңлыктан хәзер либеральләштерү темплары проблемасы һәм базар мөнәсәбәтләрен көйләүдә дәүләтнең роле аеруча актуальгә әйләнеп бара. Салым системасы законнарын камилләштерү салымнарны оптимальләштерүнең законлы юлларын һәм бу системадан законсыз тайпылышларны төгәл билгеләргә ярдәм итәчәк.

Шунысын әйтергә кирәк: Россиядә инвестицион климатның бозылу куркынычы һәм тәвәккәллек административ һәм суд реформаларының төгәлләнмәве, милек хокукын һәм суд карарларының үтәлешен гарантияли торган законнарның эффектив булмавы белән бәйләнгән.

Хәзерге этапта хосусыйлаштыру

Хосусыйлаштырылган предприятиеләрнең дәүләт милке булып калган акцияләрен сату мәсьәләсе аеруча актуальгә әйләнгәнлектән, икътисади үсешнең хәзерге этабында хосусыйлаштыру элеккечә зур роль уйный. Шулай ук дәүләт унитар предприятиеләренең дә бик күбесе, рентабельле булмаганлыктан, акционерлаштыру көтә. Мондый предприятиеләрнең эшчәнлеге, кагыйдә буларак, дәүләтнең үз функцияләрен үтәве белән бәйләнмәгән (мәсәлән, милли куркынычсызлыкны тәэмин итү). Алар, 100% акциясе дә дәүләтнеке итеп, акционерлык милкенә тапшырыла, аннан соң хосусыйлаштырыла. Әһәмиятле дәүләт эшләрен үти торган оешмалар казна предприятиеләренә әверелергә тиеш.

Базар реформаларының башлангыч этабыннан аермалы буларак, дәүләт үз милкен хосусыйлаштырудан һәм файдаланудан, шул исәптән федераль милек булып саналучы акцияләргә дивидендлар түләүдән керем ала һәм бюджетта бу керемнәр артканнан-арта бара.

Хәзерге структур реформаларның әһәмиятле юнәлеше булып икътисадның шәхси секторындагы кушылулар һәм йотылулар нәтиҗәсендә Россиядә эре корпоратив оешмалар формалашу тора. Мондый процесслар вертикаль буенча (чимал, эшкәртү, сату, финанслау юнәлешендәге предприятиеләр берләшә, һәм бизнесның тотрыклылыгы ресурслар һәм сатуның стабильлеге белән тәэмин ителә) һәм горизонталь буенча (бизнес тотрыклылыгына ирешелә) үсә. Бизнес масштабларын эреләндерүгә бәйле рәвештә, аның ачыклыгы, хуҗалык эшчәнлегенә эффектив салымнар салу, капиталны чит илләргә законсыз чыгаруны туктату, корпоратив идарәне, дивидендлар сәясәтен һ. б.ны камилләштерү тагын да актуальрәк була бара.

Институциональ реформаларның дәвамы

Базар үзгәртүләренең яңа этабында институциональ реформалар бик күпкә алга китә. Салым кодексы кабул ителә, салым системасында шактый зур реформалар үткәрелә. Аерым алганда, физик затларга керем буенча бердәм салым кертелә (ставкасы 13%). Хезмәт хакы фондына әле 1998 елда ук кертелгән бердәм социаль салым ставкасы 35,6% тан 26% ка төшерелә. Нәтиҗәдә эш бирүчеләр өчен эшләүчеләренә хезмәт хакын күтәрү һәм аны легальләштерү стимулы тудырылды. Бер үк вакытта бизнеска салымнар басымы да сизелерлек киметелде. Предприятиеләр керемнәренә дә салымнар кими төште. Өстәлгән кыйммәт салымы ставкасы 16% ка кадәр киметелде. Киләчәктә бу ставканы һәм бердәм социаль салым ставкасын тагын да киметү күздә тотыла.

Бюджет законнарын эффектив үзгәртеп кору һәм яңа бюджет кодексын (2000 ел) кертү нәтиҗәсендә, бюджет керемнәре арта. XX гасырның 90 нчы еллары белән чагыштырганда, аларда тышкы икътисади эшчәнлектән кергән керемнәр: экспорттан таможня пошлиналары һәм файдалы казылмалар өлеше сизелерлек арта, алар ярдәмендә дәүләт ягулык-энергетика

комплексы предприятиеләренең энергия чыганакларына гадәттән тыш югары бәяләр куеп җыйган гаять зур керемнәренең бер өлешен ала. Россия Федерациясенең Стабильләштерү фонды оештырылды, нефтькә бәяләр төшкән очракта кыен хәлдә калмас өчен, бюджетны финанслауга акчалар резервы тупларга кирәк, чөнки бу очракта да тышкы бурыч тиешенчә түләнергә тиеш бит. Стабильләштерү фондының средстволары билгеләнгән чик кыйммәтеннән артып китсә, бу артык өлеш Пенсия фонды дефицитын каплау яисә тышкы бурычны вакытыннан алда түләү өчен тотылырга мөмкин. Шунысы әһәмиятле: бюджет керемнәре арту һәм дәүләтнең тышкы бурычы белән идарә итүнең яхшы сыйфаты соңгы елларда дәүләтнең тышкы бурычларын һәм йөкләмәләрен бик күпкә киметә.

Яңа Бюджет кодексы кабул ителү бюджет дисциплинасын күпкә яхшырта, федераль бюджетта тотрыклы профицит тотуда һәм бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерүдә төп рольне уйный. Тагын бер актуаль бурыч: бюджет процессы бюджет акчаларын алучы оешмаларның үзләрен тотуга түгел, ә аларның эшчәнлекләре нәтиҗәсенә ориентлашырга тиеш. Бюджетара мөнәсәбәтләрдә керемнәрне федераль, региональ һәм муниципаль бюджетларга бүлүнең тотрыклы нормативларына ирешү мөһим.

Россиянең Бөтендөнья сәүдә оешмасына (Всемирная торговая организация — ВТО) керүе турында сөйләшүләр процессы дәвам итә. Яңа кабул ителгән Таможня кодексы күбрәк бу оешма таләпләренә туры килә. Базарлар ачылышы тышкы сәүдәне көйләү чаралары һәм актив рәвештә таможня пошлиналарын куллану белән бергә алып барыла.

Таможня тарифларына реформа үткәрелә, ул, таможня декларациясендә алдауларны булдырмау һәм пошлиналар җыемын арттыру өчен, читтән кертелүче күп кенә бериш товарларга пошлиналарны бердәм нормага китерә. 1999 елдан башлап элегрәк бетерелгән чыгару пошлиналары яңадан торгызыла, алар нефть һәм нефть продуктлары, кара һәм төсле металл ватыклары, балык, агач материалы һ.б. экспортын көйли. Бу — рубль девальвациясеннән соң Россия товарларының конкурентлык сәләте үсеше һәм дөньяда бәяләр күтәрелү белән бәйләнгән. Таможня тарифы реформасы нәтиҗәсендә таможня җыемнарыннан кергән керем күпкә арта, һәм импортка уртача таможня тарифы төшә (10% тирәсе генә кала).

Тышкы икътисади эшчәнлектә яңа Федераль закон кабул ителә, ул валюта мөнәсәбәтләрен көйли һәм икътисадның ачыклыгын тагын да киңәйтүне, рубльнең тулысынча алыштырылуына ирешүне, Россия Федерациясенә чит ил капиталын җәлеп итүне максат итеп куя. Соңгы вакытта валюта базарын шактый дәрәҗәдә либеральләштерүгә ирешелде, һәм рубльнең тулысынча алыштырылуы бурычы хәл ителергә тиеш. Валюта базарын либеральләштерү өлкәсендәге чаралар, дөньяның әйдәп баручы рейтинг агентлыклары тарафыннан безнең илгә югары кредит рейтингы бирелү, чит ил кредиторлары белән дәүләтнең тышкы бурычын вакытыннан алда түләү буенча уңышлы сөйләшүләр процессы — болар барысы да инвестицион климатның яхшыруына ярдәм итте, чит ил инвестицияләренең күпкә артып китүенә һәм турыдан-туры инвестицияләр өлешенең үсүенә сәбәп булды.

90 нчы елларда башланып киткән институциональ реформалар авыл хуҗалыгы җитештерүенең үсеп китүендә төп рольне уйный. Җир кодексы кабул ителә, һәм ул эре предприятиеләр, шул исәптән элегрәк крестьяннарга пайлар рәвешендә бүлеп бирелгән җирләрне арендалаучылар санының артуына китерә. Бу предприятиеләрдә яллы хезмәт җәлеп ителә, банк кредитларына алынган яңа техника файдаланыла, кредит ставкаларын өлешчә дәүләт субсидияли. Бизнесны диверсификацияләү программасы кысаларында эре корпорацияләр тарафыннан төзелгән бу предприятиеләр Җир әйләнеше турындагы законны эффектив кулланырга тиешләр. Бу закон эре авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бик зур мәйданнардагы җир биләмәләре алырга мөмкинлек бирә. Авыл хуҗалыгын үстерү өчен, өстәмә стимуллар азык-төлек һәм җиңел сәнәгать ягыннан сораулар арту хисабына тудырыла, чөнки соңгыларының үсеш темплары югарырак. Болар барысы да ВТОга кергән очракта аграр сәнәгать комплексының конкурентлык дәрәҗәсен саклау өчен генә түгел, продукцияне көнбатыш базарларына чыгару өчен дә шартлар тудыра.

Социаль сферада базар реформаларының үсеше

Хәзерге вакытта социаль сферада үткәрелә торган реформалар 90 нчы еллар реформаларының эзлекле дәвамы дияргә мөмкин. Әмма хәзерге этапта аларның әһәмияте күпкә югары,

чөнки хәзер үсешнең инновацияләр фазасына күчүе кирәк, һәм икътисади үсештә кешеләрнең капиталы зуррак роль уйный. 90 нчы елгы реформалардан аермалы буларак, алар чагыштырмача әйбәтрәк социаль фонда уздырыла, чөнки икътисадның уңай динамикасы һәм инфляция темпларын киметү халыкның үз карамагындагы реаль акча керемнәрен, шул исәптән хезмәт хакын да, тизрәк үстерә. Ярлылар саны чагыштырмача кимегән, социаль яклау нәтиҗәлерәк эшли башлаган.

Шулай да керемнәр сәясәте камилләштерүгә мохтаж. Хезмәт хакы, пенсияләр, пособиеләр дәрәҗәсе әле дә бик түбән булып кала. 40% чамасы гаилә ярлыларга күчерә, ә аларның күпчелек өлеше — хезмәткә яраклы һәм эшли торган кешеләр, еш кына квалификацияләре дә бик югары. Халыкның куллану структурасы һаман да артта калуын дәвам итә — азык-төлеккә акчаның 30% тан артыгы тотыла, шуның өстенә мәҗбүри түләүләр һәм взносларга китүче керемнәр өлеше үсә. Шуңа күрә азык-төлек булмаган товар һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү сәләте, ягъни сорау зур түгел, соңгы вакытта товар һәм хезмәт күрсәтүләргә киткән чыгымнарның өлеше түбәнәя. Икътисадтан долларны чыгару нәтиҗәсендә, чит ил валютасы сатып алуга һәм саклыкка салынуга киткән чыгымнар өлеше кимегән.

Ләкин коммерция банклары саклык кертемнәренә инфляция нормасыннан да кимрәк процент ставкалары куя, ә бу — халыкның саклык акчалары үзенең реаль бәясен туктаусыз югалта бара дигән сүз. Халыкның дециль төркемнәре һәм мәшгульлек даирәләре буенча керемнәр дифференциациясе кирәгеннән артык югары һәм әле үсүен дәвам итә. Нефть чыгару сәнәгатендә хезмәт хакы уртача хезмәт хакыннан 4,6 тапкыр югарырак, шул ук вакытта мәгариф системасында ул халык хуҗалыгындагы уртача хезмәт хакының 65% ын тәшкил итә. 2004 елның беренче яртысында иң югары керемле 10% гаиләнең өлеше минималь керемле 10% гаиләнең керемнәре өлешеннән 15,2 тапкыр артыграк булган.

Зур масштаблы социаль реформаларның берсе— пенсия реформасы, аның асылында эшләүче кешенең хезмәт хакы белән аның булачак пенсиясе арасында бәйлелек урнаштыру ята, бер үк вакытта халыкның картаюы һәм аның хезмәткә яраклы өлеше чагыштырмача кимү сәбәпле, пенсия взнос-

ларының гомуми күләме азаю да исәпкә алына. Пенсиянең гомуми суммасы өч өлештән тора:

— база өлеше, хезмәт стажына бәйле түгел, бөтен кешегә дә дәүләт гарантияләгән бер үк зурлыкта түләнә;
— страховка өлеше, эшләүче кешенең эшләгән чорындагы хезмәт хакына бәйле;
— тупланма өлеше, пенсия акчаларының бер өлешен инвестицияләү нәтиҗәсендә барлыкка килә (өлкән буын кешеләренә пенсиянең бу өлеше түләнми, чөнки алар пенсиягә чыкканчы аны кирәкле күләмдә туплап өлгерми).

Эшләүче кеше үзенең тупланыла торган пенсия акчалары белән идарә итүне шәхси яки дәүләт карамагындагы идарә итү компаниясенә ышанып тапшыра ала. Дәүләт идарә компаниясе сыйфатында Внешэкономбанк (Тышкы икътисади банк) тәкъдим ителә. Ул пенсия акчаларын, нигездә, югары дәрәҗәдә ышанычлы облигацияләргә инвестицияли, ә хосусый идарә компаниясе инвестиция фондларының акцияләренә һәм пайларына тота, аларның кереме югарырак булса да, югалту куркынычы бик зур.

Яңа этапта социаль сәясәтнең аеруча әһәмиятле элементы — сәламәтлекне саклау, мәгариф, торак-коммуналь хуҗалык өлкәләрендә, шулай ук халыкның төрле категорияләре буенча социаль өстенлекләрне финанслау сферасындагы реформалар.

Дәүләтнең бу сфералардагы күп кенә бурычлары кирәкле акча средстволары белән ныгытылмаган. Бюджет учреждениесе бар икән, эш күрсәткечләре нинди булуга карамастан, аның дәүләттән финанслану хокукы бар. Федераль һәм региональ бюджетларның социаль йөкләмәләре хәзергәчә кадәр финанслауның реаль мөмкинлекләреннән 1,5—2,5 тапкыр артып китә, әле еш кына алар халыкның ярлырак катлавыннан байларга трансфертлар формасында була. Мәсәлән, социаль страховкалау фондларына взносларның иң зур өлешен уртачадан түбәнрәк керемле кешеләр түли, ә 90 нчы еллар ахырында шифаханәләргә 70% юллама, дәүләт дотацияләнгән бәяләр куеп, югары керемле кешеләргә бирелә. Бу күренеш тагын да зуррак дәрәҗәдә дотацияләнгән электр энергиясе бәяләренә (энергия катлаулы көнкүреш техникасы булган гаиләләрдә

күбрәк тотыла) һәм торак-коммуналь хезмәтенә (алар гаилә биләгән мәйданга пропорциональ кулланыла) кагыла.

Халыкның төрле катлауларына төрле ташламаларның (льгота) гомуми саны меңнән артык, һәм алар 85 млн кешегә, ягъни гаиләләрнең 2/3 сенә диярлек кагыла. Әмма бу өстенлекләрнең бик күп өлеше гамәлгә ашырыла алмый, чөнки моның өчен бюджет средстволары җитәрлек түгел.

Мәсәлән, бушлай медицина һәм укыту хезмәте күрсәтелергә тиеш дигән йөкләмә бар. Әйтик, югары үсешле медицина фәне бик күп авыруларны дәваларга мөмкинлек бирә, әмма еш кына кыйммәтле даруларга һәм операцияләргә шактый зур суммалар таләп ителә. Нәкъ шулай ук ныклы тирән белем алу укытучы һәм профессорга югары хезмәт хакы түләүне, мәктәпләрдә яки университетта компьютер класслары булдыруны һ. б. ны күздә тота. Халыкка шундый яхшы сыйфатлы һәм күләме арта барган хезмәт күрсәтү өчен (мәсәлән, Үзәк-Кара туфраклы районда хезмәткә яраклы 1000 кешегә 500 тирәсе өлкән кеше туры килә), бюджетны тулыландыру өчен, дәүләт салымнарны һаман арттыра барырга тиеш. Ләкин бу икътисади үсешне тотып торачак һәм дөрес сәясәт дип тә кабул ителмәячәк. Нәтиҗәдә медицина хезмәтләренең пациент өчен түләүле булуы ешая, укучыны вузга әзерләүче репетиторларның хезмәт базары үсә. Тик бу процессларга «күләгәлелек» хас. Бу очракларда халыкның начар тәэмин ителешле катлаулары яхшы сыйфатлы медицина ярдәменнән, даруханәләрдән беркайчан да булмый торган бушлай дарулардан, югары сыйфатлы белем бирү хезмәтеннән мәхрүм кала. Ә инде бюджеттан килүче акчалар еш кына нәтиҗәле кулланылмый. (Мәсәлән, бу акчага сатып алынган дарулар бушлай рецептлар буенча таратылмый, ә соры базарда сатыла.)

Шунлыктан мәҗбүри медицина страховкалау системасын тагын да үстерергә кирәк, аның кысаларында эшләүче халыкны дәвалау өчен кирәкле средстволар — эш бирүчеләрдән взнослар рәвешендә, эшләмәүчеләргә медицина хезмәте өчен бюджеттан кертелә. Бу средстволар медицина оешмаларына конкрет медицина хезмәте өчен күчерелә, һәм аның күләме бу хезмәтнең күләменә һәм сыйфатына бәйле, чөнки пациент медицина учреждениесен һәм табибны үзе сайлап алырга мөмкин. Үз чиратында халыкның аерым катлауларына, дарулар

сатып алу өчен, чыгымнар бюджет мөмкинлекләреннән чыгып компенсацияләнә.

Мәгариф системасын финанслау реформасы да берничә чыганакны — бюджет средстволарын, гаилә керемнәрен һәм предприятиеләрнең табышларын файдалану нигезендә дәвам иттерелә. Мәктәптә укытуны бюджеттан (федераль һәм муниципаль бюджетлардан түгел, региональ бюджеттан) финанслау дәүләт раслаган минималь стандартлар нигезендә алып барылырга тиеш. Биредә бер укучыны укыту өчен тотылган чыгымнарның нормативы эшләнергә һәм расланырга тиеш. Нормативлар бертигез булмаска да мөмкин. Алар, мәсәлән, укучының нинди мәктәптә — шәһәр мәктәбендәме әллә бер укытучыга бик аз бала туры килгән авыл мәктәбендәме укуына, яки кайсы регионда яшәвенә бәйле. Нормативлар билгеләнгәннән соң, һәр мәктәп, үзендә ничә бала укуына карап, бюджет средстволары алачак. Болай эшләү бюджет финанславын персоналаштыру дип атала.

Әгәр шәһәр районында берничә мәктәп булса, ата-аналар һәм балалар мәктәпнең яхшырагын сайлый ала, һәм чыгымнар нормативы күләмендәге акча, балалар санына карап, яхшырак укыта торган мәктәпкә китә. Бу укытучыларга хезмәт хакын күтәрергә, мәктәпкә ремонт ясатырга, компьютерлар сатып алырга мөмкинлек бирәчәк. Нормативтан тыш белем бирү хезмәте стандарты буенча өстәмә чыгымнарны гаиләләр мәктәп бухгалтериясенә түлиләр.

Хезмәт ресурслары өлкәсендә безнең илнең конкурентлык сәләтенә ия өстенлекләрен (ресурсларның югары сыйфаты, чагыштырмача аз хезмәт хакы) мәгариф системасына дәүләт инвестицияләре кертүдән башка саклап булмаячак. Шунлыктан дәүләт бушлай (конкурс нигезендә) урта һәм югары профессиональ белем бирүне финанславын дәвам итәргә тиеш. Ләкин мәктәпкә бердәм дәүләт имтиханы кертелү югары белем сферасында да персоналаштырып финанслау системасына күчәргә мөмкинлек бирә. Моның өчен эксперимент тәртибендә махсус исемле дәүләт финанс йөкләмәләре (ИДФЙ; государственные именные финансовые обязательства) кулланыла, аларның «бәясе» һәрбер укучы өчен аның БДИ нәтиҗәләре буенча алган билгеләренә карап билгеләнә. ИДФЙ средстволары хисабына югары уку йортлары үзләренең агымдагы

чыгымнарын каплый ала. Шулай да вузларның җиһазлар алуы һәм алардагы капиталь төзелеш элеккечә дәүләт тарафыннан федераль яки региональ бюджеттан финанслана (вузның кайсына буйсынуына карап). Вуз, мәктәп шикелле үк, югары сыйфатлы белем бирү хезмәте күрсәтергә тырышачак, чөнки абитуриентлар «китергән» средстволарның күләме әнә шуларга бәйле. Ә укучы бала яхшырак укырга тырышачак, әгәр аның ИДФЙсы бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре буенча «арзанлы» булса, укытуга түләү өчен кирәкле средстволарны, ИДФЙ «бәясен» чигереп, ата-аналар түли.

Белем алу өчен түләнә торган акчаларны шулай ук банктан кредитка алырга була, страховкалау системасында белем алу максатында тупларга мөмкин. Болардан тыш, югары белем өчен тулысынча яки өлешчә акчаны вузда укучы студентның булачак эш бирүчесе дә түли ала, иң мөһиме, ул менә шушы квалификацияле белгеч белән кызыксынырга тиеш.

Торак-коммуналь хуҗалыкта реформа әле базар үзгәртүләренең беренче этабында ук башлана, ләкин гаиләләрнең түбән дәрәҗәдәге түләү сәләте һәм торак-коммуналь хезмәткә түләүнең эшләнеп бетмәгән субсидияләр системасы аркасында бик сүлпән бара. Бюджеттан финанслауның җитәрлек булмавы, торак-коммуналь хезмәткә түләү буенча гаять күп сандагы өстенлекләр һәм бу секторның монопольләшүе торак фондының сыйфаты түбәнәюне, хезмәт күрсәтү тарифларының артуын (кайвакыт нигезсез) китереп чыгара. Иң мөһиме — конкурентлы мохит тудырырга кирәк, фатирларын хосусыйлаштырган һәм торак хуҗалары ширкәтләренә берләшкән кешеләр (бер йортта яшәүчеләр) һәм бу йортка хезмәт күрсәтергә әзер булган оешмалар бер-берсе белән коммуналь хезмәтләр базарында торакны эксплуатацияләү һәм ремонтлау, бу хезмәтләрнең базар бәясен билгеләү буенча очрашалар. Әмма моның өчен халык бу хезмәтләргә тулысы белән үзе түләргә тиеш. Керемнәре билгеле бер нормативтан түбән булган гаиләләргә адреслы субсидияләр түләнә. Хезмәт күрсәтүләрнең бәяләренә дотацияләр сакланса, дотацияләрнең иң зур өлешен зуррак керемле гаиләләр үзләштерәчәк, чөнки алар биләгән торак мәйданы гадәттә урта һәм түбән җитешлелектә яшәүче гаиләләрнекеннән күпкә артык була.

19.3. РОССИЯНЕҢ ПОТЕНЦИАЛЫ ҺӘМ ИКЪТИСАДИ ҮСҮ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

Россия милли байлыклары гаять зур һәм табигый ресурслары, технологик һәм интеллектуаль потенциалы югары булган илләр санына керә. 2003 елның ахырына Россиянең милли байлыгы 35,2 трлн сумнан артыграк булып исәпләнгән.

Безнең илебез дөньяда уникаль геосәяси урын били. Табигый газның өйрәнелгән запаслары буенча дөньяда беренче урында тора. Тимер рудасының, төсле һәм сирәк металларның 20% ы, нефть һәм ташкүмернең 12% ы — безнең илдә, ул шулай ук башка табигый ресурслар буенча да алдынгы урыннарда. Россия — газ чыгару буенча бөтендөнья лидеры (дөнья буенча 30%). Ул нефть, соры күмер чыгару, төзелеш кирпече житештерү буенча дөньяда 2 нче урынны; чуен, сөт житештерү буенча 3 нче урынны; корыч, электр энергиясе, кара металл прокатлау, минераль ашламалар, киже-мамык тукыма, агач материаллары буенча 4 нче урынны; балык тоту һәм диңгез продуктлары табу буенча 5 нче урынны алып тора һ. б. Ләкин 2000 елда житештерелгән ТЭП күләме буенча Россия, АКШтан, КХР, Япония, Германия, Һиндстан, Франция, Италия, Бөекбритания һәм Канададан калышып, дөньяда 10 нчы урынны гына били. 2004 елда Россиянең ТЭПы 19,8 трлн долл. була, һәм ул дөньядагы тулай эчке продуктның 1,6% ын тәшкил итә, ә АКШ буенча бу чагыштырма — 20,8%, Кытай — 12,0%, Япония — 7,4%, Германия 4,5% була. Шулай да, икътисади фаразлаулар өлкәсендә эшләүче кайбер белгечләр вәгъдә иткәнчә, 2015 елда шушы күрсәткечләр буенча безнең илнең мактаулы 6 нчы урынга күтәрелү ихтималы бар. Илнең икътисади үсеш дәрәжәсен характерлаучы төп күрсәткечләрнең берсе — бер кешегә туры килгән ТЭП житештерү. Моның буенча 2000 елда Россия дөньяда 56 нчы урында була (1985 тә — 42 нче урын, 1970 тә — 37 нче урын). 2004 елда Россиядә бер кешегә туры килгән ТЭП шул чор бәяләре белән 137 223 сум, яки АКШ дәрәжәсенең 21% ын тәшкил итә. Шул ук вакытта Европа берлегенең 15 илендә бер кешегә туры килгән ТЭП

АКШ дәрәҗәсенең — 69% ына, Япониядә — 74%, Люксембургта 128% ына тигез була.

Россия ТЭП структурасы күрсәткечләре буенча да алга киткән илләрдән күпкә калыша. Әгәр ул илләрдә 2000 елда матди җитештерүгә ТЭПның 31,3% ы, матди булмаган җитештерүгә 68,7% ы туры килсә, Россиядә матди җитештерү өлеше ТЭПның 51,6% ын, матди булмаган өлеше 48,4% ын тәшкил итә. Бу саннарны анализлаганда, шунысын да исәпкә алу мөһим: матди булмаган җитештерү тармакларының (фән, мәгариф, мәдәният һ. б.) алга китүе, нигездә, сәнәгатьнең, төзелеш, авыл хуҗалыгының фәнни-тикшеренү институтларына, уку йортлары, медицина учреждениеләре, кораллы көчләргә һәм башкаларга кирәкле җиһазлар, материаллар һәм башка чараларны бирә алу мөмкинлекләре чикле булу белән бәйле. Матди булмаган җитештерү сферасында эшләүче һәр кешенең куллану товарларына ихтыяҗы да канәгатьләндерелергә тиеш. Шуңа күрә матди булмаган байлыклар җитештерүнең югары дәрәҗәсе — илнең, өр-яңа технологияләргә нигезләнеп, эффектив эшләүче матди җитештерүе барлыгын дәлилли торган әһәмиятле күрсәткеч ул. Әлеге күрсәткечләр Россиядә технология дәрәҗәсе һәм матди җитештерүнең эффективлыгы алга киткән илләрдән бик күпкә түбән икәнен аңлата. Моның сәбәбе планлы-административ система хакимлек иткән елларда базар системасы нык үскән илләрнең җитештерү эффективлыгына якынаю мөмкин булмау гына түгел, ТЭП җитештерүнең бик озак һәм бик түбән төшүе җитештерү җиһазлары чыгаруның нык кимүе белән бергә барды. Мәсәлән, 1970 елда Советлар Союзында 119 мең металл кисү станогы җитештерелеп, шуның 1,4 меңе цифрлы программалар белән идарә итүле булса, 2002 елда Россиядә бары тик 6,5 мең станок җитештерелә, шулардан 200 е программалар ярдәмендә идарә итүле. Тракторлар эшләп чыгару 194 меңнән 9,2 меңгә кала. Ягъни иске җиһазларны яңалары белән алыштыру, төп капиталны яңарту процессы җимерелә. Сәнәгать предприятиеләренә куелган җиһазларның уртача яшь күрсәткече шуны дәлилли. Узган гасырның ахырында аларның яше 30 елдан артып китә, һәм бу алга киткән илләрдәге җиһазлар яшеннән 3—3,5 тапкыр артыграк.

Базар реформалары үткәрү җитештерүнең озакка сузылган гомуми кимүен китереп чыгармый калмый. 19-1 таблица-

сыннан күренгәнчә, 1990 елдан 1998 елга кадәр илдә ТЭП 9,9 трлн сумга, ягъни 42,4% ка кими (1992 ел бәяләрендә). Бу кыскару — базар реформаларына икътисадның табигый реакциясе (җавабы). Икътисад белән административ-планлы идарә системасын сүтеп ташлаганнан соң, бик кыска вакыт эчендә генә аны базар системасы белән алыштыру мөмкин түгел, яңа системаны формалаштыру — катлаулы һәм озак процесс.

Кайбер предприятиеләрнең продукция җитештерүне тулысынча туктатуы, ә бик күпләре җитештерү күләмен киметсәләр дә, товар чыгаруларын дәвам итүе нәтиҗәсендә, ТЭП-ның түбәнәюе күзәтелде. Билгеле булганча (параграф 6.5), җитештерүнең кимүе мондый очракларда даими чыгымнарның кимүе белән бергә бармый. Оукен законы буенча, эшсезлек тизлеге ТЭП кыскару тизлегеннән кимрәк, ягъни түбәнәю барышында мәшгульлек ТЭП дәрәҗәсенә караганда акрынрак кыскара (параграф 13.5). Шунлыктан ТЭП җитештерүнең кимүе, кагыйдә буларак, мәшгульлекнең чагыштырмача акрынрак кимүе белән бергә бара. Нәтиҗә буларак, бер эшләүче кешегә туры килүче продукция чыгарылышы кими, ягъни хезмәт җитештерүчәнлеге түбәнәя. 1998 елдан соң башланган күтәрелеш хезмәт җитештерүчәнлеге үсү белән бергә бара, ләкин 1992—2004 еллар эчендә ул бары тик 9,35% ка

19-1 таблицасы

1990—2004 елларда Россия Федерациясенең икътисади динамикасы күрсәткечләре

	1990	1992	1994	1996	1998	2000	2002	2004
ТЭП, млрд сум 1992 ел бәяләрендә	23 398	19 005	15 166	14 033	13 467	15 358	17 336	19 815
Төп капиталга инвестицияләр,млрд сум, 1992 ел бәяләрендә	8923	4551	3044	2961	2384	2734	3104	3570
Эш белән мәшгуль кешеләр саны, млн кеше	...	71,1	64,8	62,9	58,4	64,5	65,7	67,8
Хезмәт җитештерүчәнлеге, мең сум, бер эшләүче кешегә	...	267,3	234,0	223,1	230,6	238,1	263,9	292,3

гына үсә, икенче төрле әйткәндә, аның уртача еллык үсеш темпы чиксез түбән — 0,75% кына була. Бу күрсәткеч РФ икътисадында җиһазларны массакүләм яңарту булмаган һәм, димәк, илдә төп капиталның искерүе әле дәвам итә дигәнне аңлата. Моңа тагын да ышанычлырак дәлил — төп капиталга инвестицияләр динамикасы. 19-1 таблицасындагы саннар күрсәтүенчә, 1998 елдан соң инвестицияләр туктаусыз артуга карамастан, 2004 елда аларның дәрәҗәсе әле һаман да 1992 елныкыннан кимрәк һәм 1990 ел дәрәҗәсеннән 2,5 тапкыр калыша.

Теләсә кайсы илнең икътисади үсеше өчен аның халкының гомуми хәле, белем һәм квалификация дәрәҗәсе, гомуми һәм профессиональ культурасы зур әһәмияткә ия.

Россия халкының хезмәт, белем, фәнни-техник һәм мәдәни потенциалы шактый югары. Безнең ил икътисадта катнашучы эшче көчләре буенча дөньяда бишенче урынны алып тора. Шул ук вакытта, XX гасырның 90 нчы еллары уртасыннан башлап, халыкның 1000 кешегә 4,8 дән 6,7 кешегә кадәр, яки 2000—2002 елларда 950 мең кешегә кадәр табигый кимүе күзәтелә. Чагыштыру өчен 90 нчы елларның икенче яртысында АКШта халыкның табигый артуы күзәтелгән: 1000 кешегә 5,5 тән 6,0 кешегә кадәр. Бер үк вакытта Германиядә дә, Россиядәге кебек, депопуляция процессы барган — шушы ук периодта халкының табигый кимүе 1000 кешегә 0,8 дән 1,4 кешегә җиткән.

Россиядә халык хуҗалыгында эшләүчеләрнең 26% тирәсе — тулы һәм тулы булмаган югары профессиональ белемгә, ә 30% тан артыгы урта профессиональ белемгә ия.

Россиядә меңнән артык вузда 6 млн тирәсе студент белем ала, 6,6 меңнән артык махсус урта һәм башлангыч профессиональ белем учреждениеләрендә 4,3 млн студент укый. Безнең илдә 1 мең кешегә урта, югары профессиональ һәм вуздан соң белем бирү учреждениеләрендә укучы 60 студент туры килә, АКШта бу сан — 49, ә Германиядә 25 кә тигез.

Кеше потенциалының үсеш индексын дүрт элемент буенча билгелиләр: туганда ук фаразланган гомер озынлыгы, олы кешеләрнең (болардан тыш) грамоталылык дәрәҗәсе, уку йортларына керүчеләрнең гомуми коэффициенты һәм бер кешегә туры килүче ТЭП (АКШ долларларында сатып алу

сәләте паритеты буенча исәпләнгән). Шушы индекс буенча Россия 177 ил арасында 57 нче урынны алып тора, ә бу рейтингның лидерлары — Норвегия, Швеция, Австралия, 8 нче урынны АКШ били.

Халыкара «World Economis Forum» оешмасының тикшеренүләрендә илнең дөнья хуҗалыгында конкурентлык сәләте индексы макроикътисади, технологик һәм институциональ факторлар җыелмасын исәпкә ала. 2002 елда Россия бу индекс буенча 64 нче урында була. Бюджетның баланслану дәрәҗәсе буенча 3 нче, сатып алу сәләте паритеты буенча ТЭП үсеше темплары — 6 нчы, белем дәрәҗәсе һәм инновацион мөмкинлекләре буенча 33 нче урыннар алуына карамастан, милек хокукларын яклау сыйфаты буенча 75 нче, эшлеклелек этикасы буенча 73 нче, акча «юуга» (легальләштереп урлауга) каршылык күрсәтүнең эффективлыгы буенча 78 нче урыннар нәтиҗәдә әлеге түбән урында гына калдыра.

Икътисадта яшәп килгән структур проблемалар һәм үсеш темпларының хәзергә түбән булуы эшсезлек дәрәҗәсен шактый югары күтәрә: икътисади актив халыкның 8,6% ы (2002 ел) эшсез (АКШта 2002 елда — 4,8%, Германиядә — 7,9%). Безнең ил өчен үзенчәлекле хәл булып тулы һәм тулы булмаган югары белемле (13,1%) һәм махсус урта белемле (24,6%) кешеләр арасында бу күрсәткечнең югары булуы тора.

Бөтендөнья базарының киләчәген 50—55 макротехнология билгели. Аларның 46 сын иң алга киткән 7 ил монопольләштергән, һәм алар бөтендөнья технологияләр базарының 80% ын үз күзәтчелеге астында тота. Россия 10—12 шундый технология буенча конкурентлык сәләтен саклаган дип бәяләнә. Болар — авиация һәм космонавтика, әйләнә-тирәгә җавап бирә торган яңа материаллар җитештерү, плазма технологияләре һәм биотехнологияләр, ягулык элементлары җитештерү, атом энергетикасы, электроника, мәгълүмати һәм лазер технологияләре, традицион булмаган энергия чыганакларында эшли торган энергия корылмалары һәм төш энергетикасы корылмаларын җитештерү өлкәләренә карый. Илнең фәннитехник потенциалының төп өлеше хәрби-сәнәгать комплексында тупланган.

Әле 90 нчы елларның башында ук илдә фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр белән шөгыльләнүче 45 меңнән артык оешма була, һәм аларда 1,5 млн кеше эшли. 1992 елда

фәнни тикшеренүләрне финанслау ТЭПның 0,5% ын һәм федераль бюджет чыгымнарының 2,4% ын тәшкил итсә, 2002 елда бу саннар тиндәшле рәвештә 0,28% һәм 1,46% ка төшә һәм шуның өстенә ТЭП һәм бюджет чыгымнары үзләренең абсолют зурлыкларын да югалталар. Шулар нәтиҗәсендә фәнни оешмалар һәм аларда эшләүчеләр саны да кими. 2002 елда патентлар, лицензия, «ноу-хау», инжиниринг хезмәте һәм башка фәнни-техник продукциянең экспорты өчен кул куелган килешүләр саны 1300 дән артып китсә дә, бөтендөнья фән сыйдырышлы продукция базарында (аның күләме 2,3 трлн долларга җитә) Россиянең өлеше юк дәрәҗәсендә — бары тик 0,7% тирәсе (АКШның өлеше — 40%, Япониянең — 30%, Германиянең — 16% тирәсе).

Шулай итеп, Россиянең ресурслар һәм фәнни-техник мөмкинлекләре югары булса да, дөнья икътисадында конкурентлыкка сәләте зур түгел. Табигый ресурслары буенча дөньядагы иң бай илләрнең берсе һәм аларның экспортеры булуга карамастан, бөтендөнья чимал, барыннан да элек, нефть, нефть продукцияләре, табигый газ һәм металл базарлары конъюнктурасына бәйле. 2002 елда минераль продуктлар, металл, кыйммәтле ташлар һәм аларның эшләнмәләрен чыгару ерак чит илләр белән сәүдә барышында экспорт кеременең 77% ын тәшкил иткән.

Алдарак әйтелгәнчә, Россиядә белем дәрәҗәсе югары булган эшләүчеләр саны бик күп, ләкин булган кадәресен мобиль дип әйтеп булмый. Эшләүчеләрнең хезмәт җитештерүчәнлеге түбән, шуның өстенә халыкның табигый кимүе дәвам итә.

Илнең конкурентлык сәләте түбән, базар институтлары һәм механизмнарының эффектив эшләмәве нәтиҗәсе булып соңгы чиктә халыкның чагыштырмача түбән тормыш дәрәҗәсе тора.

Россия халкының куллану дәрәҗәсе, гаиләләрнең агымдагы чыгымнарын һәм дәүләтнең социаль хезмәт күрсәтүләрен дә кертеп, 2000 елда ТЭПның нибары 52,1% ын гына алып торган (алга киткән илләрдә 69,1%, шул исәптән АКШта 70,3%). Безнең ил халкының дүрттән бере тирәсе яшәү минимумыннан кимрәк керемнәргә яши. Россиядә җан башына елына бары тик 46 кг ит (АКШта 116 кг), 40 кг җиләк-җимеш (АКШта 100 кг, Германиядә 156 кг) кулланыла.

Соңгы вакытта Россия халкының муллык дәрәҗәсе аз гына үсеп килә. 100 хуҗалык йортына — 129 телевизор, 114 суыткыч, 1000 кешегә 170 җиңел машина туры килә. 2005 елның ахырына кәрәзле элемтә абонентлары саны 100 млн га җиткән. Халыкның депозитлары һәм вкладлары (саклык кертемнәре) 2 трлн сумга җитте һәм 1999 елның гыйнвары белән чагыштырганда гына да 7 тапкыр артты.

Әмма шул ук вакытта керемнәр дифференциациясе дәрәҗәсе бик югары һәм үсүен дәвам итә. Әгәр халыкның иң аз керемле 20%ына барлык керемнәрнең 5,6%ы гына туры килсә, иң югары керемле 20%ы аның 45,8%ын ала.

Җыеп әйткәндә, илнең дөнья икътисадында хәзер тоткан урыны Россияне социаль-икътисади үстерүдәге колоссаль мөмкинлекләрне берничек тә чагылдырмый. Моның сәбәпләре күз алдында. Административ-планлы система фәнни-техник прогрессны тормозлый һәм ул чорда үсешнең төп факторлары булып: а) капиталны экстенсив кинәйтү; б) җитештерүгә яңа табигый ресурсларны экстенсив кертү; в) җитештерү процессына катнашучы эшче көчнең санын арттыру тора. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрә һәм капиталның бәрәкәтлелеген арттыруда төп роль уйнарга тиешле техник прогресс икътисади үсеш темпларын ныгытуда икенче планга кала. Планлы системадан базар системасына күчү һәм базар механизмын формалаштыру 1991 елдан 1998 ел ахырына кадәр сузылган тирәнтен һәм дәвамлы артка тәгәрәүне китереп чыгара. Бу вакыт эчендә нык үскән илләр тагын да алга китә, Россиянең артка калуы ераклаша. Үсеп килүче илләр төркеменә кергән һәм хәзер ТЭП күләме буенча АКШтан гына калышучы Кытай тәҗрибәсе базар реформаларын мондый ук зур югалтуларсыз да үткәрергә мөмкин булганын раслый.

Яңадан 19-1 таблицасына кире кайтып, шуны ассызыклап үтәргә кирәк: 1999 елдан башлап алты ел буена Россиядә икътисадның тотрыклы үсеше күзәтелә. Бу вакыт эчендә уртача еллык үсеш зурлыгы 6,7% булган. Әгәр ТЭП үсеше темплары шулай сакланып барылса, инде 2007 елда ук ТЭПның 1990 елгы дәрәҗәсеннән азга гына булса да узып китү мөмкинлеге бар (1990 елда Россия тарихында иң зур ТЭП булган). Гаять күп табигый байлыклары һәм колоссаль икътисади потенциалы булган илебезнең бу бурычны хәл итү өчен мөмкинлекләре җитәр дип уйларга кала.

КЫСКАЧА ЙОМГАКЛАУ

Россия гаять зур милли байлыкка һәм югары табигый ресурсларга, технологик һәм интеллектуаль потенциалга ия булган илләр рәтенә керә. Безнең илебез дөньяда уникаль геосәяси урын тота. Әмма хәзергә бик күп илләрдән икътисади үсеш дәрәҗәсен, хуҗалык эшчәнлегенең эффективлыгын, институциональ тирәлекне, халыкның яшәү дәрәҗәсен бәяләү күрсәткечләре буенча күпкә калыша.

Россиянең хәзерге хәлен базар икътисади нигезләренең төзелүе билгели. XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында административ-планлыдан базар системасына күчү тәгәлләнә. Ул XX гасырның 90 нчы елларында дәвам итә. Безнең илдә планлы икътисадның, әле XX гасырның 20 нче елларында ук формалашып, 60 елдан артык хакимлек итүе аркасында бу период дәвамлы һәм катлаулы уза.

Базар икътисады нигезләрен төзү этабында гамәлгә ашырылган системалы үзгәртүләр комплексына түбәндәгеләр керә:

— хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү;
— макроикътисади стабильләштерү;
— икътисадны структур үзгәртүләр;
— институциональ реформалар;
— социаль сферадагы үзгәрешләр.

Хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү товарларга, хезмәт күрсәтүләргә, кыйммәтле кәгазьләргә һәм эш көченә бәяләр куюны ычкындыру һәм ирекле итүне, бизнесны башлап җибәрү процедураларын гадиләштерүне, икътисадның ачыклыгын күздә тота. Либеральләштерү нәтиҗәсендә дәүләтнең икътисадка катнашуы масштаблары кискен кими, һәм ул хуҗалык эшләре белән административ идарәдән баш тарта.

Икътисад беренче этаптагы системалы үзгәртеп коруларга җитештерүнең бик күпкә түбән төшүе белән җавап бирә. Бәяләрне либеральләштерү котылгысыз төстә — инфляциягә һәм сорауның кимүенә, ә инфляциягә каршы тору сәясәте процент ставкаларының үсүенә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, кредитның кыйммәтләнүенә һәм инвестицион сорауның кимүенә, шулай ук дәүләт чыгымнарының кысылуына китерә. Түбән тәгәрәүне туктатуда төп тормоз ролен икътисади үсешкә каршы торучы көчле инфляция үти. Аны катгый кредит-акча һәм бюджет сәясәте юлы белән авызлыклыйлар. Шул нигездә

житештерү кабат үсә башлый, тик әле аңа структур һәм институциональ реформалар ярдәме кирәк була.

Структур үзгәртүләрне икътисадның тармак структурасын камилләштерүгә юнәлтелгән чаралар күплеге дип кенә аңлату дөрес булмас. Барыннан да элек, алар конкурент базар структуралары үсешенә юнәлтелгән. Структур реформаларның иң мөһим элементлары булып хосусыйлаштыру һәм икътисадны демонопольләштерү тора.

Институциональ үзгәртүләр — яңа хокукый институтлар, ягъни базар тәртибе кагыйдәләрен һәм нормаларын төзү ул. Алар милек хуҗаларының, шулай ук базар инфраструктурасының, ягъни базар секторы оешмалары һәм учреждениеләренең хокукларын гарантияилиләр. Институциональ үзгәртүләргә шулай ук житештерү факторлары базарындагы, финанс системасында һәм фондлар базарындагы үзгәртүләр, базар шартларындагы халык хуҗалыгы идарәсе органнарын реформалау керә. Бу институтлар базарда катнашучыларның хуҗалык эшчәнлегендәге эш тәртибен, алыш-бирешләр алып бару кагыйдәләрен, фирмаларны төзү һәм аларның базарга чыгу тәртибен, банкротлык процедуралары тәртибен көйли торган законнар системасында чагыла.

Институциональ реформалар базарда катнашучыларның базар сигналларына (бәяләр, процент ставкалары, валюта курсы, салым ставкалары һ. б. үзгәрү) гадәти реакциясен тәэмин итә.

Социаль тирәлектәге реформалар дәүләт финанславы белән тирәлекнең яшәешенә базар принципларын бергә кушып алып барыла.

Россиянең икътисади үсешенең хәзерге этабына чагыштырмача тотрыклы икътисади үсеш хас. Моңа рубль девальвациясе, уңайлы тышкы икътисади конъюнктура, базар мөнәсәбәтләренә реаль катнашучы күп кенә предприятиеләрнең рентабельлелеге һәм инвестицияләр өчен мөмкинлекләре арту, инвестицион климатның яхшыга үзгәрүе һәм чит илләр капиталы кертелү уңай тәэсир итә.

Икътисади үсешнең тышкы икътисади конъюнктурага бәйлелегеннән котылу зарурлыгы Россиянең чагыштырмача өстенлекләреннән һәм аның ягулык-чимал ресурслары экспортына специальләшүеннән баш тартуны аңлатмый. Илнең икътисади хәлен ныгытуда житештерүнең бик күп тармак-

ларында һәм экспортта диверсификация, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр, фән сыйдырышлы продукция ассортиментын киңәйтү, житештерүне һәм экспортны күтәрү, яңа технологияләр һәм җиһазлар, квалификацияле эшче көчләр нигезендә үсешне яңа сыйфатлы итү төп көч булып тора. Икътисади үсеш факторы буларак, яңа технологияләрне гамәлгә кертү дә үсәргә тиеш.

Социаль сферадагы үзгәрешләр халыкның тормыш хәлен начарайтырга тиеш түгел. Аларны үткәрүдә социаль яклау финанславын персоналаштыру һәм адреслы социаль ярдәм күздә тотыла.

❓ *Контроль сораулар һәм биремнәр*

1. Россиянең икътисади үсешенең хәзерге дәрәҗәсе нидән гыйбарәт?
2. Россиядә базар реформаларының ике этабына нинди үзенчәлекле билгеләр хас?
3. Структур реформалар нәрсә белән характерлана?
4. Институциональ реформаларның төп үзлекләре нидән гыйбарәт?
5. Хосусыйлаштыру ни рәвешле сезнең гаилә мәнфәгатьләренә туры килде?
6. Социаль сферадагы реформалар сезнең гаиләнең икътисади хәленә нинди йогынты ясады?
7. Мәгариф өлкәсендәге реформаларга сезнең карашыгыз нинди?

А

АБСОЛЮТ ЛИКВИДЛЫК (абсолютная ликвидность) — кулдагы акчаларның һәм сорап алганга кадәр салынган депозитларның гомуми танылган түләү формасы ролен һәм акчаның башка функцияләрен турыдан-туры үти алу сәләте, 262 б. (I кит.)

АБСОЛЮТ ӨСТЕНЛЕК ПРИНЦИБЫ (принцип абсолютного преимущества) — әгәр һәрбер ил, уртача чыгымнары башка илләрдәге уртача чыгымнардан кимрәк булган товарлар җитештерүгә специальләшсә, ул тышкы сәүдәдә отыш алачак, 209 б. (II кит.)

АВТОНОМ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР (автономные инвестиции) — керем зурлыгына бәйле булмаган хосусый инвестицияләр зурлыгы, 47 б. (II кит.)

АВТОНОМ КУЛЛАНУ (автономное потребление) — халыкның шәхси куллану чыгымнарының бер өлеше; аның күләме алына торган керемнең зурлыгына бәйле түгел, 38 б. (II кит.)

АВТОНОМ ЧЫГЫМНАР (автономные затраты) — иң ахыргы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә тотылган, зурлыгы керем зурлыгына бәйле булмаган чыгымнар; үз эченә автоном куллануны, автоном инвестицияләрне, товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең дәүләт сатып алган өлешен ала, 48 б. (II кит.)

АГЫМДАГЫ ДИСКОНТЛАШТЫРЫЛГАН БӘЯ (текущая дисконтированная стоимость) — капитал тарафыннан киләчәктә тудырылырга тиешле акча керемнәренең бүгенге бәясе, 242 б. (I кит.)

АДМИНИСТРАТИВ-ПЛАНЛЫ СИСТЕМА (административно-плановая система) — җитештерү средстволарына дәүләт милкенең тулысынча хакимлегенә, икътисадны үзәктән планлаштыруга һәм административ идарә

итү методларына таянып, икътисадның фундаменталь проблемаларын хәл итүгә корылган икътисади система, 37 б. (I кит.)

АКСЕЛЕРАЦИЯ ПРИНЦИБЫ (принцип акселерации) — индуцияләнгән инвестицияләр күләме ТЭП арту темпы үзгәрешләре белән туры бәйләнештә, 83 б. (II кит.)

АКЦИОНЕРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ (акционерное общество) — мөлкәте акция ияләренең милке булган юридик зат, 292 б. (I кит.)

АКЦИЯ (акция) — кыйммәтле кәгазь, аның иясенең өлеше акционерлар җәмгыятенең устав капиталында булуын раслый һәм акционерлар җәмгыяте табышының бер өлешен дивиденд рәвешендә алу хокукы бирә, 292 б. (I кит.)

АКЧА (деньги) — гомуми кабул ителгән түләү чарасы, теләсә нинди сату-сатып алу объектлары өчен түләгәндә, түләү операцияләре үтәгәндә, һичшиксез кабул ителә һәм саклык туплау чарасы буларак хезмәт итә, 252 б. (I кит.)

АКЧА АГРЕГАТЛАРЫ (денежные агрегаты) — икътисадта әйләнүче акча массасының ликвидлык дәрәҗәсенә бәйләнгән күрсәткечләре, 262 б. (I кит.)

АКЧА КАПИТАЛЫ (денежный капитал) — реаль капитал сатып алу өчен билгеләнгән акча средстволары, 238 б. (I кит.)

АКЦИЯЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ПАКЕТЫ (контрольный пакет акций) — акционерлар җыелышында тавышларның күпчелеген тәэмин итә торган гадәти акцияләр саны, 295 б. (I кит.)

АЛТЫН ДЕВИЗЛЫ СТАНДАРТ (золотодевизный стандарт) — билгеле бер илнең Үзәк банкы үз банкнотларын алтынга алыштырыла торган чит ил валютасы белән алмаштырырга мәҗбүр булган акча системасы, 256 б. (I кит.)

АЛТЫН КОЕЛМАЛЫ СТАНДАРТ (золотослитковый стандарт) — билгеле бер илнең Үзәк банкы үз банкнотларын алтын акчага алыштырыла торган чит ил валютасы белән алмаштырырга мәҗбүр булган акча системасы, 256 б. (I кит.)

АЛТЫН МОНЕТАЛЫ СТАНДАРТ (золотомонетный стандарт) — билгеле бер илнең Үзәк банкы үз банкнотларын алтын коелмаларга алмаштырырга мәҗбүр булган акча системасы, 255 б. (I кит.)

АЛЬТЕРНАТИВ ЧЫГЫМНАР (альтернативные затраты) — ниндидер товарны сатып алу яки хезмәт күрсәтүгә түләү өчен кире кагылырга тиешле товар һәм хезмәт күрсәтүләр күләме, 14 б. (I кит.)

АМОРТИЗАЦИЯ ЧИГЕРҮЛӘРЕ (АМОРТИЗАЦИЯ) (амортизационные отчисления) — товар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерүдә төп капиталның тузуын каплый торган чыгымнар өлеше, 159 б. (I кит.)

АНЫК БУЛМАГАН ЧЫГЫМНАР ($Ч_{А\,Б}$) (неявные издержки) — хезмәт һәм капитал кертүнең альтернатив вариантыннан баш тарту нәтиҗәсендә алынмый калган керем суммасы, 160 б. (I кит.)

АНЫК ЧЫГЫМНАР ($Ч_А$) (явные издержки) — к. «Бухгалтерлык чыгымнары».

АРАДАШ ПРОДУКТ (промежуточный продукт) — ахыргы продуктны эшләп чыгару өчен, икътисад тармакларының билгеле бер ел эчендә эшкәртелгән продукциясе, 8 б. (II кит.)

«АРЗАН АКЧАЛАР» СӘЯСӘТЕ (политика «дешевых денег») — Үзәк банк тарафыннан үткәрелә торган акча-кредит сәясәте, әйләнештә акча массасын үстерүгә, кредитларны киңәйтүгә һәм процент ставкаларын төшерүгә юнәлтелә, 184 б. (II кит.)

АХЫРГЫ ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЛӘР (конечные товары и услуги) — ахыргы кулланучылар сатып ала торган, ягъни кабат эшкәртү һәм кабат сату максаты белән алынмый торган продукция, 9 б. (II кит.)

Ә

ӘЙЛӘНЕШ КАПИТАЛЫ (оборотный капитал) — җитештерү процессында бер генә тапкыр кулланылып, үзенең натураль формасын үзгәртә һәм әзер продукциягә әверелә, 237 б. (I кит.)

Б

БАЗАР (рынок) — товар һәм хезмәт күрсәтүләр, күчемсез милек, кыйммәтле кәгазьләр белән валюта сатучылар һәм сатып алучылар арасында контакт формасы; бу контактлар нигезендә алыш-бирешләр гамәлгә ашырыла, 44 б. (I кит.)

БАЗАР СИСТЕМАСЫ (рыночная система) — теләсә кайсы икътисади системаның фундаменталь проблемаларын хосусый милеккә, кешеләрнең шәхси инициативасына һәм ирекле эшмәкәрлеккә нигезләнеп чишү юлы, 37 б. (I кит.)

БАЗАР СОРАВЫ (рыночный спрос) — билгеле бер товарга (хезмәт күрсәтүгә) барлык сатып алучылар тарафыннан гомуми сорау күләме, 142 б. (I кит.)

БАЗАР ТИГЕЗЛӘНЕШЕ (рыночное равновесие) — билгеле бер товар яки хезмәт күрсәтү базарында бу товарга (хезмәт күрсәтүгә) тәкъдим һәм сорау күләмнәре тигезләшкән, товарга тигезләнешле бәя куелган халәт, 80 б. (I кит.)

БАНК БАЛАНСЫ (банковский баланс) — банк активлары һәм пассивлары структурасын, аларның тигезлеген чагылдыра торган документ төре, 268 б. (I кит.)

БАНК РЕЗЕРВЛАРЫ НОРМАСЫ (норма банковских резервов) — Үзәк банк тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри резервлар суммасының сорап алганга кадәр салынган кертемнәр суммасына чагыштырмасы, 270 б. (I кит.)

БАНКНЫҢ ПАССИВ ОПЕРАЦИЯЛӘРЕ (пассивные операции банка) — акча кертемнәрен җәлеп итү һәм акча җәлеп итүнең башка операцияләре, 265 б. (I кит.)

БАНКТА АКТИВ ОПЕРАЦИЯЛӘР (активные операции банка) — банкта гаилә хуҗалыкларына, хосусый һәм дәүләт фирмаларына, шулай ук табыш алу максатыннан кыйммәтле кәгазьләргә, җир участокларына һәм башка милеккә инвестицияләр формасында кредит бирү операцияләре.

БАРТЕР (бартер) — акча катнашыннан башка товар һәм хезмәт күрсәтүләр алмашу буенча алыш-биреш, 218 б. (II кит.)

БАРТЕРЛЫ ИКЪТИСАД (бартерная экономика) — товар һәм хезмәт күрсәтүләр алышу акчадан башка гына үткәрелә торган икътисади система; хәзерге шартларда реаль чынбарлыкта яши алмый, 249 б. (I кит.)

БӘЯЛӘР ДИСКРИМИНАЦИЯСЕ (ценовая дискриминация) — бер үк төрле товар яки хезмәт күрсәтүләрнең төрле сатып алучыга төрле бәядән сатылуы турындагы монополист-фирма сәясәте, 201 б. (I кит.)

БӘЯЛӘРДӘ ЛИДЕРЛЫК (лидерство в ценах) — олигопол төзелешле тармакның барлык формалары үз продукциясенә бәяләрне бу тармакның әйдәп баручы (гадәттә иң

зур) фирмасына ияреп куя, ә башка мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә торган күренеш, 211 б. (I кит.)

БӘЯЛӘРСЕЗ КОНКУРЕНЦИЯ (неценовая конкуренция) — монополистик конкуренция алымнары, базарларга товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең яңа төрләрен чыгару, реклама һәм шуңа охшаш башкаларны, конкурентларын кысрыклау өчен, турыдан-туры бәя төшерү белән бәйләнмәгән башка юллар куллану, 211 б. (I кит.)

БӘЯНЕҢ «ТҮШӘМЕ» («потолок» цены) — дәүләт тарафыннан аерым товарларга яки хезмәт күрсәтүләргә куела торган иң югары бәяләр дәрәҗәсе, бу товарларга (хезмәт күрсәтүләргә) болардан да югары бәяләр кую рөхсәт ителми, 87 б. (I кит.)

БИТАРАФЛЫК КӘКРЕЛӘРЕ КАРТАСЫ (карта кривых безразличия) — һәрберсе файдалылыкның төрле дәрәҗәсен күрсәтә торган битарафлык кәкреләре күплеге, 129 б. (I кит.)

БИТАРАФЛЫК КӘКРЕСЕ (кривая безразличия) — бер үк файдалылыкка ия булган ике байлыкның комбинацияләрен күрсәтүче нокталарның геометрик урыны, 129 б. (I кит.)

БӨТЕНДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫ (бөтендөнья икътисады) (мировое хозяйство (мировая экономика) — дөньяның үзара бәйләнгән милли икътисадлары җыелмасы, 203 б. (II кит.)

БУХГАЛТЕРЛЫК (АЧЫКТАН-АЧЫК) ЧЫГЫМНАРЫ ($Ч_б$) (бухгалтерские (явные) издержки) — продукция җитештерүгә тотылган ресурсларның аларны фактта сатып алган бәяләрдәге кыйммәте, 158 б. (I кит.)

БУХГАЛТЕР ТАБЫШЫ (бухгалтерская прибыль) — фирма кеременең бер өлеше, җитештерелгән продукцияне сатудан кергән акча белән бухгалтер чыгымнары арасындагы аерма, 161 б. (I кит)

БЮДЖЕТ СЫЗЫГЫ (бюджетная линия) — сатып алу өчен бер үк акча чыгымнары таләп иткән ике байлыктан (ике төркем байлыктан) җыелмалар төзү вариантлары күплеген чагылдыручы нокталарның геометрик урыны, 135 б. (I кит.)

БЮДЖЕТ ЧИКЛӘВЕ (бюджетное ограничение) — кулланучының акчалата кереме белән сатып алу сәләтен чикләве, 135 б. (I кит.)

В

ВАЛЮТА БАЗАРЫ (валютный рынок) — сату һәм сатып алу объекты булып төрле илләрнең валюталары торган базар, 226 б. (II кит.)

ВАЛЮТА ДЕВАЛЬВАЦИЯСЕ (девальвация валюты) — милли валюта курсын чит ил валюталарына карата рәсми төшерү, 233 б. (II кит.)

ВАЛЮТА ИНТЕРВЕНЦИЯСЕ (валютная интервенция) — билгеле бер илнең Үзәк банк тарафыннан үз валютасы курсын стабильләштерү максатыннан чит ил валютасын сатып алу һәм сату операцияләре үткәрүе, 233 б. (II кит.)

ВАЛЮТА КУРСЫ (валютный курс) — билгеле бер илдәге акча берәмлеге бәясенең башка илләр валютасында яки халыкара түләү берәмлекләрендә күрсәтелүе, 227 б. (II кит.)

ВАЛЮТА РЕВАЛЬВАЦИЯСЕ (ревальвация валюты) — милли валюта курсының чит ил валюталарына карата рәсми төстә күтәрелүе, 233 б. (II кит.)

ВАЛЮТА ЧИКЛӘҮЛӘРЕ (валютные ограничения) — хөкүмәт яки Үзәк банкның үзенең милли валюта курсын стабиль тоту максатыннан, милли һәм чит валюталары белән баручы операцияләрне чикләү чаралары, 234 б. (II кит.)

ВАЛЮТАНЫҢ АЛЫШТЫРЫЛУЫ (конвертируемость валюты) — билгеле бер ил валютасының башка илләр валюталары белән алыштырыла алу сәләте, 237 б. (II кит.)

Г

ГИПЕРИНФЛЯЦИЯ (гиперинфляция) — инфляциянең иң кискен формасы, бу вакытта бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе артымының уртача айлык темплары 50 % ка житә, 119 б. (II кит.)

ГИФФЕН ЭФФЕКТЫ (эффект Гиффена) — «иң түбән» товарларга сорауның үзенчәлекле торышы — бу товарларга бәя күтәрелгән вакытта сорау да үсә бара, 71 б. (I кит.)

ГОМУМИ САКЛЫК АКЧАЛАРЫ (общие сбережения) — йорт хуҗалыклары керемененң куллану чыгымнарын чигергәннән соң калган өлеше, 39 б. (II кит.)

ГОМУМИ ФАЙДАЛЫЛЫК (общая полезность) — кешеләрнең билгеле бер төрдәге байлык (уңайлык) күләмен тулысы белән кулланудан алган канәгатьләнүе, 119 б. (I кит.)

ГОМУМИ ЧЫГЫМНАР (общие издержки) — фирманың барлык продукциясен эшләп чыгару белән бәйләнгән чыгымнар, 164 б. (I кит.)

Д

ДАИМИ ГОМУМИ ЧЫГЫМНАР (общие постоянные издержки) — фирманың гомуми чыгымнарының бер өлеше, аларның күләме житештерелгән продукция күләменә бәйле түгел, 164 б. (I кит.)

ДӘҮЛӘТ БУРЫЧЫ (государственный долг) — дәүләтнең йорт хуҗалыкларында, банкларда һәм хосусый фирмалардагы кыйммәтле кәгазьләренең гомуми бәясе, 194 б. (II кит.)

ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ (государственный бюджет) — дәүләтнең керем алу чыгымнарын күздә тоткан акчалата керемнәре суммасы һәм дәүләт чыгымнары статьяларын күздә тоткан акчалата чыгымнар суммасы, 26 б. (II кит.)

ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ ДЕФИЦИТЫ (дефицит государственного бюджета) — дәүләт бюджеты чыгымнарының аның керемнәреннән артып китүе, 113 б. (II кит.)

ДЕЗИНФЛЯЦИЯ (дезинфляция) — бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үсүенең акрынлап кимүе, инфляциянең сүлпәнәюе, 184 б. (II кит.)

ДЕМПИНГ (демпинг) — дөнья базарларыннан конкурентларны кысрыклап чыгару максаты белән экспорт товарларына ясалма рәвештә түбән бәяләр кую, 223 б. (II кит.)

ДЕПОЗИТ (депозит) — банкка саклыкка салынган һәм банк аны вкладчыга беренче сораудан соң яки билгеләнгән вакытта кайтарып бирергә бурычлы булган акча, 258 б. (I кит.)

ДЕФИЦИТЛЫ БЮДЖЕТ ФИНАНСЛАВЫ (дефицитное бюджетное финансирование) — дәүләт чыгымнарын аңлы рәвештә бюджет дефициты ясау хисабына финанслау, 174 б. (II кит.)

ДЕФЛЯЦИЯ (дефляция) — бәяләрнең гомуми дәрәҗәсенең сезонлы характерда булмыйча төшүе, 31 б. (II кит.)

ДИСКОНТЛАУ (дисконтирование) — гамәлдәге процент ставкасы белән билгеле бер вакыттан соң алынырга тиешле керемнең бүгенге бәясен билгеләү, 242 б. (I кит.)

ДИСКОНТЛАУ КОЭФФИЦИЕНТЫ (коэффициент дисконтирования) — *t* елдан соң түләнә торган 1 сумның агымдагы дисконтланган бәясе белән сумның бүгенге бәясе чагыштырмасы, 243 б. (I кит.)

Е

ЕВРОПА БЕРЛЕГЕ (европейский союз) — интеграцияләнүче илләрнең иң зур һәм иң югары үскән Европадагы төркеме, икътисади, валюта һәм сәяси берлек, 263 б. (II кит.)

Җ

ҖИТЕШТЕРҮ МАСШТАБЫНЫҢ ТИСКӘРЕ ЭФФЕКТЫ (отрицательный эффект масштаба производства) — житештерүнең предприятиене зурайту хисабына үстерелүе уртача чыгымнар үсү белән бергә бара, 171 б. (I кит.)

ҖИТЕШТЕРҮ МАСШТАБЫНЫҢ ҮЗГӘРМИ ТОРГАН ЭФФЕКТЫ (неизменный эффект масштаба производства) — эффектның асылы — предприятиене эреләндерү хисабына продукция эшләп чыгаруның артуы бер берәмлек продукция житештерүнең уртача чыгымнары артуга китермәүдән гыйбарәт, 172 б. (I кит.)

ҖИТЕШТЕРҮ МАСШТАБЫНЫҢ УҢАЙ ЭФФЕКТЫ (положительный эффект масштаба производства) — предприятиене зурайту хисабына җитештерүне арттыру уртача чыгымнарны киметү белән бергә баргандагы эффект, 171 б. (I кит.)

ҖИТЕШТЕРҮ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ КӘКРЕСЕ (кривая производственных возможностей) — үз ресурсларын тулысынча файдаланган очракта илнең нинди дә ике товарны яки нинди дә ике товар һәм хезмәт күрсәтүләр төркемен нинди комбинацияләрдә җитештерә алу сәләтен күрсәтүче график, 14 б. (I кит.)

ҖИТЕШТЕРҮ ФАКТОРЛАРЫ (факторы производства) — кешеләр тарафыннан куллану товарлары, хезмәт күрсәтүләр һәм яңа ресурслар җитештерү өчен файдаланыла торган ресурслар, 8 б. (I кит.), 24 б. (II кит.)

ҖИТЕШТЕРҮ ФУНКЦИЯСЕ (производственная функция) — продукция эшләп чыгаруның бер яки берничә җитештерү факторына функциональ бәйлелеген күрсәтүче тигезләмә,

бу вакытта әлеге җитештерү факторлары тулысынча файдаланыла, 142 б. (II кит.)

ҖИТЕШТЕРҮНЕ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬЛӘШТЕРҮ (интернационализация производства) — халыкара хезмәт бүленеше нигезендә илләр арасында тотрыклы икътисади бәйләнешләр формалаштыру процессы, 206 б. (II кит.)

И

ИҖТИМАГЫЙ БАЙЛЫКЛАР (общественные блага) — аерым затлардан тартып алып булмый, табигатьләре буенча бүленмәс һәм алардан җәмгыятьнең кайбер кешеләре файдаланган вакытта башкаларның да файдалану мөмкинлеген калдыра торган икътисади байлыкларның бер өлеше, 55 б. (I кит.)

ИКЪТИСАД (экономика) — а) чикләнгән ресурслар шартларында нәрсәне, ничек һәм кем өчен җитештерергә дигән проблемаларны хәл итүнең билгеле бер алымнарына нигезләнеп, байлыклар җитештерү һәм бүлү системасы; б) ресурслары чикле булган җәмгыятьтә кешеләрнең ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү өчен нәрсәне, ничек һәм кем өчен җитештерергә дигән проблемаларның ничек хәл ителүен өйрәнүче фән, 21 б. (I кит.)

ИКЪТИСАДИ БАЙЛЫКЛАР (экономические блага) — кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле һәм җәмгыять карамагында чикләнгән күләмдә булган средстволар, 7 б. (I кит.)

ИКЪТИСАДИ МОДЕЛЬ (экономическая модель) — икътисадның гадиләштерелгән тасвирламасы, ике яки берничә үзгәрешле арасындагы функциональ бәйлелекне чагылдыра, 24 б. (I кит.)

ИКЪТИСАДИ РЕНТА (экономическая рента) — факттагы бәя белән әлеге ресурсны шушы конкрет ситуациягә җәлеп итү өчен җитәрлек бәя арасындагы аерма, 234 б. (I кит.)

ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ (экономический рост) — тулаем эчке продукт күләменең абсолют күрсәткечләрдә дә, илнең бер кешесенә исәпләнгәндә дә озак вакытлы арта баруы, 79 б. (II кит.)

ИКЪТИСАДИ ҮСЕШНЕҢ ИНТЕНСИВ ФАКТОРЛАРЫ (интенсивные факторы экономического роста) — җитештерү факторларының сыйфат ягыннан яхшыруы, шул сәбәпле

хезмәт, капитал һәм табигый ресурслар чыгымнарын сан ягыннан үстермичә дә ТЭП үсешенә ирешергә мөмкин (фәнни-техник прогресс, эш көчләренең квалификациясен күтәрү һ.б.), 150 б. (II кит.)

ИКЪТИСАДИ ЧЫГЫМНАР (экономические издержки) — анык (бухгалтер) һәм анык булмаган чыгымнар суммасы, 160 б. (I кит.)

ИКЪТИСАДНЫҢ ФУНДАМЕНТАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ (фундаментальные проблемы экономики) — һәрбер икътисади система хәл итәргә тиешле проблемалар; икътисад чикле ресурслар шартларында ничек һәм кем өчен житештерергә кирәклеген хәл итәргә тиеш, 18 б. (I кит.)

ИМПОРТ (импорт) — йорт хужалыклары, фирмалар һәм дәүләт тарафыннан башка илләрдә сатып алынган товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, 16 б. (II кит.)

ИНВЕСТИЦИЯЛӘРНЕҢ ПРОЦЕНТЛЫ РЕАКЦИЯСЕ (процентное реагирование инвестиций) — автоном инвестицияләрнең процент ставкасының бер пунктка төшүенә исәпләнгән үсеше, 58 б. (II кит.)

ИНДИВИДУАЛЬ СОРАУ (индивидуальный спрос) — аерым сатып алучының теге яки бу товар төренә соравы, 142 б. (I кит.)

ИНДУЦИЯЛӘНГӘН ИНВЕСТИЦИЯЛӘР (индуцированные инвестиции) — керем белән функциональ бәйлелектә булган инвестицияләр күләме, 47 б. (II кит.)

ИНДУЦИЯЛӘНГӘН КУЛЛАНУ (индуцированное потребление) — керемнән функциональ бәйлелектә булган кулланулар күләме, 38 б. (II кит.)

ИНДУЦИЯЛӘНГӘН САКЛЫК АКЧАЛАР (индуцированные сбережения) — милли керем белән саклыкка иң зур хирыслыкның тапкырчыгышы буларак билгеләнә торган саклык акчалар суммасы, 51 б. (II кит.)

ИНФЛЯЦИЯ (инфляция) — билгеле бер илнең эчке базарында сатыла торган товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең гомуми дәрәҗәсен озак вакытлар буе тотрыклы тәстә күтәрә бару, 107 б. (II кит.)

ИНФЛЯЦИЯ НОРМАСЫ (норма инфляции) — агымдагы елдагы товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми дәрәҗә-

сенең артуы белән узган елдагы бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе чагыштырмасы, 110 б. (II кит.)

ИҢ ЧИК КЕРЕМ (MR) (предельный доход) — фирманың продукция эшләп чыгаруны бер берәмлеккә арттыру нәтиҗәсендә аның гомуми кереме артымы, 182 б. (I кит.)

ИҢ ЧИК УРЫН АЛМАШУ НОРМАСЫ (MRS) (предельная норма замещения) — *X* һәм *Y* товарлары җыелмасының гомуми файдалылыгы үзгәрешсез калган хәлдә, өстәмә рәвештә берәмлек *X* товарын алу өчен ничә берәмлек *Y* товарыннан баш тартырга кирәклеге күрсәткече, 130 б. (I кит.)

ИҢ ЧИК ФАЙДАЛЫЛЫК (MU) (предельная полезность) — гомуми файдалылыкның билгеле бер байлыкны куллану күләмен бер берәмлеккә арттыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән артым, ягъни кулланучы ала торган байлыклардан соңгы берәмлекнең файдалылыгы, 119 б. (I кит.)

ИҢ ЧИК ХЕЗМӘТ ПРОДУКТЫ (MP_2) (предельный продукт труда) — өстәмә хезмәт (эшче көче) берәмлеге куллану нәтиҗәсендә гомуми продуктның артымы, 154 б. (I кит.)

ИҢ ЧИК ЧЫГЫМНАР (MC) (предельные издержки) — продукция эшләп чыгаруны бер берәмлеккә арттыру белән бәйләнгән гомуми чыгымнар артымы, 166 б. (I кит.)

ИРЕКЛЕ БАЙЛЫКЛАР (свободные блага) — табигатьтә чиксез күләмдә булган һәм һәр кешегә аның бу байлыкка карата ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә җитәрлек туры килгән байлыклар, 7 б. (I кит.)

ИРЕКЛЕ ИКЪТИСАДИ ЗОНА (свободная экономическая зона) — нинди дә булса ил территориясенең күпмедер өлеше; биредә, чит ил инвестицияләрен җәлеп итү һәм тышкы сәүдәне үстерү максатыннан чыгып, чит ил капиталына салым салу, товарларны пошлинасыз кертү һәм чыгару өлкәсендә өстенлекләр каралган, 255 б. (II кит.)

Й

ЙОРТ ХУҖАЛЫГЫ (домашнее хозяйство) — базар системасы субъекты, гаиләдән яки гаиләсе булмаган бер кешедән тора, җитештерү факторлары хуҗасы һәм бу факторлар ярдәмендә җитештерелгән керемнәрне алучы булып тора;

йорт хуҗалыгы керемнәренең бер өлешен шәхси куллануы өчен тота, икенче өлешен саклыкка сала һәм инвестицияли.

К

КАМИЛ ДӘРӘҖӘДӘГЕ БӘЯЛӘР ДИСКРИМИНАЦИЯСЕ (совершенная ценовая дискриминация) — монополист-фирма сәясәте: ул үз продукциясенең һәр берәмлегенә төрле бәяләр куя, 201 б. (I кит.)

КАМИЛ БУЛМАГАН КОНКУРЕНЦИЯ (несовершенная конкуренция) — базар структураларының эшләү шартлары, бу шартларда товар яки хезмәт күрсәтүләрен сатучылар үз продукциясе бәясенә үзләре йогынты ясарга яки бәяне үзләре куярга сәләтле, 181 б. (I кит.)

КАМИЛ КОНКУРЕНЦИЯ (совершенная конкуренция) — стандартлашкан продукция җитештерүчеләр арасында конкуренция шартлары: фирмалар саны гаять күп, базар киртәләре юк, икътисади мәгълүмат тулысынча ачык һәм бәяләр өстеннән контроль юк, 182 б. (I кит.)

КАРТЕЛЬ (картель) — берничә олигополист фирма арасында билгеле бер тармак продукциясенә бәяләр кую һәм продукцияне сату күләмен билгеләү буенча яшерен сүз куешу яки легаль рөхсәт ителгән килешү; картель үз катнашучыларының керемнәрен арттыру һәм куркынычсызлыгын киметү максатында төзелә, 210 б. (I кит.)

КАТНАШ ИКЪТИСАД (смешанная экономика) — хосусый милеккә һәм ирекле эшмәкәрлеккә нигезләнгән, дәүләт тарафыннан идарә ителә торган базар системасы, 60 б. (I кит.)

КЕШЕ КАПИТАЛЫ (человеческий капитал) — кешенең керем китерә алу сәләтен акчалата бәяләү, 237 б. (I кит.)

КИМИ БАРУЧЫ ИҢ ЧИК ФАЙДАЛЫЛЫК ЗАКОНЫ (закон убывающей предельной полезности) — кулланыла торган икътисади байлыклар күләме арткан саен, һәрбер өстәмә байлык берәмлегенең файдалылыгы кими бара, 120 б. (I кит.)

КИМИ БАРУЧЫ ЭФФЕКТИВЛЫК ЗАКОНЫ (закон убывающей эффективности) — әгәр зурлыклары үзгәрешсез (мәсәлән, капитал һәм җир) берничә җитештерү факторы

булса, үзгәрешле ресурсның (мәсәлән, хезмәтнең) әзлекле үсә баруы, ниндидер мизгелдән башлап, үзгәрешле ресурсның җитештерүчәнлеге төшүе белән бергә барачак, 156 б. (I кит.)

КИРӘГЕННӘН АРТЫК СОРАУ (избыточный спрос) — товар һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем сорауның тулаем тәкъдимнән тотрыклы төстә артык булуы, 111 б. (II кит.)

КОММЕРЦИЯ БАНКЫ (коммерческий банк) — банк операцияләре алып баруга, ягъни фирмалар һәм хуҗалыкларның акчаларын үзенә җәлеп итү, кредитлар һәм җәлеп ителгән акчаларны инвестицияләүнең башка формаларын куллану операцияләренә лицензиясе булган шәхси коммерция фирмасы, 265 б. (I кит.)

КОНКУРЕНТ ФИРМАНЫҢ КЫСКА ВАКЫТТА ТИГЕЗЛӘНЕШ ШАРТЫ (условие равновесия конкурентной фирмы в краткосрочном периоде) — продукциянең иң чик чыгымнары *(MC)* бу продукциянең бер берәмлеге бәясенә *(P)* тигез булырга тиеш, ягъни $MC = P$, 189 б. (I кит.)

КОНКУРЕНТ ФИРМАНЫҢ ОЗАК ВАКЫТТА ТИГЕЗЛӘНЕШ ШАРТЫ (условие равновесия конкурентной фирмы в долгосрочном периоде) — продукциянең уртача гомуми чыгымнары иң чик чыгымнарга, димәк, бер берәмлек продукция бәясенә тигез булырга тиеш, ягъни $ATC = MC = P$, 195 б. (I кит.)

КОНКУРЕНЦИЯ (конкуренция) — товар җитештерүчеләр арасында үз продукциясен сату базарлары һәм аны сатудан керем алу өчен барган көрәш, 48 б. (I кит.)

КРЕДИТ АКЧАЛАРЫ (кредитные деньги) — Үзәк банкның бурычы йөкләмәләре, алар гомуми танылган түләү чарасы булып тора һәм акча функциясен үти, 255 б. (I кит.)

КРЕДИТ СЫЗЫГЫ (кредитная линия) — кредит шартларының берсе, бу шарт буенча, билгеләнгән срокта клиентка билгеле бер суммага кредит ачалар һәм, шушы срок эчендә клиентка түли алу сәләтен кабат тикшермичә генә, акча бирелә, 272 б. (I кит.)

КУЛЛАНУ ФУНКЦИЯСЕ (функция потребления) — куллану күләменең керемнәр күләменә функциональ бәйлелеген күрсәтүче тигезләмә, 41 б. (II кит.)

КУЛЛАНУГА ИҢ ЧИК ХИРЫСЛЫК (С) (предельная склонность к потреблению) — керем артымының куллануга тотыла торган өлеше, 39 б. (II кит.)

КУЛЛАНУЧЫНЫҢ ТИГЕЗЛӘНЕШ ХАЛӘТЕ (равновесие потребителя) — кулланучының үзенең барлык акчалата кеременә билгеле бәяләрдән максималь гомуми файдалылыкка ирешерлек күләмдә товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу халәте, 140 б. (I кит.)

«КЫЙММӘТЛЕ АКЧАЛАР» СӘЯСӘТЕ (политика «дорогих денег») — Үзәк банкның акча-кредит сәясәте; әйләнештәге акча массасы артуны чикли, кредитлар кинәюгә каршылык тудыра һәм процент ставкалары күтәрелүне стимуллаштыра, 184 б. (II кит.)

КЫСКА СРОКЛЫ ПЕРИОД (краткосрочный период) — кайбер житештерү факторларының зурлыгы үзгәрергә, ә калган факторларның зурлыклары билгеләнгән килеш калырга мөмкин булган вакыт интервалы, 152 б. (I кит.)

Л

ЛАФФЕР КӘКРЕСЕ (кривая Лаффера) — дәүләт бюджетына кергән салымнар зурлыгының салым ставкаларына функциональ бәйлелеген күрсәтүче график, 190 б. (II кит.)

ЛИЗИНГ (лизинг) — банк операциясе: банк жиһаз сатып ала, аны соңыннан сатып алу хокукы белән үзенең клиентына арендага бирә, 267 б. (I кит.)

ЛИКВИДЛЫК (ликвидность) — активларның (кыйммәтле кәгазьләр, әзер продукция запаслары һ.б.) иң кыска срокларга һәм бик аз чыгымнар белән акчага әйләнү сәләте, 261 б. (I кит.)

ЛОРЕНЦ КӘКРЕСЕ (кривая Лоренца) — халыкның төрле социаль төркемнәре арасында керемнәр бүленешенең тигезсезлек дәрәжәсен күрсәтүче график.

М

МАКРОИКЪТИСАД (макроэкономика) — икътисад фәненең бер бүлеге, ул икътисадны бербөтен буларак өйрәнә, 21б. (I кит.)

МӘШГУЛЬ БУЛУ; МӘШГУЛЬЛЕК (занятые (занятость) — ялланып (найм буенча) эшләүче, хосусый бизнес белән

шөгыльләнүче, дәүләт хезмәтендә торучы яки уку йортларында укучы, илдәге халыкның икътисади актив өлеше, 88 б. (II кит.)

МЕНЕДЖЕР (менеджер) — фирма һәм аның структур бүлекчәсе белән идарә итүче, башкарма вәкаләтләр һәм карарлар кабул итү хокукы бирелгән зат, 299 б. (I кит.)

МЕНЕДЖМЕНТ (менеджмент) — предприятие һәм аның бүлекчәләре белән фәнни принципларга, алымнарга һәм формаларга нигезләнеп, предприятие эшенең эффективлыгын күтәрүгә һәм керемнәрне (табыш, хезмәт хакы һ. б.) арттыруга юнәлтелгән идарә итү, 298 б. (I кит.)

МИКРОИКЪТИСАД (микроэкономика) — икътисад фәненең бер бүлеге, йорт хуҗалыкларын, фирмаларны һәм базар системасының башка субъектларын, шулай ук аерым базарлар һәм базар структураларынын эшен өйрәнә, 21 б. (I кит.)

МИЛЛИ КЕРЕМ (МК) (национальный доход) — тулаем милли продуктның амортизация чигерүләрен һәм турыдан-туры булмаган салымнарны алып ташлаганнан соң калган өлеше, 23 б. (II кит.)

МОНОПОЛИСТИК КОНКУРЕНЦИЯ (монополистическая конкуренция) — базар структурасының эшләү тибы: бик күп сандагы фирмалар бер-берсен алыштырып була торган товар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерә, 212 б. (I кит.)

МОНОПОЛИЯ (монополия) — билгеле бер төрдәге продукцияне бердәнбер җитештерүче һәм сатучы предприятие, 195 б. (I кит.)

МУЛЬТИПЛИКАТОР (мультипликатор) — автоном чыгымнар үсешенә карата милли керем һәм ТЭП дәрәҗәсенең ничә тапкыр артып китүен күрсәтүче коэффициент, 53 б. (II кит.)

Н

НОМИНАЛЬ ИКЪТИСАДИ ЗУРЛЫКЛАР (номинальные экономические величины) — агымдагы бәяләрдә күрсәтелгән икътисади күрсәткечләр, 30 б. (I кит.)

НОМИНАЛЬ ПРОЦЕНТ СТАВКАСЫ (номинальная процентная ставка) — акча бәрөмлекләрендә күрсәтелгән номиналь процент суммасының бу процентны биргән номиналь капитал суммасына чагыштырмасы, 239 б. (I кит.)

НОМИНАЛЬ ТЭП (номинальный ВВП) — илдә җитештерелгән ахыргы товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең агымдагы бәяләрдә белдерелгән күләме, 30 б. (II кит.)

НОРМАЛЬ ИНФЛЯЦИЯ (нормальная инфляция) — товар һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе артуының уртача еллык темпы 5% тан кимрәк булган инфляция, 117 б. (II кит.)

НОРМАТИВ ИКЪТИСАД (нормативная экономика) — икътисад теориясенең бер юнәлеше, субъектив фикерләүләргә нигезләнеп, эш рецептлары тәкъдим итә һәм нәрсә булырга тиешлеген күрсәтергә омтыла, 22 б. (I кит.)

О

ОБЛИГАЦИЯ (облигация) — кыйммәтле кәгазь, акционерлык җәмгыятенең яки дәүләтнең бурыч йөкләмәсе, аның нигезендә облигация иясенә билгеләнгән процент суммасы түләнә һәм билгеләнгән срокта аңа шушы облигациянең номиналь бәясе буенча акча кайтарып бирелә, 293 б. (I кит.)

ОЗЫН СРОКЛЫ ПЕРИОД (долгосрочный период) — барлык җитештерү факторлары үзгәреш кичергән вакыт аралыгы, 152 б. (I кит.)

ОЗЫН ЦИКЛ (длинный цикл) — дөнья икътисады үсешенең эзлекле килүче тизләнешләре һәм акрынаюларының 50—60 еллык периоды, 163 б. (II кит.)

ОЛИГОПОЛИК БӘЙЛӘНЕШ (олигополистическая взаимозависимость) — олигополик базарда эре фирманың эшгамәлләренә конкурент фирмаларның тәэсирен исәпкә алу зарурлыгы, 209 б. (I кит.)

ОЛИГОПОЛИЯ (олигополия) — базар структурасы, бу очракта нинди дә булса продукт базарында күп булмаган сатучы фирмалар эшли һәм, бу фирмаларның һәркайсы, базарга әлеге продуктны җитәрлек дәрәҗәдә кертеп, аның бәясенә шактый зур йогынты ясый, 208 б. (I кит.)

ОУКЕН ЗАКОНЫ (закон Оукена) — ТЭПның 2,5 % ка уртача еллык темпы эшсезлек нормасын үзгәрешсез калдыра, ә ТЭП арту темпының бер процентка күтәрелүе (төшүе) эшсезлек нормасын 0,4 процентка төшерә (күтәрә), 96 б. (II кит.)

Ө

ӨСТӘЛГӘН БӘЯ (добавленная стоимость) — предприятие, тармак яки икътисад житештергән тулаем продукция бәясенең арадаш продукт бәясен алганнан соң калган өлеше, 19 б. (II кит.)

ӨЧЕНЧЕ ЗАТНЫҢ ФАЙДА АЛУЫ (выгода третьего лица) — к. «Уңай тышкы эффект».

ӨЧЕНЧЕ ЗАТНЫҢ ЧЫГЫМНАРЫ (издержки третьего лица) — к. «Тискәре тышкы эффектлар».

П

ПОЗИТИВ ИКЪТИСАД (позитивная экономика) — икътисад теориясенең бер юнәлеше, ул икътисадның ничек эшләвенә һәм үсүенә фәнни аңлатма бирергә, шулай ук реаль чынбарлыкта нәрсә барын һәм нәрсәнең булырга мөмкин икәнен күрсәтергә омтыла, 22 б. (I кит.)

ПОРТФЕЛЬЛЕ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР (портфельные инвестиции) — чит ил инвестицияләре, алар бу капитал салынган фирманың эшчәнлеген контрольдә тотуны (мәсәлән, акцияләрнең контроль пакетын) тәэмин итми, 250 б. (II кит.)

ПОТЕНЦИАЛЬ ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ (потенциальный валовой внутренний продукт) — гамәлдәге ресурсларны тулысынча файдаланган вакытта, ягъни тулы мәшгульлек һәм житештерү куәтләрен оптималь эшләткән очракта ирешелгән яисә ирешергә мөмкин булган ТЭП дәрәҗәсе, 113 б. (II кит.)

ПРЕДПРИЯТИЕНЕҢ ИҢ КЕЧКЕНӘ ЭФФЕКТИВ ҮЛЧӘМЕ (минимально эффективный размер предприятия) — предприятиенең уртача житештерү чыгымнары минимальләшә торган продукция күләменә ирешергә мөмкинлек бирә торган үлчәме, 172 б. (I кит.)

ПРОЦЕНТ (процент) — капиталның хезмәт күрсәтү бәясе, капитал иялеренең кереме, 220, 238 б. (I кит.)

ПРОЦЕНТ СТАВКАСЫ (процентная ставка) — кредитка бирелгән капиталдан алынган еллык процент суммасының бу капитал суммасына чагыштырмасы, 239 б. (I кит.)

Р

РЕАЛЬ КАПИТАЛ (реальный капитал) — товар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерү процессында кулланыла торган эшләнмә ресурслар, 236 б. (I кит.)

РЕАЛЬ ПРОЦЕНТ СТАВКАСЫ (реальная процентная ставка) — бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үсү нәтиҗәсендә акчаның бәясе төшүгә төзәтмә ясаучы процент ставкасы, 240 б. (I кит.)

РЕАЛЬ ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ (реальный валовой внутренний продукт) — илдә җитештерелгән ахыргы товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең үзгәрешсез бәяләрдә алынган күләме, 30 б. (II кит.)

РЕНТА (рента) — җир хезмәтенең бәясе, җир хуҗаларының кереме, 220 б. (I кит.)

С

САКЛЫККА ИҢ ЧИК ХИРЫСЛЫК (*s*) (предельная склонность к сбережениям) — керем артымының кулланудан тыш кала торган өлеше, 39 б. (II кит.)

САФ ИКЪТИСАДИ РЕНТА (чистая экономическая рента) — ресурс китергән, әмма аңа тәкъдим бәясе буенча тулысынча сыгылмалы булмаган керем, 235 б. (I кит.)

САФ МИЛЛИ ПРОДУКТ (СМП) (чистый национальный продукт) — тулаем милли продуктның амортизация чигерүләреннән соң калган өлеше, 22 б. (II кит.)

САФ ЭКСПОРТ (саф импорт) (чистый экспорт (чистый импорт) — к. «Сәүдә балансы».

СӘҮДӘ БАЛАНСЫ (торговый баланс) — чит дәүләтләргә, фирмаларга һәм йорт хуҗалыкларына сатылган товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясе белән чит дәүләтләрдән һәм аларның шәхси фирмаларыннан сатып алынган товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясе арасындагы аерма, 16 б. (II кит.)

СӘҮДӘ (ТЫШКЫ) ШАРТЛАРЫ ИНДЕКСЫ (индекс условий (внешней) торговли) — экспорт товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре бәясе индексының импорт товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре бәясе индексына нисбәте.

СОРАУ (спрос) — сатып алучылар алырга теләгән һәм ала торган товар (хезмәт күрсәтү) күләме белән бу товар (хезмәт күрсәтү) бәяләре арасындагы бәйлелек, 67 б. (I кит.)

СОРАУ ЗАКОНЫ (закон спроса) — билгеле бер товарга (хезмәт күрсәтүгә) сорау зурлыгының бу товар (хезмәт күрсәтү) бәясе дәрәҗәсе белән кире бәйләнештә торуы, 69 б. (I кит.)

СОРАУ КӘКРЕСЕ (кривая спроса) — товарга (хезмәт күрсәтүгә) сорау зурлыгының бу товар (хезмәт күрсәтү) бәясе белән функциональ бәйлелеген күрсәтүче график, 69 б. (I кит.)

СОРАУНЫҢ АКЧАГА ПРОЦЕНТЛЫ РЕАКЦИЯСЕ (процентное реагирование спроса на деньги) — акчага сорауның процент ставкасының бер берәмлеккә төшүенә исәпләнгән үсеше, 66 б. (II кит.)

СОРАУНЫҢ БӘЯЛӘР БУЕНЧА СЫГЫЛМАЛЫГЫ (ценовая эластичность спроса) — сорауның товар (хезмәт күрсәтү) бәясенең 1% ка үзгәрешенә реакциясе үлчәме, 93 б. (I кит.)

СОРАУНЫҢ БЕРӘМЛЕКЛЕ СЫГЫЛМАЛЫЛЫГЫ (единичная эластичность спроса) — сорауның эластиклык коэффициенты 1 гә тигез булгандагы эластиклык очрагы, 94 б. (I кит.)

СОРАУНЫҢ ЗУРЛЫГЫ (Q_d) (величина спроса) — сатып алучыларның билгеле бер вакытта һәм билгеле урында билгеле бәягә сатып алырга әзер һәм сәләтле булган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр саны, 68 б. (I кит.)

СОРАУНЫҢ КЕРЕМ БУЕНЧА СЫГЫЛМАЛЫГЫ (эластичность спроса по доходу) — товарны (хезмәт күрсәтүне) сатып алучылар кеременең үзгәреше аркасында бу товарга (хезмәт күрсәтүгә) сорау күләменең реакциясе үлчәме, 103 б. (I кит.)

СОРАУНЫҢ СЫГЫЛМАЛЫГЫ (эластичность спроса) — к. «Сорауның бәяләр буенча сыгылмалыгы».

СОРАУНЫҢ ТӨРЛЕ ЯКЛАП СЫГЫЛМАЛЫЛЫГЫ (перекрестная эластичность спроса) — билгеле бер товар яки хезмәт күрсәтүгә сорау зурлыгының реакциясе үлчәме, бу реакция икенче бер товар һәм хезмәт күрсәтүләргә бәя үзгәрүеннән килеп чыга, 104 б. (I кит.)

СТАГФЛЯЦИЯ (стагфляция) — икътисад кризисы; инфляция һәм торгынлыкның (стагнация) берьюлы үсешендә яки ТЭП җитештерүнең кимүендә чагыла, 130 б. (II кит.)

СТРУКТУР ЭШСЕЗЛЕК (структурная безработица) — эшсезлек формасы; эшче көчнең профессиональ структурасы эш урыннарының структурасына туры килмәү нәтиҗәсендә була, 92 б. (II кит.)

СЫГЫЛМАЛЫ БУЛМАГАН СОРАУ (неэластичный спрос) — билгеле бер товар бәясен 1% ка үзгәртү бу товарга сорауны 1% тан да кимрәккә үзгәртү үзлеге, 97 б. (I кит.)

СЫГЫЛМАЛЫ БУЛМАГАН ТӘКЪДИМ (неэластичное предложение) — товар бәясен 1% ка үзгәртү бу товарга тәкъдимне 1% тан кимрәккә үзгәртә торган тәкъдим, 105 б. (I кит.)

СЫГЫЛМАЛЫ ТӘКЪДИМ (эластичное предложение) — бәянең 1% ка үзгәрүе нәтиҗәсендә 1% тан артыкка үзгәрү үзлегенә ия булган тәкъдим, 105 б. (I кит.)

СЫГЫЛМАЛЫ СОРАУ (эластичный спрос) — бәянең 1% ка үзгәрүе нәтиҗәсендә 1% тан артыкка үзгәрү үзлегенә ия булган сорау, 93 б. (I кит.)

Т

ТАБИГЫЙ МОНОПОЛИЯ (естественная монополия) — тармакта продукцияне бердәнбер житештерүче, 204 б. (I кит.)

ТАБИГЫЙ ТЭП (естественный ВВП) — к. «Потенциаль ТЭП».

ТАБИГЫЙ ЭШСЕЗЛЕК (естественная безработица) — эшсезлекнең циклик эшсезлек юк дип исәпләнгән формасы, 92 б. (II кит.)

ТАБЫШ (Т) (прибыль) — эшмәкәрнең кереме, ягъни эшмәкәрлек эшчәнлегенең бәясе, 220 б. (I кит.)

ТАМОЖНЯ ПОШЛИНАСЫ (таможенная пошлина) — турыдан-туры булмаган салым төре; чик аша чыгарыла торган товарларга салына, 221 б. (II кит.)

ТӘКЪДИМ (предложение) — фирмалар сатарга әзер һәм сата алган товар (хезмәт күрсәтү) күләме белән бу товар (хезмәт күрсәтү) бәяләре арасындагы бәйлелек, 75 б. (I кит.)

ТӘКЪДИМ ЗАКОНЫ (закон предложения) — товар яки хезмәт житештерү тәкъдиме зурлыгының бу товар (хезмәт) бәясе дәрәҗәсе белән туры бәйләнештә торуы, 77 б. (I кит.)

ТӘКЪДИМ КӘКРЕСЕ (кривая предложения) — товарга (хезмәт күрсәтүгә) тәкъдим зурлыгының бу товар (хезмәт күрсәтү) бәясе белән функциональ бәйлелеген күрсәтүче график, 76 б. (I кит.)

ТӘКЪДИМНЕҢ БӘЯЛӘР БУЕНЧА СЫГЫЛМАЛЫГЫ (ценовая эластичность предложения) — бирелгән товарга (хезмәт күрсәтүгә) тәкъдим зурлыгының бу товар (хезмәт күрсәтү) бәясенең 1% ка үзгәрешенә реакциясе үлчәме, 105 б. (I кит.)

ТӘКЪДИМНЕҢ ЗУРЛЫГЫ (Q_s) (величина предложения) — фирмаларның билгеле урында һәм билгеле вакыт аралыгында билгеле бер бәядән сатарга әзер һәм сәләтле булган продукциясе күләме, 76 б. (I кит.)

ТӘКЪДИМНЕҢ СЫГЫЛМАЛЫГЫ (эластичность предложения) — к. «Тәкъдимнең бәяләр буенча сыгылмалыгы».

ТЕХНОЛОГИК ЭШСЕЗЛЕК (технологическая безработица) — структур эшсезлекнең бер төре; житештерүгә хезмәтне аз сорый торган җиһазлар кертү сәбәпле барлыкка килә, 92 б. (II кит.)

ТИГЕЗЛӘНЕШЛЕ ТЭП (МК) (равновесный ВВП) — тулай эчке продуктның (милли керемнең) товар һәм хезмәт күрсәтүләргә тулаем сорау белән тулаем тәкъдим зурлыклары тигезләшкән очрактагы күләме, 44 б. (II кит.)

ТИГЕЗЛӘНЕШЛЕ БӘЯ (равновесная цена) — сатучылар тәкъдим иткән товар (хезмәт күрсәтү) күләме сатып алучылар сатып алырга мөмкин һәм әзер булган күләм белән тигезләшкән очрактагы бәя, 82 б. (I кит.)

ТИСКӘРЕ ТЫШКЫ ЭФФЕКТЛАР (отрицательные внешние эффекты) — кайбер эшләнмәләр житештерү яки куллануның әйләнә-тирәгә һәм кешеләр сәламәтлегенә тискәре йогынтысы, 54 б. (I кит.)

ТОВАР АКЧАЛАРЫ (товарные деньги) — акча функциясен үтәгән товар (мәсәлән, алтын һәм көмеш), 253 б. (I кит.)

ТОВАР АРТЫКЛЫГЫ (товарный излишек) — бер, берничә яки күп сандагы товар базарында була торган ситуация: бу товарларга дәүләт куйган һәм ул көйли торган бәяләр тигезләнешле бәяләрдән югарырак булу сәбәпле, аларга сорау тәкъдимгә караганда бик күпкә кими, 88 б. (I кит.)

ТОВАР ДЕФИЦИТЫ (товарный дефицит) — бер, берничә яки күп сандагы товар базарында була торган ситуация: бу товарларга дәүләт куйган һәм ул көйли торган бәяләр тигезләнешле бәяләрдән түбәнрәк булу сәбәпле, аларга сорау тәкъдимгә караганда бик күпкә артып китә, 87 б. (I кит.)

ТОВАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР ЭКСПОРТЫ (экспорт товаров и услуг) — билгеле бер елдә җитештерелгән товар һәм хезмәт күрсәтүләрне чит илләр фирмаларына, йорт хуҗалыкларына һәм дәүләтләренә сату, 16 б. (II кит.)

ТӨП КАПИТАЛ (основной капитал) — капиталның бер өлеше, аңа биналар, корылмалар, машиналар, җиһазлар һәм шуңа охшаш җитештерү чаралары керә, алар күп еллар буе производствода файдаланылып, үз бәяләрен югалтып, акрынлап тузалар, 159 б. (I кит.)

ТРАНСФЕРТ ТҮЛӘҮЛӘРЕ (трансфертные платежи) — товар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен булмаган барлык акчалата түләү төрләре, 26 б. (II кит.)

ТУЛАЕМ КУЛГА КЕРГӘН КЕРЕМ (совокупный располагаемый доход) — йорт хуҗалыклары тарафыннан алынган керемнәр суммасы, 27 б. (II кит.)

ТУЛАЕМ ШӘХСИ КЕРЕМ (совокупный личный доход) — йорт хуҗалыкларының керем буенча салым тотып калганга кадәр исәпләнгән керемнәренең гомуми суммасы, 27 б. (II кит.)

ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ (ТЭП) (валовой внутренний продукт (ВВП)) — билгеле бер илдә бер ел эчендә җитештерелгән барлык товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми бәясе, 10 б. (II кит.)

ТУЛАЙ МИЛЛИ ПРОДУКТ (ТМП) (валовой национальный продукт (ВНП)) — билгеле бер илнең җитештерү факторлары тарафыннан бу илнең үзендә һәм аннан читтә җитештерелгән барлык товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми бәясе, 12 б. (II кит.)

ТУЛЫ МӘШГУЛЬЛЕК (полная занятость) — икътисадта бары тик фрикцион һәм структур эшсезлек кенә булган очракта мәшгульлек дәрәҗәсе, 93 б. (II кит.)

ТУЛЫСЫНЧА СЫГЫЛМАЛЫ БУЛМАГАН СОРАУ (совершенно неэластичный спрос) — товарга сорауның үзенчәлеге, бу товарга сорауның күләме теләсә нинди бәяләр өчен дә үзгәрешсез кала, ягъни сорау зурлыгы бәянең теләсә кайсы юнәлешләрдә үзгәрүенә битараф кала, 97 б. (I кит.)

ТУЛЫСЫНЧА СЫГЫЛМАЛЫ СОРАУ (совершенно эластичный спрос) — товарга сорауның үзенчәлеге, бу товарга бәянең иң азга гына күтәрелүе сорауның нульгә кадәр төшүенә китерә, 96 б. (I кит.)

ТУРЫДАН-ТУРЫ БУЛМАГАН САЛЫМНАР (косвенные налоги) — фирмалар тарафыннан сатыла торган продукциягә, шулай ук чит илләргә чыгарыла яки чит илләрдән кертелә торган продукциягә салына торган салымнар; турыдан-туры булмаган салымнар товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясенә кертелә, 18 б. (II кит.)

ТУРЫДАН-ТУРЫ САЛЫМНАР (прямые налоги) — йорт хуҗалыклары һәм фирмаларның керемнәренә салына һәм бу керемнәрдән турыдан-туры алып калына торган салымнар, 18 б. (II кит.)

ТУРЫДАН-ТУРЫ ЧИТ ИЛ ИНВЕСТИЦИЯЛӘРЕ (прямые зарубежные инвестиции) — чит илләрдә инвесторның яңа яки эшләп килүче предприятиеләренә капитал салу; акцияләргә инвестиция кертү, нәтиҗәдә инвестор аларның контроль пакетына ия була; чит илләрнең фирма өстеннән контрольлеген тәэмин итүче теләсә нинди башка инвестицияләр, 250 б. (II кит.)

ТҮЛӘҮ БАЛАНСЫ (платежный баланс) — билгеле бер ил һәм чит илләр икътисадлары субъектларының акча ресурслары керүен һәм чыгуын чагылдыра торган барлык операцияләре күләменең күрсәткечләре системасы, 256 б. (II кит.)

ТЭП ДЕФЛЯТОРЫ (ИНДЕКС-ДЕФЛЯТОРЫ) (дефлятор (индекс-дефлятор) ВВП) — номиналь ТЭПның реаль ТЭПка чагыштырмасы, ахыргы товар һәм хезмәт күрсәтүләргә гомуми бәяләр дәрәҗәсенең үзгәрүен күрсәтә, 32 б. (II кит.)

ТЭПНЫҢ ИНДЕКС-ДЕФЛЯТОРЫ (индекс-дефлятор ВВП) — к. «ТЭП дефляторы».

У

УНИТАР ПРЕДПРИЯТИЕ (унитарное предприятие) — коммерция оешмасы, ләкин аның үзенә беркетелгән мөлкәткә милекчелек хокукы юк, бу милек дәүләтнеке булып кала, 296 б. (I кит.)

УҢАЙ ТЫШКЫ ЭФФЕКТ (положительный внешний эффект) — аерым фирмага яки хосусый затка гына түгел, бөтен җәмгыятькә, бу эффектны алуга чыгымнар тотылган фирмалар яки хосусый затлар төркеменә дә турыдан-туры отыш (керем) китерә торган җитештерү эффекты, 54 б. (I кит.)

УРТАЧА ГОМУМИ ЧЫГЫМНАР (средние общие издержки) — фирманың үз продукциясенең бер берәмлегенә исәпләнгән үзгәрешле чыгымнары, 165 б. (I кит.)

УРТАЧА ДАИМИ ЧЫГЫМНАР (средние постоянные издержки) — фирманың үз продукциясенең бер берәмлегенә исәпләнгән даими чыгымнары, 165 б. (I кит.)

УРТАЧА ИНФЛЯЦИЯ (умеренная инфляция) — бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе артымының уртача еллык темпы 5 % ка җитә, ләкин 10 % ка җитми, 123 б. (II кит.)

Ү

ҮЗӘК БАНК (Центральный банк) — дәүләт милке булган яки турыдан-туры ул контрольдә тота торган банк, үз иленең банклар һәм акча системасының стабиль эшләвен тәэмин итәргә тиеш, 276 б. (I кит.)

ҮЗӘК БАНКНЫҢ ИСӘП-ХИСАП СТАВКАСЫ (учетная ставка центрального банка) — Үзәк банк тарафыннан коммерция банклары өчен куела торган процент ставкасы — алар ҮБдан төп үз резервларының вакытлыча җитмәүчелеген капларга кредит алган очракта куела, 280 б. (I кит.)

ҮЗГӘРҮЧӘН ГОМУМИ ЧЫГЫМНАР (*TVC*) (общие переменные издержки) — фирманың гомуми чыгымнарының бер өлеше, аларның күләме эшләп чыгарылган продукция күләме белән туры бәйләнештә була, 165 б. (I кит.)

«ҮРМӘЛӘП БАРУЧЫ» ИНФЛЯЦИЯ («ползучая» инфляция) — к. «Нормаль инфляция».

ҮСЕШНЕҢ ЭКСТЕНСИВ ФАКТОРЛАРЫ (экстенсивные факторы роста) — җитештерүнең эффективлыгы үсмәгән хәлдә хезмәт, капитал һәм табигый ресурсларның күләме арту, 150 б. (II кит.)

Ф

ФАЙДАЛЫЛЫКНЫ ӨЙРӘНҮГӘ КАРДИНАЛИСТИК ЯКЫН КИЛҮ (кардиналистский подход к изучению полезности) — иң чик файдалылык теориясенең башлангыч фаразы, аның буенча кулланучылар байлыкларының файдалылыгын шартлы берәмлекләр (ютильләр) белән субъектив бәялиләр, ягъни файдалылыкка санча бәя бирәләр, 121 б. (I кит.)

ФАЙДАЛЫЛЫКНЫ ӨЙРӘНҮТӘ ОРДИНАЛИСТИК ЯКЫН КИЛҮ (ординалистский подход к изучению полезностей) — иң чик файдалылык теориясенең башлангыч фаразы; аның буенча, кулланучы товар һәм хезмәт күрсәтүләрне аларның файдалылыгына карап бүлә, 126 б. (I кит.)

ФАЙДАЛЫЛЫКНЫҢ МАКСИМАЛЬЛӘШТЕРҮ КАГЫЙДӘСЕ (правило максимизации полезности) — әгәр кулланучы сатып ала торган товарларның иң чик файдалылыклары арасындагы чагыштырмалар аларның бәяләре арасындагы чагыштырмаларга тигез булса, бу кулланучы үз ихтыяҗларын максималь канәгатьләндерүгә ирешә һәм тигезләнеш хәлендә булып чыга, 126 б. (I кит.)

ФАКТОР КЕРЕМНӘРЕ (факторные доходы) — җитештерү факторлары тарафыннан булдырыла торган керемнәр, 23 б. (II кит.)

ФИРМА (фирма) — базар системасының теләсә нинди төрдәге товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүче субъекты, 50—51, 147 б. (I кит.)

ФРИКЦИОН ЭШСЕЗЛЕК (фрикционная безработица) — эшсезлекнең бер формасы, яллы хезмәттә катнашучы затларның яшәү урынын үзгәртүе һәм яшь белгечләрнең эш эзләве сәбәпле килеп чыга, 91 б. (II кит.)

ФИЛЛИПС КӘКРЕСЕ (кривая Филлипса) — инфляция нормасы чагыштырмача югары булмаган очракта эшсезлек нормасы үсеше инфляция нормасы төшү белән, ә инфляция нормасы төшү эшсезлек нормасы үсү белән бергә барганын күрсәтүче график, 130 б. (II кит.)

ФИРМАНЫҢ ГОМУМИ АКЧАЛАТА КЕРЕМЕ (гомуми кереме) (общая выручка (общий доход) фирмы) — фирманың үз продукциясен сатудан алган акча суммасы, 183 б. (I кит.)

ФИРМАНЫҢ ГОМУМИ ПРОДУКТЫ (общий продукт фирмы) — фирманың билгеле бер периодта җитештергән продукциясе күләме, 153 б. (I кит.)

ФИРМАНЫҢ ТИГЕЗЛӘНЕШЕ (равновесие фирмы) — фирманың үз хәлен үзгәртү мотивлары булмаган халәте, 188 б. (I кит.)

ФИРМАНЫҢ УРТАЧА ПРОДУКТЫ (средний продукт фирмы) — фирманың бер хезмәт берәмлегенә, ягъни бер эшләүчегә, бер эш сәгатендә башкарылган эшкә һәм башкаларга исәпләнгән продукциясе күләме, 154 б. (I кит.)

ФИШЕР И. ТИГЕЗЛӘМӘСЕ (акчаның санча теориясе тигезләмәсе) (уравнение Фишера (уравнение количественной теории денег) — әйләнештә йөрүче акча массасы (*M*) белән аның әйләнеш тизлеге (*V*) тапкырчыгышы ТЭП күләме (*Q*) белән ахыргы товар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләре (*P*) тапкырчыгышына тигез, ягъни $MV = QP$, 63 б. (II кит.)

Х

ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕ (производительность труда) — к. «Фирманың уртача продукты».

ХЕЗМӘТ ХАКЫ (*W*) (заработная плата) — хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, ялланып эшләүчеләрнең кереме, 220 б. (I кит.)

ХЕЗМӘТКӘ СӘЛӘТЛЕ БУЛМАГАН ХАЛЫК (нетрудоспособное население) — халыкның хезмәткә сәләтле яшькә — 16 га җитмәгән һәм пенсия яшенә җиткән (55 не узган хатын-кызлар һәм 60 ны узган ирләр) өлеше, 87 б. (II кит.)

ХЕЗМӘТКӘ СӘЛӘТЛЕ ХАЛЫК (трудоспособное население) — илдәге халыкның 16 яше тулып узган һәм әле пенсия яшенә (хатын-кызлар өчен 55, ирләр өчен 60 яшькә) җитмәгән өлеше, 87 б. (II кит.)

ХОСУСЫЙ БАЙЛЫКЛАР (частные блага) — икътисади байлыкларның индивидуаль куллану өчен билгеләнгән өлеше, 55 б. (I кит.)

ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ (приватизация) — дәүләт милке булган предприятиеләрне һәм башка объектларны физик һәм юридик затларга сату яки бушлай тапшыру, нәтиҗәдә алар физик һәм юридик затларның хосусый милкенә әверелә, 280 б. (II кит.)

ХУҖАЛЫК ШИРКӘТЕ (хозяйственное товарищество) — устав капиталында һәрбер катнашучының өлеше (кертеме) билгеләнгән коммерция оешмасы, 289 б. (I кит.)

Ц

ЦИКЛ ТӨБЕ (дно цикла) — икътисади циклның бер фазасы, бу вакытта ТЭП, инвестицияләр һәм эшлекле активлыкның башка күрсәткечләре циклик түбәнәю барышында үзенең иң түбән дәрәҗәсенә төшә, 78 б. (II кит.)

ЦИКЛИК КҮТӘРЕЛЕШ (циклический подъем) — икътисади циклның бер фазасы, аның барышында ТЭП, инвестицияләр, мәшгульлек һәм эшлекле активлыкның башка күрсәткечләре дәрәҗәсе үсә, 78 б. (II кит.)

ЦИКЛИК ПИК (циклический пик) — икътисади циклның бер фазасы, ТЭП, инвестицияләр, мәшгульлек һәм эшлекле активлыкның башка күрсәткечләре циклик төшү алдыннан үзләренең иң югары дәрәҗәсенә ирешә, 78 б. (II кит.)

ЦИКЛИК ТӨШҮ (циклический спад) — икътисади циклның бер фазасы; ТЭП җитештерү, инвестицияләр күләме, мәшгульлек дәрәҗәсенең кимүе белән характерлана, 78 б. (II кит.)

ЦИКЛИК ЭШСЕЗЛЕК (циклическая безработица) — эшсезлекнең бер формасы, циклик төшү вакытында барлыкка килә һәм ТЭП үзенең потенциаль дәрәҗәсенә җиткәч юкка чыга торган эшсезлек, 93 б. (II кит.)

Ч

ЧАГЫШТЫРМАЧА ӨСТЕНЛЕК ПРИНЦИБЫ (принцип сравнительного преимущества) — әгәр һәрбер ил, уртача чыгымнары башка илләрдәге уртача чыгымнардан чагыштырмача кимрәк булган товарлар җитештерүгә специальләшсә, ул тышкы сәүдәдә отыш алачак, 212 б. (II кит.)

ЧЫГАРЫЛМА СОРАУ (производный спрос) — җитештерү факторларына сорау, ул бу факторларны кулланучы фирмаларда җитештерелә торган товар һәм хезмәт күрсәтүләргә бәйле, 222 б. (I кит.)

Э

ЭШМӘКӘРЛЕК (предпринимательство) — табыш алу максаты белән капитал хуҗалары, кредит алучылар яки арендаторлар тарафыннан товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү буенча алып барыла торган инициативалы, мөстәкыйль эшчәнлек; эшмәкәрлек җитештерүне яңача оештыруны күздә тота, эшмәкәрнең үз керемен һәм милкен тулысынча яки өлешчә югалту куркынычы зур, 285 б. (I кит.)

ЭШСЕЗЛӘР (безработные) — икътисади актив халыкның эше булмаган, ләкин эшләргә теләге булган һәм эш эзли торган өлеше, 88 б. (II кит.)

ЭШСЕЗЛЕК (безработица) — икътисадта билгеле бер сандагы эшсезләр булу; эшсезләр саны, 89 б. (II кит.)

ЭШСЕЗЛЕК НОРМАСЫ (норма безработицы) — эшсезләр санының мәшгульләр һәм эшсезләр суммасына чагыштырмасы, 130 б. (II кит.)

Ю

ЮТИЛЬ (ютиль) — файдалылык үлчәменең шартлы берәмлеге, 121 б. (I кит.)

Я

«ЯРТЫ БӘЯ» («полцены») — дәүләт тарафыннан аерым товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куела торган бәяләр дәрәҗәсе, бу товарларга (хезмәт күрсәтүләргә) болардан да түбән бәяләр кую рөхсәт ителми, 88 б. (I кит.)

ЯШЕРЕН ЭШСЕЗЛЕК (скрытая безработица) — эшсезлек формасы, аны эш атнасын тулысы белән эшләми һәм хезмәт биржасында эшсез буларак теркәлми торган затлар тәшкил итә, 94 б. (II кит.)

IS КӘКРЕСЕ (кривая *IS*) — ТЭП дәрәҗәсе белән процент ставкалары зурлыгының нинди комбинацияләрендә товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тигезләнеш хәле урнашуын күрсәтүче график, 61 б. (II кит.)

IS-LM МОДЕЛЕ (модель *IS-LM*) — товар һәм акча базарларында гомуми тигезләнешне күрсәтүче макроикътисади модель, 70 б. (II кит.)

LM КӘКРЕСЕ (кривая *LM*) — ТЭП дәрәҗәсе белән процент ставкаларының нинди комбинацияләрендә акча базарында тигезләнешкә ирешеп булуын күрсәтүче график, 69 б. (II кит.)

РОССИЯ ИКЪТИСАДЫ ЦИФРЛАРДА

1 нче таблица

2004 елда Россиянең социаль-икътисади хәлен характерлаучы иң мөһим күрсәткечләр

Милли байлык*	35 221 млрд сум
Тулай эчке продукт	17 008 млрд сум
Тулай эчке продукт, җан башына	118 500 сум
Сәнәгать продукциясе күләме	11 209 млрд сум
Авыл хуҗалыгы продукциясе	1366 млрд сум
Төп капиталга инвестицияләр	2730 млрд сум
Икътисадта мәшгульләр саны**	67,1 млн кеше
Эшсезләр саны **	5,77 млн кеше
Эшсезлек нормасы**	7,9 %
Уртача айлык номиналь хезмәт хакы	6832 сум

* 2003 елгы мәгълүмат.
** Ел ахырына.

2 нче таблица

Россиядә тулай эчке продуктны куллану структурасы (агымдагы бәяләрдә, гомуми суммага % ларда)

Күрсәткечләр	1995	2000	2004
Тулай эчке продукт базар бәяләрендә	100	100	100
Ахыргы куллануга чыгымнар	71,2	62,5	66,1
Шул исәптән:			
— йорт хуҗалыкларында	49,3	46,1	47,8
— дәүләт учреждениеләрендә	19,5	14,4	16,5
— йорт хуҗалыкларына хезмәт күрсәтүче, коммерция булмаган оешмаларда	2,4	2,0	1,1
Тулай җыем	25,3	17,1	21,5
Шул исәптән:			
— төп капиталның тулай җыемы	21,2	17,8	18,2
— матди әйләнеш чараларының запаслары үзгәрү	4,1	−0,7	2,5
Товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең саф экспорты	3,5	20,4	12,4

3 нче таблица

Иң әһәмиятле икътисади күрсәткечләрнең индекслары (үткән елга карата % ларда)[1]

Күрсәткеч	1991	1999	2000	2001	2002	2003	2004	2004 ел 1991 елга карата % ларда
Тулай эчке продукт	95,0	106,4	110,0	105,1	104,7	107,3	107,2	87,0
Сәнәгать продукциясе күләме	92,0	111,0	111,9	104,9	103,7	107,0	106,1	70,5
Авыл хуҗалыгы продукциясе	95,6	104,1	107,7	107,5	101,5	101,5	101,6	73,6
Төп капиталга инвестицияләр	85,0	105,3	117,4	110,0	102,8	112,5	110,9	35,5
Икътисадта мәшгульләрнең уртача еллык саны	98,0	100,5	101,1	100,0	100,9	100,0	100,8	89,2
Эшсезләр саны	—	102,2	77,0	90,1	97,6	92,9	95,3	
Уртача айлык реаль хезмәт хакы	97,0	78,0	120,9	119,9	116,2	110,3	110,8	79,0
Куллану бәяләре индексы (узган елның декабренә)	—	136,5	120,2	118,6	115,1	112,0	111,7	27 450 тапкыр

[1] Чагыштырырлык бәяләрдә.

4 нче таблица

Милек формасы буенча предприятиеләр һәм оешмалар саны (ел башына)

Предприятиеләр	1996	2000	2001	2002	2003	2004
Барысы (мең берәм.)	2250	3106	3346	3594	3845	4150
Шул исәптән милек формалары буенча (%):						
— дәүләт предприятиесе	14,3	4,8	4,5	4,3	4,1	3,9
— муниципаль предприятие	8,8	6,4	6,5	6,4	6,2	5,9
— җәмәгать берләшмәләре милеге предприятиесе	4,2	6,9	6,7	6,6	6,4	6,1
— шәхси предприятие	63,4	74,4	75,0	75,8	76,9	78,0
— башка формалардагы[1] предприятиеләр	9,3	7,5	7,3	6,8	6,4	6,1

[1] Катнаш милекне, чит илләрнең юридик затлары милеген, гражданнары милеген һәм гражданлыгы булмаган затлар милеген кертеп.

5 нче таблица

2003 елда базарда доминант урын тоткан предприятиеләр[1]

Предприятиеләр	Предприятиеләр саны	Алар продукциясенең гомуми җитештерү күләмендә чагыштырма өлеше (%)
Барлык сәнәгать	239	17,0
Шул исәптән:		
— ягулык	7	4,4
— кара металлургия	26	66,8
— төсле металлургия	23	23,5
— химия һәм нефтехимия	36	33,4
— машиналар төзү һәм металл эшкәртү	120	23,3
— урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь	10	17,0
— төзү материаллары	4	1,9
— җиңел сәнәгать	1	0,4
— азык-төлек сәнәгате	6	0,3

[1] Базарда билгеле бер товарның өлеше 35% тан артык булган предприятиеләр.

6 нчы таблица

Кече эшмәкәрлекнең икътисад тармаклары буенча структурасы (2004 ел ахырына) (%)[1]

Икътисад тармаклары	Кече предприятиеләр саны	Эшләүчеләр саны	Җитештерелгән продукция күләме
Сәнәгать	13,4	21,9	23,3
Авыл хуҗалыгы	2,0	2,6	1,1
Төзелеш	12,7	19,4	21,5
Транспорт	2,8	3,9	4,1
Сәүдә һәм җәмәгать туклануы	46,3	33,6	32,4
Җитештерү-техник кулланылыштагы продукция белән күпләп сату итү	2,7	1,9	2,7
Сәламәтлекне саклау һәм физкультура	2,3	1,7	1,1
Мәгариф	0,3	0,1	0,1
Фән һәм фәнни хезмәт күрсәтү	2,2	1,8	1,8
Башка тармаклар	15,3	13,1	11,9
БАРЫСЫ	100,0	100,0	100,0

[1] 2003 елда Россиядә кече предприятиеләр саны 953 мең тәшкил итә.

7 нче таблица

Россиянең тышкы сәүдәсе
(гамәлдәге бәяләрдә, АКШның млрд долларларында)

Ел	Экспорт	Импорт	Сәүдә балансы сальдосы
1995	82,4	62,6	19,8
2000	105,0	44,9	60,1
2001	101,6	53,8	47,8
2002	107,3	61,0	46,3
2003	135,9	75,4	60,5
2004	183,2	94,8	88,4

8 нче таблица

2004 елда Россиянең тышкы сәүдәсендә товар структурасы (%)

Товарлар	Экспорт	Импорт
Азык-төлек товарлары һәм авыл хуҗалыгы чималы (туку чималы керми)	1,8	18,3
Минераль продуктлар	57,7	4,0
Химия сәнәгате продукциясе, каучук	6,6	15,8
Агач материал һәм целлюлоза-кәгазь эшләнмәлар	3,9	3,8
Текстиль, текстиль эшләнмәләр, аяк киеме (тире чималын һәм затлы мехларны кертеп)	0,8	4,6
Металл, кыйммәтле ташлар һәм алардан эшләнгән эшләнмәләр	20,3	8,0
Машиналар, җиһазлар, транспорт средстволары	7,8	41,2
Башка төрлеләр	1,1	4,3
БАРЫСЫ	100,0	100,0

9 нчы таблица

Халыкның тормыш дәрәҗәсе турында төп социаль-икътисади күрсәткечләр

Күрсәткечләр	2002	2003	2004
Җан башына уртача айлык акчалата керем (сумнарда)	3964,0	5142,0	6337,0
Кулдагы реаль акчалата керем (үткән елдагыга карата %ларда)	111,0	115,0	108,0
Уртача айлык номиналь хезмәт хакы (сумнарда)	4360,0	5509,0	6832,0
Уртача айлык реаль хезмәт хакы (үткән елдагыга карата % ларда)	116,0	110,9	110,9
Уртача пенсия зурлыгы (сумнарда)	1379,0	1637,0	1915,0
Яшәү минимумы зурлыгы (сумнарда)	1808,0	2112,0	2376,0
Акчалата керемнәре яшәү минимумыннан кимрәк булган халык саны — барысы, млн кеше	34,6	29,3	25,5
— гомуми халык санынан % ларда	24,2	20,4	17,8
Яшәү минимумы зурлыгы белән нисбәтләре[1] (%):			
— уртача җан башына акчалата керемнең	220,0	224,0	266,0
— уртача айлык номиналь хезмәт хакының	222,0	239,0	263,0
— уртача айлык пенсиянең	100,0	102,0	106,0
Керемнәр дифференциациясенең дециль коэффициенты[2]	14,0	14,5	14,8

[1] Халыкның тиндәшле социаль-демографик төркемендә.

[2] Керемнәр буенча социаль катламлану дәрәҗәсен характерлый, иң югары керемле 10% халыкның акчалата керемнәре белән иң түбән керемле 10% халыкның керемнәре арасындагы нисбәт буларак билгеләнә.

10 нчы таблица

Россияде мәгариф үсешенең төп социаль-икътисади күрсәткечләре

Күрсәткечләр	1995	2003	2004	2004 ел 1995 елга % ларда
Күндезге гомуми белем бирү учреждениеләре саны, мең	70,8	66,2	63,2	89,2
Аларда укучылар саны, млн кеше	22,0	17,8	16,2	73,6
Махсус урта уку йортлары саны	2612	2628	2637	101,0
Аларда укучы студентлар саны, мең кеше	1923,0	2502,0	2504,0	130,2
Югары уку йортлары саны	762	1046	1071	140,5
Шул исәптән:				
— дәүләт югары уку йортлары	569	654	662	116,3
— дәүләтнеке булмаганнар	193	392	409	211,9
Аларда укучы студентлар саны, мең кеше	2791,0	6456,0	6884,0	246,6
Шул исәптән:				
— дәүләт югары уку йортларында	2655,0	5596,0	5860,0	220,7
— 10 000 кешегә	189	448	477	237,0
Шул исәптән:				
— дәүләт югары уку йортларында	179	393	406	219,5

11 нче таблица

2004 елда Россия Федерациясенең консолидар бюджеты*

Бюджет статьялары	Млрд сум	%
КЕРЕМНӘР — барысы	**5427,3**	**100**
Шул исәптән:		
Салым керемнәре	4936,2	91,0
Шулардан:		
— оешмаларның табышына салым	867,6	16,0
— физик затлар керемнәренә салым	574,5	10,6
— өстәлгән кыйммәткә салым	1069,7	19,7
— акцизлар	244,3	4,5
— бердәм социаль салым	444,7	8,2
— милеккә салым	296,2	2,7
— табигый ресурслардан файдаланган өчен түләүләр	579,5	10,7
— тышкы сәүдәгә һәм тышкы икътисади операцияләргә салымнар	859,7	15,8
Салымнан тыш керемнәр	421,4	7,9
Шулардан:		
— дәүләт һәм муниципаль милектән файдаланудан яки дәүләт һәм муниципаль предприятиеләр эшчәнлегеннән кергән керемнәр	330,0	6,1
— тышкы икътисади эшчәнлектән керемнәр	38,5	0,7
Түләүсез кергән керемнәр	−132,0	−2,4
Максатчан бюджет фондлары керемнәре	172,0	3,2
Эшмәкәрлек эшчәнлегеннән кергән керемнәр	18,2	0,3
Башка керемнәр	11,5	0,2
ЧЫГЫМНАР — барысы	**4665,4**	**100,0**
Шул исәптән:		
— дәүләт идарәсенә һәм җирле үзидарәгә	223,0	4,8
— милли оборонага	430,0	9,2
— халыкара эшчәнлеккә	54,0	1,2
— хокук саклау эшчәнлегенә һәм дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итүгә	381,2	8,3

* Консолидар бюджет федераль дәүләт бюджетыннан һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан тора.

— сәнәгать, энергетика һәм төзелешкә	394,1	8,4
— авыл хуҗалыгы һәм балыкчылыкка	78,2	1,7
— транспорт, элемтә һәм информатикага	48,7	1,0
— юл хуҗалыгына	86,0	1,8
— торак-коммуналь хуҗалыкка	291,3	6,2
— социаль-мәдәни чараларга	1465,1	31,5
– максатчан бюджет фондлары чыгымнары	183,2	3,9
— дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә	230,4	4,9
— башка чыгымнар	800,2	17,1
ПРОФИЦИТ (+)	**761,9**	

11 нче бүлек. ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ ҺӘМ МИЛЛИ КЕРЕМ ... 3
11.1. Ни өчен милли продуктның күләмен белергә кирәк ... 4
11.2. Тулай эчке продукт нәрсә ул ... 6
11.3. Тулай эчке продукт ничек исәпләнә ... 13
11.4. Саф милли продукт һәм милли керем ... 21
11.5. Кулга кергән шәхси керем ничек формалаша ... 25
11.6. Номиналь һәм реаль ТЭП ... 29

12 нче бүлек. МАКРОИКЪТИСАДИ ТИГЕЗЛӘНЕШ ... 36
12.1. Керем, куллану һәм саклык акчалар. Куллану функциясе ... 37
12.2. Саклык акчалар һәм инвестицияләр ... 45
12.3. Мультипликатор ... 53
12.4. Товар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында тигезләнеш һәм процент ставкасы. *IS* кәкресе ... 56
12.5. Процент ставкасы һәм акча базарындагы тигезләнеш ... 61
12.6. Товар һәм акча базарларында гомуми тигезләнеш. *IS-LM* моделе ... 70

13 нче бүлек. ИКЪТИСАДИ ЦИКЛ, ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛГӘНЛЕК ҺӘМ ЭШСЕЗЛЕК ... 76
13.1. Икътисади цикл ... 77
13.2. Икътисади цикл механизмы ... 80
13.3. Мәшгульләр һәм эшсезләр ... 87
13.4. Эшсезлекнең сәбәпләре һәм формалары ... 91
13.5. Эшсезлек нәтиҗәләре һәм дәүләтнең эш белән тәэмин итүне җайга салуы ... 95

14 нче бүлек. ИНФЛЯЦИЯ 105
14.1. Инфляцияне билгеләү һәм аны үлчәү 106
14.2. Инфляциянең сәбәпләре 110
14.3. Инфляция формалары 117
14.4. Халыкның төрле социаль төркемнәре өчен инфляция нәтиҗәләре 124
14.5. Филлипс кәкресе 127

15 нче бүлек. ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ 135
15.1. Икътисади үсешнең эчтәлеге 136
15.2. Икътисади үсешне үлчәү 141
15.3. Җитештерү функциясе һәм үсеш факторлары 144
15.4. Экстенсив һәм интенсив үсеш факторлары 150
15.5. XX гасыр ахырында икътисади үсеш темпларының кимүе нәрсәгә бәйле 153

16 нчы бүлек. ИКЪТИСАД ҺӘМ ДӘҮЛӘТ 164
16.1. Икътисади тотрыклылык сәясәте 165
16.2. Бюджет-финанс сәясәте 168
16.3. Кредит-акча сәясәте 176
16.4. Икътисади үсешне стимуллаштыруда дәүләтнең роле 185
16.5. Дәүләт бурычы 194

17 нче бүлек. ХАЛЫКАРА СӘҮДӘ ҺӘМ ВАЛЮТА БАЗАРЫ 202
17.1. Бөтендөнья хуҗалыгы 203
17.2. Халыкара сәүдә 208
17.3. Тышкы сәүдә сәясәте 221
17.4. Валюта базары 225

18 нче бүлек. КАПИТАЛЛАРНЫҢ ХАЛЫКАРА ХӘРӘКӘТЕ. ТҮЛӘҮ БАЛАНСЫ. ИКЪТИСАДИ ИНТЕГРАЦИЯ 241
18.1. Капиталларның халыкара хәрәкәте 242
18.2. Түләү балансы 256
18.3. Халыкара икътисади интеграция 262

19 нчы бүлек. ХӘЗЕРГЕ РОССИЯ ИКЪТИСАДЫ 270
19.1. XX гасырның 90 нчы елларында
Россиядә базар үзгәртеп корулары 270
19.2. Россиянең икътисади үсешенең хәзерге этабында
базар үзгәртүләре 291
19.3. Россиянең потенциалы
һәм икътисади үсү мөмкинлекләре 303

ГЛОССАРИЙ 313

Статистик кушымта.
РОССИЯ ИКЪТИСАДЫ ЦИФРЛАРДА 341

Учебное издание

Иванов Сергей Иванович
Шереметова Вера Владимировна
Скляр Моисей Абрамович и др.

ОСНОВЫ ЭКОНОМИЧЕСКОЙ ТЕОРИИ

Учебник для 10—11 классов
татарской средней общеобразовательной школы

Профильный уровень образования

В двух книгах

Книга 2

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Иванов Сергей Иванович
Шереметова Вера Владимировна
Скляр Моисей Абрамович һ. б.

ИКЪТИСАД ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10—11 нче сыйныфлары өчен дәреслек

Профильле белем бирү

Ике китапта

2 нче китап

Редакторлары *Р. З. Закирова, Л. Х. Мөхәммәтҗанова*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучылары *Л. Г. Зиргизова, Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректорлары *С. З. Гыйматетдинова, А. М. Закирова, Г. Р. Ногманова, Р. Ә. Фәйзуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2006. Форматы $60 \times 90\ ^1/_{16}$.
Офсет басма. «Таймс» гарнитурасы. Офсет кәгазе. Басма табагы 22,0.
Нәшер-хисап табагы 19,4. Тиражы 7000 д. Заказ С-409.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ИКЪТИСАД

ТЕОРИЯСЕ НИГЕЗЛӘРЕ